# КАЗАН УТЛАРЫ

6. 1993





# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ



Р. Мөхәммәдиев



Ә. Фәтхетдинов

## 1993 ЕЛ ӨЧЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕН БИРҮ ТУРЫНДА

Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң, **карар бирәм:**

1993 ел өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирергә:

1. **Мөхәммәдиев Ринат Сафа улына,** «Сират күпере» романы өчен (Татарстан китап нәшрияты, 1992 ел);
2. **Фәтхетдинов Әхсән Сәрим улына,** «Ияләр» художество әсәрләре циклы өчен.

Казан, Кремль,
1993 ел, 24 апрель.

Татарстан Республикасы Президенты
**М. Ш. ШӘЙМИЕВ.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**6**

**(848)**

**1993**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

М. ХАФИЗОВ. Ике җәһәннәм. *Повесть* . . . . 3
Р. ХАРИС. Өч үбешү. *Эротик поэма* . . . . . 62
Г. АХУНОВ. Тимерханның яшьлеге. *Повесть* . . 79
Г. ХАФИЗОВ. Иртә. *Шигырьләр* . . . . . . . 139
БАТУЛЛА. Хикәяләр . . . . . . . . . . 142

ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР АВЫЗ ИҖАТЫ МИРАСЫННАН

Ә. СИНУГЫЛ. Кырым татар мәнәләре һәм чыннары . . . . . . . . . . . . . . 129

ДИСКУССИЯ ДӘВАМ ИТӘ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Үткәнеңнән гыйбрәт ал . . . 152
Р. ФӘИЗОВ. Алда яктылык күренә . . . . . . 160

БЕР ӘСӘР ТАРИХЫ

М. ЮНЫС. «Митакса-Атлас» . . . . . . . . 164

ПУБЛИЦИСТИКА

Д. ЗАҺИДУЛЛИНА. Татар мәктәбенең кыйбласы 169

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Г. ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА. Идел-Урал буенда мөселман мәдәнияте . . . . . . . . 175
Г. САТТАР. Г. Ибраһимов әсәрләрендә исем-аталар . . . . . . . . . . . . . . 180

ЛАТИН ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ
ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Ф. ХӨСНИ. Хәзинә. *Хикәя* . . . . . . . . . 185

Укучы сүзе . . . . . . . . . . . . . 184
Котлыйбыз . . . . . . . . . . . . . 128
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . . 189


■

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәуфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повести М. ХАФИЗОВА «Два ада» и Г. АХУНОВА «Юность Тимерхана», рассказы БАТУЛЛЫ, эротическая поэма Р. ХАРИСА и стихи Г. ХАФИЗОВА.
«Из народного творчества тюркских народов»: Народное творчество крымских татар.
«Дискуссия: Наша жизнь. Наша литература»: статьи Т. ГАЛИУЛЛИНА и Р. ФАИЗОВА.
«История одного произведения»: статья М. ЮНЫСА «Митакса-Атлас».
«Публицистика»: статья Д. ЗАГИДУЛЛИНОЙ «Направление татарской школы».
«К истории культуры»: статьи Г. ВАЛИЕВОЙ-СУЛЕЙМАНОВОЙ «Мусульманская культура в Волжско-Уральском регионе», Г. САТТАРОВА «Имена-названия в произведениях Г. Ибрагимова». «Навыки чтения на основе латинской графики»: рассказ Ф. ХУСНИ.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Летний двор» — картина Уфимского художника З. Шайхелисламова; известный критик Ф. Миннуллин.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 4.05.93 ел. Басарга кул куелды 27.05.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 26 573. Заказ Я-243. Бәясе 20 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1993 ел.



## Мияссәр Хафизов

# ИКЕ ҖӘҺӘННӘМ

ПОВЕСТЬ

### I

Сугыш гөрелтесе, ил чиген үтеп, Европаның үзәгенә таба китте. Тынычлыкка әле ияләшеп булмый. Кырыс фронт кануннары урам ташларына, тән күзәнәкләренә, сулыйсы һавага кадәр сеңгән. Әмма яшәү үзенекен итә. Тыныч тормышка күнегә башларга кирәк.

Тышта — 1944 елның сентябрь киче. Тротуар кырыендагы каштаннарга көзге моңсулык өртелгән. Ык буенда үскән татар егете мең газаплы юллар үтәр дә, сугыш арбасыннан шушы Вилейка дигән шәһәрдә төшеп калыр дип кем уйлаган. Партизаннар отрядын тараткач, Нурислам Таһировны мәгариф бүлеге мөдире итеп калдырдылар. Татарга хас каударлык белән эшкә тотынган Нурислам дөньяда ашау да барын истән чыгара торганнардан түгел иде. Ашханәгә соңладыңмы, хезмәткәрләргә бирелә торган ризык — йөз илле грамм йомшак ипи һәм эремчектән коры каласыңны көт тә тор, аннары сохари кимерергә кала.

Ашыгып атлаган Нурисламның юлын ниндидер таныш булмаган лейтенант бүлде.

— Нурислам Батькович, безгә кереп чыгыйк әле, майор Темляков чакыра сезне.

НКВД начальнигы Темляков исемен әйткәч, күпләр иманеп китә, йөзләренә чарасыз курку җәелә иде. Әмма Нурисламның гадәти тыныч чыраена карап, лейтенант куркыту ләззәте ала алмады. Ә нигә куркырга! Окоп күрмәгән, дары исен татымаган көр гәүдәле, һавалы сөйләшә торган майорны Нурислам яхшы белә, кабинетында да берничә тапкыр булганы бар иде. Мин-минлеген кара син аның. Шәһәрдән немецларны бәреп чыгаргач, яңа оешкан җирле властьларның ныгып җитмәвеннән файдаланып, җимерелми калган мәктәп бинасын басып алган да идарәсен кертеп утырткан. Сентябрь азагы җитеп килә, балаларны укыта башларга кирәк, ә ул мәһабәт бинадан чыгарга уйламый да, һаман суза, сәбәп арты сәбәп таба. Бүген исә Темляков галиҗәнабләре үзе мәгариф бүлеге мөдирен чакырта икән, димәк, ул йокыдан уң ягы белән торган, димәк, мәктәп бинасын бушатырга җыена. Җирле властьны никадәр

---

Әсәр Марсель Галиевнең әдәби эшкәртүендә бирелә.

санламаса да, балалар мәнфәгатенә кул сузуның зур гөнаһ икәнен чамалый башлагандыр.

«Шәп чыкты бу. Эремчек белән ипи качмас, тимерне кызуында сугарга кирәк»,— дип Нурислам, ике арада туган кытыршылыкның бүген җиңел генә хәл ителәсенә ышанып, майорның кабинет ишеген ачты.

Киң өстәле артында утырган майор башын күтәреп карады да, алтын балык тоткан шикелле шатланып, аягүрә торып басты. Нурислам исәнләшергә дип кенә авызын ачкан иде, йөзенә туфрак сиптеләрмени...

— Таһиров, кайда, ничек, кайчан илне саттың, сөйлә!

Нурислам бер мәлгә катып калды. Сугышның кырыс җиле дә аның беркатлылыгын өтеп ала алмаган иде. «Әллә шаяртамы бу?» дигән уй бер мизгелгә күңелен тырнап узды. Әмма майорның үчле-салкын карашын тойгач...

Әйе, сау-сәламәт килеш, дошман кулында әсир калу сәбәбен компетентлы органнарга сөйләп бирергә тиешлеге турында белә иде ул. Шуны белгәнгә күрә дә әсирлектән качып, партизаннарга кушылган көнне үк, бригада командиры исеменә рапорт язып биргән иде. Әсирлектә чакта күргән-кичергәннәрен, кылган гамәлләрен түкми-чәчми теркәгән. Ул рапорт Мәскәүгә җибәрелгән икән. Берничә ай үтүгә, аннан вәкил булып контрразведка капитаны килде. Әнә шул капитан җентекләп тикшерү-сорау алулар үткәргәч: «Дошманны намус белән кыйна, егетем, үзебезгә кайтуың ватанга бирелгәнлегеңне раслый. Син — чын патриот. Сиңа беркайчан да, беркем дә тел-теш тигермәс»,— дип киткән иде. Хәзер исә, партизан хәрәкәте беткәч — мә сиңа!— Темляков аны менә ничек каршы ала, бәгырьгә басып тупас сорау куя. Дәүләт куркынычсызлыгы вәкиле, рәсми кеше каршында җавапсыз каласыңмы?

— Мин беркайда да, беркайчан да илемне сатмадым, иптәш майор.

— Уйлабрак сөйлә!

— Сезне, мөгаен, минем әсирлектә булуым кызыксындырадыр?

— Коерык болгама! Төлке түгелсең! Сорау шул: кайда, кайчан, нинди шартларда илне саттың?!

— Нинди шартларда әсирлеккә эләктем, ул турыда сөйләп бирә алам.

— Тьфу, шайтан алгыры! Мин аңа Фома хакында, ә ул миңа — Ерема турында,— диде Темляков. Папканы эләктереп, ачу белән өстәлгә ыргытты. Шуннан соң, ничектер, басылып, озак кына сүзсез утырды. Бераздан «Широка страна моя родная» көен шыңшый-шыңшый, өстәл артыннан чыкты. Кулларын артка куеп, Нурислам тирәсендә арлы-бирле йөренә башлады. Бер әйләнде, ике, өч... аннары, тәрәзә каршысында туктап, анда таратылган тәмәке яфракларын уыштырып «кәҗә тоягы» ясады. Галифе кесәсеннән бик затлы немец зажигалкасын чыгарды. Чыртлап ут кабынганда, тук, канәгать карашы Нурисламны кистереп узды. Мондагы халык «мультан» дип атый торган үтә хуш исле тәмәкене ләззәт белән тирән итеп суырды да, шуннан да мөһимрәк эше юк шикелле, озак итеп кабызгычтагы ялкын тибрәнешенә карап торды. Корт чаккандай кинәт талпынып алды да, масаюлы биеклектән торып, усал итеп Таһировка текәлде:

— Н-ну!

«Өстемә бүре ташландымыни... Шундый ук халәт... Ул чакта күзгә төртсәң күренмәслек дөм караңгы иде. Чытырманлыкны ерып мин алдан барам. Артта унлап партизан. Кинәт каршымда ут ноктадары ялтырап китте, ажгырып нидер өстемә килә. Куркуданмы, тәвәккәллектәнме — аек уй белән хисап бирерлекмени — ихтыяр көченнә сынаган бер мизгел бит ул... Автоматымнан ут көлтәсе сирпелүгә, төн карачкысы аяк астыма гөрселдәп килеп төште.

— Ни булды, иптәш командир? Ник аттың?

Иптәшләрем минем янга өелештеләр. Плащ-палатка астыннан сүрән фонарь яктысы бөркелде. Карасак... бер адымда гына биниһая зур гәү-

дәле бүре тартышып ята. Авызы, азау тешләрен күрсәтеп, аңкауга кадәр ачылган. Күзендә ерткыч уты әле сүнәргә дә өлгермәгән».

Шуны хәтерләгән Нурисламның бөтен тән күзәнәкләрен өшетеп өметсез дулкын узды. Бу очракта инде ул коралсыз иде. Әмма ялан кул булсаң да бирешмәскә, рухны сындырмаска кирәк.

Үзенә бирелгән хакими көчтән исергән майор әдәп саклап тормады, тәмәкесен тирән итеп суырды да, иренен очлайтып, ләззәт белән, әзеп-әзеп, Нурисламның йөзенә өрә башлады. Шуннан соң тыныч тавыш белән, башта әйткән сүзен кабатлады:

— Ну...

Нурислам төтеннән яшьләнгән күзләрен читкә борды, дәшмичә тора бирде. Майорның йөзенә кызыл таплар чыкты. Янә зәһәрләнеп өстәде:

— Туры кара, күрик, ни турыда сөйли икән оятсыз татар күзләре!

Егет гарьләнде, рәнжеде. Моңарчы тоеп карамаган эчке нәфрәтләнү, ачу кабару халәте кичерде. Ләкин бу халәтен Темляковка сиздермәскә тырышты: иренен тешләп, карашын кабинет түрендәге борынгы шкафка юнәлтте. Җансыз һәйкәл кебек тик кенә басып тора бирде.

Күпмедер вакыт шушылай торгач, майор:

— Үз кабыгыңа йомыласыңмы?! Эшлә, изалан, да!...— дип башлаган җөмләсен тел бармас кабахәт сүзләр белән тәмамлады.

— Нигә сүгенергә, Владимир Иванович. Мин бит сезнең сорауларга җавап бирергә әзер. Тик...

— Молчать!.. Син минем ата-анам кушкан исемемне пычрак теленә алма. Синең өчен Владимир Иванович юк. Хәтта иптәш майор да юк. Шуны бел... Хәзер син — кулга алынган немец ялчысы, хыянәтче.

Бу хәтәр сүзләрне ишеткәч Нурисламның тыны кысылды. Бары да аңлашыла... Темляков тырнагыннан ычкыну юк болай булгач... Кичке аш — ипи-эремчек тә, немец яндырып киткән шәһәрдә мәктәпләр ачып йөрүләр дә язмышының бәхетле сәгатьләре булып кына истә калачак икән. Немец әсирлегеннән исән-аман котылган иде, тагын икенче җәһәннәмгә ташлаячаклар. Рәхим-шәфкать көтмә монда, берничек тә аклана алмаячаксың. Бары тик вөҗданыңа тап төшермәү, рухыңны таптатмау өчен көрәш кенә кала. Кешелегеңне югалтмыйча үлә бел. Бүре Темляков синнән ни хәтле көлсә дә түз, тешеңне кысып түз. «Ванька-встанька» аумый, син дә аума.

Темляков исә Таһиров кебекләрне күп күргән иде. Кеше язмышын аяк астына салып таптарга, рухын сындырырга, ахыр чиктә, аны тәмам изеп, үзенә кирәк җавапны сыгып чыгарырга өйрәнгән кансыз бүре иде.

— Әйләндер кесәләреңне!

Таһиров немец тимер юлчылары киеменнән иде. Ыспай кара мундир. Шуның күкрәк кесәләреннән документларын ала башлады. Тәртип белән. Берәм-берәм. Ашыкмыйча. Ләкин бу майорга ошамады. Җикеренергә сәбәп булды:

— Әйләндер дим! Чукрак түгелсеңдер бит!

Түш кесәләрен әйләндереп була димени. Эче тулы кәгазь-документ җитмәсә. Аның болай акрын мыштырдавы майорны чыгырыннан чыгарды. Чыраендагы тимгел-тимгел таплар бергә кушылып зурайды.

— Түмәр! Томана!— дип кычкырды да, җәһәт килеп, мундирның дүрт кесәсен дә умырып төшерде. Аларда ни бар, барысы да идәнгә коелды. Моның белән генә чикләнмәде майор, чалбар кесәсенә дә күчте. Аларын да, бик оста гына ябышып, әйләндереп ташлады. Кесә төбендәге тәмәке идәнгә сибелде, кабинет ачкычы, кабызгыч кебек вак-төякләр каядыр читкә атылдылар. Сәгать кесәсен генә әйләндермәде. Андагы сәгатьне алып, өстәлгә куйды да, эш бетте, дигән сыман үзе дә шунда менеп утырды. Сәгатьнең капкачын ача-яба, мул кашларын сыйпаштыра-сыйпаштыра, һаман шул «Широка страна моя родная»ны шыңшырга тотынды. Аннары, өстәлдән төшеп, әрле-бирле йөреп, тагын Нурисламны сүгәргә кереште.

— Адәм актыгы! Нигә идәнне чүплисең? Каян килгән хан вәзире, артыңнан хезмәтче йөрергә тиеш дип уйламыйсыңдыр ич... Хәзер үк җыештыр!

Егеттән ачыктан-ачык көлә Темляков. Аны мәсхәрәләп рухын сындырырга чамалый. Алдан уйланган спектакль. Моны аңлаудан үҗәтләнә барган Нурислам майорның сүзләрен тыныч кына үткәреп җибәрде, ә теге аның саен кыза барды:

— Ну!.. Җыештыр, диләр ич сиңа!

Хәрби билеты, партизан штабы биргән сугышчан характеристика, партизан кенәгәсе, орден, медаль таныклыклары, ниһаять, соңгы һөҗүм вакытында һәлак булган Хөснетдин дусты истәлеге — бик тә матур зажигалка киләчәк тормышында үтә кирәк, үтә кадерле әйберләр саналсалар да, аларны алам диеп иелмәде Нурислам. Казык та казык, ул да казык, баскан килеш катып тора бирде. Бу хәтлене көтмәгән Темляков:

— У-у, вражина! Чыңгыз хан токымы! — дип, калтыранган куллары белән ашыгып-кабаланып, китель төймәләрен эләктерде, фуражкасын киде дә кабинет ишеген ачып кычкырды:

— Лейтенант! — Бу тавышка бая Нурисламны алып килгән лейтенант кергәч: — Мин әйләнеп кайтканчы барысы да тәртиптә булсын! — дип, күздән югалды.

Ул минутларда караңгы төшә, күз бәйләнә башлаган иде инде. Димәк, Нурислам, аз дигәндә, дүрт сәгатьләп аяк өсте басып тора. Шуңадыр, күрәсең, электән авырткан тубыгы да, оча сөяге дә сызлый, җитмәсә каты немец ботинкалары тар, аяк бармакларын кыса иде.

Лейтенант өстәл артына узып маташкан арада, Нурислам кесәләренә күз төшереп алды. Аскы җөйләрендә генә эләгеп торалар. Эче тышка әйләнгән чалбар кесәләре дә буш тәмәке янчыгы сыман асылынган. Моңа игътибар иткән лейтенант:

— Яшер чалбар кесәләреңне. Бу почмакларны да өзеп ыргыт, — дип мундир түшенә ымлады.

— Кичерегез, лейтенант. Аларны мин ертмадым, мин әйләндермәдем. Майор үзе башлады, үзе бетерсен.

— Үзеңчә горурлыкмы инде бу?;

— Түгел дә, кеше өлешенә керә торган гадәтем юк.

— Идәнне җыештыру да аның эшеме?

— Әйе.

Нурисламның бу җавапларын тыныч үткәрде лейтенант. Әйтерсең, бер сорау да бирмәде, җавап та алмады, кулларын билендәге киң каешына кыстырып тик кенә басып торды. Урта буйлы, кырык-кырык биш яшьләрдәге тупыйк борынлы бу бәндә тулы түгәрәк чырае, кыска юан муены, киң җилкәсе һәм кабарынкы күкрәге белән имәнне хәтерләтә иде. Бөтен кыяфәтеннән ныклык, чыдамлык, көчлелек, киребеткәнлек аңкып тора. Бу сурәткә тагын ике потлы гер хәтле йодрыклар, бер тойгы да чагылмый торган салкын күз карашын да өстәсәң, мондый кеше дә була микәнни дөньяда, дип, нинди җанвар белән чагыштырырга белмичә аптырап каласың.

Лейтенант, ут кабызып, җиделе лампаны өстәлгә куйды. Кулларын янә бил каешына кыстырып, әкрен-үшән атлап йөри башлады. Калын табанлы, сыер күненнән тегелгән авыр итекләрнең шыгырдап алуы хәвеф-хәтәр көтеп торган Нурисламның йөрәгенә шик-шөбһә өсти торды. Хуҗа һаман хәрәкәттә. Иелми, үрелми генә идәнгә таралган әйберләрне караштырып йөри. Нурислам аның һәр хәрәкәтен игътибар белән күзәтә. Әнә, якынлашып килә. Менә олы кызыл колагы Нурисламның борын төбендә, яннан гына үтеп бара... Юк, лейтенант кулларын каеш астыннан алмыйча гына, җилкә белән кагылып Нурисламны чөеп ыргытты. Читкә атылган Нурислам егылмавына сөенмәде, чөнки сизә иде, бу — әле башы гына.

Аның шикләнүләрен расларга теләгәндәй, күтәрелеп карамый гына:

— Идәнне җыештырырга туры килер бит, Нурислам Батькович,— диде лейтенант.

Нурислам:

— Сез нәрсә, җыештырмасам кыйнарга җыенасызмы,— диюгә, якынаеп, элеккечә, җилкә белән генә янә чөеп ыргытты. Бу юлы да аумый калгач инде, уң кулын каеш астыннан чыгарып, ике потлы гер хәтле йодрыгы белән егетнең күкрәк авызына төртеп алды. Ат типте мени, Нурислам бу юлы шундук идәнгә тәгәрәде. Бер мәлгә тын ала алмый азапланды.

— Нәрсә, җыештырасыңмы?!

Таһиров тарафыннан ул-бу ишетмәгәч, лейтенант киерелеп итеге белән ике тапкыр аның эченә типте. Авыртуга чыдый алмыйча, идәндә кәлтәдәй бөтерелә Нурислам: әле бөгәрләнә, әле сузыла. Тагын тибү... тагын... тагын... Аңына килгәндә колаклары чыңлый, изелгән күкрәк читлеге суларга ирек бирми, арка-биле үтереп сызлый иде. Күзләрен ачканда исә идән җыештырылган, лампа элеккечә яна, лейтенант үзе өстәл артында басып тора иде.

Тагын аңын җуйды Нурислам. Янә зиһене ачылып, күз алдыннан кара томан таралгач, ул лейтенантны түгел, ә өстәл артында утырган майорны күрде. Чәчен тарый-тарый, тыныч кына эндәшә тегс:

— Тоткын Таһиров, нишләп ятасың, тор!

Әмер биргәнгә түгел, үз ихтыярына буйсынып аягына басарга чамалаган иде дә Нурислам, оча сөяге чатнап китте дә, сыны катып, кабат ауды.

— Ну и ну... Нәрсә булды? Нигә аудың тагын? Бума чирең юктыр бит?

Бу сүзләр Нурисламга төштә генә ишетелгән сыман тоелса да, аңын гел үк югалтып бетермәгән иде әле, зиһененә ачык килеп җитте: «Әһә, бу кара йөрәк һаман мыскыллый. Идәндә аунавыма шатлана! Шатланмый тор әле!»... Нурислам бар көчен, чыдамлыгын туплап, стенага тотына-тотына торып басты.

— Ба-а-а, орденнарыңны да алып яшергәнсең түгелме...

Нурислам шунда гына искәрде: түшендә чынлап та Кызыл Йолдыз ордены да, медальләре дә юк иде. Идәннән җыеп алынган документлар өстәлдә ята. Димәк, ул аңын югалтып яткан арада лейтенант алып куйган. Майор исә моның шулай икәнен белүен яшермичә күзгә-күз мыскыллый. Нәфрәтен тыеп торалмады Нурислам:

— Булдырасың, майор. Бу кылану белән кылансаң, тиздән генерал-майор итәрләр!— дип, булдыра алганча, әче итеп елмайды.

— Син, казанская сирота, үзеңне әллә кемгә куйма. Монда, бу өстәл янында — кеше җаннарының инженеры утыра. Кирәк тапсам, мин синең пычрак җаныңны сүтеп җыярмын. Җайга салынмасаң, яңадан ботарлап ташлармын, аңладыңмы?

— Миннән сиңа нәрсә кирәк?

— Әһә, бусы ичмасам сүз! Әлбәттә инде, башта куйган соравыма җавап бирерсең. Кайда, кайчан?...

— Мин сезнең бу соравыгызга тиешле җавапны бирдем инде. Кабатлап әйтәм: бер кайда да, бер кайчан да!

Майорның ачуы тагын кабарды. Чырае бозылды. Сул яңагы, сул күз төбе тартышып-тартышып алды.

— Корчаңгы!.. Дон-Кихот!...— Тагын да чәнечкелерәк сүзләр таба алмадымы, ни әйтергә белмичә, өстәл артыннан чыгып, тәрәзә төбендәге тәмәкесенә ташланды. Төреп кабызгач, тынычланырга теләпме, сейфыннан ниндидер язулар чыгарып, шуларны укырга тотынды. Озак утырды ул. Аяк өсте торып тәмам арыган Нурисламның күз алдында очкыннар уйнаклый башлаган иде. Майор кинәт башын күтәреп:

— Ну?!— дип куйды.

Башын югалткан чәче турында уйламый, диләр. Нурислам шундый кеше халәтендә иде, сүзгә-сүз, пычакка-пычак торырга булды.

— Буш хәсрәт, Темляков. Сез миннән үзегез көткән җавапны ала алмассыз. Бусы бер, икенчедән — сезнең мине болай җәфаларга хакыгыз юк. Сезнең эш — минем үткән юллар, кылган гамәлләр турында үземнән сөйләтеп, шуларның дөреслеген тикшерү, ул юлларымда гаеп-кыек тапсагыз хөкемгә тарту...

— Менә ничек!.. Синең немец ялчысы икәнеңне белүем өстенә синең файдага дәлилләр, шаһитлар эзләп йөримме? Мә! Менә моны күрәсеңме?— дип майор баш бармагын ике бармак арасына тыгып, Нурисламның борын төбенә төртте.— Син шушы килеш миннән котылырмын дип уйлыйсыңмы? Тот пычагымны! Әй, кем анда?!

Ишекне шыгырдатып ачып бер солдат килеп керде. Билендә наган.

— Алыгыз!

Солдат шундук Нурислам артына килеп басты.

НКВД урнашкан бу мәктәпнең идән асты — подвалы да булган икән. Солдат аны шунда төшереп, ябып куйды.

Тәрәзәсе дә юк икән. Шыксыз караңгылык. Җитмәсә, биниһая сасы. Бу сасылык Нурислам кебек бәхетсезләрнең аңарчы да «кунак» булып чыгулары турында әйтеп тора.

Нурислам аркасын хәзер генә ябылган ишеккә терәп, тупсага гына утырды. Авыртмаган, сызламаган җире юк иде. Аяклары яна. Ботинкаларын салды. Балтырын, тубыгын капшап караса, гөбе кебек шеш. Бармак белән басып торсаң, урынында тирән эз кала.

Төрле хәлләргә тарыган, күп үлемне күргән егетне аяклар шешенү генә әллә ни куркытмады. Бөтен гәүдәсе белән янга борылып, аякларын ишек яңагына куеп ятты. Бераздан аяклары буйлап кан йөри башлагач, рәхәт изрәп, якты дөнья йөзендә калган уй-хатирәләргә бирелде...

Нурислам хезмәт иткән партизаннар берләшмәсен тылда калдырып, Совет армиясенең Көнчыгыш Пруссиягә бәреп кергән көннәре иде. Ирле-хатынлы табиб-партизаннар белән бергә төшкән фатирына, көндезге ашка дип, Нурислам күтәренке күңел белән кайтып керде.

Табиблар өйдә. Иртәнге якта үлән-чәчәкләр җыеп кайткан ире шуларны киптерергә дип мәш килеп йөри, хатыны, чыбылдык артыннан ишетелгән пышылдауларга караганда, мөгаен, берәр сырхауны карыйдыр. Сәбәп башкада икән. Нурислам кул юып йөргән арада, чыбылдык артыннан чыгып, табип ханым үзе ачыклап бирде:

— Янымда үтә сәер бер чибәр туташ утыра, Нурислам. Кем дип әйтсәм дә хата булыр сыман... Әмма шунысын әйтә алам: күрәзәче ул. Ирем белән икебезгә дә фал ачты. Тел төбеннән аңлавымча, сине дә күрәсе килә аның... Хәер, нигә әле юкка вакытны әрәм итәбез. Үзең кара инде. Шундый чибәркәйдән нервларыңны кытыклатып алу үзе ни тора, шулай бит,— дип табип ханым күз кысып куйды.

Ниндидер күрәзәче, им-томчыларга ышанмый иде Нурислам, чибәр дип, башын югалтканы да булмады. Әмма ул көнне, кәефе әйбәт чакка туры килгәнгәме, табиб ханымның сүзен кире какмады:

— Нигә, кытыклатабыз аны,— дигән булды.

Төз гәүдәле, коңгырт күзле — яше егерме биш тирәсе булыр — чыннан да гаҗәп чибәр кыз иде ул. Кыю да, терекөмештәй хәрәкәтчән дә икән, матур елмаюы, ягымлы кыланышы белән мавыктырып, егетнең кулын үзенең кайнар, йомшак учына алырга да өлгерде.

Әмма кыз никадәр чибәр булмасын, Нурислам барыбер сагая калды. Башында: «Безнең кеше түгел бу»,— дигән уй тынгы бирмәде. Үзе алай да кызыкайның серле карашын, йөгерек чишмә тавышын хәтерләткән ипле көлү авазларына сихерләнеп, кулын аның җылы кулларыннан ала алмыйча, аңа ияреп, стена буендагы эскәмиягә барып утырды.

Юк, барыбер ул уяулыгын җуймады. Буржуаз Польша, буржуаз Литва яклы һәртөрле дошман белән тулы ят җир ич бу. Йөзләгән

сугышчы язмышы өчен җаваплы партизан командиры, бигрәк тә, һәр чит-ят кешедә шпион, диверсант, халык дошманы күрергә өйрәтелгән кып-кызыл сталинчы Нурислам Таһиров, чибәр кыз очраттым дип, уяулыгын югалтамы?! Мөмкин түгел! Нурислам йөрәгеп кызларның әкияти гүзәле дә йомшарта алмас! Һаман шул, баштагы уен куәтләде егет: «Билләһи, безнең кеше түгел бу. Билләһи, шпион бу. Мөгаен, полякларның Лондондагы эмигрант хөкүмәте файдасына эшли торгандыр бу. Сак бул, Ык буе егете...»

Ә кыз самими күзләрен аның уч төбенә текәгән дә: «бисмиллаһиррахманир-рахим...»— дип утыра.— Мин сезгә әйтер сүзләремнең иң кирәклеләрен кыска-кыска гына әйтергә мәҗбүрмен. Нигә, дисәгез, прошен пане[1], сизенеп утырам, сез мине өнәмисез. Чит итәсез. Миндә дошман күрәсез... Әстәгъфирулла тәүбә! Бала чакларыгыздан бирле үк сихәтлеккә туймыйсыз икән ләбаса. О-о-о, тагын әле үтә дә авыр җәфалар да чиккәнсез, михнәтләр дә кичергәнсез икән. Әйе, әйе! Инде алары үткән, артта калган. Хәзер, иншалла, саулыгыгыз да, күз тимәсен, әйбәт, үзегезне күктәге бөркеттәй сизәсез. Өметләрегез зурдан. Олы эшләр майтарырсыз сыман. Альбо[2] кызыкмагыз, алданмагыз... Йәйә-йә, Аллаһ Тәгаләм, җәллә мине — гөнаһлы кызыңны, үзеңнең мәрхәмәтеңнән ташлама, мин бу Мөхәммәд өммәтенә, үз ихтыярыма каршы төшеп, үтә дә авыр сүзләр әйтергә җыенам,— дип, күзләрен ишеккә таба юнәлтте дә, нәкъ безнең татар карчыклары кебек, дога кылып утырды. Анысы беткәч, инде тагын нәрсә әйтергә белми тордымы, әллә инде үзенә хас алым гына идеме, ягымлы кыланып, егетнең кулын янә үзенең учына салды да, сыйпый-сыйпый:— Хөрмәтлем минем, сүзләремне берүк авырга ала күрмәгез, озак айларга, озак елларга сузылган казенный йорт көтә сезне,— дигәч, кабат тын утырды. Бу юлы күзләре тулы яшь иде.

Кызның мөселманнарча, Коръән сүрәләрен үз итеп, аларга ианып сөйләүләре Нурислам күңеленә хуш килсәләр дә, аның күрәзәлек кылу хәтлесен кабул итә алмады. Күз яше күрсәтүен исә оста артистлану, ышаныч казанырга тырышу дип кенә тапты. Шуңадыр күрәсең, кырт кистереп әйтте:

— Ышанмыйм! Юк сүз! (Ярый әле, тел очында торган «Син шпион, мине сихерләп, үз эшеңә тартырга җыенасың», дигәннәреннән тыелып калды).

Ә кыз сабыр да, әдәпле дә икән. Егетнең бу сүзләрен ишетмәгәндәй, боек карашын үзгәртмичә, яшьле күзләрен сөртеп тә тормыйча, үзенекен сөйләде дә сөйләде:

— Бәлки, хөрмәтлем, тынлап бетерерсез. Әйткән сүзләрем өчен кичерегез. Аларда — рәхимсез дөреслек. Әмма, бер Алла сезгә шундый язмыш биргәч, мин, ярлы телле кыз бала, бу хакыйкатьне нинди сүзләр белән ачып салырга тиеш идем соң?! Алай да киләчәгегезгә өметегезне өзмәгез, Аллаһ Тәгалә боерса, бүгенге дошманыгыз иртәгә булмас, бүген юк дустыгыз иртәгә килер. Сезне әле ерак киләчәктә, кабатлап әйтәм — ерак киләчәктә, олы бәхет, олы сөю көтә. Тик, берүк яныгызга Газраилне генә җибәрмәгез дә, үлемгә генә бирешмәгез. Соңгы сулыш, дигән сүзне онытыгыз. Ул сезнең өчен түгел,— дип урыныннан торды.

Нурисламны катлаулы уйлар, буталчык тойгылар биләп алды. Бу чибәркәй, киеменә караганда, гади белорус кызы, күзләренең моңлы очкынынннан аны Мөхәммәд өммәтеннән, ягъни татар кызын, кыю, хәтта әрсез күрәзәчелеге — чегән кызын хәтерләтә иде.

— Кем син?

— Туташ.

— Алай гынамы?

---

[1] Прошен пане — гафу итегез *(полякча)*

[2] Альбо — ләкин *(полякча)*

— Шул, кардәшем, шул гына. Һәрхәлдә, сез уйлаганча, куркыныч начар кеше түгелмен.

— Нигә кердең?

— Үзегезне тотышыгызда тупаслык, коры куыклану сизелә. Сөйләшүегез дорфа. Безнең якларда кызлар белән болай сөйләшмиләр. Бәлки, башта ук чыгып китәргә булгандыр миңа. Альбо нигә китим? Үзем кебек үк татар ла сез! Минем моңарчы рус партизаннарын күргәнем юк иде. Күрәсем килде. Бигрәк тә, аларның олы командирларының берсе милләттәшем татар икәнен ишеткәч. Бер күреп сөйләшим, үземне дә күрсәтим дип керү иде... Җавабым канәгатьләндерәме сезне?

— Рәхмәт. Ә күрәзәлек кылу хәтлесе?

— Анысы сезнең янга үтү өчен бер сылтау гына. Дөрес, ул якка сәләтем бар, ахры. Миңа ышаналар. Сез дә ышаныгыз. Чынлап та сезне авыр киләчәк көтә...

— Каян беләсең?

— Монысына җавап бирә алмыйм. Авыр, бәхетсез көннәр көтә сезне. Күрәсең, Алла шулай куша. Кичерегез, довидзенья.

Ул чакта партизан-командир Таһиров әлеге кызның дошманнар файдасына эшләүче түгел, ә бары тик күрше шәһәрчектә яшәүче модельер гына икәнен тикшереп белсә дә, аның алдында үзен тупас тотуы, нахактан аны шпион санавы өчен үкенмәгән иде. Янәсе, сыйнфый көрәш, канлы сугыш логикасы шулай, һәркемнән шикләнү уяулыгы кирәк.

Менә хәзер... Көтмәгәндә... Сугыш мәхшәреннән котылып, тыныч тормышка күчәм дигәндә генә... Шпион тамгасы салыну куркынычы үзенә килгәч, сасы подвалга эләккәч, акылга килә башлады. «Ни хакың бар иде синең үзең белән танышырга дип кергән гөнаһсыз чибәрдә шпион күрергә?! И аңгыра бәрән!... И әхлактан мәхрүм калган ишәк!... Томана!...»— дип, чәчләрен йолкый-йолкый елап яйты һәм шушы әче кичереш вакытында кызның алдан күреп әйткән сүзләре раслана башлауга инанды: «... озак айларга, озак елларга сузылган казенный йорт көтә сезне».

Ашарга-эчәргә бирмичә тагын бер көн, бер төн аяк өсте тотты аны майор Темляков. Шул арада үзе «Ну!» эндәше астында аннан көлү, аны мәсхәрәләү белән шөгыльләнсә, лейтенантыннан ике тапкыр рәхимсез кыйнатты. Соңгы тапкыр кыйналгач, аңына килгәнче үк, подвалга төшереп ташлаганнар иде. Күзләрен ачканда шунда ята иде. Әнә шул шартларда кызның «Газраилне якын җибәрмәгез. Үлемгә бирешмәгез...»— дигән сүзләре исенә төшеп, су төбенә киткәндә тотынып торырдай салам гына түгел, учма хезмәтен үтәделәр. «Мондый кыйнатулар Газраилне якын җибәрү ул, кыйнатмаска, хәзергә үлми торырга кирәк»,— дип, Темляковның «Ну!»ына ул көткән җавапны бирергә булды.

Аяклары гөбе кебек шешкән, хәлсез, көчсез Нурисламны ике солдат култыклап, Темляков каршысына китереп бастырганда, ул өстәле артында селедка ашап утыра иде. Иреннәре майланган, авызы чәпелди. Тамагын кырып, селедканың сырт сөяген суырып ташлый да, кайнар чәй йота. Янә ипигә, балыкка үрелә.

Нурисламның авызы шундук селәгәй белән тулды. Аның да шулай селедка ашыйсы, кайнар чәй йотасы килә. Шушы теләк сәбәпче булды, күрәсең, башы әйләнде, күз аллары караңгыланды да, гөрселдәп идәнгә ауды. Ауган чакта кычкырып өлгерде:

— Яз!

— Нәрсә языйм, Таһиров?

— Үзең теләгәнне. Мин кул куярмын.

— Менә бусы егетлек. Әллә кайчан кирәк иде. Хәзер, Таһиров, хәзер... «Ә» дигәнче язылыр...

Шул көннең кичке ягында бу татар егетен, саф күңелле сталинчы дип тормадылар, НКВДның халык телендә «душегубка» дип йөртелә торган эчке төрмәсенә (шул ук Вилейка шәһәрендә) илтеп яптылар. Хәзер ул иң куркыныч җинаятьче — илен саткан хыянәтчегә әверелде.

Эчке төрмә. Нурисламның үз гомерендә мондый төрмә турында ишеткәне дә, укыганы да юк иде әле. Кайчакларда ГПУ подвалы, дежурство дигән сүзләр ишеткәләсә дә, андый подвалларның, душегубкаларның булуына, яки булу мөмкинлегенә ышанмады. Ул турыда сүз кузгаткан кеше коткы таратучы булып тоела иде. «Ничек инде безнең Ленин-Сталин партиясе җитәкли торган бөек илдә душегубка дигән корылмалар булсын!»

Чынлыкта исә, бу илнең подвалы да, душегубкасы да бар, тик аның исеме генә гөнаһсыз: эчке төрмә икән. Әйтик, менә, Нурислам килеп капкан төрмә камерасы душегубка түгелмени? Аның турында үзе күрмәгән кешегә сөйләсәң, бу бәндә акылдан язган, саташып сөйли дияр, ышанмас иде. Билләһи ышанмас. Буе өч, иңе ике атлам зурлыгында ул, идәне, стеналары, түшәме тоташ бетоннан. Тәрәзәсез, караңгы. Кап та кап, ул да кап. Күрәсең, анда кайчандыр бәдрәф булгандыр. Идәненнән юан торба башы чыгып тора. Канализация торбасы. Һәм аннан тәүлекләр буе, әйтерсең, вентилятор эшли, суык җил өрә. Өстендә ярым ефәк юка плащ-палаткадан гайре бүтән өс киеме булмаган егеткә бу җил әкиятләрдәге тәмуг уты — тәмуг ялкыны булып тоела. Кайбер төннәрне аннан кергән җил суыкмы, кайнармы икәнен дә аера алмаслык хәлгә килә. Зиһене чуала. Чынбарлык каядыр убыла, саташу-бастырылулар башлана.

Бу шыксыз капта утырып торырдай урындык ише әйбер юк. Бары тик идәненә салынган озынлыгы ике, киңлеге ярты атлам чамасы топчан гына бар. Ул кытыршы такталардан кагылган. Кичке поверкадан алып, иртәнге туалеткача яту урыны да (бусы мәҗбүри), көндезләрен утыру урыны да шул. Әйе, утыру урыны. Чөнки көндез ятарга ярамый. Камера-кап турында тәрәзәсез дию дөрес үк түгел. Аның түр стенасында — нәкъ түшәм астында фрамуга дип атала торган тишеге бар. Безнеңчә — олы төнлек. Ул төрмә кухнясының коридорына чыга. Шуңа күрә аннан, иртәдән алып кичкә кадәр кәбестә исе аңкый, кухня пары кереп тора.

Һәр көнне, урыннан торгач, бәдрәфкә чыгарып кертәләр дә (анысы коридорның икенче башында), өч-дүрт йөз грамм чамасы ләчтә ипи, иске, янчек консерв банкасы белән бер чүмеч җылы су биреп, карап торып ашаталар. Аннары инде ишек тагын ябыла. Төшлеккә тагын ачыла. Шул ук банкада, шул ук чүмеч белән баланда бирелә. Анысы күбрәк әче яки төче кәбестәдән һәм берничә вак бәрәңгедән тора. Гадәттә тозсыз була. Ишекнең өченче тапкыр ачылуы инде — поверкага. Анда, надзирательдән тыш, йә старшина, йә кече лейтенант керә. Кулларында — һәрвакыт янып торган фонарь һәм агач чүкеч. Телләрендә бердәнбер сүз: — «Те!» Нурисламның фамилиясенең баш хәрефе булыр бу. Егет аңа күнеккән. Бу авазны ишетүгә, шундук пышылдап, алар ишетерлек итеп кенә: «Таһиров Нурислам», — дип әйтә. Кычкырып әйтергә ярамый. Алла сакласын. Юкса — җәза: бер көнгә ипинең яртысы гына бирелә. Бу йоладан соң фонарь уты астында, агач чүкеч белән капның стеналарын суккалап чыгалар. Күрәсең, бу Таһиров атлы тоткын, бетон стенаны җимерер дә качар дип юләредер. Шуннан соң надзиратель бер чүмеч җылы су эчерә дә: «Ят!» — дип, ишекне яба. Бикли. Нурислам бу тәртипне дә яхшы үзләштерде. Ишек ябылуга ук плащ-палаткасына төренә дә топчанга ава, үзенең җылы тынын куенына өрә башлый...

Бетләде. Тәненең кай төшенә генә кагылмасын, анда — мыжлаган бет. Башыннан алып кашы, сакалы-мыегы, аяк бармакларынача бет таламаган, кычытмаган урыны юк. Хәзер аның бөтен эше, бөтен мәшәкате исәбе жуелган көннәр буена бетмәс-төкәнмәс хәшәрәт чүпләү дә, бармаклары белән сакалын аралау, мыегын шомарту. Шул вакытта уйлану, уйлану һәм уйлану...

Уйларының йөрсә дә, утырса да, ятса да башыннан чыкмый торганнары: «Нигә аны хөкем карарына хәтле төрмәгә яптылар да, нигә шушы хәтле тузга язмаган начар шартларда тоталар? Кеше дип аталган җан

иясе нинди генә җинаять эшләсә дә, аны җәзалауданиндидер әхлакый норма, чик булырга тиештер ич. Бигрәк тә бөек Сталин җитәкли торган бөек мәдәниятле Совет илендә»,— дигән уйлар иде.

Чыннан да, нигә аны бердәнбер кеше — Темляков власте белән иркеннән мәхрүм иттеләр? Темляков та, Таһиров та СССР гражданнары буларак тигез хокуклыдыр лабаса! Нигә Темляковка ышаналар да, нигә аңа — Таһировка ышанмыйлар? Нигә сугыш кырына якын да килеп карамаган җирәнгеч Темляковка, сугышның утын-суын, барлык җәһәннәмнәрен кичкән патриот Таһировтан көләргә, аны мәсхәрәләргә, кыйнатырга, шундый юллар белән үзенә кирәк «признания»лар алырга, ялган беркетмәләр язарга ирек бирәләр? Бу бит золым! Кем биргән аңа мондый хокукны? Кемгә буйсына ул? Анысы кем дә, үз чиратында кем ихтыярын үти? Шушылай НКВД системасы буйлап өскә таба үрмәләсәк, Лаврентий Павлович Бериянең үзенә хәтле үк күтәреләбез түгелме? Аннан да өстәрәк, аңа боерык бирергә хокуклы шәхес бармы? И-и-и, Алла, әлбәттә, әлбәттә бар. Ул Иосиф Виссарионович үзе.

Нурислам, математик буларак, бу логик баскычны кат-кат йөреп чыккач, аны монда тотучы кеше — тотучы гына түгел, суыктан, ачтан, беттән интектерүче кеше дә Иосиф Виссарионович үзе булып чыкты. Ләкин Нурисламның акылы моңа ышана, алмый иде. Чөнки Сталин бит ул, Сталин! Халыклар атасы! Гаделлек иясе! Кешелекнең ышанычы, өмете!

Алайса, кем? кем?! Темляковтан алып, Сталинга хәтле сузылган чылбырга кем кереп кысылган да, гөнаһсыз Нурисламны кем шушылай интектерә?!

Нурислам узган гомерен кайта-кайта күңеленнән чигерә. Бәлки, аның чынлап та гаебе бардыр. Юк, моңа вөҗданы ышана алмый. Кайчан? Ничек? Кайда?..

## II

Кырыгынчы елны Казан университетын тәмамлап, сигез ай гына укытып калды ул. Ак билет бирелгән чирләшкә Нурислам Таһировны көтмәгәндә армиягә алып (әйтерсең, чик саклау буенча олы белгеч), бүген-иртәгә немец ташланасы чиккә озаттылар. Анда барып урнашкач, гөнаһ шомлыгына каршы, ант биреп, кулга корал тотып чын солдат булырга өлгерә алмый калды, үсмер чакларыннан ук килә торган чире — остеомиелит яңарып чыкты да. Госпитальгә салдылар үзен. Аннан савыгып чыгуга, сугыш башланды.

Сугышка, үз сүзләре белән әйтсәк, нуль сыйфатында керде Нурислам. Кулында коралы да, башкарырга тиешле вазыйфасы да юк иде. Хәтта, сугышның беренче минутларында, фәлән эшне эшләп кил әле, дип, берәр йомышка җибәрүче дә булмады үзен. Шәһәр тирәсендә урнашкан танкистлар, артиллеристлар, пехота һәм бүтәннәр тревога белән күтәрелеп юлга чыкканда аны бер бәләкәй машина-пикапка утыртканнар иде. Соңынтын ачыкланды, үзе хезмәт итәргә тиешле танк полкының автобат машинасы булган икән ул — шул утырудан, фронт дигән нәрсәне күрмичә, биш тәүлек юл куды да, фин сугышын кичергән пикап, карт алаша сыман, адым саен туктый, төчкерә, тартмый башлагач, яннарындагы лейтенант приказы белән аннан төшеп, тәпи-тәпи атлауга күчте. Үзе генә түгел, янында колгадай озын яңа система мылтык тоткан сугышчы да бар. Связной. Алларына куелган бурыч: дүрт тәүлек эчендә Шипатовка каласына кайтып җитәргә. Аларның полкы шунда җыелачак, шунда тулыландырылачак һәм шунда кораллындырылачак икән.

Юл тулы гаскәр. Чигенеп баручы Кызыл Армия сугышчыларын көйдерим, гомерләре буе онытмаслык итеп теңкәләренә тиеп калыйм әле дигән сыман, Алла күк йөзенә ичмасам гына да бер болыт кисәге

китерми, кайнар кояшын капламый. Арыш-бодай күтәрелеп килә торган басулар кара тузан астында. Җитмәсә фашист самолетлары кара тилгәннәр кебек, бомба коялар, пулемет утына тоталар. Кеше гәүдәләре белән бергә металл эри, ботарлана, кан, ут, тузан бергә укмаша. Җирдә мәхшәр. Һавада — үлем исе...

Гаскәрләр отыры чигенә. Бу җәһәннәмгә эләккән иксез-чиксез сандагы сугышчылар арасында Нурислам кебек хуҗасыз-командирсыз атлаучы дуадаклар яки ике-өч кешедән торган ятим төркемнәр дә күп. Аларның шактый өлеше коралсыз, өс киемсез, каешсыз, пилоткасыз. Хәтта яланаяк элдертүчеләр дә күренгәли. Болары — барысы да диярлек, куркуга төшкәннәр, солдат рәвешен җуйганнар. Аналарын югалткан каз бәбкәләрен хәтерләтәләр. Сүзләрендә, күзләрендә көчсезлек, өметсезлек. Ләкин аларны канат астына алучы юк. Үтеп баручы роталар, батальоннар, артдивизионнар, машина колонналары, окопларга кереп урнашкан полклар да күп югыйсә. Әмма алар мондый ятимнәрне үз яннарына сыйдырмыйлар. Кая сыйдыру! Әйтерсең, алар тозланган, каешланган гимнастеркалары астында махау чире йөртәләр, ул бичараларны якын җибәрмиләр. Өстән төшкән фәрман шундый.

Бу хәл Нурисламга ошамый, әлбәттә. Аңа калса, әгәр рөхсәт итсәләр, ул мондый ятим-бичараларны бер командага җыяр, ашатыр, киендерер, иң мөһиме, юатып-тынычландырыр иде дә янәдән корал тоттырып, окопка төшереп утыртыр һәм «үзең исән чакта фашистны бер адым да җибәрмә!» дияр иде.

Хәер, мондый уйлар тузанлы юлда чарасыз атлаудан туган хыяллану да университет белемле егетнең эчтән бер хөр фикер күрсәтеп алуы гына иде.

Коралсыз булса да, ул барыбер үзен солдат итеп хис итә иде. Аңа дүрт көн эчендә Шипитовкага кайтып җитәргә әмер бирелгән, ул шуны, тик шуны гына үтәргә тиеш.

Беркөнне, таң ата башлауга, олы юлны калдырып әрәмәлеккә борылганнар гына иде, дошман засадасына — пулемет, автомат уты астына эләктеләр. Ятарга туры килде. Таһировның юлдашы ушлы егет иде. Коралын шундук дошманга төбәде. Төбәде, әмма аннан бер тапкыр гына ата алды. Олы өметләр баглап килгән, берьюлы ун патрон белән корыла торган яңа системалы ярымавтомат атмый гына бит. Засадага эләгү уен эш түгел, анда мылтык төзәтеп утырмыйлар. Язмышыңны хәл итү өчен керфек кагып алыр вакыт та җитә. Шуңа күрә, алар мылтык бирелгән тәпәчне төзәтүне киләчәккә калдырып, үрмәли-шуышa тизрәк ут астыннан чыгу ягын карадылар. Ләкин болай гына пулялардан котылып буламы? Кая гына үрмәләмәсеннәр, пулялар аларны эзәрлекләп торды.

Нурисламга шунысы сәер тоелды: күпләгән пулялар алга, артка, кырыйга төшеп кадала яки колак төбеннән сызгырып үтә тора, әмма аларга тими иде. Бу ни хикмәт бу? Ходай саклыймы?..

Нурислам, иптәшенә караганда, яшькә олырак, акылы утыра төшкән. Логика да көчлерәк, ни әйтсәң дә математик, немецларның кычкырып көлүләренә, сызгыру, акырышуларына колак салгач, шушылай «кыек ату» сәбәбен шәйләп алды. Ул үләт кыргырларының бу ике бәхетсез «рус солдаты»н пуля уты астында уйнатып маташулары икән. Үзләренә калса «тычканга үлем — мәчегә көлке» уйнаулары.

Бу ачыш Нурислам акылына очлы кадак булып кадалды. Шул хәтле гарьләнде, шул хәтле хурланды, бөтен тәне калтырый, яңакларын көзән җыера башлады. Түзү, чыдау мөмкинлеге калмагач инде, үрмәләгән җиреннән капылт торып, русчасын, татарчасын бергә кушып кычкырды.

— На, курва, ат! Мин — совет солдаты. Тычкан түгел. Ат!

Атмадылар аларны. Колга буе немецлар автоматларыннан ут көлтәсе сиптерә-сиптерә, яннарына килеп, сугып ектылар. Аннары — әсирлек...

Әйтергә генә ансат. кырык беренче елның көзендә бер лагерьга дүрт меңгә якын совет әсирен кертеп япканнар иде, кырык икенче елның язына шулардан йөз үндүрте генә исән калды. Аларның да уникесе икенче лагерьга күчергәндә юлда җан тәслим кылды.

Яңа лагерь Таһиров башына тирән шикләр төшергән урын булды. Андагы тәртипләр килеп төшүнең беренче сәгатьләрендә ук, шомлы да мәкерле дә сыман тоелган иде, тора-бара «сыманнар» барысы да расланды. Ач атларны хәтерләтеп эчкә баткан күзле, чуан баскан муенлы «доходяга» әсирләрне китерәләр дә, юындырып киендергәч, пычкы оны катнаштырып пешерелгән «эрзац-брод», әчегән мармелад, кортлаган сыр һәм бәрәңге белән ай чамасы тотып, тәннәренә ит, чырайларына төс кундыргач, күпләрен кайдыр озаталар. Сирәкләре — шул лагерьда торып кала. Калганнар арасында үзара танышу, сер уртаклашу дигән нәрсә юк. Алай да кемнең кем икәнлеген белергә була. Алар күбрәк лейтенанттан алып, полковникка хәтле элекке совет офицерларыннан, студент яки урта, югары белемле солдатлардан, сержантлардан тора. Дөресен әйткәндә, бу лагерьда калганнар ике бозауга кибәк аерып бирә белә торган кешеләр.

Ике татар егете белән эләкте Нурислам. Икесе дә аның ахирәт дуслары. Әсирлекнең беренче атналарында ук очрашкан, узган кышның ачлыгын, суыгын, эч китүләрен, тифын бергәләп кичергән, аларны бергә җиңеп чыккан Мәскәү студенты Асланов Хөснетдин белән Әзәрбәйҗаннан агроном Бәхтияри Сәгъдәт. Кем — кем, әмма болар инде кибәк кенә аера торган егетләр иде. Немецның бу лагерьдә ашаткан өчен, кырындырып, юындырып, беттән арындырган өчен ни бәя сораячагын, нинди эшләр таләп итәчәген шиксез аңлыйлар иде. Бу уңайдан өчесе бергә утырып, ачыктан-ачык сөйләштеләр. Нишләргә? Һәм уртак фикергә дә килделәр: хәзергә әле аларның әсир солдат намусына кагылучы юк. Шулай яшәгән килеш яшәп бирергә. Акыл, түл җыярга. Алда күз күрер. Әмма сак кыланырга. Очраклы коткыларга бирешмәскә.

Шушы сөйләшүдән соң күпме генә вакыт үтте икән — әүмән-тәүмән атлап Нурислам янына бер шәүлә килеп басты.

— Һаумы, агай-эне! Мин Ишкилдин Харис,— дип кул биреп күреште. Таныштылар. «Кулымда граната бар сакта никләр генә үдемне-үдем шартлатмадым микән дә, никләр генә үдемне кол итәргә бирдем микән»,— ди. Исән килеш әсир калуы өчен үкенә. Сер сыйдырмалы, саф йөрәкле егеткә охшаган дип, Нурислам аны да үзләренә якынлаштырды. Сердәшләр дүртәү булып киттеләр.

Нурислам хәтерендә ул чорда очраган татарлардан тагын берсе саклана. Үзен «Апуш» диеп таныштырган иде. Мөгаен, Габдулла булгандыр. Касыйм мишәре. Миңгә, бәлки миллионга бер генә очрыйдыр андый бәндә. Әтисе карт, авылдан авылга күчеп, кубыздан алып аршинлы малга хәтле вак-төяк сатып йөри торган кеше — кырык тартмачы булган. Утызынчы ел башларында колхозга кер дип, кыстый, кыса башлагач, бар мөлкәтен сатып, читкә чыгып китәсе икән дә, ул киткәләгәнче тотып алып, балалары-ниләре белән себер җибәргәннәр. Бу бәхетсез гаилә шунда бер ел эчендә юкка чыга. Унике яшьлек Апуш кына исән калган. Язу-документ кебек нәрсә юк малайда, заемкадан заемкага, авылдан авылга күчеп, кайда туры килә шунда йоклап, кем нәрсә бирсә шуныкын, бирмәсә урлап ашап йөри торгач тимер юл станциясына барып чыккан. Исәбе — туган ягына кайту икән. Әмма кайтып кара син җиңел генә! Станса саен милиция! Эләктереп алып, приютка озаталар үзен...

Утыз алтынчы елны булган бусы, аннан качып Кузбасска барып чыга. Шахтага эшкә керә. Ат куучы — коногон. Берничә елдан — армия. Социаль чыгышы чиста хәзер: приютта тәрбияләнеп үскән пролетариат. Комсомол. Шахтер. Җитмәсә, өске иреңендә сызылып чыккан кара мыек йөртә торган сөлек буйлы сибиряк. Күзгә ташланып торган хакыйкать

шушындый икән, чик сакларга җибәрү өчен аннан да кулайрак егет табылырмы?! Аны илнең Көнбатыш читенә җибәрәләр.

Эчкерле, мәкерле түгел диген син аны шуннан соң! Бу Апуш совет кешесенең чәчләре үрә торырлык яман уйлар йөрткән икән. Сугышның беренче минутларында ук, мылтыгын штыгы белән җиргә кадап, кулларын күтәргән: «Һайль Гитлер! Гутен таг! Шталин капут!». Үзе сөйләгәнчә, болай: «Китте, мин сезгә әйтим житуха түгел, малина. Суткасына өчәр сыерның бугазына пычак салам — значит, дәдәгез немец ротасында мясник. Брюха майда, нос төтендә. Исәп, немец Касимовны алса, нәселемне корыткан андагы большевикларның бугазына острый пычак тыгу, расчет ясау... Но дело барып чыкмады. Немецның кишка тонка, торык кыска икән... Хотя, бер уйлаганда, большевик кайда да большевик. Вязьма тирәсендәгеләренең коелган яшьләре, каннары жидеиче буыннарына барып житәрлек итеп иманнарын укытып цыктым».

Нурисламнар янына ул очраклы рәвештә генә килеп эләккән иде, ахры, бер-ике тапкыр күрешеп, мактанып алгач, каядыр китеп олакты. Хәер олакмаса да, Нурислам аны үз табынына сыйдырмас иде.

Ул бәндә киткәч, Таһировлар үзләре дә озак юанмадылар. Лагерь житәкчеләре һәр көнне бер-ике «Дис Дайге вахеншау» — атналык киножурнал күрсәтүләрен, өченче Рейх яки Россия тарихын өйрәтүләрен калдырып (тизләтелгән программа), партизаннарга каршы сугышу тактикасын өйрәтеп йөргәндәй иттеләр дә (ай чамасы) вагоннарга төяделәр. Кырык икенче елның октябре иде бу. Ниятләре шундук беленде, көнчыгышка, совет партизаннарына каршы көрәшкә алып китүләре икән.

Бу инде, үзен совет патриоты дип санаый торган әсир өчен, үзендә кешелек сыйфатларын йөртә торган теләсә нинди антифашист өчен дә, намуслыкның соңгы чигенә якынлашу, фашист ялчысына әверелү дигән сүз иде. Ә Таһиров белән аның дуслары чыннан да совет патриотлары иде. Һәм аларның фашист ялчысына әвереләселәре килми иде, поезд кузгалып китүгә үк, күзләре түгәрәкләнде, әсәренделәр. Ана сөте белән кергән, совет чынбарлыгында ныгыган рухи көчләрен егетләр бер йодрыкка тупладылар. Тартылган җәя кебек киеренке халәттә иде алар. Бар уй-хыяллары, бар омтылышлары — ничек кабул итсәләр дә: атып үтерәләрме, авыр җәзага тарталармы — беренче мөмкинлекләр туугa ук партизаннар ягына чыгу иде.

Капитан Кузнецов һәм майор Горбач тирәсенә тупланган тагын ике яшерен төркем барлыгын һәм ул төркемнәрнең дә үзебезнекеләр ягына күчәргә максат куюларын күптән сизенә иде Таһиров. Октябрь азакларында Белоруссиянең Глубокое шәһәренә кайтып төшкәч, аларның кылларын тартып карарга булды. План-ниятләр зурдан. Көчләрне туплап, әлеге йөз утыз — йөз кырык әсирдән торган команданы партизаннар ягына тулаем күчереп булмасмы... Бу эшне — Кузнецов белән Горбачның кылларын тартып карауны Бәхтияригә тапшырды Нурислам.

Белоруссиягә кайтып төшүнең беренче көннәрендә немецлар һәркемгә режимсыз ятарга-торырга, шәһәргә чыгып, халык белән аралашырга, гаилә мәҗлесләрендә катнашырга һәм теләгеңә карап, мыек чылатып кайтырга да ирек бирделәр. Атна-ун көнгә сузылды бу. Ач үлем тырнагыннан котылган әсир өчен, әйтерең бармы — җәннәт инде. Өсләренә кигән киемнәре фашист-немецныкы түгел, чех армиясенеке булгангамы, җирле халык болай яхшы кабул итте аларны. Шуңадыр күрәсең, көннәр буе шәһәрдән кайтып кермәделәр. Ләкин, кызганыч ки, кайберәүләр бу хөрлектән исереп, тиешле-тиешсез урында, кирәк-кирәкмәс кешеләр арасында артыгын сөйләп, серләрен-ниятләрен ачып ташладылармы, әллә бүтәнме, кайтып төшүнең унынчы көнендә команданың алты кешесен немецлар кулга алдылар. Араларында Бәхтияри белән Кузнецов та бар иде. Егетләрнең кулга алынуларына тәүлек тә үтмәде, кулларын бәйләгән килеш, машинага төяделәр дә, шәһәр читенә алып чыгып, атып үтерделәр.

Ул көнне шәһәргә чыгарга беркемгә дә рөхсәт булмады. Барча әсир һич ни күрмәгән, һични турында ишетмәгәндәй, күршесенә, якынына сүз катарга кыймыйча, идәнгә җәелгән салам өстендә көне буе аунадылар. Нурислам салам өстендә төн буе күз дә йоммыйча, һәлак булган иптәшләре, аеруча ахирәт дусты Сәгъдәт Бәхтияри турында уйланып ятты. Уйларлык та иде шул. Сәгъдәт бит туган илгә хыянәт итмичә, чиста-саф вөҗданлы килеш дөньядан китеп барды. Уртак сердәш булу өстенә, Нурисламны бер юлы өч чирдән — дизентерия, тиф, остеомиелит шешеннән үләргә ятканда, аны кулларында күтәреп йөрткән, соңгы сынык ипиен аңа каптырган, шулай итеп аны үлемнән алып калган олы, изге җан да иде.

Йөз ел яшә, йөз ел өйрән, немец-фашист психологиясен барыбер аңлап җиткерә алмассың, билләһи. Әллә ул бу командага җыйган рус әсирләрен корсак тутырудан, тәмәке көйрәтүдән гайре бүтән нәрсә турында фикер йөртә белми торган мәхлукләргә тиңләдеме, әллә инде алтысын атып, калганнарын куркыттым, өннәрен алдым дип уйлады, шул ату вакыйгасыннан соң ике тәүлек тә үтмәде, әсирләрне тревога белән йокыдан уятып корал өләшергә тотындылар. Теләсәң күпме патрон, теләсәң ничә граната ал. Сафка бастырып, беренче әмерне дә бирделәр: күрше Докшица шәһәренә бандалар һөҗүм иткән, имеш (немецлар совет партизаннарын шулай «банда» дип атыйлар иде).

Юлга җыендылар. Бер ачык кузовта ике немец солдаты, калганнары коралланган әсирләр. Шушындый биш машинадан торган колонна кузгалып та китте.

Докшица дигәннәре Глубокое шәһәреннән егерме чакрым чамасы ераклыкта икән. Яктыра башлауга, алда шәһәрчек күренде. Колонна, янып-пыскып яткан агач күпергә җиткәч, тукталды.

Нурисламның йөрәге кага башлады. Янәшәсендә утырган Асланов белән Ишкилдинга терсәкләре белән төртеп куйды: әзерләнегез, тәвәккәллибез, янәсе. Ул арада немец приказы яңгырады: машиналардан төшәргә!

Таһиров тирә-юньне яшен тизлеге белән күзәтеп алды. Әнә, уң якта — ялан. Сулда — ике-өч метр ераклыкта калын урман. Алда — бер чакрым чамасы арырак — Докшица. Якында, Нурисламнан ун метр чамасы гына алдарак — немец, обершарфюрер атлый. Җилкәсе киң, арты калын. Каскадан. Кулында автомат, билендә парабеллум. Аннан ерак түгел — майор Петр Горбач...

Менә хәзер, менә хәзер, дип типте Нурисламның йөрәге.

— Пошли, Петро! — дип кычкыруын үзе дә сизми калды ул. Күз ачып йомган арада, обершарфюрер киң аркасына төбәп атып җибәрде дә урман ягына ташланды. Кемнәрдер ата башладылар. Немец телендә бирелгән өзек-өзек приказ-команда авазлары ишетелеп алды, Нурисламга дөньяның асты өскә килгән сыман тоелды. Ни генә булмасын, тизрәк урманга барып җитү кирәк иде аңа. Арттан, янәшәдә аяк тавышлары ишетелде. Кемнәрдер аны узып киттеләр. Соңгы көннәрдә янбашы сызлап тора иде Нурисламның, хәле китте, аксый-туксый, сызлана-ыңгыраша, урман авызына барып керде.

Менә ул ирек!.. Җаны җырлый, тойгылары ургылып кайный иде аның. Урманны яңгыратып бер кычкырасы иде хәзер. Әмма хәвеф әле һаман куа килә, баш очыннан пулялар сызгыра, агач кәүсәләренә шартлап тия иде.

Әнә ешкынлык арасыннан Хөснетдин белән Харис килеп чыктылар. Авызлары ерылган. Әйтерсең, укытучы Таһиров аларны — ике татар егетен, юк, алай гына түгел, бөтен илне, Европаны фашист тырнагыннан котылдырган. «Рәхмәт дускай, мең яшә!» — дип аны кочаклап алдылар да елап җибәрделәр.

Кичке якта алар партизаннарга юлыктылар...

III

Нурислам, тикшерүдән соң бирелә торган бер чүмеч җылы суны чүмереп, топчанына яткан гына иде, ишек янә ачылды.

— Те!

— Таһиров Нурислам.

— Кулларыңны артка! Үзең дә борыл! — Нурислам борылган иде, кулларын шундук тимер чыбык белән боргычлап та куйдылар. Чыбыкның бер очы солдат кулында калды. — Алга атла!

Солдат аны төрмәдән алып чыгып, каядыр алып китте. Төн. Караңгы. Күзгә әрсез яңгыр. Тездән пычрак. Аяклар тая. Таеп, янтаеп киткәндә кулларын бәйләгән чыбык тартылып ала да, чәнечкеләре белән Нурисламның беләкләренә кадалып зәһәр авырттыра. Бусына да түзәр иден — гарьлеге ни тора. Ут астында әсирлектән качып, ил иминлеге өчен җанын-тәнен җәлләмичә сугышкан саф йөрәкле патриотны үзебезнең үк солдат шушы рәвешле чәнечкеле тимер чыбык белән бәйләп, дилбегәләп йөрсен әле! Егетнең күзләреннән әче яшь тамчылары бәреп чыкты. Шунда ук урамдагы ләмгә авасы да үләсе, бу хурлыктан мәңгегә котыласы килде. Әмма шул мәл көрәзәче татар кызының чибәр йөзе күз алдына килде: «Сез, кардәшем, бик үк хафаланмагыз әле, ерак киләчәктә сезләрне олы бәхет, якты сөю көтә... Бүген бар дошманың иртәгә булмас, бүген юк дустың иртәгә килер, түз», — дигән үгет-нәсихәте исенә төшкәч, егетнең аякларына җегәр иңде. «Бу вәхшиләргә үч итеп яшәргә дә яшәргә...».

Урам уртасыннан атлаган җиреннән солдат аны уңга борды. Тәрәзәләреннән тонык ут сузылган баракка керделәр.

— Тукта! — дип, солдат Нурисламның кулларын чиште. Якты бүлмәдә утырган чибәр йөзле өлкән лейтенант Нурисламны күтеп торган, күрәсең, ниндидер язулар укып утырган җиреннән башын калкытмый гына эндәште:

— Фамилия?.. — Нурислам җавап кайтаруга: — Менә шушыңа кул куй, — дип, машинкада басылган ике-өч юл язылган бер бит кәгазь сузды.

Нурислам Таһировны кулга алырга, дигән прокурор санкциясе иде бу. Нурислам кул куйгач, өлкән лейтенант солдатка карап: — Бетте. Алып кит! — дигән әмер бирде дә кәгазьләре өстенә иелде. Бу таш чырай өчен күзгә яңгыр астында пычрак ерып, манма чыланып килгән юка киемле кеше чүпкә дә тормый иде шул. Нинди ана тудырган, кайда үскән бу бәгырьсез бәндә?!.

Алып килгәндәге кебек, кулларын бәйләп, төрмәгә кайтарып куйдылар аны. Янә үз камерасына. Хәзер инде Таһиров чын тоткын, законлаштырылган. Статьясы: 58.1.б. Ватанга хыянәт иткән хәрби җинаятьче. И-и-и, Алла, димәк, аны кулга алу, интектерү, илен саткан дип хөкем чыгару майор Темляковтан гына тормаган. Аңа каршы бөтен бер система эшләгән. Аның һәр адымын каләм астына ала килгәннәр. Димәк, ул һәрдаим күзәтү астында йөргән! Коточкыч хәл!..

Бер имза куйдырту өчен төн уртасында пычрак ярдыртуларына өстәлеп, әрнү, гарьләнү тойгысы күп төннәргә Нурисламның йокысын алды, йөрәгенә чәнечкеле чыбык аша мәңге төзәлмәс яра ясады.

Атналар, айлар үткәндер (көннәр исәбе күптән югалды), Нурислам тормышында үзгәреш-фәлән күренмәде. Һаман шул кәбестә пары. Аннары бет чүпләү. Отыры ябыкты, хәлсезләнде. Баштарак, ике атлам уңга, өч атлам сулга, иртәнге аштан соң кечке поверкага хәтле дүртәр-бишәр йөз әйләнеш ясый иде, соңгы көннәрне инде йөзгә дә тутыра алмый. Хәле бетә, аяклары җилсенгән, оча сөяге сызлый. Җитмәсә, гомер булмаган хәл, күз алдында төрле-төрле куркыныч сурәт-чаткылар сикерешә, башы әйләнә иде.

Беркөнне кәбестә баландасын чүмереп бетерүгә — камера ишеге ябылмаган да иде әле — кече лейтенант керде. «Те», «Таһиров Нурислам»

сүзләре әйтелгәч, кече лейтенант аны төрмә ишегалдына алып чыкты. Андагы аклык, андагы аклы-ык! Бу илаһи аклыктан егетнең күзләре чагылды, учлары белән ул йөзен каплап хәтсез басып торды. Башы әйләнә башлады. Кече лейтенант әйди, ә ул, исерек кешедәй, алпан-тилпән килә. Нурисламның бу рәвешле атлавы лейтенантка ошамады, җикеренергә тотынды:

— Син, тоткын, конвой астында. Туры атла. Юкса бер адым — уңга, бер адым — сулга чык, искәртеп тормыйча атып үтерәчәкмен!

Шулчак, кайдан килеп чыкты да ничек пәйда булды диген — майор Темляков тавышын ишеткәндәй булды Нурислам.

— Нәрсә, кече лейтенант, симулянтланамы? Атам дисең икән, ат син аны. Хакың бар... Ба-а-а, кара син, Таһиров икән ләбаса! Димәк, син әле һаман исән? Һаман әле безнең өлешкә дигән һаваны сулыйсың, ә?!

Сорау алгандагы кебек, тагын мыскыллап көлә Темляков. Майорның бу сүзләрен ишеткәнче, бер мизгелдә кече лейтенант пулясыннан үлем алу кулайрак түгелме? Нурислам бөтен ачуын чыгарып:

— Беләсеңме син кем, Темляков? Син бит!.. Ас! Аттыр! Тик белеп кал. Барыбызны да атып бетерә алмассың. Гомерең җитмәс. Китте-е-ек! — дип кычкырды да янга ташланды. Ташланды, әмма ерак китә алмады. Ату тавышы да яңгырамады. Гөрселдәп йомшак карга ауды. Темляков аяк чалып еккан икән. Шунда тагын бер кат аның тавышын ишетте. Әйтерсең, һичнинди күңелсез вакыйга булмады, Темляков тыныч тавыш белән:

— Аз гына көтеп тор, кече лейтенант, ярдәмгә солдатлар чыгарырмын,— дип, китеп барды.

Күп тә үтмәде, ике солдат килде. Алар, Нурисламны култыгыннан эләктереп, кече лейтенант озатуында каядыр алып киттеләр. Еракка түгел икән, ике квартал урам үтүләренә — Нурисламның күзләре яктыга күнегә башлаган иде инде — биек капкалы, биек таш коймалы икенче бер төрмәгә илтеп керттеләр. Өч катлы мәһабәт бина. Хәлсез Таһировны яртылаш култыклап, яртылаш сөйрәп, шуның өченче катына менгерделәр дә, бер ишекне ачып... юк, кертмәделәр, ә ябылганда гәүдәне ишек үзе этеп кертте. Хәлсез егет, тигезлеген җуеп, ниндидер кешеләр өстенә ауды. Алар барысы да, берсе икенчесенә елышып, идәнгә утырганнар иде. Аларның каралган йөз-чырайларын җирән, ак сакал-мыек баскан. Чәчләре чәч түгел — пумала. Күпләре трусиктан яки эчке ыштаннан гына, күпләре шәүләгә тартым — төссез. Мондагы сасылык! Мондагы әшәке ис! Ул ис Нурисламга шулхәтле көчле тәэсир итте ки, чак кына косып җибәрмәде.

Аңа торып басарга булыштылар.

Бу мәхшәрне күздән кичереп чыкты Нурислам. Моңарчы ул утырган камера-капка охшамаган олы зал. Тәрәзәләре дә бар. Ләкин берсе дә пыялаланмаган. Кышкы җил үтәли исеп, кешеләр өстенә кар тутыра. Шуңадыр күрәсең, ишек катындагылар ярым шәрә утырсалар, тәрәзә янындагылар тун-толыптан, бүректән. Шул җылы киемлеләрнең берсе — калын йон фуфайка кигәне — аяк басып, Нурисламга бәрхет тавыш белән поляк телендә эндәште:

— Кем? Каян?..

Нурисламның җавабы русча яңгырагач, саф шул телдә: «Кил бирегә!» — диде. Нурислам аңа буйсынып, тезелеп утырган кешеләр арасыннан үрмәләп, шуышып, ничек кирәк алай янына барып җитте. Бәрхет тавышлы адәм аңа, тәрәзәдән ишеккә таба дүртенче кеше итеп, ян стена буеннан урын бирде. Ачлыктан интеккәнлеге йөзенә чыккан егетнең кулына сохари кисәкләре тоттырды. Нурислам сохарины комсыз бер ләззәт белән шытырдатып чәйни-чәйни камера эчен кызыксынып күзәтүен туктатмады. Монда тәртип шундый икән: җылы киемле берәү аякларын сузып аркасын түр стенага терәп утыра. Аның бот арасына икенче берәү, аныкы арасына өченчесе, дүртенчесе урнаша... Каршы стена ягын-

нан да шундый ук рәт килә. Бу ике рәт зал уртасында тоташа, һәръяктан соңгы кешеләр күзгә-күз карап, тезгә-тез терәп утыралар. Мондый капма-каршы урнашкан рәтләр саны камерада унике. Һәр пар рәттә унбиш-уналты кеше булса, җәмгысы камерадагы кешеләр саны йөз җитмеш, йөз сиксән дигән сүз. Эчтән генә арифметика белән шөгыльләнеп хисаплап чыгарган санны мыегына урап куйды Нурислам. Бу камера тук. Почмак саен, идәннән алып түшәмгә кадәр капчык-төенчекләр өелгән. Аларда, һичшиксез, ипи, сохари кебек ризыклар бардыр. Тәмәке исе дә сизелә. Мондагыларның барысы да җирле халык — белорус, поляк, күрәсең, сөйләшү-аңлашулары, үзләре әйтмешли, «тутэйний» телдә — җирле диалектта бара.

Шулай итеп, Нурислам үзенең кая, кемнәр арасына килеп эләгүен аңышкандай булды. Ләкин ул елның кай вакыты икәнен тәгаен генә белми иде әле. Шуны ачыклау максаты белән, янына чакырып алган йон фуфайкалыга мөрәҗәгать итте:

— Кичерегез, иптәш, бер соравым бар иде.

— Рәхим итегез.

— Бүген кай елның ае, кай көне дигәндәй...

Фуфайкалы бу сораудан бер мәлгә сәерсенеп калса да егетнең хәләтен тиз аңлады.

— Ә-ә-ә, вакытмы! Бүген, иптәш, егерме сигезенче декабрь. Моннан өч көн элек католиклар рождествосы булган иде, өч көннән яңа — кырык бишенче ел, олы өметләр елы башлана.

— Рәхмәт, туган — диде Нурислам. «Димәк одиночкада туксан җиде көн утырып чыкканмын», — дип, эчтән нәтиҗә ясап куйды.

Шушы мәхшәрдә яшәп китте Нурислам. Көн артыннан көн, ай артыннан ай үтә торды. Сорау алырга чакырмадылар. Үзе янына чакыртып алган кеше Илья Максимович Малько белән якыннан танышып, аңа тәмам ияләште. Үз гомерендә Америка илләрен йөреп чыккан йомшак табигатьле, әйбәт холыклы, үтә шәфкатьле белорус иде ул. Көче-кодрәте, ихтыяры да Аллага шөкер икән, мең мирдән торган камераны бер йодрыкта тота белә.

Таһиров — совет партизаны, командир. Бу турыда камерага эләккәч үк белделәр. Арадан кемнәрдер аңа каршы сугышкан булып чыкты. Совет властена каршы корал күтәргән буржуаз Польша яклы егетләр. Үзләре әйткәнчә: жолнежлар[1]. Шуларның берничәсе Нурислам камерага кертелгән көннән үк, читлектәге бүреләр шикелле, карашлары белән аны ашардай булып утырганнар иде, бер төнне өстенә үк ташландылар. Берсе бугазыннан эләктереп алды. Нурисламның йокыга китә алмыйча яткан чагы иде бу. Ялт кына кубарылып басты да бугазына ябышкан бәндәнең иягенә сылады:

— Мә сиңа, чүл бүресе!

Тавыш купты. Илья Максимович уянды һәм, бер талпыну белән, әлеге бәндәне әллә кая чөеп ыргытты. Шулай итеп, Нурисламны үлемнән алып калды.

Илья Максимович физик яктан гына түгел, ипле сүз белән дә ышандыру көченә ия иде.

— Сез бит террористлар түгел, панове, ә политик көрәшчеләр. Ул совет патриоты дип, үзегез белән бер үк язмышка тарыган белемле татарга ташлану, аны буып үтерергә җыену, миңа калса, сезгә дан өстәми. Советлар системасына каршы корал күтәрү хәтлесе сезнең вөҗдан эше. Миколайчик[2] Польшасы өчен көрәшергә, шул юлда җан бирергә дә риза, дип ант иткәнсез икән, анысына да тел-теш тидермим. Әмма татар татарны, рус русны, әйтик, поляк полякны буа башласа, кешелек

---

[1] Жолнеж — солдат *(полякча)*.

[2] Миколайчик — буржуаз Польшаның эмиграциядәге хөкүмәт башлыгы.

кая барып чыгар?! — дип, үзенең хаклыгына тирән ышаныч белән әйтелгән сүзләре масаюлы жолнежларны уйга салды. Ни хикмәттер, шуннан соң Нурисламга кагылучы, янаучы булмады.

Камерада үләт зәхмәте — тиф таралды. Өч-дүрт көн үтте микән, тоткыннарның яртысы диярлек, ярып ыргыткан утын түмәрләре шикелле, кайсы кайда аркылы-торкылы яталар иде инде. Тик аерма шунда гына, түмәрләр тораташ булса, болар хәрәкәттә — селкенәләр, саташалар, ыңгырашалар иде. Нәкъ фашист лагерьларындагы кебек. Анда да һәр авыру үзенең ана телендә алмашына-саташа иде, монда да шулай. Рус, белорус, поляк, литва телләрендә «Су!», «Су!» — дип кычкыралар, инәлеп ялваралар. Әти-әниләренең, якын туганнарының исемнәрен атыйлар. «Хәбәрсез югалырга, үләргә бирмәгез... Халкыбызга җиткерегез, ярдәмгә килсеннәр!.. Бөтен илләргә хәбәр таратсыннар!..» — дигән боерулары, үтенү-ялварулары Нурисламның йөрәген тетрәтә. Аякта тора алганнар туктаусыз ишекне дөмбәслиләр: «Дайте воду!.. Кацы!..[1] Сталин кац!.. Москали[2] кацы!» дип акырынулары, һич көтмәгәндә тагы: «... Еще Польска не сгинела»...[3] «Пока мы жиемо...[4]», «Марш, марш Полония...» — дип, элекке Польшаның милли гимнын җырлый башлаулары, ахыр чиктә, яшьләрен коя-коя дога кылучукынулары, мондый да тирән тәэсирләнү, шашыну-тузынуларны кичереп карамаган, бөек партия тарихына табынудан гайрене белмәгән кичәге совет студенты Нурислам Таһировта бер яктан ят тойгы уятсалар, икенче яктан ул сәбәбен үзе дә аңлап җиткерә алмаган яңа бер хистән каядыр тирәндә йөрәк түрендә нинди дер өмет сулкылдавын тоя иде.

Гүләп торган камера хәзер тәүлеккә ике тапкыр гына ачыла. Иртән олы мичкә — парашаны бушатып, хлорны известь белән агулап кертәләр, кичләрен ипи өләшенә, поверка үткәрелә. Элегрәк иртәнге якта, консерва банкалары белән җылы су, ә көндезләрен баланда бирелә иде, хәзер алар да бетте. Имеш, хак булса, елгадан мичкә белән су ташый торган әсир немецләрне Себергә озатканнар да, ташыр кеше калмагач, төрмә сусыз утыра. Су кичтән мыскаллап кына бирелә, әҗәлгә дарудай — яртышар банка гына.

Надзирательләргә тагын бер мәшәкать өстәлде: камерадан мәетләр чыгару. Үлеме-тереме, тикшергәндәй итәләр дә, аякларыннан әләктереп, коридорга сөйриләр.

Соңгы көннәрдә тоткыннар арасында яңа гадәт таралды. Башкисәр чаяраклары сагалап торалар да, йозак чалтырап, ишек ачылуга гауга куптаралар. Надзирательләр аларга әллә ни шашынырга ирек бирми, күрәсең, тавышлары тиз басыла. Теге тоткыннар әйләнеп кермиләр, аларны каядыр илтеп олактыралар. Әмма аңа карап, коридорга ташлану хикмәтләре тукталмый, гел кабатланып тора.

Гомумән, камера бер дә тынып тормый. Чирлиләр, үләләр... Елаусыктау, җырлау, Аллага ялвару, сүгенү, дөньяны каһәрләү — барысы да яшәү белән үлем арасындагы йөрәкләр тибешенә сыйган.

Көннәрнең берсендә Нурисламның коткаручысы, аркадашы Илья Максимович та ауды. Яна, саташа, бар сораганы — су. Көн ката, төн ката Нурислам тәрәзәгә кунган саран кар бөртекләрен җыя, чүпрәк юешли. Шуның белән хастаның иренен чылата, чүпрәкне маңгаена куя.

Бер тапкыр, иртәнге якта ишек ачылгач, коридор надзирателенең йөреш-кыланышына, кыяфәтенә карап, Нурислам: «Бу бәндә татар түгел микән», — дип, юри генә ана телендә:

— Саумы, якташ! Мин Бөгелмәдән. Туган якларга хат язсаң, миннән дә сәлам әйт! — дигән иде, надзиратель сискәнеп китте, аңламагандай, читкә карап:

---

[1] Кац — палач *(полякча)*.
[2] Москаль — мәскәүле рус *(полякча)*.
[3] Не сгинела — үлмәде *(полякча)*.
[4] Жиемо — яшибез *(полякча)*.

— Һе,— диде. Һәм шуның белән үзенең татарлыгын ачты да салды. Чөнки татар гына шулай «һе» дип әйтә ала.

Нурислам өчен бу гадәти кызыксыну гына түгел иде, уйлаган уен ул бүтән үк тормышка ашырырга ниятләде. Көн уртасы якынлашканда Нурислам колагын ишеккә куйды. Аяк тавышлары якынайгач, ишек кагып, надзирательгә эндәште. Морадына ирешә бит! Кормушка ачылды. Сүз катар җай туды:

— Кичер, туганым. Тыңла. Кар алып кер, ә! Үтермә, зинһар, ә!..

Көтмәгәндә ана телендә әйтелгән бу ялвару егетне тетрәтеп ташладымы, әллә иртән ишеткән сүзләрдән соң үк камерадагы якташы турында борчыла идеме, анысын бер Алла белә, надзиратель икәнен онытып, ул, көйләнгән автомат диярсең, саф татар телендә ычкындырды:

— Ничек инде?!

Нурисламга аның шушылай саф татарча эндәшүе генә кирәк иде дә:

— Бик ансат, туганым. Мә! — дип ул үзе белән йөртә торган плащ-палатканы күз ачып йомганчы кормушка тишегенә тыкты.

Чигенер чара калмаган иде надзирательгә. Алды, кормушканы шундук ябып та куйды.

Билгесезлектән дә яман нәрсә юк, көтә-көтә күпмедер вакыт үткәч, Нурислам хафага калды. Ике нәрсә борчый иде аны. Берсе — плащ-палатка. Соңгы киеме — соңгы бөркәнчеге. Икенчедән — якташы. Плащ-палаткага төрелгән кар белән эләгә-нитә калса, кемгә дә ачык, контр белән бәйләнешкә кергәне өчен аңа — төрмә яный. «Уйламыйчарак эшләдем. Егетне кыен хәлдә калдырдым бугай»,— дип үз-үзен битәрләп торганда, ишек тавышсыз гына ачылды да, мендәр хәтле булып кабарган плащ-палатка очып керде. Ишек шапылдап ябылды. Надзиратель чырае кормушкада:

— Үзең эләккәнсең — җиткән. Мине дә бутама! Әнә, ал! Бүтән теңкәмә тимә. Синең өчен мин юк!

Бөтенесеннән дә элек Илья Максимович өчен дип тырышкан иде Нурислам. Ләкин кар аңа файда китерә алмады. Туйганчы су эчәргә аңа тәкъдирдә язмаган икән шул. Соң иде инде. Нурислам өчен тормыш юлында очраган игелекле җаннарның тагын берсен югалту иде бу.

Аяныч хәл. Ә кар суын эчкән хасталар арасыннан шактые терелеп, аякка басты. Шундыйлардан берсе, баштан Нурисламны өзгәләп ташларга җыенган Станислав атлы Польша җолнежы иде. Тора бара ул Илья Максимовичны алыштырырлык дәрәҗәдә аңа якынайды. Вилейка каласыннан икән үзе. Атнага бер аңа өйдә пешкән ипи, кабыклы бәрәңге, киптерелгән эремчек-сыр кебек тәмле ризыклар кертәләр, бу нигъмәттән ул Нурисламга да өлеш чыгара, тәмәкене дә бергәләп тарта торган булдылар.

Тышта чыпчыкларның дәртле чыркылдашкан авазлары ишетелә — яз килә. Кичкә авышкан якты кояш нуры пыяласыз тәрәзә уемы аша үтеп, каршы стенага төшә, андагы серле шәүләләр уйнаклавына карап Нурисламның хис-тойгылары уяна. Җанны кысып торган бу таш стеналарны этәреп табигатькә чыгасы, кырлар куенында бер онытыласы, ак болытларга багып җирдә ауныйсы, урманнарга кереп адашасы килә. Их, кодрәтеннән килсә, кош булып, газиз туган ягы — әрәмәле, баланлы, бөрлегәнле Ык буйларына очып кайтыр иде. Булмый шул, булмый. Калын төрмә диварлары иреген буып, җанын кысып, каймалап алган.

Текә, авыш эшләнгән тәрәзә төпләре шактый биектә. Тышка карыйм дисәң, башта берәр кешене бөкрәйтеп, аның аркасына басарга, үрелеп тимер рәшәткәгә тотынырга кирәк.

Стас Нурислам кебек үк тиктормас егет. Әллә инде тифтән шулай җиңеләеп калган, сүз сөрешендә, хәрәкәт-кыланышында тиле-милелек бар. Бер карасаң, боегып-уйланып ясиә үзалдына моңланып утыра да, кинәт калкынып, Нурисламга ым кага, тәрәзә турына барып бөкерәя. Тышкы дөньяны күзләргә дисәң, Нурисламга куш. Ул көнне дә шулай,

Нурислам Стасның сыртына җиңел генә менеп басты да, үрелеп рәшәткәгә тотынды. Яңа килгән кара каргалар, чыпчыклар чыркылдашуыннан хозурланып, ул гөрләвекле урамнарга, тимер юл вокзалына, еракта күгелҗемләнеп күренгән урманнарга йотлыгып карап торды. Күңеле тулды. Рәшәткә артында тормыш бара, яз тантана итә иде. Бу манзараның һәр сызыгын күңеленә беркетеп, аяклары тала башлагач, төшәр алдыннан ул төрмә ишегалдына күз салды. Йә, Хода! Күзенә генә күренәме?.. Мәетләр, адәм скелетлары түгелме соң бу?! Шәрә, ярымшәрә мәетләр! Төрмә дивары буена әрдәнәләп тезгәннәр. Мәетләрнең аяк очында офицерлар кайнаша: полковник, майор кебек дәрәҗәдәгеләре дә бар, алар янәшәсендә ак халатлы табиблар да күренә.

Бу күренештән өнсез калган Нурислам идәнгә сикереп төште. Чират — Стасныкы. Рәшәткәгә ул менеп тотынды. Күпме генә карап торгандыр, атылып төште дә, алагаем сүгенә башлады.

— Пся кревь прусак! Пся кревь москаль! Бичара поляк ике ерткыч арасында. Алар сугыша. Курва мать! Карагыз, күрәсегез килсә! — Стас куллары белән ишарәләр ясап, тышка күрсәтте.— Анда күпме безнең туганнар! Аларны бит прусаклар үтергән. Төрмә ишегалдына күмгәннәр дә, хәзер, москальләр дөнья халкы алдында яхшы күренергә тырышып, җирдән казып алганнар. Күрегез, янәсе, фашистлар полякларга карата нинди кансызлар, ә без — москальләр, нинди мәрхәмәтле! Ә үзләре полякларны төрмәдә черетәләр, меңәрләп-меңәрләп себер сөрәләр. Ой, син аларны, пся кревь москальләрне! Хәерчеләр! Хәзер мин беләм... Хәзер мин нишләргә икәнен беләм. Курва мать! — Стас ярсыганнан-ярсый барып, ишеккә ташланды. Ике куллап дөмбәсләргә тотынды:— Ач, пердун! Ач дим мин сиңа, бетле большевик! Сасы коммунист! Комсомол, пионер, октябрят! Пся кревь...

Егетнең бөтен тәне калтырый, җилкәсенә төшкән калын чәчләре калтырап дулкынлана, күзләре калайланып, куркыныч ялтырый иде.

Гөнаһ шомлыгына күрә, ул арада ишек ачылды, Стас кыргый мәче кебек, ишектә беренче күренгән офицер өстенә ташланды. Төбенә кадәр ачык калган ишектән барысы да ачык күренә. Коридорда сүгенү, көрәштарткалаш купты. Әнә, таза гәүдәле офицер тифтән терелеп тә җитмәгән хәлсез Стасны болгап кына ыргытты. Әнә кулларын артка каера башлады... Ул да булмады, камерадагы тоткыннар арасыннан Стасның милләттәшләре атылып чыгып, офицер өстенә ташландылар. Бераздан ишек ябылды, тавышлар тынды. Стасны һәм аның артыннан чыккан иптәшләрен камерага кабат кайтармадылар.

## IV

— Әйберләрегезне алып чыгыгыз! Тиз кыланыгыз!

Мондый ашыгыч җыенуларга күнекмәгән тоткыннар, башта югалыбрак калганнар иде, аннары нәрсәгәдер өметләнеп, дәррәү җыендылар да коридорга чыгып бастылар. Иң алда Таһиров. Чөнки аның, бүтәннәр кебек, төенчек-капчыклар белән әвәрә киләсе юк. Бар алганы, бар күтәргәне шул: әлеге дә баягы бер плащпалатка.

Тоткыннарны подвалга алып төштеләр. Мунча рәвешенә китерелгән подвал булып чыкты ул.

— Чишенергә!

Тоткыннар анадан тума чишенгәч, нинди өс киеме, нинди сәләмә чүпрәк бар — һәммәсен җыештырып, бет өтәли торган камерага озату өчен ыргакларга элдерделәр. Тоткыннарның чәчен, сакал-мыегын, тәненең кай төшендә чәч-төк үсә, шуларны бөртекләп машинка белән кыркып төшергәч, ул урыннарны сасы сыекчага манылган мамык белән сөртеп агулап чыктылар (өч кеше кырка, берәү агулап тора). Бусы да беткәч

инде, тоткыннарга калай лəгəн, чиклəвек хəтле генə сабын кисəге тоттырып, юыну бүлмəсенə кудылар.

Мунча. Əй андагы рəхəтлек! Эссе һава, кайнар пар Нурисламның күпме кыйналган, бəрелгəн-сугылган сөяклəрен, җиде ай буена керлəнеп, бет кимерə килгəн тəнен рəхəт кыздыра. Бу лəззəткə түзə алмыйча, өтəлəнеп, ул аркасын, түшен, ботларын кытыршы кирпеч стенага ышкый. «Их, булсачы шушында берəр себерке аламасы, бөтен тəнем пешеплəр чыкканчы чабыныр идем дə таш идəнгə таралып ятар идем».

Шушы көннəргə калыр диеп уйлаган идемени соң ул. Тəрəзə кашагаларына чүплəм сөлгелəр элентəн, күпереп торган мендəрлəргə ак челтəр ябылган, ишек башына изге дога язылган шамаил куелган, бисмиллалы мөселман өендə туып үскəн малай иде бит ул. Атна саен мунча кереп, яңадан туып чыгарга күнеккəн, тəһарəтле, чиста-керсез гаилəдə тəрбия алган иде ул. Кешене менə ничек хайваннан түбəн дəрəҗəгə төшереп, яшəү рəвешен изеп-таптап була икəн. Моңа кем гаепле? Нурислам моны җаны белəн тоя, əмма сүзлəр белəн аңлатып бирерлек акыл кодрəтенə ирешмəгəн иде əле. Соңыннан, дистə еллар үткəч, ачы бер хакыйкатьне төшенер ул: бу коточкыч империяне тудыру өчен, ничə гасырлар буена кешене чүп урынына да күрмичə, сугыш машинасы эшлəп торган. Бер кешенең бəргəлəнүе нəрсə ул — иллəр, җирлəр, халыклар тапталган, туфрак булган. Бəлки, кайсыдыр кавемнəргə шулай изелеп, пычракка батып яшəү ошыйдыр. Ə ул мөселман өммəтеннəн, аның Аллага, кояшка, җир-суга табынып, табигатькə күндəм ярашып, итагатьле яшисе килə...

Чарасызлыктан əрнеп, шул ук вакытта эссе пардан изрəп, үзен-үзе таш диварга ышкыган Нурислам кайнар пар белəн озак хозурлана алмады. Тиз тоттылар. Киенү ягына чыгарга тупас əмер бирелде.

Кызган киемнəрдəн борынга əшəке ис бəрə иде. Гадəти тормышта яшəгəн кеше андый ис барын белмидер. Тынга каплана, укшыта торган коточкыч яман ис. Дөньяга афəт килгəндə үрчи торган хəшəрəт бет армиясе яныл куырылганда чыга торган ис ул.

Ач күзеңне, төрмə бу! Күңелем болгана, дип назланып тора алмыйсың. Нурисламның немецтəн калган трофей бəйлəм ыштаны, бəйлəм күлмəге яртылаш көйгəн булып чыкты. Җитмəсə, кесəлəрен майор Темляков умырып төшергəн мундирының да бер җиңе күгəрек тимер төсе алган. Кул белəн кагылуга, көлгə əверелеп, коелып төште.

— Таһиров!

— Мин.

— Исемең?

— Нурислам.

— Киенеп беттеңме? Киттек! — Надзиратель аның ялгызын гына алып, мунчадан ерак та түгел бер бинаның аскы каттагы камерасына ябып куйды.

Камера эчке төрмə одиночкасы кебек үк цемент идəнле иде. Аерымлыгы шул: тышка караган тəрəзəсе бар. Лəкин шунысы яман, ятар, утырыр өчен топчан, урындык ише берни дə юк. Шып-шыр идəн.

Шул көнне үк, күпмедер вакыт үткəч, тагын бер бəндəне керттелəр. Чал башлы. Өс-кыяфəте дə, киеменнəн аңкыган яман да таныш исеннəн дə аның əле генə теге мунчадан чыкканын белеп була иде.

Фамилиясе Заря, миллəте белəн поляк икəн. Үткəн тормышы турында: «Чемоданнарымны чемодан ясап тутыра идем», — дип шаярта. Агачтан өй җиһазлары ясау остасы, янəсе, тамагын сандык-чемодан ясап туйдырган. Лəкин Нурислам аның бу сүзлəренə ышанмады. Саф рус телендə шома сөйлəшүе, бирчəймəгəн, сөяллəнмəгəн җыйнак куллары аның акыл хезмəте белəн шөгыльлəнүче зыялы кеше икəне турында əйтеп тора иде.

Кич булды. Керфеклəр авырайды. Лəкин җылы күрмəгəн бетон камераның шəрə идəненə ничек ятасың да, ничек йокыга китəсең, ди?

Җитмәсә, мунча кереп, тиреләрне юкартып чыккан көн. Нурислам, шушы турыда уйланып, нишләргә белми торган арада, поляк Заря бар мөлкәтен — буш арыш капчыгы һәм өстендәге кыска чикмәнен — идәнгә җәеп салды да сузылып ятты.

— Сез дә авыгыз, партизан. Аркагыз белән куеныма керегез. Кысылырбыз. Плащ-палатканы — өскә ябыгыз. Бераз яткач инде, минем арка туңа башлагач, бергәләп, икенче якка борылып ятарбыз. Шулай итсәк, сезнең җылы миңа, минем җылы — сезгә күчәр, уртак җылы икебезгә дә җитәр, шулай бит...

Нурислам, ул кушканча, аркасы белән аның куенына кереп оялаган иде, гел ярап куйды. Икенче ягына борылып ятканчы, шактый ара йоклап та алды.

Төннәр шулай уйдык-уйдык йоклап үтә, көндезен аяк өстендә — сөйләшү, бәхәс. Кузгатып җибәрүче, гадәттә, Заря була.

— Сез, хөрмәтле татар, бу поляк тупас сүзле, димәгез. Рәнҗемәгез дә. Безнең хәлдә дипломатларча комплиментлар әйтешеп торырга җай юк. Турыдан бәрәләр. Йә булмаса, баштан ук якадан алыша, чәкәләшә башлыйлар. Уйлап кына карагыз әле: рус белән герман үзара нәрсә кылаларнар, ә? Дүрт ел бит инде, чәкәләшүдән һаман туктарга исәпләре юк. Икесе дә сыңар аяклары белән кабердә, югыйсә, алай да туктату турында уйламыйлар. Үзләре генә үтерешсәләр бер хәл иде, бер басылырлар, тынарлар, дияр идең. Юк, каһәр суккырлары, үзләре генә түгел бит. Әйтик, немец мадьярны, румынны вә дә бүтән милләтләрне ияртеән, ә рус үзенең чабаталы мужигы белән аралаштырып, горур Кафтау кешеләрен, мәхлук татарны, Урта Азия мөселманнарын куа. Нәтиҗәдә, гөнаһсызлар каны коела. Әйтик, менә сез үзегез, кырык беренче елдан бирле тәмуг утында, дисез. Нигә кердегез сез ул утка?! Әлбәттә, үз ихтыярыгыз белән түгел. Әлбәттә, рус мәҗбүри кертте. Нигә? Һаман бер сүз: әлбәттә, Германга каршы торырга. Ләкин дә бит сез анда герман солдатын гына үтермәдегез. Сез аткан пуля мадьяр, румын, чех, словак, австралияне дә әйләнеп үтмәгәндер, шөт. Бер очтан полякка да эләккәндер, шулай бит...

— Сез дөрес сөйләмисез, пан. Мине Көнбатыш чигенә немец, мадъяр, чех яисә бүтән берәүләрне үтерергә дип җибәрмәделәр. Минем кебек миллионнардан торган Кызыл Армиянең бурычы социалистик Ватанны фашист агрессиясеннән саклау иде. Шулай булгач, минем бурыч, кеше үтерү түгел, ә ил саклау була түгелме? Инде килеп кемдер минем социалистик Ватаныма басып кергән икән, сакчы буларак, мин аны тотып богауларга, буйсынмаса атып үтерергә мәҗбүр. Чөнки барча халыклар да үз илләрен сакларга тиеш, диалектика шулай.

— Менә ничек!.. Логикагыз дөрес, әлбәттә. Бик матур сүзләр. Ә шулай да... Нәрсә соң ул социалистик ватан?

— Җә инде, шаяртма. Мин бала түгел ич. Сүз, әлбәттә, Советлар Союзы — СССР турында бара.

— Әйе, хөрмәтлем. Сез бала түгел. Әмма социал аңыгыз түбән баскычта калган. Сездә Кеше дип атала торган затка хас мөстәкыйльлек, хөр хисләр юк. Руслар сездә кол психологиясе тәрбияләгән. Кол булып тугансыз, кол булып үсеп җитлеккәнсез. Шуңа күрә рус ни кушса, шуны эшләп, ни сораса, ни таләп итсә, шуны биреп, аның алдында баш иеп яшәргә өйрәнгәнсез. Сезнең өстән идарә итеп бары тик рус кешесе торырга тиеш, сез шуңа күнеккәнсез. Үз арагыздан берәрегезнең эшлекле, олы шәхес булып китүенә ышана алмыйсыз. Күзгә бәреп әйткәндә шул: кешелек җәмгыятендә тоткан урыныгыз белән борынгы Рим колларыннан күпкә түбәнсез. Халкыгызның Спартак кебек батыр зат үстерә алуы икеле. Аяныч, үтә аяныч хәл. Юкса бит татар кайчандыр...

Үзен ни хәтле сабыр тотарга тырышмасын, Нурислам булдыра алмады, полякны ярты юлда бүлеп кычкырды:

— Җитте, пан!! Син мине мыскыл итәсең! Күрәләтә көләсең! Вөҗданыма басасың!..

— Чур, хөрмәтлем, чур! Ярсымагыз! Башлаган фикеремне әйтеп бетерим. Вакыт җитәрлек, сез дә сөйләрсез. Хәзергә миңа ирек бирегез. Шулай, башта куелган соравымны кабатлыйм: нәрсә ул Советлар Союзы? Социалистик ватан? Үзем үк җавап бирәм. Шүл үк Октябрь алмашынуларына кадәр хакимлек иткән Россия империясе ул, дускаем. Тик өстенә ялганын каплау өчен ялтыравык җиләнен генә кигән. Бусы — сезнең кебек беркатлы мәхлукларны кызыктыру өчен. Әмма сарык тиресе ябындырып кына бүрене сарыкка әверелдереп булмаган кебек, илен Сесесер дип атау белән генә Россия империясе үзгәрмәде. Чөнки гасырлар буе тәрбияләнеп килгән бөекдержавачыл шовинизм психологиясе — һаман шул, күрше халыкларны талау, аларны юк итү, юлбасар психологиясе калды һәм ул дәвам итә.

— Ялган! Яла! Син, пан, буш сүз сөйләмә миңа. Һәр фикереңне нигезләп әйт. Һәр сүзеңне исбатлап бир.

— Ә-ә-ә, исбатларгамы! Рәхим итегез, хөрмәтлем. Тыңлагыз алайса. Соңгы елларда гына Россия Бессарабияне, Балтик буе дәүләтләрен, Польшаның бер өлешен, Монголияне басып алдымы? Алды. Бу сугыштан соң тагын да киңәергә чамалый әле.

— Әлбәттә, киңәер. Чөнки Советлар Союзы фашист Германиясен тар-мар итеп, бөтен Европаны фашист тырнагыннан коткарып бара. Шуның белән ул үзенең тормышка сәләтлелеген һәм череп бара торган империализмнан өстенлеген дә күрсәтәчәк. Моның шулай икәнлеген аңлаган һәр халык, әйтик, Польша, Чехословакия, Румыния, Австрия халыклары, сугыштан соңгы үзгәреш-корылышлар вакытында социализм юлын, социалистик системаны сайлаячаклар. Бу хәтлесе көн кебек ачык.

Күзләреннән яше чыкканчы көлде Заря. Эре, сәламәт, ак тешләрен ялтыратып көлде.

— Хурланма, кимсенмә, татарым. Тагын да тупасрак сүзләр әйтәм: гипнозланып, шуннан айнымый калган хаста хәлендә сез. Хаста һәм куркыныч томана. Бу сугышта Россия җиңми. Аның хәзер җиңәм диеп Берлинны алырга ашыгуы — яралангач, өенә качарга ашыккан ерткычны хәтерләткән Гитлерның итәгенә ябышып бару гына. Ул да хәлсез. Ул да үлем алдында. Монда, бу сугышта, Россия җиңми, Америка, Англия, Франция җиңә, дускай. Белегез, Россия Берлинны аламы ул, алмыймы, җиңүчеләр арасында ул булмаячак. Әмма җиңүче илләр вакытлыча аның белән исәпләшәчәкләр. Чөнки Россия коточкыч нык коралланган. Халкы ач-ялангач дип тормый, бар тапканын самолетка, танкка, пушкага әйләндерә бара һәм бу ягы белән ул котырган ерткычны хәтерләтә. Җайлы-җайсыз матапсаң, эләктереп алуы, өзгәләп ыргытуы бар. Шуңа күрә, прошу пана, хәзергә аның белән исәпләшәләр...

Россиянең шушындый куркыныч империя булуы турында Уинстон Черчилль онытгысызынчы елны ук нәрсә дигән: «Ач һәм шәрә Россия караңгы төнне шыксыз өендә, суык мич башында, үзенең күршесен суярга дип, бритва кайрап утыра».

— Беләсеңме син кем, Заря әфәнде! Син... Син, буржуазиянең коткыга бай, акылга сай пропагандисты. Ләкин мине — бөек Сталин тәгълиматлары нигезендә үсеп ныгыган совет укытучысын мондый пропаганда белән юлдан яздыра алмассың. Совет укытучысы кайда да, кем каршысында да совет укытучысы булып калачак. Әйтергә кирәк, сугышчан агитатор.

— Мин сезнең фикергә каршы чыкмыйм, хөрмәтле укытучым. Бу уңайдан бер фикер генә әйтәм. Ул да булса, Сталинга кагыла торганы. Бөек Сталин дидегез. Әйе, ул бөек. Әмма, үзен күрсәтергә тырышканча, бөек юлбашчы да, халыклар атасы да була алырлык әхлак иясе түгел, ә бөек интриган. Һәм хәзерге чор рус империясенең бөек ялчысы, бөек палачы. Ге-Пе-У, Эн-Ке-Ве-Де төзеп, үтерүчеләр өерен оештыручы залим. Руслар аның каисызлыгын корал итеп, шул корал белән тарих

биеклегеннән караганда какшый, таркала башлаган империяләрен нытыгырга чамалыйлар... Сугышчан агитатор дидегезме әле? Бусына каршы килмим. Шулай калыгыз. Максим Горький: «Шуышырга туган оча алмый», дигән. Һәр идиот — үзенчә идиот. Җаны теләгән — җылан ите ашаган. Тудырып үстергән ата-анагыз каһәрләмәсен... Мин үзем дә милләтем-халкым турында шулай уйлыйм: полякларның күпчелеге социализм дигән нәрсәне кабул итмәячәк. Читтән килгән күрсәтмәләргә буйсынмаячак. Минем халкымның үз тарихы, үз уе, үз юлы бар. Ул үзенчә яшәргә, үзенчә көн күрергә тели. Төрле «изм»нар аны кызыксындырмый, ул җир эшкәртү, күмер чыгару, заводлар корып, аларда тыныч кына эшләү, яшәү, сөю, бала үстерү турында хыяллана. Хөрлек турында хыяллана. Чөнки Польша рус тырнагыннан ычкынып, егерме ел гына булса да үзенчә яшәп, азатлык тәмен татып карады.

Бәхәс соңы ни белән бетәсе булгандыр, шул мәлдә шыгырдап ишек ачылып, надзиратель кычкырды:

— Таһиров?!

— Мин.

— Чыгарга! Тиз!

Заря камерада калды. Нурисламны каядыр алып киттеләр.

Тышта карлар эреп бетеп, чирәмнәр яшәрә башлаган чак иде. Яңгыр сибәли — җир юына. Урам буендагы тирәкләрнең тулышкан бөреләре энҗе тамчыларга төренгән, тирә-якка хуш ис сирпеп утыралар. Гамьсез чыпчыкларның ботактан-ботакка күчеп чыркылдашуында салкын кышны исән-имин чыгуларына сөенү-куаныч сизелә.

Табигатьнең үтә дә самими халәте Нурисламда тирән тойгылар уятты. Әллә инде поляк Заряның әче сүзләре дә эз калдырмый үтмәде — күзләренә яшь бәреп чыкты. Гаделлек, тигезлек, кешелеклелек, яшәеш дип атала торган бөек төшенчәләр турындагы уйларына күләгә төшерде бит әле ул. Үз халкының бәхетле икәне дә ваемсыз бер мәгънәгә әйләнгән иде. Читтән караганга яхшырак күренә микән әллә, ят бер милләт вәкиле Нурисламның күңелен актарды да салды, әллә нинди шик-шөбһәләр уятты.

Шулай уйланып атлаган Нурисламны озатучы солдат тәрәзәсенә тимер рәшәткәләр кадакланган бер йортка алып керде. Бүлмә бәләкәй, анда бер капитан гына иде.

— Ә-ә-ә, Таһиров! Килдеңме? Утыр! — дип урындык күрсәтте. — Ничек соң, камера бик ялыктырмыймы?

Шаккатты Нурислам. Нишләп әле күптәнге танышы сыман кешечә эндәшә, төчеләнә соң әле бу капитан? Башына шик төште. Юкка түгелдер бу. Алай да күрсәтелгән урынга барып утырды.

Капитан әрле-бирле йөреп тора. Кесәсеннән «Беломор» кабы чыгарып Нурисламга сузды.

— Ничек әйтәләр әле, без янганчы ул янсын диләрме, сүзгә керешкәнче кабызып бер көйрәтеп алыйк булмаса.

Капитан сузган зажигалкалдан Нурислам папирос кабызып, үпкәләре төтен белән тулганчы тирән итеп бер суырды.

— Шә-ә-әп. Күптән авызга алган юк иде.

— Ошаса кабы белән ал. Кайткач тартырсың.

— Гафу итегез, Сезнең бу юмартлыгыгыз мине сагайта, күнегелмәгән. Сез кем буласыз?

— Ә-ә-ә, менә нәрсә! Курыкма, мин сиңа зыян китерергә җыенмыйм. Синең партизан-разведчик, шул ук вакытта гадел совет патриоты икәнеңне исәпкә алып, әһем, әле ни... бер йомыш кушмакчы гына булам. Әгәр ризалык бирсәң, тамагың тук, борының төтендә булыр.

— Нинди йомыш инде ул?

— Берние дә юк анын. Кеше сөйләгәнне тыңлап, мыекка урый бару гына.

— Аңламадым, гражданин капитан.

— Беләсеңме нәрсә, Таһиров. Бу төрмәдә синең кебек туган илен яратучылар бик аздыр. Ә дошманнар — санап бетергесез. Берәүләр фашист ялчысы, икенчеләр — буржуаз милләтче, кыскасы, полягы, белорусы, литвалысы — кем генә юк. Әйтик, менә синең белән бер камерада утыра торган тип... Заря. Ничә көн бергә әле?

Капитанның тел төбен аңлады Нурислам. Ул аны әләкче, сексот итеп файдаланырга чамалый. Кинәт кенә тәртәгә тибүне кирәк тапмады Нурислам:

— Ун көн чамасы.

— Танышыр вакыт булган алайса. Үзе турында нәрсә булса да сөйләгәндер инде?..

Капитанның кыштанлану сәбәбе аңлашыла, калканы ачыла барган саен, Нурисламда нәфрәтләнү тойгысы көчәйгәннән-көчәеп йөрәк тибешләре ешая, тыны кысылгандай булды.

Капитан исә, ваемсыз кыланып, һаман үзенекен тукыды.

— Чамалыйсыңдыр, Таһиров. Миңа аның асылы кем икәнен белү кирәк. Аннары... Аннары күз күрер. Синең сәләттән тора инде...

Бу сүзләрдән соң инде, кызу канлы, гарьчел татар төрмә оҗмахы вәгъдә итәсе капитанның сайравын үткәреп җибәрә алмады, берьюлы кайнарланып, тартылган җәя киеренкелеген алды, шартлады.

— Син мине кем дип уйлыйсың, капитан?! Мин беркайда да, бер кемгә дә олтырак хезмәтен үтәмәдем. Оятсыз син! Мине бер папироска сатып алырга җыенасың,— дип, Нурислам суырылып бетмәгән утлы төпчеген капитанның чыраена ыргытты.

Бәхеткә каршы, төпчек офицерның иягенә, юеш башы белән генә барып тиде, капитан аны кагып төшерде дә Нурислам өстенә ташланды. Алай да сукмады, якасыннан каерып алып ыжгырды гына:

— Бәдбәхет син, Таһиров. Адәм актыгы! Сиңа төрмәдә черергә язган. Буш капчык! Әй, конвой!..

Нурисламны карцерга кайтарып яптылар. Көненә дүрт йөз грамм ләчтә ипи, ярты литр су. Ун тәүлек утырып чыкты...

## V

Нурислам Таһировны 1945 елның 16 апрелендә следователь янына алып бардылар. Ә ул — көз көне кулга алу турындагы прокурор санкциясенә кул куйдыртып җибәргән өлкән лейтенант икән. Фамилиясе Полянский. Темляков кебек һавалы һәм кешедән көлә торган ук булмаса да, каты бәгырьле. Нурисламга шул язганнар астына кул куярга куша. Табигый ки, Нурислам моңа каршы. Шул сәбәпле аны көннәр, кайчакларда төннәр буе бастырып тота.

Егетнең аяклары шешенде. Тубыгы, оча сөяге сызлый. Күз алдында кызыл, сары, кара... очкыннар уйнаклый. Озын, ыржайган тешле, эчкә баткан һәм акайган күзле нинди дер кеше, мәче карачкысына тартым шәүләләр куркыныч рәвештә сикереналәр, бииләр. Следователь үзе, өстәле-ние белән биек дулкыннарда тирбәлә...

Берничә тапкыр саташып идәнгә ауды, янә торып басты Нурислам. Бу интегүләрнең барысын да күреп торган Полянский исә, әйтерсең, аның каршында адәм баласы түгел, җансыз робот сыман, нинди дер язулар укуын дәвам итте.

Әмма безнең егет нинди генә авырлыклар кичермәсен, көннәр артыннан төннәр, төннәр артыннан көннәр үтә тордылар. Егерменче май көнне Полянский беркетмәнең соңгы битенә Нурисламнан кул куйдырды да, шат кыяфәттә:

— Булды бу, Таһиров. Эш бетте,— диде.

Ләкин тикшерү-сорау алулар тәгәлләнү белән генә Нурисламга җиңеллек килмәде. Камерага кайтаргач, шешенү-җилсенүләрдән арына,

янәсе, берничә тапкыр аякларын стенага куеп, ятып торган иде, шул арада цемент идән салкыны бәрдеме, иске чире яңадан уянды. Оча сөяге турысыннан тәне шешеп чыкты. Иң начары көннәр-төннәр сызлап, саташтырып, шешнең тишелүе булды. Лазаретсыз, врачсыз, даруларсыз төрмәнең барлы-юклы ләчтә ипие һәм баландасы белән бу чирне җиңеп аякка басканчы җәй үтеп китте.

— Таһиров чык. Судка барасың.

Урамга алып чыктылар. Анда, багана башына асылган репродуктордан көчле тавыш агыла. Йә, Ходай, бүген беренче сентябрь җиткән..., мәктәпләрдә укулар башланган икән бит. Укытучы өчен изге көн ич бу. Шау-шулы балалар дөньясыннан мәхрүм ителүенә чиксез рәнҗегән Нурисламның күз төпләре дымланып алды.

Вилейка шәһәренең таныш урамы. Тимер юл үтә торган көнбатыш ягы иген басуларына чыга. Шәһәрнең калган өч ягы урманга таяна. Урман култыгында — хәрби корылмалар, ерактан байлар утары сыман балкып торалар. Ике конвоир Нурисламны шунда алып бара. Чырае йончу, тәне хәлсез югыйсә Нурисламның, ә кәефе болай ярыйсы. Чөнки төрмәдән котылуына өмете уянган чагы. Сорау алулар вакытында Темляков, Полянский көчләп таккан яла-җинаятьчеләрне кире кага алса, хөкем утырышы, әлбәттә, аны яклар. Акламый диме, ил-халык алдында сабый баладай гөнаһсыз ич ул.

Әлеге, ерактан күзне иркәләп торган казарма-корылмалар арасында төрмә бинасы да бар икән. Нурисламны шуның бер камерасына илтеп керттеләр. Анда тупас такталардан кагылган шәрә өстәл янында өч офицер утыра иде. Уртада — карт майор, аның як-ягында — ике яшь лейтенант. Өстәл каршысында урындык. Нурисламга шул урындыкка утырырга куштылар. Бу — аның язмышын хәл итә торган хөкем утырышы. Офицерлар йә фәрештәләр, йә газраилләр булып чыгачак.

...— Сез илгә хыянәт итүдә гаепләнәсез,— диде майор-председатель, юка-ябык «дело»ның битләрен актаргалап утырды да Нурисламга шундый сорау бирде:— Гаебегезне таныйсызмы?

— Нинди гаеп?

— Сорауны судья куя. Кабатлап сорыйм:— Гаебегезне таныйсызмы?

— Юк. Танымыйм. Таныр гаебем юк.

— Кулга алынуның беренче көнендә дә, соңгы сорау алу вакытында да «Немец-фашистлар ягыннан үзем теләп чыктым. Максатым — Советлар Союзына каршы корал тотып сугышу иде. Партизаннарга кушылдым нәкъ шул максатымны тормышка ашыру өчен иде»,— дигәнсез. Бу сүзләрне раслыйсызмы?

— Юк, расламыйм. Аларның берсе дә минем тел белән әйтелмәде,— дип Нурислам, йөрәге туктап калудан курыккандай, кызып-кызып сөйли башлады.

— Немецлар мине әсирлеккә көчләп алдылар, дисез. Ничек булды? Шул хакта тулырак сөйләгез.

Нурислам кырык беренче елны ничек армиягә алынуы, кайчан Кремене шәһәренә барып җитүе, анда хезмәт итә башлауга чирләп госпитальдә ятып, аннан хезмәткә яраксыз дигән язу белән частька кайтуы һәм шул кайтуның икенче таңында сугыш башлануы, ул сугышка коралсыз керүе, әсиргә эләккәндә кулында коралы булмавы турында сөйләп биргәч, карт судья тагын бер сорау бирде:

— Тикшерүләр вакытында, кырык икенче елның апрелендә немецлар икенче лагерьга күчерделәр, дигәнсез. Бу дөресме?

— Дөрес.

— Шул лагерь турында сөйләгез.

— Беренче лагерьдан күпкә аерыла. Ашатулары туйганчы. Бет юк. Атна саен мунча. Өс бөтен. Корал тотарга өйрәттеләр. Россия, Германия тарихы буенча лекцияләр укыдылар. Сәяси әңгәмәләр булды. Кинофильм-

нар карадык. Әмма лагерь территориясеннән чыгып йөрергә ярамый, дисциплина каты иде.

— Димәк, хәрби лагерь. Хезмәт хакы да алгансыздыр инде алай-са?— Бу искәрмәне лейтенантларның берсе әйтте.

— Акча бирмәделәр. Әмма көненә кеше башына алты сигарет ала идек.

— Нинди сугыш кораллары өйрәнә идегез?

— Мылтык, автомат, пулемет, гранаталар.

— Ул лагерьда немецлар кемнәрне әзерләделәр? Кемгә каршы?

— Мөгаен, оккупацияләнгән районнарда немец файдасына эшләтү өчен чиновникларды.

— Ул лагерьга алганда ризалык сорадылармы?

— Сорамадылар. Мисал өчен мин утырган беренче лагерьда үлми калганнарның барысын да алдылар. Бәлки, башка лагерьлардан килгәннәр белән дә шундый ук хәл булгандыр. Әмма атна-ун көн ашатып аякка бастыргач, күбесен каядыр алып киттеләр. Әлеге лагерьда офицерлар, урта һәм югары белемле сержант-солдатлар гына калды...

Белоруссиягә кайтып, партизаннар ягына чыкканчыга хәтле күргән-кичергәннәре турында да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде Нурислам.

— Бу сөйләгәннәрегезне раслардай шаһитлар күрсәтә аласызмы?

— Күрсәтә алам. Майор Горбач һәм бер үк вакытта немецтан качкан иптәшләр. Алар да Горбач белән бер партизан бригадасында булырга тиешләр. Ләкин партизаннарга күчкәч, аларның берсен дә күргәнем булмады. Исәннәрме, сугышларда корбан булганнармы, ул хәтлесен әйтә алмыйм. Алай да майор Горбачның исән икәнен ишетеп беләм. «Железняк»та отряд командиры иде ул.

— Командирларыгыз кем иде? Әлеге икенче лагерьда диюем.

— Үзебезнең арадан әсирләр.

— Немецлар ягыннан?

— Берәү. Штурмфюрер Шпильман. Рус командирлары белән Шпильман арасында тагын берәү бар иде. Анысы Россия немцы. Иван Иванович. Фамилиясен белмим. Материаль частьны рус командирлары өйрәтсә, тарих буенча лекцияләрне, сәяси әңгәмәләрне ул алып барды. Күп белә, укымышлы иде.

Судья-майор башын уңга-сулга борып лейтенантларга карап алды. Шуннан соң аларның берсе Нурисламга сорау бирде:

— Гаепләнүче Таһиров. Сез үзебезнең армиягә каршы сугышу өчен дошман кулыннан корал — мылтык, гранаталар алгансыз. Илгә хыянәт итү түгелме бу?

— Түгел. Бердән, немец кулыннан корал алганда ул коралны Советлар Союзына каршы юнәлтермен дип мин, аңа сүз бирмәдем. Икенчедән, мәкерле дошман алдында чаялык күрсәтмичә, тегеләй ярамый, болай ярамый дип, төчекәйләнеп йөргән булсам, партизаннар ягына кайта да алмас, сугышчан характеристикамда күрсәтелгән эшләрне дә эшли алмас идем. Минем үткән юлларыма, кылган гамәлләремә бәя бирү, әхлакый, юридик яктан дөресме-хатамы, хөкем карары чыгару сезнең карамакта әлбәттә. Әмма шуны белегез: дошман кулыннан корал алып, үз коралы белән санаулы гына булса да дошманны юк итә алуым белән горурланам мин. Минем халкым «ятып үлгәнче, атып үл», ди. Бу әйтем сугышның һәр минутында да минем девизым булды.

Майор-судья лейтенантларга тагын бер кат карап алды да, алары аны-моны әйтмәгәч, Нурисламга борылды:

— Гаепләнүче Таһиров, сезгә соңгы сүз бирелә.

— Әйтер сүзем юк.

— Суд киңәшкә чыга,— дип майор урыныннан торды.

Әмма суд беркая да чыкмады, шул бүлмәдә калды. Ә менә Нурисламны күршедәге бер караңгы камерага кертеп яптылар.

Камера нинди генә булмасын, егетнең күңеле жырлый иде. Җырламый диме, ул бит озын сөйләп судьяларны ялыктырып тормыйча, фикер-дәлилләренең иң кирәклеләрен генә, йөрәкләрен эретә торганнарын гына әйтте. Игътибар белән тыңладылар. Мәкерле сораулар бирен, сүздә тотарга маташу кебек алымнары да булмады. Бу инде аны аңлаулары, акларга җыенулары дигән сүз, әлбәттә... И-и-их, акласалар, бу җәһәннәмнән коткарсалар! Туган Татарстанына кайтып киткәнче, башта күрәзәче белорус татар кызы, чибәркәй янына кереп, сорау алу газапларын нык кыйнатмыйча, имгәнмичә генә үткәреп җибәрү юлларын өйрәткәне, киләчәккә өметләр бөркеп, җанына тынычлык биргәне һәм дә олы бәхет-сөю юраганы өчен аңа ихлас күңелдән рәхмәтләрен әйтеп китәр иде...

Алда көткән азатлык хакына барын да кичерергә була. Язмышның болай борылыш алуы бер сатаһу-төш кенә булып калыр. Менә хәзер уяныр да... Аны дошманга санап шулай ничә айлар буена талкыганнары өчен ул беркемгә дә рәнҗемәс. Болгавыр чор бит, димәк, шулай кирәк. Кем, каян килеп кермәс, ачыклау, асылына төшенү зарури.

Теге чакта, ике иптәше — Харис Ишкилдин һәм Хәснетдин Асланов белән партизаннарга килеп юлыккач, ни хикмәттер озаклап тикшереп тормадылар аларны. Күрәсең, гамәлдә сынап карарга булгандыр исәпләре. Өчесен өч отделениегә билгеләделәр дә взвод белән Торгуна дигән авылда куна калдылар. Ә иртәнге якта авылга немец обозларының якынлашып килүен хәбәр иттеләр. Ике отделениегә авылның ике башына чыгарга приказ булды.

Отделение командиры, сакаллы өлкәнрәк абзыйның Нурисламны сынап каравы иде, ахрысы, ул аңа инеш аръягына чыгып позицияне сайларга кушты. Немецтан үч алырга күпме теш кайрап йөргән егет өчен моннан да уңайлы форсат булмас кебек иде, ул сай инешне бер талпынуда атлап чыкты да түгәрәк артына посты. Бераздан немецлар күренде. Алдагы арбада теркелдәп килгән кара шинельле немецны мушкага алгач, ату тавышы белән бергә Нурисламның: «Мә сиңа, палач!» — дигән җан авазы атылып чыкты. Немец арба төбенә авып төшүгә, янәшәдәгеләре, тараканнар кебек төрлесе-төрле якка чәчелделәр. Нурисламның тәтегә баскан бармагыннан бөтен тәненә күчкән калтырау бетеп, җегәр иңде. Ул гарьләнеп ата башлады. Безнекеләрдә — кул пулеметы, немецта — станоклысы. Җитмәсә, авыл өстенә туктаусыз миналар ява.

Нурислам бу атышка ничек кенә йөрәкләнеп тотынмасын, барыбер дәртен канәгатьләндерә алмады. Партизаннарның патрон ягы бик такыр икән, шушылай засададан кинәт кенә ут ачалар да, унлап патрон аткач, чигенеп, урманга кереп юк булалар икән. Тактикалары шулай.

Нурисламның патроны бихисап. Абзарларга ышыкланып ул урманга таба чигенгәндә дә күзгә ташланган немецларны мушкага ала барды. Ул урманга барып җиткәндә взвод җыелган, тик Ишкилдин генә юк иде. Карсак буйлы, борыны җәлпәк, күзе кысынкы бу Урал татарының нинди дер мөлаемлыгы бар иде. Нурислам килеп җитүгә, партизаннарның берсе:

— Сезнең теге симпатяга фрицлар ягына китеп барды бугай,— дип ычкындырды.

— Була торган хәл түгел, егетләр!

Нурислам кырыена Асланов та килеп басты. Партизаннар аларны шундук камап алдылар. Күренеп тора, коралсызландырырга исәпләре.

Хариска үзенә ышанган кебек ышанса да, эшләр болайга киткәч, Нурислам бер мәлгә үзе дә шигәя калды: «Бу дөньяда кем кемне белеп бетергән. Ни булмас та ни кылмас адәм баласы. Ләкин бу шикне белдертсәң, үзең дә бетәсең, дигән сүз. Карашлар нык булырга тиеш.

Ярый әле арага взвод командиры килеп басты. Кичә Нурислам белән бер өйдә йоклап киткәнче сөйләшеп ятканнар иде. Шилков Саша. Кызыл Армия сержанты. Кырык беренче елны камалышта калган, хәзер

менә партизан — взвод командиры. Карашлар кырыс. Күзләрендә ут. Командирның бер сүзе бу мизгелдә ут өстенә ут, ут өстенә су бөрки ала:

— Кем күрде фрицлар ягына китеп барганын?— Бу үткен сорауга туры җавап кайтаручы булмады.— Шул шул менә. Ашыгып яла якканчы ачыкларга кирәк. Кайсыгыз эзләргә бара?

Берничә партизан, шул исәптән Нурислам белән Хөснетдин дә «мин», «мин» диешеп алга чыктылар. Шилков отделение командирына приказ бирде: «Таһировтан башка янына тагын ике партизан ал да эзләп кайт. Аннары күз күрер...»

Юлга чыктылар. Ишкилдинның чиркәүгә таба чигенүен күреп калганнар икән. Шуннан соң ул күздән югалган.

Авылда немецлар булганга күрә, саклык белән генә, урман кырые буйлап авылның чиркәү урнашкан башына барып җиткәләгәнче, кояш тәбәнәкләнде. Кайда үрмәләп, кайда шуышып чиркәүгә якынлаштылар. Кич җиткәнче эзләп-эзләп та таба алмагач, отделение командиры:

— Соң, яңа партизан, нишлибез?— диде.

— Рөхсәт итсәгез, мин шушы тигәнәкле чокыр-чакырларны актарып, эзләп кайтыр идем.

— Әйдәгез, алайса бергәләп.

Нурислам сизеп тора: отделение командиры аңа ышанып бетми. Шуңа күрә «бергәләп» ди.

Әгәр Харисны тапмасалар, үзләрен агачка терәячәкләрен белә Нурислам, монысы бер хәл, иң хәтәре шул: бу вакыйга бөтен татарга карата ягылган кара булып, партизаннарның буыннан-буынга сөйләячәк гыйбрәтле риваятенә әйләнәчәк. Бусы — үлемнән дә авыррак.

Бер-берсеннән ерак ара калдырмыйча гына эзли торгач, ниһаять, Нурислам дусты Харис өстенә барып чыкты. Бичаракайның уң кулы, аяклары читкә сузылган, сул кулы белән автоматы гәүдәсе астында. Нурислам әллә нинди өметләр белән барып тотынган иде — дустының суынган, җансыз гәүдәсен тойгач, күз аллары караңгыланып китте...

Татар барда хәтәр бар икәнен сугышта раслады Нурислам. Кырык өченче елны үзенең егерме-егерме биш партизаннан торган разведка төркеме белән бер төн эчендә полустанокка үтеп, андагы дзотка оялаган унике дошман солдатын, яртылаш җиргә күмелгән вокзал бинасындагы баштанаяк коралланган унтугыз тимер юлчысын юк итеп кайту дисеңме, Глубокое гарнизонына үтеп, аннан немецның разведка капитанын урлап чыгу дисеңме... Юк, мин партизан, дип корал күтәреп йөргән өчен генә Беренче дәрәҗә партизан медале дә, Кызыл Йолдыз ордены да бирмиләр. Ә Кызыл Йолдыз орденын Белоруссиянең партизан хәрәкәте җитәкчесе, партиянең Белоруссия Үзәк Комитеты секретаре Пономаренко егетнең күкрәгенә үз куллары белән беркетеп куйды.

Партизан хәрәкәтенең иң авыр көннәрендә (кырык дүртенче елның май аенда) мең кешедән торган бригада командирының ярдәмчесе итеп Нурислам Таһировны билгеләделәр. Хәрби белеме булмаган егет өчен үзе бер дәрәҗә түгелмени?!

Шул елны Вильно шәһәрен азат иткән чакта күпме утны-суны бергә кичкән дусты Хөснетдин һәлак булды. Япа-ялгызы калды дияр идең, күрше бригадада сугышкан майор Петро Горбач исән булырга тиеш...

Нурислам алдагы бәхеткә ышанып, суд хөкемен көтеп утырган арада, үзенең кан-үлем, дан-дәрәҗә аша үткән елларын моңсуланып та горурланып та искә алды.

Судья, карарны укыганнан соң, Темляков кебек майорларның явызлыгы өчен, сәбәпсезгә шундый кешене төрмәгә тыгулары өчен Нурисламнан гафу үтенер микән? Әлбәттә, үтенер... Их, күпме михнәтләрдән арган җан кинәт килгән бу шатлыкны сыйдыра алыр микән? Нигә сыйдырмасын. Авырлыкка күнеккәнне, куанычны гына күтәрер лә...

Ниһаять, егетнең читлеккә эләккән коштай талпынган йөрәген атылып чыгар хәлгә җиткереп, яңгыравык тимер ишек ачылды.

— Чык!

Нурисламны янә хөкем бүлмәсенә керткәндә офицерлар аяк өсте басып торалар иде. Майор, әйтерсең, кеше язмышын хәл итә торган олы йола башкармый, вак-төяк эш, игътибарга лаек булмаган йомыш турында гына әйткән шикелле, юка «Дело»ны култык астыннан алып та тормастан:

— Таһиров, сезнең бу эшне кабат тикшерергә кайтарабыз,— диде дә, гамьсез атлап, бүлмәдән чыгып китте.

Төрмәдән котылам, якты дөньяга чыгам дип атлыгып көтеп торган егет өчен коточкыч рәхимсезлек булды бу. Күз аллары караңгыланды, чак егылып китми калды. Күпне белергә, хөкем итү йолаларын төгәл сакларга тиешле өлкән яшьтәге офицер-судья илгә чиксез бирелгән яшь патриотның изге хисләрен аңламасын, аяк астына салып таптасын әле! Егылмас җиреңнән егылырсың!

«Тормыш гел шулай ак белән карага бүленермени? Мин шул гел кара якта каһәрләнеп калырмынмени? Хакими көчкә ия булганнар миңа һәрчак бүре кебек карарлармы?... Әнә бит, следователь Полянский да тикшерүләрне йомгаклап, беркетмәгә кул куйдырту өчен чакыргач... 11 май көне иде ул... Сугыш афәтеннән сыгылган илнең аягүрә басып бәйрәм иткән көннәре... Балтыйк буеннан алып Тын океанга чаклы мәйданда шаулаган бәйрәм кайтавазы төрмә диварлары аша да саркып кергән иде. Шатланырга Нурисламның да хакы бар иде бит.

— Җиңү бәйрәме белән тәбрик итәм сезне, гражданин следователь. Янәдән сугышырга язмасын!— Аның эчкерсез беркатлылык белән әйтелгән сүзләренә каршы өлкән лейтенант Полянский кистереп:

— Дурак! Минем алда хәйләкәрләнеп бирәр нәрсә отармын дип уйлыйсыңдыр. Юк, синең көн күптән беткән инде,— диде.

«Әйе. Болар бүтән дөнья кешеләре шул. Мин — кара сызык аръягында. Маңгаема каһәрләнгән мөһер сугылган. Җан рәнҗетелүгә ничекләр чыдарга...»

Судтан шундый уйлар белән гасабиланып, конвой астында кайткан Нурисламны кара авызын ачып, шыксыз камерасы көтеп тора иде.

## VI

Таш капчык эчендә көннәр, айлар санын җуйган тоткынның уйлары гына сау. Аяклары гөбе кебек шешенгән — ботинкалары сыймый. Торып бастымы, башы әйләнә, хәле китә. Катгый режим буенча һава суларга да чыга алмый. Стенага карап, бөгәрләнеп яткан да күзен йомган. Иң хәтәре шул: тәнендә яшәү уты сүнә бара, сүнә бара...

— Таһиров! Тор! Симулянт!

Төрмә начальнигын да аягүрә торып каршылый алмагач, бу тоткынга өмет бетте дигән сүз...

Ә йөрәк тибә, шыгыр-шагыр эшләп, чарасыз битарафлыкка тарган җанны өметсез киләчәккә сөйрәп маташа.

— Мин сиңа, Таһиров, күрмәгәнеңне күрсәтермен! Анаңны!.. Паразит!

Төрмә хуҗасы төкерекләрен чәчеп, йодрыгын селки-селки җикерең-де-җикеренде дә чыгып китте.

«Күктән төшепме, җир астыннан чыгыпмы кил дә, Газраил, җанымны ал, бу түбәнлекләрдән коткар мине»,— дип ялварып яткан көннәре иде... Бу караңгылык патшалыгында да өмет очкыны төшәр икән...

Ишек дөбердәп ачылды. Бу юлы төрмә начальнигы үзе генә түгел, янында иярчене дә бар иде. Керфек арасыннан карап яткан Нурислам аларның итек башларын гына күрә, «этеп керткән»,— дип уйлады ул. Ялтыр күнитекле хәрби кеше тоткыннарны күзләп чыкты да:

— Мин надзор буенча прокурор. Әйтер зарларыгыз булса, әйтергә мөмкин,— диде. Йә, Хода! Нинди таныш тавыш бу?!.. Саташамы әллә Нурислам, өнеме бу, төшеме? Күтәрелеп караса... ыспай киемле прокурор аның күптәнге танышы, сугышчан дусты капитан Казарцев икән ләбаса. Николай Тихонович. Коля. Заманында «Смерть фашизму» дип атап йөртелгән партизан бригадасының разведка башлыгы иде ул.

Әмма иске дусны күрдем дип аның кочагына ташлана ала идеме соң Нурислам. Мондый куанычтан аякка басарлык кына хәл табар иде дә бит... Юк, булмый шул. Алар хәзер икесе ике дөнья кешеләре. Әнә, Казарцев нинди югарылыкта, ә Нурислам... күселәр арасында... Язмышы тапталган.

Юк, дәшә алмады Нурислам. Җан елавын күрсәтмәс өчен күзләрен йомды.

Камерадагылар тарафыннан зарлану сүзләре ишетелмәгәч, прокурор-капитан Казарцев һәр тоткын каршында тукталып торды да, югары урындагы түрәләргә хас сабыр һәм дәрәҗәле адымнар белән камерадан чыгып китте. Аның артыннан начальник та кузгалды.

Эчтә кайнарланып тулган яшь, күз кабакларын ачса, түгелер шикелле иде. Таш стенага аркасын терәп яткан Нурислам үз-үзен юата алмыйча, әрнүле уйларыннан гаҗиз иде. «И-и-и язмыш! Моннан ел ярым элек кенә икебез дә бертигез, икебез дә җиңүгә, киләчәк бәхеткә зур өметләр баглап ут эченә керә идек бит. Хәзер, кара инде, ул кем дә, мин кем?»— дип көрсенә. Кырык өченче елның август аенда Казарцевта да, Нурисламда да отряд Шарковшизна шәһәрчеге янындагы госхозга янәшә торып һөҗүм ясадылар. Немецларны чигендергәч, партизаннар кулына йөз баш чамасы ат эләкте. Сыер, сарык, дуңгызларны санап бетергесез. Партизаннар, ат менеп, көтүне партизан бригадалары урнашкан урманга таба куа башладылар. Ашыгырга кирәк иде — яктырып килә. Бәхетсезлеккә күрә, урман өстеннән генә тәреле ике самолет килеп чыкты да мал көтүе, партизаннар өстенә аяусыз ут яудыра башлады. Мәхшәр купты. Тигез басу үлгән, яраланган кеше, ат, сыер, сарык, дуңгыз гәүдәләре белән чуарланып бетте.

Кабат әйләнеп килә-килә самолетлар бөтен запасын тереклек өстенә сибеп, урман артына китеп югалдылар. Исәннәрне барлау, үлгәннәрне җирләү, яралыларга ярдәм күрсәтүне оештыру Нурисламга калды. Чөнки... капитан Казарцев сафтан чыккан иде. Яраланып егылган аты астында калып аягын сындырган, каты бәрелеп һушыннан язган иде ул...

Камера ишеге ачылды. Надзирательнең боеручан тавышы ишетелде:

— Таһиров, чык!

Нурислам дәшмәде дә, селкенмәде дә.

— Таһиров, сиңа әйтәләр түгелме, шайтан алгыры!

Бу юлы да җавап юк иде. Надзиратель килеп, ык авырттырмый гына, аркасына типте.

— Әй, син! Кәкрәйдеңме әллә?

Шуннан соң гына борылды Нурислам.

— Чыга алмыйм, гражданин надзиратель. Аякларым — шеш. Ботинкаларым сыймый,— дип ул шәрә тубыкларын ачып күрсәтте. Моны күргәч, надзиратель, артыгын бәйләнеп тормыйча, камерадан чыгып китте.

Бераздан ул олыдан олы итек башлары күтәреп килеп керде:

— Мә, ки! Киттек! Прокурор чакыра.

«Әһә, Казарцев,— дип уйлады Нурислам, эчтән генә.— Таныды микәнни?»

Чынлап та Казарцев чакырткан икән. Төрмә ихатасындагы кечкенә йортның ишек катына ук килеп каршылады ул аны.

— Исәнме, Нурислам! Камерада чакта никадәрле танытмаска тырышсаң да, таныдым мин сине, дускай. Ятлар алдында сүз катасы килмәде... Нишлисең, ситуация шундый... Вакыт ягы тар, алай да сине күрмичә

китеп бару гөнаh булыр иде. Син бит мине үлемнән йолып калган фәрештә,— дип, Нурисламны кочагына алды.

— Саумы, Николай Тихонович! Саумы! Мин сиңа болай эндәшергә дә кыймыйм хәзер.

— Әйе, Нурислам. Юллар аерылган шул. «Эшең» безнең ведомствода булмагач, сиңа ярдәм итү артыннан йөрү дә файдасыз. Беләсең, ул ведомствога кемне дә якын җибәрмиләр. Шаhит итеп күрсәтсәң генә инде... Төрмәдәге хәлеңне җиңеләйтү хәтлесенә килгәндә, анысына көч җитәр. Әйт кенә, нинди гозерең бар?

— Чирлим, Коля. Бетеп барам. Тамак ач. Өс-башны күр,— дип, Нурислам җиңе яртылаш янган мундирын күтәрде. Аның эче аркасына ябышкан шикелле коргаксыган кабыргалардан гына торган тәне чиркангыч иде.— Юка кием белән цемент идәндә аунау — үлем. Үзең беләсең, минем чиргә салкын hич тә ярамый...

— Аңлыйм, Нурислам. Барысын да аңлыйм. Ләкин хәзергә түз инде. Хәлеңне генә җиңеләйтә алам. Үпкәләмә,— дип урыныннан торды да, кабинет ишеген ачып эндәште:— Әй, кем анда?!

Шул көнне үк Нурисламны башка камерага күчерделәр. Такталардан кагып ясалган унлап карават кебек нәрсә тезелгән иркен, якты бүлмә. Ятакларда матрац. Хәтта шинель туласыннан киселгән япмасы да бар. Нурисламга да бер ятак эләкте. Янәшәдәге тоткыннар белән танышкандай иткәч, шуны белде: төрмәнең шифаханә-лазареты икән бу. Ачылганына, чирле-сырхауларны кабул итә башлавына ай чамасы гына икән әле.

Көндезге аш керттеләр. Аны, гадәттәгечә, консерв банкалары белән кормушка аша бирмәделәр, ә ак халатлы хатын-кыз, кәндиләргә салып, hәр авыруның үз кулына тоттырды. Беренчегә кәбестә ашы. Куе. Теләсәң, өстәмә дә бирә икән. Бу мөмкинлектән файдаланып, Нурислам өч тустаганны бер-бер артлы бәреп ташлады. Аннары икенчегә — изгән бәрәңге иде, анысын да күз йомганчы юк итте.

Карыны тулгач, изрәп, караватка яткан гына иде, чакыртып алдылар да киендереп кайтардылар. Хәзер киеме байларча — өстендә юылган ак күлмәк, ак ыштан. Җиңсез мундир урынына шәhәрдәге ярлы-ябагай кия торган кыска чикмән. Иске булса да шинеле бар. «Дустың прокурор булгач, тамак тук, өс бөтен шул...» дип (кайчандыр мәет өстеннән салдырып алынган булуы да бик ихтимал), шуннан канәгать булуыннан гарьләнү әчесе белән үзалдына көлеп куйды.

Шифаханәдәгеләрнең бишесе карт, гарип-гораба, доходягалар, өчесе — урыннан торалмый яткан каты авырулар иде.

Бер тәүлек эчендә ике хаста теге дөньяга китеп барды. Бернича көннән алар урынына ике авыруны носилкада керттеләр. Капланып ятканнар. Чалбар-ыштаннары тезләренә хәтле төшерелгән. Утыра торган итләч урыннары чүпрәк белән генә капланган. Икесен дә носилкаларыннан кузгатып тормыйча матрацлары алынган караватларга куйдылар.

Көндезге аш тараткан хатын бер үк вакытта санитар, фельдшер, табип вазифасын да үти икән, чирлеләрне кертеп урнаштыргач, бераз югалып торды да яраларын бәйләү өчен кирәк-яраклар алып керде.

Носилкадагыларның берсе озын буйлы, үтә нык сызлана, ыңгыраша торган ябык чырайлы егет иде. Икенчесе үсмер малай. Табиб хатын башта шунсы янына килде.

— Кая әле, тоткын, яраңны чистартып, дару сөртеп алыйк әле,— диде.

Малай исә башын күтәреп, терсәкләренә таянды да, киңәш сорагандай, карашын әле иптәшенә, әле бүлмәдәгеләргә күчергәләп алды, бар булган көченә поляк телендә:

— Мин сезнең чистартуга мохтаҗ түгел! Китегез янымнан! Күрәлмыйм!— дип кычкырды да кызу-кызу укына-чукына башлады. Носилка тактасына тып-тып яшь тамчылары тама иде.

Моның өчен малайны шелтәләп, ни дә булса аңлатып тормады табиб хатын, бигайбә, минем әйтүем хак булсын дигәндәй, тыныч кына озын буйлы егет янына юнәлде.

— Син дә баш тартасыңмы?

— Ачыгыз, күрсеннәр! Күрегез, панове, коммунистлар әнә ничек азат итәләр.

Табиб хатын гаҗәп сабыр иде. Үз эшен белеп, егетнең арт санын каплап торган чүпрәкне җәһәт кенә күтәреп алды. Алса!.. Ярабби!.. Егетнең ике арт битендә дә чынаяк тәлинкәсе хәтле уелып кергән яра. Уртасында, күгәрчен күкәе зурлыгында булыр, ап-ак сөяк башлары күренеп тора. Йомры сөяк башлары чүпрәкне куптарганда бәреп чыккан кан күбеге астында калды. Бу хәтлесен күреп торган Нурислам, үз-үзен белештермичә, ихтыярсыздан кычкырып җибәрде:

— Нәрсә бу?!

Моңа кадәр сабырлыгын саклаган хатын ачу белән аяк тибеп:

— Тик утыр! Кысылма!— дип кычкырды.

— Җикеренмә, кац!.. Күрсен, кысылсын. Бу тәмугтан исән котыланитә калса, кешеләргә дөресен сөйләп бирерлек итеп күрсен.— Егетнең көче-егәре шушы сүзләрне әйтергә генә житте ахры, авыр ыңгырашып, башын носилка тактасына салды. Аның яраларына иодоформ сибеп, марля белән каплагач, табиб хатын чыгып китте, камера тып-тын булып калды. Ул тынлыкны үсмер егетнең ярасы тирәсенә җыелган көзге чебеннәр безелдәве генә боза иде.

Шушындый тынлыкта, һәркем үзенчә интегеп озак яткач, егетләр тагын кыбырсый, ыңгыраша башладылар. Олырагы Нурисламнан су китерде. Шулчак доходяга картларның берсе егеткә иелеп сүз какты:

— Сезне, балам, бу хәлгә пся кревь москальләр төшерде, димәк?

— Шул каһәр суккырлары, әлбәттә. Алар булмый, кем булсын!

— Прошен пане, кай тирәдән соң үзегез?

— Икебез дә Норочь күле буендагы утардан без. Менә нәрсә эшләтеп ташладылар бит. Бер атна чамасы элек. Чәнечкеле тимер чыбык учмасы белән һаман шул бер төшкә суга, имансыз. Үзе офицер. Җитмәсә майор. Чекист. Ә үзе кешенең ыштанын төшереп туный.

— Алар шундый, туганым, шәфкать дигәнне белмиләр. Кемгә дә бер чара: кыйнау да үтерү. Үлми калганына — Себер. Менә мине генә алыйк. Тиздән — сиксән тула. Ә чыгару турында уйламыйлар да.

— Күптән утырасызмы?

— Ел була инде.

— Ни өчен алдылар?

— Америка машиналары, имеш, Советныкыннан яхшырак дигәнмен. Үзем хәтерләмим, югыйсә. Ә сезне?

Бу кеше янында әйтергә ярый микән, дигән сыман, Нурисламга карап алды егет.

— Проше пана, безнең җинаять катырак. Кулда автомат. Берничә чекистның башына җиткән идек.

— Бардзо добре, пан. Бардзо...[1]

Баядан бирле ыңгырашып яткан үсмер, аякларын сузып киерелгәндәй итте дә башын күтәреп, иртәнге йокысыннан әле генә уянган сабый сыман елмаеп, аяз караш белән:

— Әни!... Әнием!...— дип кулларын алга сузды.

Шул хәтле мөлаем яңгыраган бала тавышын ишеткәч, камерадагы барча кешеләр, үсмер малайга төбәлделәр. Нурислам аның янына ук барып басты, саташа башлаган малайга ул хәленнән килгән ярдәмне күрсәтергә әзер иде.

— Нәрсә кирәк? Ишлим, туган...

Малай күзләрен зур ачып сискәнеп китте:

---

[1] Бардзо добре — бик әйбәт *(полякча)*.

— Ә-ә-ә, һаман күземнән югалмадың мыни әле?! Палач, палач!...— Кинәт җилпенеп Нурисламга ташланмакчы булды. Бөтен тәне тартыша башлады. Тузган чәчле башы Нурисламның күкрәгенә сыгылып төште. Шәрә ботының яраларыннан шаулап кан китте. Носилкага җайлап салганда Нурислам аның актыккы сулышын тойды. Бу бәхетсез балага инде хәзер анасы да ярдәм итә алмый, палач та куркыныч түгел иде.

Ай чамасы сасып, сызланып, череп, коры сөяккә калгач, егетнең озын буйлысы да кырыс дөнья белән исәп-хисапны өзде...

Язның матур бер көнендә Нурисламны тикшерүче Полянский чакырттырды. Бу юлы, тузга язмаган сораулар биреп, аяклары шешенеп чыкканчы бастырып тотмады ул аны. Тикшерү вакытында язганнарын судта кире какканы, гаебен тануы өчен шелтәләп алды. Майор Горбачны табып, аңардан Нурислам хакында сорашканнар икән, аның җавапларын бәян итте дә, синең эшең Мәскәүгә особое совещаниегә җибәрелә, дип эшне бетерде.

Конвой астында һаман шул төрмәгә — ачлыкка, хурлыкка юл тотуына карамастан, Нурисламның тагын өмете уянган иде. Беренчедән, дусты майор Горбачның исән икәнен тәгаен белде. Бәлки, кайчан да булса күрешү язгандыр әле. Икенчедән, эшенең Мәскәүгә китүе. Анда бөртекләп тикшерерләр, ачыкларлар, Аллаһе боерса...

Җәй башында егерме-утыз тоткынны тимер юл стансасына алып бардылар да товарнякка төяделәр. Ике тәүлек дигәндә Гродно төрмәсенә илтеп керттеләр. Төрмә генәме — үзе бер шәһәр. Биниһая таза эшләнгән, хәтта сугыш давылы да тимәгән, бары тик үзәктәге олы бинасын яртылаш җимертеп, Нурислам кебек бәхетсезләргә эш ясап киткән. Ә ул эшләрне оештыручы карсак буйлы кеше, сүгенүенә, үз-үзен тотышына караганда урыс булырга ошый. Шуңа күрә Нурислам эшкә чыккан көнне аның янына килеп, әйтерсең, күптәнге танышлар, тәкәллефсез генә сүз катты:

— Син мине, земеля, эшнең күп ипекәйле җиренә куй әле. Туйганчы бер ипи ашыйсы килә.

Бу кеше Нурисламның әлеге сүзләрен ишетмәгән шикелле гамьсез кыяфәт чыгарып, үсеп килә торган куе сакалын кашыштырып торгач:

— Ипи дисеңме?.. Хәзергә утырып тор алайса. Мужикларга эш биреп бетерим дә. Сиңа да берәр шөгыль табарбыз,— диде.

Нурисламга ошады бу җавап. Читкәрәк китеп, хуҗаның эш бирүен күзәтә башлады. Әнә ул тоткыннарның тазарак, яшьрәк күренгәннәренә олы чүкеч, корыч чөй, йончуыракларына балта, чүкеч яки зубило кебек кораллар тоттырды да каядыр озатты.

Озак күзәтте аны Нурислам. Күз карашы белән генә ияреп аның артыннан сүтелә торган стеналарга менде, тозлап-борчылып, рус теленең гаҗәеп мөмкинлеген үз хутына ташлап, сүгенүен тыңлады. Баш очына күтәрелгән кояш мәлҗерәтә башлагач, күләгә урынга күчеп дөньясына төкерде дә черем итеп алды.

Эш бирүче хуҗа көндезге баландадан соң гына аның янына килде:

— Кем син? Кайдан? Ничек?

Нурислам тоткынлыкта яшәгән тәрҗемәи хәлен бер-ике сүз белән генә аңлатып бирергә мәҗбүр булды.

— Рәсми язулар сырлый беләсеңме? Мисал өчен помилование турында прошение?

— Язган юк та, сынап карарга була...

— Ярый, алайса, иптәш. Хәзергә мин сине бер җиргә җибәреп ашатып кайтарыйм. Аннан соң иркенләбрәк сөйләшербез, киттек.

Бер-ике бинаны әйләнеп үткәч, утынлыкка килеп чыктылар. Анда — утын төялгән носилка. Носилка янында чалбарлы яшь, чибәр хатын басып тора иде.

— Менә сиңа кулдаш, Зинка. Ач чагы, хәлсез чагы, сабырсызланып, хур итеп ташлый күрмә,— дип бригадир, Нурисламга ымлап, хатынга елмайды.

Хатын Нурисламны «үлчәп», күмердәй кара күзләрен уйнатып кына алды да:

— Ярый бу, бугор, килештек. Үзен чын егет итеп күрсәтә алса, хур булмас. Тирбәтеп кенә йоклатырмын, сөеп кенә уятырмын мин аны. Шулай итеп аякка бастырырмын. Ә хәзер тел сатып торганчы, кузгала тору яхшы. Киттек,— дип носилканың ал ягына кереп, җилкәсенә ләмкә киде. Нурислам көттереп тормыйча, носилканың арткы тоткаларына ябышты.

Вахтада торучы кораллы солдат аларны күрше ихатага кадәр озата барды. Анда төрмә офицерлары өчен ашханә икән. Кухняга үтеп, утыннарны бушаткач, повар икесенә дә берәр тустаган аш китереп бирде. И Аллам... Исе дә исе, тәме дә тәме... Патшалар ашыдыр бу! Мондый да тәмле ризыкны Нурисламның татып карамаганына ничәмә-ничә ел бит инде... Америка тушенкасы салып пешерелгән макарон ашы. Хәтта бәрәңгесе дә бар. Аны бәреп ташлагач, буш носилканы күтәреп, төрмәгә кайттылар. Шунда Нурислам сүз катты:

— Нигә шул хәтле күп төйисез? Носилкадагы утын аз дигәндә йөз кило тартадыр?

— Җиңел эш кайда соң?— диде Зинаида.

— Һәр яшь хатынның ана буласы бар, авыр күтәрмәскә, үзеңне сакларга кирәк.

— Вәгазь укучыларны җенем сөйми. Әйдә, иң яхшысы, бер көйрәтеп җибәрик. «Син кем дә, мин кем?»не уйнап алырбыз: нинди ана, нинди ата балалары эләккән бу җәһәннәмгә?— дип, Зинаида чалбар кесәсеннән кәгазь, керләнеп беткән янчык чыгарып башта үзенә төрде, аннары Нурисламга сузды. Кабызып, тирән итеп суыргач, юашланды, йөзенә мөлаем елмаю чалымы җәелде.

— Сөйләшүеңә караганда ни рус, ни поляк, ни белорус түгелсең, кем син?

— Бәхетсез егет мин, Зинаида, беркайчан да эше уңмый торган алама бәндә.

— Шаяртмыйча әйткәндә...

— Ирексездән солдат. Аннары — партизан. Хәзерге көндә гаепсез гаепле.

Зинаида әсәренде, юка борын канатлары калтырап алды, нәзек кашлары өскә сикерде.

— Партизан дисеңме?! Нинди бригададан?

— Минем бригада «Социалистик Белоруссия өчен» дип йөртелә иде.

— Димәк, Федоровский Николай Ивановичтан?

— Әлбәттә, шул, каян беләсең?

— Ай, Аллам. Ул минем якташым ич. Үзем дә партизанка.

Шушы сүзләрдән соң ике бәхетсез җан бер ата, бер ана балалары кебек, бер-берсенең кочагына ташландылар. Зинаида, иркәләнеп, Нурисламга сыенды. Күзләре тулы яшь иде. Ләкин аларга рәхәтләнеп сөйләшеп утырырга ирек булмады. Бик тә ашыгып килгән бугор Нурисламны үзе белән алып китте. Аның һаман үз тугызы тугыз. Мәскәүгә прошение язарга кирәк, ди. Тоткын өчен күп кирәкме, блатлы эш урыны елмаерга торганда, ничек инде каршы килә алсын Нурислам.

— Ара тар. Ашыгырга кирәк,— диде бугор.— Әллә каян гына кәгазь-каләм, муенлы чүлмәк белән куас, бер бөтен ипи алып килде. Кирпеч өемнәре арасына аулакка кереп утыргач, үзенең «эше» турында сөйләргә тотынды.

Бик буталчык иде аның хикәяте. Шушы Гродно стансасына килә торган төрле-төрле байлыкларга җаваплы булган икән ул. Германиядән кайтып төшкән бала-чага киемнәрен приютларга җибәрергә тиеш булса да, аларның җитмеш җиде мең сумлык бер өлешен балдак-йөзек, беләзек-браслет, кыйммәтле сәгать, муенса кебек зиннәтле әйберләргә алыштырган. Юк, һич кенә дә урлау, үзләштерү нияте булмаган үзендә... Андый

усал уйдан, Аллам сакласын, ди. Бу — саташу гына, кирәгеннән артык беркатлы булудан гына, шайтан котыртуына каршы тора алмау аркасында туган гөнаһ кына икән. Үз гомеремдә беренче тапкыр кыек юлга кергәнмен, ди... Сугышта ике улын югалткан. ВКП(б) әгъзасы, немец-фашистны җиңеп, ничәмә-ничә медаль белән кайткан фронтовик күрәләтә андый җинаятькә бара димени! Әлбәттә, бармый. Шуңа күрә Югары Совет председателе иптәш Шверник аны аңлар, суд биргән сигез ел срокны гамәлдән чыгарып да, төрмәдән азат итәр. Аның моңа өмете зур... Тагын ул, Аллага ышанган кебек, Таһировка да ышана. Әгәренки матурлап, җиренә җиткереп язса, иптәш Шверник шундый ихлас күңелдән язылган прошениены уңай хәл итми калдырмас. Башкача мөмкин түгел.

Эзен югалтасы килгән кышкы куян сыман, дөресен әйтәсе килмичә, кылган җинаятьләре тирәсендә озак бөтерелгәч, тәрҗемәи хәленә күчте. Бабасы Дунай болгарларын төрекләрдән азат иткән, атасы Порт-Артур батыры, ә үзе Антонов бандасын тар-мар итүдә катнашкан (егерменче ел башларында Рязань, Пенза тирәләрендә шундый банда йөргән икән). Коллективлаштыру чорында кулакны тамырыннан юк итүдә дә иң алгы сафта йөргән. Аннан соң да партия, хөкүмәт тапшырган һәр эшне төгәл, вакытында үтәп килгән. Боларны расларлык егермеләп Мактау грамотасы бар икән. Кирәк булса, исемлеген китерә ала.

Нечкә муенлы чүлмәктән куас уртлый-уртлый озак сөйләде ул. Соңыннан болай дип бетерде:

— Мин, Таһиров, чая кеше. Сыйнфый көрәштә дә, сугышта да башны кызганмадым. Прошениедә нәкъ менә шушы моментны калку итеп күрсәтә алсагыз, рәхмәт әйтеп калу гына түгел, мәңге онытмас идем.

Ул сөйләгәндә мөһим дип тапкан урыннарын кәгазьгә төртә барган иде Нурислам. Шуңа күрә, әллә ни көч куймый гына үтенечне язып та ташладым. Караламасын кычкырып укыган иде, бугорның күзләреннән яшь тамчылары бәреп чыкты. Үзенең никадәр әйбәт кеше икәненә ул менә хәзер тагын бер кат ышанды.

— Кара син ә, үзең татар югыйсә, ә русчаны рустан шәп беләсең,— дип тел шартлатты.

Кичен тоткыннарны эштән туктатыр вакыт җитте. Кулына бөтен бер ипи тоткан Нурисламны да камерага кертеп яптылар. Егетнең Гродно төрмәсендәге беренче көне әнә шулай үтте.

Икенче көнне иртән, тотканнарга эш биреп чыккач, бугор Нурисламны читкәрәк алып китеп, үзе өчен мөһим булган хәбәрне җиткерде:

— Аллага тапшырып җибәрдем мин теге язуны. Хәере белән барып җитсен дә, хәере белән уңай җавап килсен. Рәхмәт. Ихлас күңелдән рәхмәт. Үзеңнең «эшең»дә Мәскәүдә дисең, алайса, бәлки гел бергә дә чыгарбыз әле. Аңарчы мин сиңа эш биреп тормам инде. Үзеңчә яшә, ял ит, ныгы. Ипи, куасны Алла бирмеш һәр көн дә китереп торырмын. Әйткән сүз — аткан ук. Анысы закон. Зинка белән утын кертkәләрсең. Командирлардан калган ашны ялмашу да ярап торыр, иш янына куш булыр. Шулай итеп, хәл ала, түл җыя төшкәч инде... Зинаны берәр тынычрак урында эләктереп, теге ни, кети-кети уйнап алсаң да, яшь кешегә гөнаһ саналмас. Барча хатыннарның да күңелен күреп булмый, әмма дә ки шуңа омтылырга кирәк, диләр бит французлар... Хи-хи-хи... Яһүдә шәйтан, болай ләззәтле күренә. Шарлары тыгыз... Гродно больницасында эшли иде ул. Эләккәненә күп түгел, курыкма. Андый-мондый чире юктыр. Шулай да сак кылан. Чамаңны белмичә ташланып, карцерга эләгә күрмә. Юкса, еллык сыеңны алырлар.— Әнә шулай шактый акыл өйрәткәннән соң, бугор бераз тын гына торды да, монда яшәүче халык телен дә белгәнлеген күрсәтергә теләп: «довидзенья, пан!» дип, китеп барды.

Шуннан соң Нурислам аны иртәнге якта тоткыннарга эш биргәндә дә, ипи, куас алганда гына күрә торган булды.

— Саумы, фәрештәм!

Партизан хатыннар, гадәттә, сүз артыннан кесәгә керми торганнар иде. Зинаида да шундыйлардан икән.

— Саумы, Аллам! Ничек йокладың, төшләреңдә күреп миннән туймадыңмы?— дип шаяртып алды да, башын Нурисламның күкрәгенә салды.— Төрмәдә партизанга юлыгырмын да хисләрем кузгалыр дип, һич кенә дә уйламаган идем. Әллә ни булды. Төн буе партизаннар белән саташтым. Имеш, өстә бомбалар шартлый, ә мин окопта бик якын кешемнең ярасын бәйлим икән. Икенче карасам, ул мине кулларына күтәргән. Дәһшәтле урман шавы, пуля сызгыруларына да исе китмичә мине күтәреп бара. Мине сөя, иркәли, киң күкрәгенә кыса, имеш. Мин бәхетле. Бәхеттән елыйм. Аны үбәм... Уянып китсә-ә-әм, янымда кем дә юк. Беренче булып сине искә төшердем. Язмышларыбыз уртак булгангамы, әллә инде син Николай Иванович бригадасыннан дигәнгәме — якын булып тоелдың...

Нурислам рәхәт елмайды.

— Күңелеңә хуш килгәнмен икән, әйдә, алайса, ныклап танышыйк. Нурислам Таһиров булам.

— Ә мин Зинаида Генихович. Шәфкать туташы. Романов бригадасында партизан идем.

— Романовта?! Алайса, капитан Казарцевны да беләсеңдер, ә?

— Каян искә төшердегез аны?

— Бәй, кырык өченче елны бер яудан соң, аттан егылып аякларын сындыргач, шул Романов бригадасына озаттырган идем мин аны. Быел кышын төрмәдә очраттым. Надзор буенча прокурор икән...

— Игелексез бәндә ул. Сездән соң булган инде алайса, кырык өченче елның көзге яңгыры астында арбага салып, носилкада күтәреп, дигәндәй, ике йөз километр чамасы саз ярып, партизаннар аэродромына илттек, самолетка салып Мәскәүгә озаттык югыйсә үзен. Ә шушы кышта, мин бәлагә эләккәч, ярдәм кулы сузудан баш тартты. Җил кайсы якка иссә, шул якка ава торган тупас мужлан һәм чеп-чи антисемит ул. Мин андыйларны яратмыйм.

— Ә миңа ярдәм итте. Камера-шифаханәгә күчертте. Ачтан үләм дигәндә шунда хәл алдым.

— Беркатлы син, Нурислам. Табигать баласы. Ул сине төрмәдән чыгарып, үзе белән тигез итү турында уйлап та карамаган. Шовинист ич ул. Безнең ише кешенең бәясе юк аның өчен.

— Кызы-ык. Очрашуның беренче минутларында ук чәнечкеле сүзләр. Миннән русларга дошман ясарга телиләр инде әллә, атлаган саен аларны хурлап кына торалар. Руслар яулап алучы, руслар колонизатор, руслар шовинист, руслар фәлән-төгән.

— Кемнәр инде «алар»?

— Очраган һәр поляк. Менә хәзер син.

— Мин, хөрмәтлем, һәр нәрсәне үз исеме белән атарга өйрәнгән. Начарны яхшы дип әйтә белмим, үпкәләмә. Мин икейөзле булып совет чынбарлыгында тәрбияләнмәгән. Сезнең мохит шундый. Хәер, нигә әле, шайтан алгыры, политика да политика! Уртак язмышлы партизаннар ләбаса без. Сөйләшәсе сүзләр азмыни?!

Шулвакыт ишегалды түрендә чаң кактылар: көндезге аш килгән. Тозлы килькадан гына пешерелгән әче баланда кызыксындырмаса да, йөз илле грамм ипие бар. Аннан тыш, бугор да ни дә булса китерергә тиеш. Нурислам шунда китте.

Шактый вакыт торып әйләнеп килгәндә, Зинаида көндезге баландага бармаган. Нурисламны утын төягән носилкасы янында көтеп тора иде. Ашханәгә утын илтер вакыт җиткән икән. Озак юанып тормыйча, носилканы күтәреп шул якка борылдылар.

Зинаның тагын бер шөгыле бар икән әле. Ашханәдән соң ул Нурисламны шунда алып китте. Ишегалды түрендәге дүрт катлы озын бинаның җимерек башына кердeләр. Кай урыннары сынган, янып бөгәрләнгән, кай урыны чак эләгеп тора торган тимер баскычтан алар ничек кирәк алай өченче катка күтәрелделәр. Алар тукталган төштә тәрәзәләрнең тимер рәшәткәләре генә калган, рамы да пыяласы да юк иде. Идәне дә шулай: өрлекләре генә калган, җәйгән такталары сүтелеп алынган иде. Алай да, сак маташсаң, өрлектән-өрлеккә сикерә-күчә идәннәре исән калган якка керергә була икән. Кулга-кул тотынышып шунда керделәр. Йә, Хода, никадәр байлык монда! Тәрәзә тупсасына хәтле сабагы-ние белән өелгән көлтә-көлтә тәмәке. Исе дә исе, борыннарны ярып керә дә үпкә юлларын ләззәтле кымырҗыта башлый.

Зинаида көлтә өстенә капланып ятты да, йодрыгы белән тукмый-тукмый еларга тотынды.

Нурислам ни кылырга да белмичә бер мәлгә югалып калды, аннары кырыена тезләнде дә, хатын-кыз назы күрмәгән, коргаксыган кулы белән Зинаиданың куе кара чәченә кагылды. Тере чәч учмасына күмелгән бармаклары калтырый башлады.

Зинаида чалкан әйләнеп ятты, сабый бала кебек, йодрыклары белән күзләрен угалады, керфегенә кадалган эре-эре яшьләр аша елмаеп:

— Кил яныма... Бу дөньядан минем синнән дә якынрак кешем юк. Үп, юат мине,— дип, Нурисламны кочагына алды.— Елавым өчен кичер мине, җаныем. Нишлим соң, нишлим... Күкрәгемдә көч-егәр кайнагач... Күкләргә күтәреләсем, ерак илләргә китәсем, үземчә генә яшисем, сөясөеләсем килә...

Борынгы Бибил иленең эссе кояшы кайнарлыгы канында буыннан-буынга күчә килгән, үтемле карашы бөтен барлыгыңны ялмап алып, төпсез кара тирәнлегендә эретә торган күзләрнең елдырым-исерткеч нурын сусаган иреннәр белән генә сүндерерлек түгел иде. Изүе ачылган иске күлмәк эченнән бәреп чыккан тыгыз имиләрнең горур яктысы, затлы чыбылдык эчендә, аксөяк куллар гына сыйпыйсы бу ганимәтләр, сулышын тыеп, язмыш хөкеменә бирелгән иде.

Җирнең төрле кыйтгаларында туып, һәр җәһәттән караганда да мәңге очрашмаска, мәңге кавышмаска тиешле бу ике җан, кыерсытылган гомерләренең мизгеллек төмен белеп, ике бәхетсезлекне уртак итеп бирбирсенә кушылган икән — кайсының дине моны гөнаһка санар...

Тәмәке исе... дөньяда шушы ис бөтен чәчәкләрдән аңкыган хушлыктан да кадерлерәк булып исендә калыр Нурисламның. Тәмәке исе... Бөгелеп торган озын керфекләр астында йомылган күзләр. Саташулы пышылдап әйтелгән поляк, яһүд сүзләре. Алар бөтенләй чит-ят дөньяның илаһи догасы кебек — колакны иркәли, чынбарлыкны аера.

Тәмәке исе... Бүтән берни дә кирәкми. Дөньялыкның кыл уртасы шушында. Тәмәке көшеленә чалкан төшкән егетнең әсирлек богавыннан ычкынган хис ташкынына бирелеп үксеп бер җылыйсы килә. Йомшак кул аны иркәли, мәҗүси сүзләр пышылдап юата — ана назы кебек. Тулышкан күңел үз ярына кайта. Тәмәке исе...

— Рәхмәт сиңа, кадерлем. Бу мохиттә миңа һава җитми иде, тын ала алмый идем. Менә син килдең дә миңа сулыш бирдең.— Зинаида егетне иелеп үпкәндә, исерткеч карашы ток булып аны үз караңгылыгына йолып алды.

Тәмәке исе... Табигатьнең бу әчкелтем, исерткеч, куәтле исе гүя кырыс, кимсетелгән язмышларны тынычландыру, әрнүле хисләрне бәлзәмләү өчен яратылган.

Зинаида сабыр гына сөйли башлады да, котырып кайнарланып, сүзләрен ядрә урынына сибә башлады.

— Әгәр, Зинаида Генихович төрмәдә җимерек баскычлар буйлап өскә үрмәли, янында ят бер егет тә бар дисәләр... Зинаида Генихович тәмәке көлтәсе өстендә... Юк, бөтен Польша иленең кешеләре генә түгел,

хәтта этләре дә моңа ышанмас иде, билләһи! Мине, өч ел буе Советларга ышанып партизанлыкта утны-суны кичкән хатынны, иректән мәхрүм итсеннәр әле. Хурлык! Язмышның миннән көлүеме бу! Гарьлек, тагын бер кат гарьлек! И Аллам!

Нурислам аны кысып кочаклады да, сулышын буып, иренennән озаклап үпте.

— Тынычлан, Зиночка. Башлар шундый хурлыкка төшкән икән, ярсып, елап кына котылып булмас. Акыл һәм сабырлык кирәк.

— Әйе, әйе, хөрмәтлем. Бөтенләй онытылып киткәнмен. Эш турында да уйларга кирәк бит...

Бу бинаны немецлар тәмәке склады итеп файдаланганнар икән. Советлар азат иткәч, тәмәкене бинаның җимерек башындагысыннан гына алганнар да, кул җитмәгәне, исән бүлмәдәгеләре кала килгән. Хәзер менә шуларны тоткын хатын-кызлардан яфрагын-яфракка, сабагын-сабакка аертып, капчыкларга тутырдылар. Нормасы да бар. Һәр борынга биш кило. Боларны, тәрәзә катына килеп, иренгә-ирен куеп, төтен өрешә-өрешә тартканда Зинаида аңлатты.

— Син ярдәм итсәң, кеше башына ике ярым кило гына туры килә,— дип мут елмайды.— Аннары кичкә кадәр җәннәт — безнеке...

Чын тәмәке төтене кан тамырларына куәт биреп, акылны изрәтеп тарала иде. Аннары... Зинаида егетне үзенә тартты.

— Кил, ят яныма да керим куеныңа. Безнең хәлләр шундый, хөрмәтлем. Иркәләнү-песиләнү өчен әйбәт түрнәчә өй дә, йомшак түшәк тә, ак җәймә дә юк безгә. Бар булганы менә шушы тәмәкеле бүлмә генә. Аның каравы син бар, мин бар. Уртак язмышлы ике бәхетсез партизан бар. Якты киләчәккә өмет бар. Әй, Аллам, онытты мине бу бәхетсез дөнья-ны!..

Нурислам хәзер бу кайнар холыклы ханым белән көн саен очраша, аңа булыша башлады. Беренче танышкан көнендә үк комбриг Федоровский турында сүз чыкты да өзелде. Нурислам сорашырга дип гел кымыр-җып торса да һаман җае чыкмый иде.

Кырык икенче елның язында Нурислам аны беренче тапкыр күргән иде. Разведка командиры Шилков Саша Хөснетдин белән Нурисламны комбриг Федоровский янына китереп бастырды.

— Менә, иптәш командир, яңа партизаннар. Әйтүләренә караганда немецтан качканнар. Безгә каршы сугышырга дип китерелгән булганнар.

Озын буйлы, ачык чырайлы кырык тирәсендәге бу командир үтә сабыр иде:

— Немецтан качу җиңел эш түгел. Ул хәтлегә барганнар икән, димәк, аларга качмый яшәүдән мәгънә калмаган. Димәк, алар чын йөрәкле антифашистлар. Әйдәгез, алайса, дуслар, рәхим итегез, бергә-бергә фашистларның муенын сындырыйк. Начар сугышсагыз, яратмам. Булсынга йөрсәгез, олы эшләр тапшырырмын, үзегезне күрсәтергә мөмкинлек туар. Миндә сезнең кебекләр күп ул. Хорват, чех, поляк, хәтта немец та бар. Үткән юлларыгызда кылган гамәлләрегез турында сорашып тормыйм. Аның үз кешеләре бар. Килерләр, казынырлар. Кисәтеп куям, дөресен сөйләгез.

Аның аталарча ягымлы мөгамәләсен Нурислам шул минутларда ук ошаткан иде. Аннан соң кылыч йөзеннән бергә үткәндә комбригның гаярьлеген дә күреп ышанды.

Кырык өченче елның иртә язы. Белоруссия сазлыкларының кар-боз кисәкләре йөзеп йөри торган иксез-чиксез дәрьяга әверелгән чагы. Ул елны яңгыр да кимен куймады. Көн яуды, төн яуды. Немец моннан файдаланырга уйлады ахрысы, партизаннар урнашкан урманга һавадан да, җирдән дә торып һөҗүм башлады. Ике меңгә якын партизан үзләренең чирле-яралылары белән бәләкәй бер утрауда кысрыкланып калды.

Комбриг Федоровский барча партизанны үз янына җыйды:

— Күрәсез, туганнар, язмышлар кыл өстендә. Нишлибез?

— Без сиңа ышанабыз, командир. Син ни әйтсәң, шул булыр,— диештеләр партизаннар.

— Алайса тыңлагыз. Утрауга керергә, чыгарга бердәнбер юл бар. Озынлыгы өч чакрым. Теге башында — немец. Нияте утраудан чыгармыйча безне ачтан үтерү. Бөтен көчне бергә туплап, шушы төндә немец өстенә ташланырга, аның безне саклый торган көчләрен тар-мар итеп олы урманга чыгарга, аннары эзләрне югалтырга тиешбез. Иң алдан үзем барам. Кемнәр риза?

— Мин... мин... Сайла, командир, Әмереңне бир! Барыбыз да риза,— дигән тавышлар ишетелде.

Шулчак Шилков Саша кычкырды.

— Тик, командир, алдан сез түгел... Мин — разведчик. Алдан мин барырга тиеш.

— Мин риза.

— Таһиров! Асланов! Капуста! Васильевич...— Тагын берничә фамилия атады Шилков.— Минем арттан! Марш!

Яңгыр ява, төн караңгы. Гаять дигәне сазга бүрәнәләр, чыбык-чабыклар салып ясалган юл аламасы. Җайлы-җайсыз бассаң йә бүрәнә бата, йә аягың таеп китә дә суга чумасың. Шуның өчен тычкан тотарга җыенган песи кебек кенә атларга тиешсең. Башта бер аягыңны нык күтәреп алга китерәсең, аннары әкрен генә бүрәнә өстенә төшерәсең дә икенче аягыңны күтәрәсең. Шулай күпме барганнардыр, кинәт, Нурисламның аяк астында ут көлтәсе бөркелде — пулемет тыкылдавы!

Юл белән мавыгып, гөнаһ шомлыгы, Нурислам аяк астына игътибар итмичә, дошман секреты өстенә барып менгән икән. Тегесе, күрәсең куркып, ихтыярсыздан пулеметының гашеткасына баскан. Нурислам да ихтыярсыздан тәтегә басты. Бәхете бар икән, сукыр килеш чирттереп алуга, «А-а-а» — дигән аваз яңгырады. Нурисламның зиһене тиз эшли башлады, иелеп аяк астын капшаштырам дисә, анда — пулеметчы! Ул арада якында гына комбирг Федоровский тавышы ишетелде:

— Калганын иптәшләрең карар, Таһиров. Әйдә, минем арттан! — дип олы юл өеменә үрмәләде. Алларында дзот иде. Комбриг аның ишегенә таба бер-бер артлы ике граната ыргытты да, шартлау тавышлары тынгач, Нурисламга:

— Түбәгә мен. Гранаталарыңны вентиляция тишегеннән төшер! — дип кычкырды да үзе ишеккә ташланды.

Соңынтын белде Нурислам. Дзотта бер станковый, ике кул пулеметы белән ун немец утырган булган. Исән калганнарын Федоровский җиңел генә әсир алган.

Кызганычка күрә, партизаннар да күп кырылды ул төндә. Һәлак булганнар кырык өч кеше иде. Шулар арасында Нурисламның командиры Саша Шилков та бар. Аның урынына Федоровский Нурисламны куйды...

Бер көнне Зинаида, ниһаять, ачылып партизаннар командирының соңгы язмышын сөйләп бирде.

— Комбриг Федоровский, үзенең партизан отрядларын таратып бетергәч, кырык дүртенче елның октябрендә яңа эшкә — Белоруссиянең Тышкы эшләр министрлыгына җибәрелә. Ләкин яңа эштә Мәскәү билгеләгән түрәләр белән моның арасында каршылык чыга. Төрле интригалар, итәк астыннан ут йөртүләр башлана. Тора бара бу үзсүзле яшь дипломатны эзәрлекләүләрнең нәтиҗәсе билгеле инде. Совет шартларында төрмә белән бергә бетә. Безнең Николай Ивановичка да шундый куркыныч яный. Тугызынчы май — беренче җиңү бәйрәмен ул НКВД подвалында каршылый.

Сорау алулар вакытында тикшерүче, ул китергән дәлилләрне санга сукмыйча, тикшерү кануннарын бозып килгән. Федоровский ялганга бара торган шәхесләрдән түгел. Озак уйлангач, ул бер карарга килә. Утыз

тугызынчы елны Польшаның Картуз Береза төрмәсеннән качкан булган икән. Монда да шулай эшләргә карар кыла. Һәм узган көзнең янгырлы бер төнендә сорау алырга алып барган чакта Аллага тапшыра — конвой абайламаганда читкә ыргыла. Ябалактай очып ихата, ишегаллары аша күчә-күчә эзен югалта. Мылтыктан аткан тавышлар ишетелеп китсә дә, караңгы төн аңа юлдаш була. Федоровский Польшада чакта подпольеда бергә эшләгән коммунист иптәшенә керә, анда юынып, кырына, киемнәрен чистага алмаштыра. Иртәгесен ул Белоруссия Үзәк Комитетының беренче секретаре Пономаренко янына керергә ниятли. Ләкин, бәхетсезлегенә күрә, нәкъ шул көндә Пономаренко Гроднога киткән була. Федоровский, озак юанып тормыйча, яшерен юллар белән Гроднога юл тота. Һәм тәүлек дигәндә барып та җитә. Ләкин аның эзенә төшәләр. Эзәрлекләүчеләрдән кача башлагач, аңа атарга мәҗбүр булалар. Пуля беләгенә тия.— Зинаида бер мәлгә тынып торды. Күзеннән мөлдерәп яшь чыкты.— Төрмә лазаретына китереп салганда уң кулы төптән үк юк иде инде мескенемнең. Гангрена башлангач, шәһәр больницасына илтеп кискәннәр. Менә шулай, дускай, батько комбригыбызны мин шушы төрмәдә, шул хәлдә очраттым.

— Шуннан?! Хәзер исәнме әле ул?

— Тотылган качкынның язмышы нинди була — эт типкәсе. Температурасы төшкәнче атна чамасы монда ятты да каядыр алып киттеләр. Чыдам кеше иде ул. Шул атна эчендә температуралы килеш, үзенең мажараларын миңа сөйләде, кәгазь, карандаш таптырып, берничә адреска хат яздырды. Дусларын иреккә чыгаруны кайгыртты. Кемнәрдер котылды бугай, төрмә түрәләре бу эштә фетнә күреп, мине ун тәүлек карцерда яткырып чыгардылар, аннары лазареттан кудылар. Тыныч кына яшисең килми икән, мә сиңа, янәсе, кирпеч кыр, тәмәке сыдыр. Әмма бу дөньяда нәкъ капитан Казарцев кебек игелекле күренергә тырышучылар да бар. Шуларның берсе мине офицерлар ашханәсенә утын ташырга куйды. Имеш, миңа көненә бер тапкыр булса да тупас рус авызыннан калган шулпа эләгә... Уф, Аллам! Кайчан гына әле Польшада дан тоткан медицина докторы Гинненбаум кызы Зинаида сасы рус артыннан калган аш ашап йөрсен инде! Нинди түбәнлек! Нинди хурлык!.. И-их, татарым шул син минем, татарым! Цивилизацияле илләрдә ничек яшәүләрен белмисең шул син. Сөйләсәм дә син аны барыбер кабул итә алмыйсың. Чөнки син «патриотизм», «сыйнфый көрәш» кебек Сталин ләчтитләре белән тәрбияләнгән. Үпкәләмә, акылың бар синең, тик... түшәмең тәбәнәк. Шуңа күрә син мине барыбер тулысынча кабул итә алмыйсың. Кызганыч... без икебез ике яссылыкта...

Зинаида тагын елый башлады. Нурислам аның чәчләреннән сыйпап, кочагына кысты.

— Алай димә, Зиночка, минем синнән дә якын кешем юк.

Зинаида курчак алган сабый кебек елмайды.

— Шулаймы, кадерлем. Рәхмәт. Бу жидовка бик холыксыз нәрсә, әле елый, әле көлә, дип уйлыйсыңдыр инде. Мин бит хатын-кыз. Һәрчак көчле ир-ат яклавына мохтаҗ. Тирәмдә моңарчы андыйлар булмады. Менә син очрадың. Әмма алданам бугай. Минем хис — тойгылар ят сиңа, шулаймы?..

Нурислам «юк» дигәнне аңлатып башын чайкады да, ханымның күзләреннән, иреннәреннән үбә-үбә, аны хуш исле тәмәке диңгезенә күмеп ташлады.

Тәмәке сыдырулар шулай гадәткә кереп китте. Әмма, башы барның соңы да бар икән шул. Нурислам бер көнне иртән, гадәттәгечә, тоткынnarга эш бирә торган урынга гамьсез генә барса, анда карт бугор юк, аның урынында таза бер егет эш биреп йөри иде. Нурисламга да лом тоттырды. «Мин моңарчы кирпеч өя идем»,— дип әйтеп караса да, яшь бугор аның сүзләрен колагына да элмәде. Көндезге баландадан соң, утын чыгарырга тиешлеләр исенә төшергәч, сүгенеп, Нурисламның артына типте.

— Пшел!.. Татарская морда!.. Бирермен миң сиңа утын! — Бугорның каядыр киткән мәлен чамалап, Нурислам утынлыкка рөхсәтсез китте. Барса анда Зинаидага булышырга дип бер кыз килгән икән.

Әмма аңа карап Нурислам Зинаида белән очрашуларын туктатмады. Юк юк та, эштән качып булса да, тәмәкеле бүлмәгә баргалап йөрде.

Бер тапкыр шулай, очрашырга сүз куешкан көн дип, бугорны тыңламыйча, аның белән тәмсезләнеп киткән иде, Зинаида янында күпме генә булгандыр, өсләренә ике надзиратель килеп чыкты. Аларның шакшы сүзләрен ишетәсе килмәгәндер күрәсең, Зинаида, нәфрәтләнеп, торды да баскычка ташланды. Күп тә үтми аның ачыргаланып кычкыруы ишетелде. Баскычка килеп җиткәндә Нурислам аның аскы катка очкан гәүдәсен генә күреп калды. Чарасыз калып, ул ничек төшеп җиткәнен дә сизмәде. Зинаиданың йөзенә үлем аклыгы кергән, хәрәкәтсез ята, сызлануын белдерәсе килмичә тартылган иреннәре дерелди иде. Яшьле күзләре белән Нурисламга карап:

— Бәхил бул, партизаным,— дип пышылдады. Нурислам, аны күтәреп алырга теләп, кочагына алган иде, инәлеп: — Кузгатма, тимә, жаным,— дип ыңгырашты.— Билем сынды бугай. Беттем... Шулай язгандыр миңа. Ә син сау яшә. Рәнҗемә, яме. Мин сине яраткан идем... Әнә, теге хәшәрәтләр киләләр!..— Ул арада надзирательләрнең берсе Нурисламның кулын каерып алды, аны карцерга китереп ыргыттылар.

Таш капчыкта ун көн утырып, кара күмергә әйләнеп чыкты Нурислам. Зинаиданы, өметсез дөньяда бәхетле көннәр бүләк иткән Зинаиданы аңа бүтән күрергә насыйп булмады...

## VIII

Таң атмаган иде әле. Унбиш-егерме тоткынны төрмә ишегалдына чыгарып кул фонаре яктысында чырайларын «дело»ларындагы фотолары белән чагыштырып тапшыру — кабул итү йолаларын үтәгәч, һәр тоткынның кулларын бәйләделәр дә, сүгенүче солдатлар һәм ярсу этләр озатуында каядыр алып киттеләр. Тимер юл стансасына җиткәч, бер читтә ялгызы гына торган вагон янында туктаттылар. Ни гаҗәп, вагоны соклангыч матур иде. Пассажир вагоны. Нурислам өчен көтелмәгән нәрсә иде бу. Беленеп кенә килгән алсу таң нурымы, әче әрем исеме, якындагы Неман елгасыннан искән салкынча җил дымы тәэсир иттеме, егет, ничектер дулкынланып, ихлас күңелдән кычкырып җибәрде:

— Менә бит нинди культура, ә! Цивилизация! Күрәсезме, мужиклар. Арестантка да кунак вагоны бирәләр.

Шуннан соң үзе өчен генә нәтиҗә ясап куйды. Димәк, сугыш беткәч илкәй ныгый, яңара, матурлана бара. Аның үтә беркатлылык белән әйтелгән сүзләрен хуплаучы да, кире кагучы да булмады.

Ул арада вагон ишекләре ачылды. Дүртенчеме-бишенчеме булып вагонга ул да керде. Караңгылык иде әле, алай да күз шәйләрлек. Алдан кергәннәр беренче купеда тукталганнар да, җан-фәрман ипи белән кипкән балык кимерергә тотынганнар. Бу, ни хәл? Ипи, балык өеме сәкедә тулып ята. Каян килгән дә, кем калдырган боларны? Ачлык үзенекен итте, ул хәтлесен уйлап тору юк, Нурислам бер бөтен ипи белән беләк буе балыкны эләктереп, сәндерәнең иң өстәгесенә менеп кунаклады.

Бер заман ипи дә, балык та шактый кимеп, тамагыннан үтми башлагач, авыз чылатып алырдай су булмас микән дип, аска төшим дигән иде, кая ул, анда мәхшәр купты, бер көтү тоткын пыр тузынып үзара чәкәләшергә тотынды. Ул арада тоткыннар бер-бер артлы коридорга оча башладылар. Ниндидер фантастик көч суырып алып Нурисламны да коридорга чөйде.

Бу әкәмәтнең сере бераздан ачыкланды. Егермеләп тоткын бер купега сыялмый башлаган, җитмәсә соңыннан кергәннәргә ипи дә, балык та калмаган. Ачның ачуы яман, каннары кызган тоткыннар буза куптарып якадан алыша башлаганнар. Шулчак конвой җитәкчесе лейтенант, хикмәтнең нәрсәдә икәнен аңлап алып, солдатларына тоткыннар кулыннан ризыкларны тартып алырга, эт итеп кыйнап бүтән купега күчерергә, дигән әмер биргән. Нык «эшкәрттеләр» тоткыннарны ул чакта. Типкәләп, изеп бетерделәр дә, ике купега бүлеп, рәшәткәле ишекләрне шартлатып бикләп куйдылар. Һушка килүгә, яралы, канлы чырайларын сөртү, үзләрен тәртипкә китерү турында онытып, тоткыннар Нурисламнан көләргә, төртеп күрсәтеп хихылдарга тотындылар.

— Цивилизация дип син әйткән иденме әле?! Күрсәттеләрме совет культурасын?!

— Бусы гына пүчтәк! Котыпка илтеп ташлагач, цивилизациянең берәгәйлесен күрсәтерләр әле. Анда молибден белән никель күп ди. «Күбрәк ал, ераграк ыргыт!» түң руданы.

— Аңарчы аякларын сузмаса. Ха-ха-ха... Хи-хи...

Бу минутта Нурислам җир тишегенә кереп китәр, йә булмаса, муенына бау салыр иде. Әмма, ни хәл итәсең, җирдә тишек тә юк, баш очында бау да асылынып тормый. Сер бирмәскә тырышып үзе дә көләргә тотынды. Әмма рәхәтләнеп көлү түгел иде бу, еламас өчен көлү иде.

Вилейкага кайтып җиткәнче (өч тәүлеккә якын ара) купе ишеген ачучы булмады. Тоткыннарга су эчү, ризык җыю дигән нәрсәне оныттырдылар. Туалетка чыгаручы да булмады. Барысы да купеда. Моның сәбәбен Вилейкага кайтып җитәр алдыннан лейтенант үзе аңлатып бирде. Тоткыннарны озата баручы солдатларның юл паекларын вагонның беренче купесына лейтенант үзе кертеп куйган булган. Әмма ул бәләкәй генә ялгышлык җибәргән, купены бикләргә, тоткыннар керергә тиешлесен ачып куярга оныткан. Тоткынга нәрсә, кайда ишек ачык — шунда керә, ризык ятканны күрсә — тәкате калмый. Җәза бирүнең сәбәбе әнә шулай бик гади булып чыкты.

— Сездәй чүл бүреләренә нарком паегы ашатып, үз солдатларымны ач йөртмәм бит инде! Аларны үземә каршы куйыйммыни, минем яшисе бар ич,— диде лейтенант.

Нурисламның теле аңкавына ябышып каткан. Башы әйләнә. Күз аллары караңгылана. Һава җитми. Тыны кысыла. Күрәсең, ул кунаклаган өске катка сасы һава гына менә.

Аста берәү зарлана.

— Ни сөйли бит, ә, имансыз лейтенант. Имеш, аның яшисе бар, җанкойгыч! Палач! Нинди ана сөте имеп үскән диген! Имансыз!

Күпләр зарланулардан узган. Көчсез тавыш белән һаман бер сүз кабатлана:

— Су... су... су...

## IX

Өлкән лейтенант Полянский, Нурислам Гродпода утырган арада тагын бер йолдыз алуга ирешкән. Капитан. Ялтырап торган әр-яңа алтын погоннар. Кителе дә энәдән-җептән генә чыккан. Тәненә сыланып, нәзек билен, киң күкрәген аермачык сиздереп тора. Менә ул күзгә каршысында озын сүс чәчләрен тарады. Нурисламга гадәттәгечә кырысланмыйча ачык чырай, йомшак тавыш белән:

— Утыр! — диде. Үзенең эш өстәленнән ике метр читтәрәк идәнгә беркетелгән такта урындыкка ымлады.— Синең «эш» особое совещаниедән кайтты, Таһиров. Бирелә суд карарга тиеш, диелгән. Кылган җинаятьләреңне беренче судта ук инкарь итмәгән булсаң, әллә кайчан инде лагерьда, үзең кебекләр арасында йөрер идең. Хатыннар кысарлык дәрт-

көч туплый алмасаң да һаваң саф, күгең иркен булыр иде. Гомер буе төрмәдә черергә уйламыйсыңдыр ич?! — Бу сүзләргә каршы Нурислам бер сүз дә әйтмәгәч,— мә, алайса, укы,— дип, Мәскәүдән килгән язуны укытып, кул куйдырды да, эшен бетерде. Яңа китель, яңа погоннарга өстәлгән йолдыз холкын бөтенләй үзгәртеп җибәргән, ахрысы, Нурисламны ачык чырай, үгет-нәсихәт белән озатты: — Син, Таһиров, бу юлы судта кәҗәләнеп маташма. Беркетмәдәге минем язганнарым белән ризалаш та, тиешле срогыңны алып, моннан ычкын. Аңла, кара ягылган икән, бездән котыла алмыйсың. Котылганнар рекомендациясез партиягә керә ала, ә син юк. Әсир булу фактыңны мәңге юа алмыйсың. Димәк, тегеләй дә, болай да сиңа срок. Өлешеңә тигән көмешең...

Нурисламны төн уртасында уятып, ят бер подполковник янына илтеп керттеләр. Суык камерада, үткән кыш поляк Заря белән яткандагы кебек, ике кеше бергә кысылып җылыга чумгач кына уятып алгангамы, әллә нервлары тәмам какшагангамы, подполковник каршысына баскан-да бизгәк тота диярсең, теше тешкә тими, туңа, калтырана иде ул.

Подполковник ап-ак туннан, изүе ачык. Гәүдәгә таза. Горур. Өстәлне, кабинеты да үз дәрәҗәсенә тиң: олы, иркен, хәтта берничә артлы урындык та бар.

— Утыр, Таһиров! — дип подполковник урындыкларның өстәлгә якынына күрсәтте.

Утыргач та Нурислам калтыраудан туктый алмады. Подполковник та моны искәртеп алды.

— Нигә калтыранасың? Тынычлан. Калтыраганнарны яратмыйм,— диде.

Гаҗәеп хәл, шушы кинаяле боерудан соң, Нурислам шундук тынычланды.

— Мин МГБ идарәсенең тикшерүләр бүлеге начальнигы Чурляев. Менә гаепләүләр акты. Укып чык та, кул куй,— дип Нурисламга бер бит язу сузды. Һәм өстәл артыннан чыгып, әрле-бирле йөри башлады. Нурислам тиз генә укып чыкты да:

— Кул куймыйм,— диде.

— Нигә?

— Монда язылган җинаятьләр яла булганга.

— Җүләр, танышу турында гына ич. Өстеңә бернинди дә җаваплылык алмыйсың. Куй.

Нурислам урыныннан торып, Чурляев сузган каләмне кулына алды: «Таныштым. Яла»,— дип язып куйды.

Подполковник әрле-бирле йөреп торса да җилкә аша күзәткән, ахры, кинәт Нурисламга ташланып, кулын каләме-ние белән кысып алды. Тавышы колакны ярырлык иде.

— Нишлисең, хәшәрәт?! — Йөзе зәңгәрләнгән, күзләре калайланган. Бу кычкыруы белән Нурисламны куркыта алмады ул. Шул мизгелдә егетнең хәтереннән малай чагыннан бер күренеш сызылып узды. Төпсез итек кигән малай, әнисе итәгенә ябышып суга бара, әллә каян гына атылып чыккан ата каз ыслап аның өстенә ташлана... Их, самими курку мизгелен кайтарырга иде хәзер...

— Утыр урыныңа! — дип, подполковник үзе дә тынычланырга теләпме, аякларын чалыштырып өстәл өстенә менеп утырды. Ялтыр итек башы Нурисламның борын төбендә калтырап тора иде.

— Күрәм, Таһиров, син чик буендагы бу төрмәне ошаттың, ахрысы. Гроднода сине антисоветчиклар Черчилльның фултондагы чыгышы белән таныштырганнар булса кирәк. Америка гаскәрләрен биредә каршыларга чамалыйсыңмы? Юк, Таһиров, андый-мондый хәл булса, әйтик, без моннан китә калсак, сине мәңгегә бикләп китәрбез!

Шулчак Нурисламның чаялыгы бәреп чыкты:

— Кая китәсез, гражданин подполковник?! Миңа калса, Совет Армиясе беркая да китәргә җыенмый...

Урынсыз сүз ычкындыруын шәйләп алган подполковник, кинәт җилпенеп:

— Син, татарва, акыл сатма. Минем сүзгә кармак салма! — дип кычкырды. Күн итек очы, калтыраудан туктап, Нурисламның борынына төртелде. Атылып кан китте.

Горур офицер, өстәлдән төшеп, мажикларча кабахәт итеп сүгенә башлады...

— Конвой, алып кит!

Полянский белән Чурляевның бер-бер артлы янауларына тәмам күнегеп, срок алмыйча төрмәдән котылмаячагына тәмам ышанды Нурислам. Капылт кына бөтен нәрсәгә дә битараф-чарасыз калды. Бусы — шушы ике ел ярым вакыт эчендә кичергән ачлык, кыйналу, төрле кимсетүләр нәтиҗәсе иде, ахрысы. Тора-бара үзе күргән, кичергән вакыйгаларга, ишеткән хәлләргә бәя бирү, аларны хуплау яисә кире кагу кебек хис-тойгыларга аңы үтмәсләнде. Иркен генә камерада алар икәүдән икәү. Өлкән яшьтәге бик тә әдәпле, бик тә мәгълүматлы поляк қанонигы үз тормышыннан яки дин, мәдәният тарихыннан кызыклы вакыйгалар сөйләгәндә, Нурислам аны бер тәэсирсез тыңлый: шатланмый да, нәфрәтләнми дә, хупламый да, бәхәскә дә керми. «Булса икән», «торса ни», «үтерешсәләр ни» кебек сыек мәгънәле сүзләр әйтү белән генә чикләнә дә ишекле-түрле йөрүен генә белә. Хәзер инде ул гадәти тормыштагы кешеләргә хас яшәү, көрәшү, сөю кебек сыйфатлардан ераклашкан, сүрелгән, сүлпәнләнгән иде. Аның мондый үзгәрүенә игътибар иткән кеше булса, бу бәндәнең җанын битарафлык юшкыны басып килә икән, дияр иде мөгаен.

Әмма бер яклап, шушылай сүрелсә-сүлпәнләнсә дә, икенче яклап уйлану, анализлау сәләтен җуймаган иде әле ул. Ул хәзер «тигезлек», «дуслык-татулык», «гаделлек» дип атала торган бөек төшенчәләр турында уйлана иде. «Волга — русская река» — диләр. Идел буенда яшәүче башка халыкларның да өлеше анда юкмыни? «Великая русская нация» диләр. Нигә рус кына бөек? Утыз алтынчы елны, бала вакытта үзен укыткан карт укытучы абыйсы: «Үз илебездә җирсез без, су буенда сусыз без», — дигән иде. Бу сүзләрнең мәгънәсе ул чакта башка килмәгән...

Хәзер инде Нурислам срок алачагын, лагерьга җибәреләчәген алдан ук белеп тора, шуңа күрә судка бару, судьялар алдына басу кебек шөһбәле, дулкынландыргыч көнне ул кадәр көтеп алмады. Гөнаһлымыгөнаһсызмы, анда барыбер үзен аклый алмаячагын белә иде ул.

Шуңа күрә, судтан ул ун елга лагерьга җибәрергә, аннан чыккач, өч ел хокуксыз йөртергә, дигән җәза алып кайткач та, бу җәзаның коточкыч икәнлеген уйлап бетерепмәде. Җаны ваемсыз иде. Хөкем утырышы ябылгач, судья полковник Семенов белән санаулы гына минутлар булса да сөйләшеп алу хәтлесе генә хәтеренә уелып калды.

— Без синең белән якташлар бит, Таһиров. Казанда бер үк елларда укыганбыз. Син — университетта, мин — юридик институтта. Бер чорда тәмамлаганбыз.

— Аннан кемгә нинди файда соң...

— Бөтен бәла да шунда шул, Таһиров. Рәнҗе-рәнҗемә, ярдәм итә алмыйм. Тегеннән әйтелгәч, — Семенов бармагы белән түшәмгә күрсәтте, — мондый карарны якташыңа түгел, тудырып үстергән анаңа карата да чыгарырсың...

— Сафсата! Мин түгел, минем кебек гадел солдатны хөкем иткән сез җинаятьче...

Семеновның горур чырае турсайды, үпкәләве тавышына чыкты.

— Теләсә нәрсә уйла, Таһиров. Миннән генә торса икән... Хуш! — дип, Нурисламга күтәрелеп карамыйча гына, суд барган камерадан чыгып китте.

Нурислам өчен иң авыры шушы сөйләшү булды.

## X

Гродно, Брест, Вилейка, Минск төрмәләреннән китерелгән бер эшелон арестантны Орша шәһәренең күчерелүчеләр төрмәсе ишегалдына керткәч, нигәдер көн буе диярлек тышта тоттылар. Җепшек карлы март аеның искиткеч җылы көне иде бу. Нурислам кебек озак айлар-еллар буе таш капчыкта ятканнарга җәннәт иде. Җитмәсә, төрмә ихатасында төрле эш белән мәшгуль конвойсыз тоткыннарга якын килергә, сүз катарга да ярый икән. Бу мөмкинлектән файдаланып, бер тоткын Нурислам янына килде дә плащ-палаткасына күрсәтеп:

— Сат! — диде.

Нурисламның бик ачыккан чагы иде, озак еллар гадел хезмәт иткән, өрсәң оча торган ярым ефәк плащ-палатканы, бәгыреннән өзгәндәй, сатып җибәрде. Хакы: бер кирпеч ипи, бер котелок пешкән бодай. Караңгы төшеп камераларга кертә башлаганда аның корсагы бүдәнә кебек тыгыз иде.

Камера дигәннәре ябык ындыр табагы кебек озын зал икән. Андагы тоткын! Иге-чиге юк сыман. Меңгә җитәдер, билләһи. Кеше өстендә кеше.

Таң алдыннан, тәпәч башына сумалалы чүпрәк урап ясалган факеллар күтәреп, өрлек кебек таза егетләр керде. Унлап бардыр. Алар, сүз катып тормыйча гына, тоткыннарны әйдәп, кайсын якаларыннан эләктереп, камераның бер яртысына тупладылар. Икенче яртысы буш калды. Аннары һәр тоткынның кулларына көнлек норма — ипи кисәге тоттырып, камераның буш калган башына озата тордылар. Ә анда караңгы. Бераздан шул караңгылыкта шау-шу, гауга купты, күрәсең ипи талаулар башланды. Аңа карамастан өләшү дәвам итте.

Нурислам да өлешенә тигән көмешен — кызыл балчыкка тартым ләчтә кисәген алды. Һәм тиз генә яртысын диярлек тешләп авызына тутырды, калганын инде, булдыра алганча ваклап-изеп күлмәк астына төшерде. Шул сәбәпле, караңгы якка күчкәч тә «кемнәрдер» аның өлешенә тия алмадылар. Күлмәк астындагы вак кисәкләрне алып, аларны ашыкмый гына чәйни-чәни, тыгыз халык арасында, «Браун хәрәкәте»ндәге молекула шикелле, тегендә бәрелеп, монда сугылып, тик буталып йөри бирде. Ипекәй ашалып беткәндә таң атып камера яктырды.

Шулчак ишек янә ачылды. Бу юлы ылыс төнәтмәсе керттеләр. Витамин «С» диеп йөртелгән бу шифалы эчемлек бөтен кешегә дә түгел, савытлыларга гына эләкте. Кемдә тар муенлы чүлмәк, кемдә кәнди, кемдә котелок... Ләкин бу савытлар шул арада «блатной» дип атала торган төркем кулына күчте. (Бу сүзне Нурисламның беренче тапкыр ишетүе.) Димәк, ылыс кайнатмасы да аларга гына тәти икән...

Ишек ябылды. Блатнойлар шайкасы янында гына, Нурислам күзәтә: атаманнары булса кирәк — урта буйлы, төссез, шешенке чырайлы утызкырык тирәсендәге салкын күзле бәндә, кушаматы — «Горячий», нечкә муенлы чүлмәктәге сыекчаны озак итеп эчкәч, тын алырга туктады, ахрысы, чүлмәген ияк турына төшереп, тәмен тәненә сеңдерергә теләгән сыман, ялманып, хозурланып торды. Нурисламның күптән инде шешенкеләнгән теш казналары тагын да ныграк сызлап, сулкылдый башлады сыман. Шул ылыс кайнатмасын аз гына йотып куйса да шифасы тияр иде бәлкем. Авыз суларын йотып ул Горячий янына килде, күптәнге танышы кебек, чүлмәккә үрелде:

— Мин дә татып карыйм әле, братка славян. Юкса...

Ай, Аллам! Кулы тиеп киттеме, чүлмәк көтмәгәндә идәнгә төшеп челпәрәмә килде. Шунда ук Горячий, аның бугазына ябышып, буа да башлады. Мондый хәлдә Нурислам алдын-артын уйлап тору дигәнне белми — нәселдән килгән гадәт — кайнарланып, күз ачып йомганчы бандит кулыннан ычкынды да, колакларыннан эләктереп, тешләре белән аның баш түбәсенә кадалды. Горячий шырыйлап кычкырып идәнгә чүкте. Башыннан кан китте. Нурислам курыкмады. Авызына эләккән чәч

йолкымын жирәнеп түкеренә бирде. Ул арада кемнәрдер ишекне дөмбәсли башладылар: — Җәтрәк керегез, үтерешәләр!

Блатнойлар шайкасының борын асты кипмәгән унбиш-уналты яшьлек малайлары — аларны шестеркалар дип атыйлар икән — чүл бүреләре мени, Нурислам өстенә дәррәү ташландылар. Кулларында — ботинкадыр, кунитектер, берсе хәтта очлы кырлы чүлмәк төбен тоткан. Арадан берсе — озын буйлысы ботинка табаны белән Нурисламның сул яңагына менеп тә төште. Күз алдында — көлтә ут. Кызу канлы татарга җитә калды бу.

— Ә-ә-ә, сез шулаймы, бетләр! Мә, алайса, мәгез! — Нурислам башта берсен, аннан икенчесен тибеп екты да залга кычкырды:

— Нәрсә сез, мужиклар?! Әйдәгез, бу бетләрне сытып ташлыйк!

Тоткыннар кара болыт кебек кузгала башлады. Идәнгә чүккән Горячий жилнең кай яктан исә башлавын, аның ни белән бетәчәген шәйләп алды, күрәсең, яраннарына шундый әмер бирде:

— Тимәгез земеляга. Бирегез, туйганчы эчсен!

Әмма Нурисламга ылыс суын эчәргә язмаган иде. Шулчак ишек ачылып китте. Өч-дүрт надзиратель һәм ак халатлы табип килеп керделәр. Надзирательләр барча блатной шантрапаны, сыекчалары-ниләре белән, камерадан алып чыгып киттеләр.

Эт тормышына да бер кояш нуры төшәр икән. Кичкырын иде. Нурислам падишаһлар җәяү йөри торган җиргә барып кына житкән иде, кормушка ачылды да, аннан берәүнең йөзе күренде:

— Әй, туганнар, славяннар! Арагызда берәр математик юкмы? — дип сөрән салды.

Исе-акылы китте Нурисламның. Бу бәндә аның математик икәнен белгән дә юри кылана диярсең. Алай да сабыр калды. Дәрәҗәсен төшерми, янәсе, горур кыяфәттә җавап кайтарды.

— Славян булмасак та математик без...

Кормушкадан йөзен күрсәткән кеше бу сүзләргә ышанмады, ахрысы, күзләрен түгәрәкләндереп кабат сорады:

— Чынлапмы? Бушкуыкланма!

— Мин славян түгел, дөресен сөйлим.

— Чак кына көтеп тор алайса, тиздән килермен, яме.

Кормушка ябылды. Китә димени, Нурислам, әлбәттә, китми, йомышын үтисе бар бит әле аның. Бераздан кормушка түгел, ишек үзе ачылды. Ак халатлы бәндә Нурисламны каядыр алып та китте.

— Чынлап та математикмы?

— Шикләнмәгез.

— Кем? Каян? Ничек?

— 58.1.б. Ун ел...

— Аңлашыла. Уртак язмышлы бәхетсезләр икәнбез. Мин сезне хәзер төрмә медсанбүлеге начальнигы янына алып барам. Сизеп торам, үз йомышы. Шуңа күрә, нык сөйләш, каты тор. Арзанга төшмә, сатулаш. Аңлашыламы?

— Әйе.

Биек бинадан чыгып, икe катлы озын бинага керделәр. Ак халатлы кеше бер бүлмә ишеге төбендә тукталды да, Нурисламның аркасыннан кагып:

— Чумыгыз! Ябагадан — йон, бүдәнәдән май сезгә! — дип, ишекне ачты. Җыйнак кабинет. Берничә урындык, бер шкаф. Һәм ак материя белән капланган гади өстәл. Аның артында ягымлы гына карашлы майор. Үтемле караш, кыяфәте — яһүднеке. Нурисламны өстәл янына чыгып каршылады.

— Кем дип белик?

— Таһиров.

— Татармыни?! Ә-ә-ә, әйбәт. Сезнең халыктан дусларым күп. Рәхим итеп утырыгыз, — дип, урын күрсәтте, үзе дә утырды. — Бу шартларда

хәлегез турында сорашып тору яралының җәрәхәтенә тоз сибү белән бер инде ул. Төп эшкә кучик булмаса. Сез математик буласыз, әйеме? Укытканыгыз бармы? Әйтик, урта мәктәптә.

— Бер ел.

— Әгәр мин тугызынчы класс укучысына өйдә укытучы, ягъни репетитор була алмассызмы, дип сорасам, ни әйтерсез?

— Шартлар тудырылса, риза диярмен, әлбәттә.

— Нинди шартлар инде ул?

— Иң мөһиме — дәреслекләр, таблицалар, логарифмик линейка. Алардан кала мунча керү, кырыну, тырнакларны кисү, чиста киемнәр кию. Һәркөнне теш чистарту. Укыр өчен әдәби китаплар. Шушылардан соң тагын кешечә ризык булса... җылы, тыныч бүлмә...

Өстәле артыннан чыгып майор йөреп алды.

— Рәтле ризык табу авыр мәсьәлә. Безнең илдә җунле ашка авызы тигәннәр аздыр ул. Хәзинәдә барын табарга тырышырбыз. Калган шартларыгыз, һичшиксез, үтәлер. Сүз куештык. Риза, диешсәк, мин сезне хәзер үк лазаретка салам. Сораган кешегә ашказаны ярасы белән ятам, диярсез. Аерым бүлмә һәм, телисез икән, һәр көнне кичен мунча булыр. Элекке партизан дисез ич, партизаннар үткен булалар, калган ягын үзегез карарсыз. Мин дә онытмам.— Нурисламга ошарга теләве идеме, ягымлы куштанланып көлде майор. Күрәсең, аңа репетитор бик тә кирәк иде.

Ак халатлы кеше Нурисламны икенче каттагы бәләкәй буш бүлмәгә урнаштырды.

— Хәзер сөйләгез инде. Моська әти нигә чакырткан?

Нурислам сөйләп биргәч, рәхәтләнеп көлде:

— Менә ничек тарта икән ул җил тегермәне! Суы каян килгәнен генә белмибез, ә! ... Ой, жид! Ой, моська!.. Хәзер ныклап танышыйк инде алайса. Миндә дә сезнең статья: 58.1.6. Срок шул ук — ун ел. Фамилиям Кузнечик. Хәзергә шушы лазаретның хирургы, иртәгесе — Алла кулында. Бүлмәм коридорның теге ягында, нәкъ сезнең каршыда. Димәк, без сердәш булырга тиеш бәндәләр... Сөйләшер вакыт булыр әле, хәзергә хуш иттек.

Шушы бүлмәдә «чирләп» калды Нурислам. Иртәнге якта ук Кузнечик логарифмик линейка, таблицалар, математикадан берничә китап кертте. Алексей Толстойның «Хождение по мукам» китабы, теш порошогы, щеткасы да бар.

Тагын ике көннән сестра-хозяйка бүлмәсенә чакыртып, болай ярыйсы гына пинжәк, чиста чалбар кидерделәр дә, борынгы татар кияүен беренче тапкыр кәләш куенына керттеләр мени, ак чыбылдык артына кертеп җибәрделәр. Анда, чыннан да, кәләшкә яраклы матур кыз утыра иде. Димәк, майор кызы шушы була инде.

Танышуны озакка сузмыйча, шундук эшкә тотындылар. Таня математикадан начар укымый, киресенчә, бик яхшы белә икән. Шуңа күрә хәзердән үк математиканы тирәнрәк өйрәнәсе килә, максаты — Мәскәүнең Бауман исемендәге физика-техник институтына керү, атом буенча белгеч булу. Азып-тузган, иркә бер шалопай малайга тарымыйм тагын, дип йөргән Нурислам өчен ипле, җитди фикерле кызны күрү үзе бер куаныч иде.

Кыз авыр-авыр, стандарт булмаган мәсьәләләр тәкъдим итә, егет алдына көтелмәгән теоретик сораулар куя. Алар турында бергәләп уйлашалар, мәсьәләләрне бергәләп чишәләр. Мәктәп программасындагы мәсьәләләр генә булмагач, аларны чишү Нурислам өчен дә кызык.

Таня өч көнгә бер килеп тора. Үзе белән бутерброд, тәмәке, сөт, сирәк кенә каймак та алып килә. Китаплар турында да онытмый.

Нурислам врач Кузнечик белән һәр көнне кич шахмат уйный, врач оттыра, әмма күңеленә авыр алмый. Бу — аның Нурисламны санга сукмавы. Үз-үзен тотышы, ара-тирә шундый сүзләр ычкындыргалап торуына караганда, Нурисламның университет бетерүен дә, беренче разрядлы

шахматчы булуын да Алланың ялгышы дип кенә саный. Ничек инде Идел аръягындагы сәхраләрдән чыккан татар кыргыйлыктан алай тиз генә арына алсын. Ул үзе Воронежда медицина профессоры гаиләсендә туып үскән. Утыз ике яшендә — полковник. Сугышның беренче көнендә үк Белосток шәһәрендә немецлар кулына әсирлеккә эләккән. Качып котылган да бит... барыбер ун елны чәпәп куйганнар. «Эшләр шулай, Таһиров, Россиянең хуҗасы жид булгач... Шверникны күздә тотып әйтәм... Хәзер илдәге жидларның яртысы Мәскәүгә килеп урнашкан, калган яртысы Мәскәү юлында... Шулай булгач, без сезнең белән алар колпагы астында», — ди.

Кузнечик авыруларны көндәлек йөреп чыгу вакытында, күз буяу өчен генә, Нурислам янына да сугыла, хәйләләп буламы, дигән сыман, мыек астыннан кинаяле елмая. Нурисламның аңардан бәйсез булуыннан көнләшә, кытыгы килә бугай.

— Әйдә, әйдә, кылан, булдырасың! — дип, чыгып китә.

Майор үзе дә күренгәли. Кул биреп күрешә. Әмма озаклап сөйләшеп тормый, хәл-әхвәл сорый да тизрәк китү ягын карый. Күрәсең, вакланудан курка.

Авыруларга пешерү өчен дип бирелә торган азык-төлектән поварлар үзләренә аерым пешерәләр. Шуннан Кузнечикка да өлеш чыга икән, хәзер инде араларына Нурисламны да алдылар.

Бүлмә почмагында күптән инде ягылмаган иске мич тора. Аның тимер авызы да ачылмаслык итеп бикләнеп куелган. Учак-ут белән бәйле булгангамы, мич кешедә аңлатып бирә алмый торган тойгылар уята. Нурислам да мичнең акшары астыннан сызыклары беленеп торган кирпечләрне сыйпап карады. Җил тавышы ишетелмиме дип колагын куйды, әмма мич эче тып-тын, җансыз иде. Әгәр рөхсәт итсәләр, менә хәзер бу мичне сүтеп үк яңадан җыяр иде — күңелен басу өчен, әлек авыр тоелса да хәзерге халәтеннән караганда бәхетле тоелган үткәненә хәтерендә генә кайтып юану алыр өчен...

Утызынчы елны Нурислам Казан педагогия техникумына кабул ителде. Тулай торакка урнаштырсалар да, ашау-эчү ягы укулар башланганчы булмас, диделәр. Ә укулар ай ярымнан гына башланасы икән. Нурисламга нишләргә? Кайтыйм дисә, юлга акчасы юк. Өйдән алып килгән бер шешә сары май күптән бетте, сохари да саегып бара. Авыр эшкә ярамый, җиңелен таба алмый. Ачтан үләсе килмәсә, йә хәер сорашырга, йә урларга гына кала. Һәм урлашты да ул.

Ул елны Кызыл Армия яныннан түбән төшеп, Казан елгасын кичсәң, помидор түтәлләре башлана иде. Малай шунда ияләште. Төннәрен барып, күтәрә алганчы помидорларның пешкәннәрен генә капчыгына тутырып кайта да, көндезләрен Печән базарына чыгарып сата. Шуннан ипичәйлек акча чыгара. Атна чамасы шулай йөргән иде. Көндез помидор сатып утырганда янына бер карт килеп басты. Эштән кайтып килүе ахры, өс-башы балчыкка буялган. Нурисламны сөйләштерә башлады. Аның моң-зарын белгәч:

— Мине тыңласаң, урлашмыйча да тамагың тук, өстең бөтен булыр, — диде.

Тыңламыйммы соң, аның бит һич кенә дә бур-карак исемен йөртәсе килми. Курка да. Эләгә-нитә калса, кыйнап ташлаулары, кешелектән чыгарулары бар.

— Иртәгә, иртәнге намаздан соң ук шушында кил! — дип ул малайның кулын кысты. Соңгы биш-алты помидорын алып, хәтсез генә акча калдырды да саубуллашып китеп барды.

Нурислам иртән сүз куешкан урынга килеп кенә житте, кичәге карт та күренде.

— Әс-сәламе-галәйкүм, шәкерт. Аллага тапшырып, әйбәт кенә йокладыңмы? Исән-сау гына килдеңме? — дип, Нурислам белән, кул биреп, матурлап күреште. — Әүвәл шуны әйтим, эндәшкәндә син мине Әхмәт-

жан бабай, дисәң, мин сине Нурислам шәкерт, дип атармын, мөхтәрәмлек — күңел байлыгы. Күңел байлыгы — бәхет чишмәсе. Шушылай сүз куешыйк та һәр икебезгә дә бәхетләр юрап, җиңел кулдан Аллага тапшырыйк,— дип, малайны ияртеп, әле төнге йокысыннан уянып җитмәгән Печән базары аша каядыр алга атлады.

Үтә дә киң күңелле, үтә дә ягымлы бу бабайның алтын куллары җиңел булган икән, бер ай эчендә Нурислам әллә ни көчәнми-ватылмыйча гына аңардан мич чыгару һөнәрен үзләштерде. Бу һөнәрне укулар башлангач та ташламады. Һәркөнне диярлек, дәресләр беткәч, эшкә йөгерә торган булды. Казанда җимерек мичле өйләр бихисап иде. Бер мич чыгарганчы яннарына әллә ничә кеше белешергә килә. Көтеп алалар. Ике кичкә — бер мич, ун сум акча. Аның өч сумы — Нурисламга. Ашаутуклану хәтлесе дисәң, анысы кунак сые. Пилмән, сумса, гөбәдияләрнең тәмен Нурислам гомерендә беренче тапкыр шунда татыды.

Әлеге һөнәр Нурисламның тамагын туйдырып кына калмады, алга таба педагогия техникумын тәмамларга, алай гынамы, заманына күрә курчактай киенеп йөрергә, аннары университет бетереп диплом алырга да ярдәм итте. Авылга, ялгызы калган әнисе янына ул яулык, кибет оегы яки җаена карап өч-дүрт метр күлмәклек тукыма алып кайтып күңелен күрергә дә өлгерде...

«Әни нишли икән хәзер? Абый-энекәшләр исәннәр микән, аларны язмыш җиле кайларга ташлады микән?..» Җилдән гүләми торган тыптын мич янында Нурислам яшьсез генә, эчтән елап, үткәннәрен искә төшерде.

Бер карасаң, бүгенгә аның тамагы тук, өсте бөтен, әмма сагынудан бәгырь сызлатып, шушы бүлмәдә ялгыз башың күпме ятарга була. Исән җанга хәрәкәт, онытылыр өчен ике кулга бер шөгыль дә кирәк.

Нурислам лазарет канцеляриясенә ияләнде. Аның писаре — шәп егет, дивгезче офицер. Нәрсә өчен икәнен әйтми, сигез ел чәпәгәннәр. Диңгезче кайда да диңгезче, такмазалар ярата. Шушы ягы белән Нурисламга ошый. Аның язу-сызуларында булыша, аның такмазалы «тарих»ларын тыңлый.

Бер көнне шулай күңелле генә эшләп утыралар иде, канцеляриягә бер көтү офицер килеп керде. Иң алда — мәһабәт генерал, иң артта Нурисламның майоры. Анысының төсе качкан, гәүдәсе көянтәдәй бөгелгән. Тәмам куркуга төшкән бичара.

Генерал кырку холыклы икән. Түргә үтеп, озын буе биеклегеннән писарьның «дело»лар шкафы өстенә авызын очлайтып өрде дә, аннан бөркелеп тузан күтәрелгәч, шкафны гөрселдәтеп идәнгә аударды. Аннары писарьның йөзенә бармагын төбәп:

— Кем? — Писарь җавап кайтарды, тагын сорау: — Статья? Срок? — Бусына да җавап сүзе ишеткәч, инде: — Ерак этап исемлегенә! — дип, ишеккә таба борылды, үтешли күзе Нурисламга төште: — Кем?

Ай, Нурислам, ай егеткәем... Шунда алдый белмәдең бит...

— Мин бирегә сырхау сыйфатында...

— Бусы ни дигән сүз тагын?!

Нурислам телен йоттымыни, җавап кайтара алмады, әнә, аннан сорагыз, дигән сыман, тутырып майорга карады.

Генерал барысын да аңлады бугай. Нурислам хакында:

— Ерак этап исемлегенә! — дип кычкырды, майорга борылып приказ бирде.— Чакырыгыз теге эшлексезне!

Күз ачып йомарга өлгерделәр микән, майор Кузнечикны ияртеп тә керде:

— Товарищ генерал...

— Ерак этап исемлегенә!

Кырыс генерал иярченнәре белән чыгып барганда иң соңгы булып кузгалган майор Нурислам янында азга гына тукталды. Күзендә яшь. Иреннәре калтырый.

— И-и-и иптәш! Үзенне генә түгел, мине дә харап иттең.
Ни әйтсен Нурислам. Язмыш шулай кушкандыр инде.
Бер сәгать вакыт үтте микән, Нурислам һәм аның белән бергә горур Кузнечик та, такмазалар остасы диңгезче офицер да ерак этап белән китүчеләр арасында басып торалар иде инде.

## XI

Меңәрләгән бәхетсезне кара язмышка илтә торган озын товарняк Идел күперенә якынайган саен, Нурисламның ата-ана, Туган җир дип атала һәм бәгырьдә саклана торган бөек төшенчәләр турында уйланулары көчәя, тирәнәя барды. Бәләкәй чаклары искә төшеп, хис-тойгылары нечкәрде. «Язмыш син, язмыш! Каһәрле язмыш! Нигә туа да, нигә үсә бу адәм баласы?!»
Болай булыр дип уйлаган идемени. Кайда син, гөнаһсыз малайчак?!
Әле дә хәтерендә — егерменче ел булырга тиеш — әтисе бодай чаба, әнисе көлтә бәйли. Бер кишәрлек җирдә чуп-чуар кеше. Нурислам абыйсы белән коелган башак җыя. Теле ачылып килә торган энекәше Нургалигә генә эш юк. Ул арба күләгәсендә. Теләсә елый, теләсә уйный, тели икән, чебен талый дип тормый, ята да йокыга китә. Көн шундый эссе, туфрак шундый кызган, ялан аяк килеш хәтта камылда йөрүе дә авыр. Табан пешә. Билгеле инде, шук та, мут та Нурисламның мондый эсседә эшлисе килми. Әбөткә кайтып кына җитсеннәр, исәбе — төштән соң башак чүпләргә бармау. Нурислам аштан баш тартып, баз куышына кереп ятты. Салам ябылган куышта салкынча, рәхәт иде. Янәсе, малайның эче авырта. Башта бәләкәй Нургали, аннары түтиләре, иң соңыннан әнисе чыгып: «Кер инде, ашың суына»,— дип үгетләп, кыстап та карадылар, юк, кермәде. Чирли, вәссәлам.
Черки кушаматлы мут малай чирли дип, табында берьюлы сигез кашык уйната торган ишле гаилә башы Чепи Гомәр (яшь чагыннан ук куш керфек үсә торган булган аңа, шуңа Чепи дигәннәр), уттай урак өстендә өйдә ятмас ич инде, янә — басуга!
Әти-әнисе, туганнары атка утырып чыгып киткәч, капка ябылырга гына өлгерде, Нурислам ялт — аяк өстендә. Эче авыртмый, ә өзелеп-өзелеп ашыйсы килә. Өйгә кереп, үзенә дип калдырган сөтле умачны бөреп чыкты. Әмма тамагы туймады. Тагын нәрсәдер ашыйсы килә, эче эзләнә. Ә-ә, менә! Шундук бакчага йөгерде, бәләкәй генә бер кыярны элəктереп тә чыкты. Аның янында калган уймак Нургали аннан киммени? Ул да ә дигәнче бер кыярны күтәреп килде.
Берничә тапкыр урадылар бакчаны. Ләкин кыярның төчесе, сусылы эләкмәде. Шуңа күрә эч эзләнүе дә басылмады. Кетәклеккә менеп, тавык оясын капшап төште Нурислам. Анда шып-шыр. Кар базында каймак та, катык та бар да бит, капкачы йозакта.
Аптырагач урамга чыкты Нурислам. Аның тирәсенә күрше малайлары-кызлары җыелды. Шуннан соң китте уен! Китте уен! Шулхәтле кызык уйналган, бакча нигъмәтләре белән шулхәтле мул сыйлаган Нурислам, кичке якта әнисе кайтуына кыяр белән бармактан юанрак булып килә торган кишер түтәленнән тап-такыр «көтү туплавы» гына торып калган. Энесе Нургали аны шундук әнисенә сатты:
— Нузый кыял бән киселне малайга асатты,— диде.
Олылар теленә күчерсәк, «Нурислам абый кыяр белән кишерне малайларга ашатты», диюе.
Әниләре Нургалинең ярты сүздән үк аңлап, түтәлләрне күздән кичереп чыккач, башын чайкап торды да Нурисламның башын җылы күкрәгенә кысып, «И-и балам, и тынгысызым. Кемнәр генә чыгар икән синнән?! Бәхеткайләрең була гына күрсен инде»,— дия-дия елап алды. Аның каравы, әтисе кайткач, малайның кирәген бирде: ыштанын төше-

реп, шәрә артын кычыткан белән пешерде. Ул гына түгел, сыек чыбык тәмен дә татытты...

Нурисламның урыны вагон сәкеләренең икенче катында, стена кырыенда. Шуннан кергән җил бәрде бугай, янбашы сызлап уянганда таң аткан, поезд туктап тора иде. Төн яңгырлы иде. Нурислам стена ярыгыннан тышка караганда, тирә-юнь яңгырдан соңгы куе томан эчендә иде. Һични күрерлек түгел. Кемнәрнеңдер үзара сөйләшү-сукрану авазлары ишетелә. Әнә, рус телендә әшәке сүгенеп бер ир-ат үтеп китте. Менә хатын-кызлар тавышы. Татарча сөйләшәләр. Нурислам әсәрендә. Берсе зарлана:

— И-и-и малакаем! Оятсызлар, җир битләр алар, левчигына яшергән әзме-күпме акчасын, хлиб карточкаларын да алганнар. Хәзер кая бара да, кемгә, ни рәвешле сүләп бирә ала инде ул?! И Аллам, ахырзаман килүедер, ипекәең үзеңнеке дә, үзеңнеке дә түгел...»

Нурислам тыңлап бетерә алмады, ямьсез дөбердәп вагон ишеге ачылды. Конвой тавышы:

— Әй, мужиклар! Торыгыз! Казань, татарва. Ипи, иртәнге чәй. Берәм-берәм ишек янына!

Ипи, дисәң тору гына түгел, утка-суга ташланырга да риза ач тоткыннар. Ишек төбенә дәррәү килеп бастылар. Аларның кулларына солдатларның берсе ипи кисәге тоттыра, икенчесе тустаган белән җылы су бирә. Өченчесе «борын башына бер уймак», дип көлә-шаярта, ул арестант сузган чүпрәк кисәгенә уймак чаклы гына чүмеч белән шикәр комы сала. Дүртенчесе исә кычкырып санап тора: «Бер борын, ике борын, өч борын... Илле борын. Җитте, бетте». Шулай... вагонда илле генә «борын». Чирләүче, үлүче, качучы хәзергә юк. Ачылгандагыча ямьсез дөбердәп ишек ябылуга барча тоткын иртәнге чәйгә утырды. Берәүләр ипиен баллы суга турап пюре ясый. Икенчеләре ипинең чиреген куенына яшерә — кичкә калдыра, калганын гына чәйни башлый. Нурислам да ипи сыныгын шикәр комына манчыды да шуннан соң гына тешләп алды. Аны озак чәйнәгәч, бераз җылы су өстәп, йотып җибәрде. Тәмле, ашаган саен ашыйсы килә. Ләкин туйганчы ашый алмады — ипекәй алты йөз грамм гына бит, тиз бетте. Янындагы ике поляк үзара сөйләшә.

— Прошен пана, инглиз шахтеры сугыш вакытында карточкага дүрт йөз грамм ипи алган, алай да үзен ач тоймаган, ә без...

— Алай димә, пан Казьмиж, аңа тагын дүрт йөз грамм ит, сөт, май, шикәр, кофе өстәлгән. Монда исә су, кәбестәдән гайре мат та перемат кына.

Полякларның үзләрен өстен куеп, руслардан көлүләре Нурисламны күптән туйдырган. Шуңа күрә аларны тыңлап тормыйча стенага таба борылды да ярыктан тышны күзәтергә тотынды. Баягы хатыннар да үзебезчә сөйләштеләр, солдат та «Казань, татарва» диде, әллә соң туктальш, чыннан да, Казанда микән? Башкаланы ярыктан гына булса да күреп каласы иде бит.

Бәхеткә, томан сыеклана төшкән. Әнә еракта, бик еракта, өрфия томанга төренгән авыш Сөембикә манарасы гына моңаеп тора. Ун елга якын Казанда яшәп, шәһәрне читләтеп тимер юл үтүен, шунда станса барлыгын белми иде Нурислам. Шактый ара күзләп, чамалап торгач кына, аны Себергә илтүче товарнякның «Восстание» дип аталган бистәдә, кырыгынчы завод артында туктаганын аңлады.

Вагон кинәт тартылып алды да акрын гына кузгалды. Сыек томанга төренгән авыш манара ераклаша, бәләкәйләнә барып артта калды.

Вагон ярыгыннан кергән җил сөякләргә кадәр үтә. Нурисламның малай чактагы чире — янбашы сызлый башлады. Авырткан җир дә үкенечле хатирәләргә бәйле шул...

Җиденчене тәмамлыйсы елны (егерме тугызынчы ел) язгы каникуллар нәкъ ташу төшкән көнне башланды. Соңгы дәресне ничек кирәк алай үткәргәч, ерык авызлы Нурислам дигән малай өйләренә йөгерде. Авыз

ерылмый димени — иртәгә өчен дәресләр хәзерлисе юк, аннары — ташу карау. Кайтып керсә... әтисе түшәктә. Төсе кәгазь кебек. Чепи күзләре йомык. Битен киң сөлге белән бәйләп куйганнар. Нурислам куркуга төште:

— Нәрсә булды, әтәй?!

Карт авырлык белән генә күз кабакларын күтәрде:

— Сорама, улым. Хәлем мөшкел, энем...

Ул арада Нургали кайтып керде, ул да куркуда. Күзләре зур ачылган.

— Беләсеңме нәстәкәй! Теге эчкече Сәхәби жыя башлаган әртил күмхуж бар бит әле, шуңа мир үгезе кайтарганнар икән дә, бәеннән ычкынып, әллә ничә кешене сөзеп ыргыткан. Безнең әтәйне дә...

— Син, Нурислам улым, хәзер үк балниска илт инде мине.

Сүз куертып тору файдасыз. Әтисе «балнис» ди икән, димәк, барысы да аңлашыла, хәле чыннан да мөшкел. Больница Бөгелмәдә генә. Малай шундук юлга чыгу чарасына керешге. Якты күздә Бөгелмәгә барып житә алса, әтисен бүген үк больницага салу хәтлесен Мирсәет абзыйсы башкарып чыгар. (Мирсәет Таһиров шунда, кантон башкарма комитетында эшли.) Туры алашаны әнисе белән бергәләп жиктеләр, әтисен печән түшәгән, ястык салган чанага яткырып, Нурислам юлга чыкты.

Өч-дүрт чакрым ара жинел үтелде. Ләкин Качкыннар үзәненә төшкән ташуны кичкәндә, чанага су керде, Нурислам кендеккә хәтле үзе дә чыланды, әтисен дә чылатты. Алда озын юл — илле чакрым ара. Тагын шулай манма чыланып, андый ташу сулары аша берничә тапкыр чыгарга туры килде. Әтисенең хәле отыры начарланды. Шәһәргә житәргә бик аз гына калган иде, әтисе:

— Туктат, улым, бахбайны. Ул да ял итсен, мин дә тын алыйм, — диде.

Нурислам туры алашаны туктатып эченә төшкән суыктан куырылып әтисе янына килде.

— Булмады бу, улым. Әжәлем шушы чанададыр... Васыятемне тыңла.

Әтисенең бу сүзләре Нурисламны куркуга төшерде:

— Нинди әжәл ди, нинди васыять, әтәйкәем?! Барып житәбез ич инде.

— Юк, балам, житә алмам. Тыңла сүземне, нык тыңла. Берүк авылда калма. Мәскәү ялгыш юлда. Калхуз дип, крәстиянне бөлдерергә жыена. Ялчыга әйләнәбез. Авыллар бетәр. Кызык калмас, кит, улым. Апаең Нургалине дә иярт... Әнием сыер да, ике сарык кына тотсын...

Нурислам түзә алмады, елап жибәрде.

— Куркыныч сүзләр сөйлисең бит, әтәйкәем. Мин үзем генә...

— Кичер, балам... Бәхиллек... Мин сезне бикләр дә яратадырыем...

Шушы сүзләрдән соң әтисе тынып калды, кинәт караңгы төште.

Нурислам йокыга талган әтисе уянгалаганчы барып житим дип, шәһәргә таба алашаны куды да куды.

Мирсәет абыйсының фатир капкасы төбенә барып житкәч, чанадан төшеп, үз аяклары белән өйгә керә алмады. Гәүдәсенең билдән түбән өлеше, аяклары, чабатасы-ние белән чанага ябышып каткан иде. Нурисламны абыйсы күтәреп өйгә кертте. Фатир хужасы Анастасия Михайловна — тәтә Начта — ачулана-юата бер чәй йомыркасы борычлы аракы эчертте дә малайны анадан тума чишендереп, бөтен тәнен сылады. Аннары жылы мич башына менгереп яткырды. Нурислам изелеп йоклап китте. Иртән ул аякларына баса алмады.

Әтисенен вафат булуы турында да ул иртән генә белде. Кичке якта чанада чакта ук инде ул суынган булган икән.

Мирсәет абыйсы Нурисламны ничек кирәк алай больницага салды. Мәрхүм әтисен авылга алып кайтып жирләгәннәр. Нурислам больницада өч ай ятып чыкты. Шул елдан башлап чир-сызланулар Нурисламның аерылмас юлдашы булып калды. Аз гына көчлек килдеме, яисә салкын

тидердеме — янбашында шеш яңара да чыга. Моның шулай булачагын белгән кебек больницадан алган көнне Мирсәет абыйсы аңа:

— Синә, энем, хәзер инде аякларыңны юрганыңа карап сузарга кирәк. Авыр эшкә ярамассың. Өйгә кайтып, катык-сөттә ныгы да Казанга шыл. Уку, урынга керү ягын кара,— дигән сүзләрен колагына киртләп куйган иде. Ләкин әүлиялеге житенкерәмәгән икән, Нурисламның тормышы ул юраганча ук тигез генә бармады шул...

## XII

Ике рәтле чәнечкеле тимер чыбыктан торган ихатаның балта эзләре сагызланырга да өлгермәгән саргылт кайрылы нарат баганаларына игътибар иткәч, «Әһә, бу лагерь төзелеп кенә килә икән әле»,— дип уйлады Нурислам. Ике бүлектән, ике зонадан торган бу лагерьда адәм баласын җил-яңгырдан саклардай бараклар да, палаткалар да юк иде. Үткән кыш кына киселгән урманнан калган ботак-сатак, төп-тамырлар да, үсеп килә торган сусыл үлән дә урман чәчәкләре генә күренә. Күбәләкләр уйнап оча. Тимерчыбык ихата, пулемет урнаштырылган вышкалар һәм капка төбендәге шыксыз озын барак булмаса, бу лагерьда бер да адәм баласы йөрмәгән, эз калдырмаган икән, дияр идең.

Тоткыннарның озын колоннасы әлеге баракка якынлашуга аннан бер көтү солдат чыкты. Аларның башлыгы камыт аяклы, тупас гәүдәле өлкән лейтенант иде. Әүмән-тәүмән атлау рәвеше җим улагы яныннан кузгалып кына киткән тук үрдәкне хәтерләтә. Җитмәсә, кара тут йөзе шадра икән әле. Һәр нәрсәдән киная эзләүне дәрәҗәгә саный торган полякларга житә калды бу, кайсыдыр әче теллеләнергә өлгерде:

— Бу зат, прошен пана, безнең Варшава зоопаркындагы горилладан туган булырга тиеш.

Колоннада кычкырып сөйләшү-көлү тыелган булса да, күпләргә житә калды, кычкырып көлеп җибәрделәр.

Лагерьның сул ягына гына карап, ихата буйлап атлаган Нурислам уң якны игътибарыннан читтә калдырган икән. Шул якка борылып караса, анда төзек лагерь күрде: бараклар, ниндидер корылмалар, юллар-сукмаклар. Кешеләре мәзәк, ят киемдә. Баягы лыгырдык поляк шундук бәя бирде:

— Кояш чыгышы иленнән — японнар. Димәк, Атлантикадан алып Тын океангача таралган кешелек чәнечкеле тимер чыбык артында. Москаль, пся кревь, үзе ач-ялангач дип тормый, күршеләрен кол итү, империясен киңәйтү ягын карый. Кара инде син аны. О-о-о, тамка боська... Психологиясе бозык. Яуларга да таларга ярата.

Колонна башы капка турына килеп житкән икән, ямьсез бирелгән әмер авазлары яңгырады:

— Туктарга! Утырырга! Сөйләшмәскә!

Әле генә килеп туктаган ЗИСның артын ачтылар. Кузовта өч әрҗә. Аларда тулы ипи. Яннарында бер сержант. Шул кычкыра:

— Соң нәрсә, иптәш Хабибуллин! Башларгамы?

И-и-и тәңрем. Сержантның иптәш Хабибуллин, дигәне баягы поляк, «горилладан тудырган» камыт аяк икән ләбаса! Җавапны шул кайтарды:

— Вәләй!

Димәк, камыт аяк — татар, милләттәш. Үз хәлен онытырга тырышкан Нурислам башына кайгы төште: «Бичара, бигрәкләр дә кеше күзенә ташланып тора шул. Әшен әйбәт алып баралса ярый ла. Бу көтүне тыңлата алу өчен сәләт кирәк. И Аллам!».

Ул арада һәр тоткынга ярыйсы гына кисәк ипи, ике шакмак шикәр тоттырып, яшел үлән, чәчәкләр каплаган зонага озата башладылар. Зона олы, иркен иде. Теләсәң, рәхәтләнеп йөр. Теләсәң, сузылып ят та, зәңгәр күкне күзәт...

Нурисламның кәефе әйбәттән түгел иде, шуна күрә капкадан ерак китми генә басып калды. Күзе — японнар лагеренда. Эшкә җыеналар, ахры, өчәрләп-дүртәрләп баракларыннан чыгалар да тегендә бер, монда бер күренеп торган «гөмбәләргә» кереп, анда аякларындагы хәшәпләрен, өсләрендәге пинжәк дисәң пинжәк, пижама дисәң пижама түгел, ак нәрсәләрен салып, эш киемнәре кияләр. Аннары капка янына килеп, взвод-взвод булып сафка басалар.

Ул да булмады, капка ачылды, аннан чыккан һәр взводны кораллан-ган бер совет солдаты каядыр алып китте. Японнар зонада берән-сәрән генә калдылар. Алары капкага бара торган олы юлны, барак араларын тоташтыра торган сукмакларны сибереп, чүп-тузаннарын чиләкләргә җыярга тотындылар, сукмак-юл буена утыртылган чәчәкләргә су сип-теләр.

Японнар артыннан озак күзәтә алмады ул. Лагерьга совет тоткын-нарының тагын бер колоннасын китерделәр. Аларны капка төбенә утырттылар, аннары кулларына ипи-шикәр тоттырып, зонага кертә баш-ладылар. Беренче колоннада күбрәк поляклар, белоруслар иде, икен-чесендә исә мат та перемат — сүгенү, бугаз ертып кычкырышуларына караганда, руслар булса кирәк. Нурислам иң арттан атлаучы берсен туктатып:

— Кай яклардан, якташ? — дип сораган иде, теге бәндә, чынлап та бу таныш түгел микән, дигән сыман төбәп карады да:

— Сиңа Брянски бүресе якташ, шуннан сора! — диде.

Шуннан соң инде Нурислам бу колоннаның, чыннан да, Россиядән икәненә тәмам инанды.

Колонна койрыгында хатын-кызлар төркеме иде. Аларны лагерьга ике яклап тезелгән солдат арасыннан саф-саф итеп кертеп, күрше бәләкәй зонага таба юнәлделәр. Күптән хатын-кыз заты күрмәгән, наз-нәзакәткә сусаган меңәрләгән ач ир-ат аларны камап алырга әзер иде. Китте кычкырышу, аты-юлы белән сүгенү... Арада матур сүзләр әйтеп кайсы да булса бер чибәрнең игътибарын тартмакчылары да бар, хәтта, тәкатьсез-ләнеп, каешын ычкындырып, чалбарын төшерә башлаучылар да күренә. Хатын-кызларның лагерь шулпасы эчмәгән яшьрәкләре, кызарып, бу мәхшәрдән акылдан язар кебек кыяфәт чыгарып атлый иде. Шулай итеп, үткен күзле мең караш астында алар, бер йомгакка оешып, үз зоналары-на кереп киттеләр, капка ябылды. Бу якта әрсез карашлы, тел базмас әшәке сүзләр акырынып ирләр кавеме торып калды.

Халык кайный, мыж килә. Моннан бер-ике сәгать элек кенә, күпереп торган чәчәкле җир мәсхәрәләнә, таптала. Кемдер учак та кабызып җибәргән. Кыскасы, тормышның бер учка җыелган халәте монда: таны-шу да, элеккеге төрмәдәшеңне очрату да, сату-алу, алыш-биреш китерү дә, йодрыкка ирек биреп кан чыгарып алу да, талап, өс киемен чишендерү дә — барысы да шушында эшләнә.

Нурислам бер төпкә барып утырган гына иде, шунда үзенә эндәшкән тавыш ишетте:

— О-о-о, пан математик! Сәлам сезгә! — Күтәрелеп караса, каршын-да, кайчандыр бик фәлсәфә сатарга яратучан поляк Заря басып тора. — Вилейка тәмугын артта калдырдык, хәзер Себернекенә кереп киләбез, ә? Саумы, саумы, мөхтәрәм егетем! Атаклы Байкал буйларына барып чыгармын да, шунда сине очратырмын дип һич тә уйламаган идем.

Нурислам мондый очрашуны көтмәгән иде. Сихәте бик үк шәптән булмаса да, электән әзме-күпме күргән кешесен очратуга куанган сыман булды.

— Исәнме, пан Заря. Яңа лагерьга төкле аягың белән! Киемнәрең дә үзгәргән, үзең дә ябыгыбрак киткәнсең димме... — Заряның өстендә иске сырма, шундый ук сырган чалбар, аякларында ЧТЗ[1] иде.

---

[1] ЧТЗ — машина шиныннан тоткыннар өчен тегелә торган аяк киеме.

— Мин бит, хөрмәтлем, елдан артык Комида урман кискән кеше. Тулы хокуклы зек. Шуннан кайткан скафандр бу...

— Ничек анда барып чыктың?

— Кырык бишенченең җәендә, синнән аерылгач, ун ел лагерь плюс биш ел сөрген чәпәп, мине шунда — Комига озатканнар иде...

— Хәзер ялга кайтардылар мыни?

— Көт рустан. НКВД палачларының җанда казынуларыннан котылдым, дигән идем, алай гына котылып булмый икән шул алардан. Тагын алып кайттылар. Тагын сорау алулар, интектерүләр, җәфалау китте. Бу юлы шаһит сыйфатында.

Герман оккупациясе вакытында Белосток гестапосында бик тә юньсез, бик тә мәрхәмәтсез бер рус егете эшләгән иде. Күпләрне теге дөньяга озаткан бәдбәхет. Тумышы белән Воронеж өлкәсеннән икән, язулар юнәтеп алгандыр инде, сугыштан соң орден-медальләр тагып, өенә кайткан. Без капчыкта ятмый, диләр бит, эсэсэсэф дип аталган олы капчыкта да яшеренә алмаган бу. Кулга эләккән. Шаһит сыйфатында мине шул бәндә каршысына китереп бастырдылар.

— Шуннан?

— Шуннан... суд булды. Егеткә җәзаның иң җиңеле: маңгаена тугыз грамм кургаш, ә миңа — кабат интегү. Ач карынга юл йөрүләр авыр булса да, шәһәр урамыннан штык астында атлаулар хурлыклы булса да, Россиянең үзәген күреп китүдән канәгатьмен.

Халыклар тарихы гел үзара сугышлардан тора. Берәүләр җиңә, икенчеләре җиңелә. Әмма җиңелгән халыкны бөтенләй, башы белән юкка чыгару, аны мәңге дошман санап яшәү гадәте булмаган. Еллар үтү белән алар янә дуслашканнар, сәүдә итешә башлаганнар. Россиянең швед, француз, герман белән барган сугышлары да шулай беткән. Ә менә төрекләр, татарлар белән алай түгел. Аларны юк итәргә тырышу, шул нигездә күрәлмау, дошманлык гасырларга сузылган. Чамасыз үчлек, дошманлык тәрбияләүне гасырларга сузу — каш төзәтәм дип күз чыгаруга охшамыймы? Якын күршең татарны, атлаган саен, башкисәр итеп күрсәтү, сабыйларны шул рәвешле куркытып йокыга салу христиан әхлагына хилафлык кылу лабаса! Ахыр чиктә, үз баласыннан кеше сөйми торган шовинист, шәфкатьсез залим үстерә ич. Һәм ул шулай булып чыкты да. Бу империянең әхлагы бозык түгелмени: карагыз әнә, чәнечкеле тимер чыбык белән каймаланып алган бәхетсезләргә! Никадәр залимлек?! Бу хәтлегә кешелеген җуйган бандитлар шайкасы гына бара ала. Кем генә юк монда: япон, кытай, поляк, татар, немец — руслар үзләре дә күпме — барысы да бар. Арада профессор-генерал, эшче-игенче, карак-бандит, чехоткалысы, сифилислысы, ире-хатыны, үсмере — барысы бергә буталган миллионнар. Менә шушы хәл бу илне таркатуга алып барачак. Рим империясе ялкаулыктан таркалган, ди. Россия империясен демагогия очлаячак. Бу поляк әйткән иде диярсез, тарих масштабында аның көннәре санаулы.

— Син, пан Заря, революциягә хәтле булган Россия чынбарлыгын дөрес тасвирлыйсың. Әмма Советлар сез күзаллаган рус империясе түгел ул, мөстәкыйль социалистик республикалар союзы. Кабатлап әйтәм: Со-юз!

Нурисламның бу сүзеннән матур тешләрен ялтыратып көлде генә поляк. Көлде дә тагын эләктереп алды.

— Чү, хөрмәтлем. Бердән, сезнең татар ул союзда түгел. Сезгә анда урын юк. Сез Россиянең колониаль өлкәсе генә. Моның шулай икәнен партия өлкә комитеты дип язылып торган сүз үзе үк әйтеп тора. Дөрес, сез аны автономияле республика дип йөртәсез. Сезнең бар тапканыгыз Мәскәү казнасына ага бара. Үпкәләмәгез туры әйткәнгә, сезнең халык Россиянең борынгыдан килгән мәхлүк колы. Шахта аты. Дөнья яктысын күрүдән мәхрүм калган мәхлүк. Сезнең һәлакәт шунда: хәлегез мөшкелләгән аңламыйсыз, аңларга да теләмисез. Әйтик, менә син университет

бетергәнсең, математиканы да начар белмисең. Ә милләт язмышы турында уйлый беләсеңме? Юк, белмисез. Чөнки син дә шахта аты. Шахтадан чыгу, якты дөньяны күреп карау дигән төшенчә зәгыйфьләнгән. Европа илләрендә дә, әйтик, хәтта ярлы Польшада, Төркиядә, бәләкәй Финляндиядә, Швециядә дә университет бетергәч, күрше илләргә сәяхәткә барып, андагы тормыш, мәдәният белән танышып кайту гадәте бар. Бу — үзенә күрә бер күз ачу, дөньяга карашны киңәйтү. Менә синең берәр яры, хәтта күрше шәһәрләргә генә булса да барып кайтканың булдымы? Юктыр. Чөнки син ул турыда уйлый да, хыяллана да белмисең. Кыскасы, эшкә батыр, хөрмәткә такыр. Кол, шахта аты. Ленин Россия турында «халыклар төрмәсе» дип дөрес әйткән, ләкин аны азат халыклар иле итә алмаган. Кем белә, бәлки теләмәгәндер дә...

Кызгануны белмәс, туры әйтелгән бу сүзләргә каршы төшәргә теләмәде Нурислам. Юк, аның патриотлыгын болай гына какшата алмый иде поляк. Кайнар кояш астында сызланып озак утыру хәлен алды, ихтыяр көчен дә йомшатты бугай. Ул чакта аның бар теләге күләгәдә сузылу да күзләрен йому гына иде. Егетнең хәлен аңлапмы, Заря:

— Әйе, хөрмәтлем, без кечкенә кешеләр, халыклар язмышын, мөгаен, үзгәртә алмабыз,— дип, фәлсәфәсен төгәлләде.

Ул арада команда тавышлары яңгырады:

— Ботка, мужиклар, ботка! Артка чигенегез. Әй, пахан! Кемгә әйтәләр?!

Унлап солдат-надзиратель капка, барак тирәсендә буталып йөргән тоткыннарны зона түренә куа башладылар. Заря белән Нурислам да шул агымга эләктеләр.

Бераздан зонаның буш калган ягына иртәнге якта ипи китергән иске ЗИС килеп туктады. Бу юлы аның кузовында биш олы мичкә, һәркайсы озын саплы чүмеч тоткан таза гәүдәле биш кеше иде. Киемнәренә, үз-үзләрен тотуына караганда күптәнге зеклар.

Кабинадан иртән үзенең «чибәрлеге» белән поляклар теленә эләккән өлкән лейтенант Хәбибуллин төште. «Менә ул мин!» дигән сыман, карашын туплаудагы мәзлүмнәргә юнәлткән хәлдә, башындагы фуражкасын салып, шадра битен сөртеп алды.

Бу кешене аеруча игътибар белән күзәтте Нурислам. Нигә дисәң, бердән лагерьның башлыгы сыман ул, икенчедән, ни әйтсәң дә, милләттәше. Ятлар, бигрәк тә үзләрен харап эре тоткан поляклар алдында, күп белдекле Заря турында әйтеп торасы да юк инде, андый-мондый ялгыш эш эшләп ташламагае, хурлыкка төшмәгәе дип борчылды. Ә Хәбибуллин, үзенә күрә түгел, чуанына басалармыни — чыраен сытып, ачулы кыяфәттә сөйләшкән була. Сөйләшми, жикеренә, сынык теле белән русча сүгенеп тә җибәрә. Болгавыр үзе, ашыга-кабалана. Менә шушы абзагыз хәзер дүрт мең ярым чамасы ач тоткынны кайнар аш белән сыйларга җыена.

Нурислам шикләнә: шушындый кола яланда, бер өлеше караклардан, кеше талаучылардан торган ачулы гавемны ашату дигән изге эш буш хәсрәт булып кына калмас микән? Чөнки күренеп тора, сактагы солдатлар туплаудагы тоткыннарны чак-чак кына тыеп торалар. Ач халык бөселеп менә-менә ерылып китәргә торган буаны хәтерләтә. Әгәр шундый нәрсә чыкса, Хәбибуллинның хәле — ят та үл. Ә камыт аяк баемсыз, бушатылган машинаны озаттырды, мичкәләрдән читкәрәк китеп, фуражка түбәсе белән тирләгән йөз-чыраен сөртеп алгач, тәмәке кабызды, аннары уң кулын күтәреп, кинәт аска төшерде.

— Вәләй! — Без ботканы өләшә башларга әзер, беренче төркемне җибәрегез, дип солдатларга әмер бирүе, янәсе.

Ләкин аның бу әмере солдатлардан бигрәк алгы сафта торган ач каракларда, кеше талаучылардан һәм төрле адәм актыкларыннан торган стенага барып җитте. Һәм ул стена күз ачып йомган арада чатнап ярылды да китте. Берсе икенчесен ега-таптый, алга ташланган ярсу дулкынны туктату мөмкин түгел иде.

— Шулай булыр дип уйлаганыем аны,— диде Нурислам, сызланып. Янәшәсендә Заря басып тора иде.

— Ай-һай ла москаль! Ай-һай ла кыргыйлар! — диештеләр аның тирәсендәге яшьрәк поляклар. Авызлары ерык. Кайсылары кул чаба.

Мәхшәр купты. Боткалы мичкә тирәсе умарта күче кебек кайный иде. Бер-берсен таптарга әзер кыргый төркем эченнән савытлар ялтырап оча, калаклар читкә чәчри. Күзе тонган тоткыннар этешә, кыйнаш, сүгенү отыры кыза, көчәя генә бара.

Әнә берсе савытына ботка тутырып алган да кашыксыз гына чөмерергә дип авыз турына күтәрде. Күтәрде, әмма ботканы авызына озатырга җитешми калды, кемдер берәү савытны аның йөзенә чәпәде. Чыраена, муенына аккан кайнар боткадан тәне пешкән бичара чырыйлап кычкырып, савытын күккә чөйде. Савытта калган ботка кемнәрнеңдер йөзенә чәчрәде, бу исә гауга-чәкәләшне кыздыруга тагын сәбәпче булды.

Әлеге тамашаны читтән карап торган полякларга җитә калды, мыскыллап кычкырыналар:

— Һәйдүк, Иван, кыйна үзеңнекеләрне, читләр шүрләсен!

— Ботка үзеңә тәтеми икән, күршеңә дә эләкмәсен! Тапта! Из! Бу — социаль тигезлек дип атала. Болай син коммунизмны якынайтасың...

Күзен кан баскан тоткыннар кызганнан-кыза баралар. Мичкәләрдән агып чыккан ботка аяк астында җәелгән, күпләр шунда таеп егыла, өсте-өстенә өелеп тапталган хәлдә дә ботканы учына җыеп, авызына озатырга өлгерүче елгырлары да бар.

Фуражкасын югалткан өлкән лейтенант Хәбибуллин: «Әйдәгез минем арттан!» — дип солдатларына кычкырды да капкага таба йөгерде. Зәңгәр галифе чалбарының кабарынкы читләре фил колагы шикелле җилфердәп бара.

Кояш тәбәнәкләнеп урман артына төшүгә яңа командир белән солдатлар килде. Хәтәр командалар астында тоткыннарын тезеп саф-саф бастырдылар. Мичкә белән яңадан сыек ботка китерделәр. Штыклы солдатлар тоткыннарны унарлап-унарлап кына зонаның икенче ягына, ботка бүлгән урынга җибәрә башлады. Баш белән уйлап эшләгәндә меңләгән тоткынны тәртип белән дә ашатып була икән.

Сакчылар башлыгы капитан да, иртәнге якта адәм көлдергән өлкән лейтенант Хәбибуллин кебек тирләп-пешеп, мичкәләр бушатышып йөрми. Билендә пистолет. Читкәрәк баскан да бик мөһим кыяфәттә үзенең бер лейтенантына, өч-дүрт старшина-сержантына боерыкларын шуннан гына биреп тора.

Караңгы төште. Биек күгендә эре йолдызлар балкыган серле Себер төне. Җилсез, артык шомлы төн. Туңдыра, калтырата. Яңа җирдә күпләр йокыга китә алмый интегәләр. Ютәлләү, сызлану, ыңгырашу авазлары ишетелә.

Йокыга китә алмауның тагын бер сәбәбе бар. Кеше талаучы блатнойлар тынгы бирмиләр. Беренче тапкыр алар белән Орша төрмәсендә чакта очрашкан иде Нурислам. Блатнойларда иман юк. Җылырак киемле кешене очратсалар, яшьме ул, картмы, үзләре әйтмешли, Алламы, мулламы, эләктереп алалар да, анадан тума чишендереп китәләр. Кая йоклау — әле бер, әле икенче урында күтәрелгән каргыш-елаш барча тоткынны әсәрү халәтендә тота. Тоткыннарның күбесе таушалырга өлгермәгән өрлек кебек ир-егетләр, фронт, олы сугыш кичкәннәр югыйсә, нигәдер шул блатнойлар каршында көчсез калалар. Берләшә алу юк.

Нурислам да үзенең күз күргән төрмәдәш белоруслары, поляклары арасында бер төпкә башын терәп яткан иде дә һаман йокыга китә алмый. Уйлана. Алда тагын ниләр күрәсе бар микән — моны бер Алла белә.

Нурислам аркасын поляк Заряның аркасына терәп ятты, җылынып туңу, сызлануларын басарга тырышты. Ерак Белоруссиядә калган күрәзәче татар чибәрен, аның: «Газраилны якын җибәрмәгез, үлемгә бирешмәгез», — дигән өметле сүзләрен исенә төшереп ятты.

Йомшак җилме, фәрештә рәвешендә шул күрәзәче кызмы, аның маңгаеннан сыйпап алгандай булды. Үзе шифалы сулыш өргәндәй пышылдый сыман... Яшисең әле... Яшисең әле... Яшисең...

## Соңгы сүз

Әсәр шушы урында өзелә. Язучының каләме, нокта куя алмыйча, кулыннан төшеп китә. Йөрәге тибүдән туктый...

Еллар үткәч, чәнечкеле тимер чыбык артында, тоткынлыкта газаплы чорын искә төшереп, ирегеи буган үкенечле тормышын кабат кичергәндә йөрәге түзмәгәндер, мөгаен. Тагын берничә елны сызлаган бәгыреннән үткәрәсе иде дә... туган җиргә кайту шатлыгы белән әсәрне тәгәллисе иде бит, югыйсә. Юк икән шул, изге теләкне тормышка ашырасы вакыт тормыш мәшәкатьләренә сарыф ителгән. Җәмгыятьтә сүзгә ирек алып килгән бәрәкәтле җилләр бераз гына элегрәк искән булсалар, бу әсәр дә үзенең соңгы ноктасын күргән булыр иде. Кызганыч...

Мияссәр Хәмзә улы Хафизов 1914 елда Ютазы районы Бәйрәкә авылында дөньяга килә. Ул кичергән сугыш һәм аннан соңгы дәвер шушы әсәрдә чагыла. 1954 елны ул совет тоткынлыгыннан котылып иреккә чыга һәм гомеренең актык көненә кадәр Азнакайда яши. Башта төзелеш оешмасында, аннары мәктәптә укытучы булып эшли. Пенсиягә чыкканчы нефтьчеләр әзерли торган техникумның директоры була...

Мияссәр ага кыяфәткә чибәр кеше иде. Татар иҗтимагый үзәге оешкач, ул аның утырышларына бик теләп йөрде. Бу черек империягә карата йөрәгендә кысылып йөргән фикерләрне ул кыю итеп ярып сала, үз язмышы аша төшенгән хакыйкатьне, никадәр әче булса да, йөзгә бәреп әйтә иде.

Хәтерлим әле, бер елны без аның «Жигули»енә утырып Әлмәттән кайттык. Кышкы юл озын иде, сөйләшергә сүзләр күп иде. Мияссәр ага шулчакта роман яза башлавы турында әйткән иде. Мин аның бу сүзенә әллә ни игътибар бирмәдем. Язучылар Союзында эшләгән чагым иде. Орден-медальләрен чылтыратып, үзенең ветеран булуын аеруча искәртеп, ул чакта безгә көн аралаш картлар кульязма күтәреп килә, үзенең тормыш юлын һичшиксез китаплык дип саный, салкынрак сөйләшсәң, партия өлкә комитетына әләкләргә дип ашыгалар иде алар. Шундыйлардан арып беткәнгә, Мияссәр аганың да, язам әле, дигәненә ничектер ышанып бетмәдем. Сораштырасы, кульязмасын күздән кичерәсе булган да бит!.. Бер җылы сүз аны очындырып җибәргән булыр иде, илһамлы каләменә җегәр бирер иде. Күңел күзе булмаган шул. Бу болгавыр фани дөньяда кешегә үз вакытында игътибар итә белү зирәклегенә кайчан өйрәнербез микән?..

Мияссәр Хафизов — язучы булырга теләп түгел, ә бәлки әйтер сүзе тынгы бирмәгәнгә, фаҗигале, гыйбрәтле бай тормыш юлын кешеләргә сөйләргә дип кулына каләм алган шәхес. Аның әйтер сүзе элеккеге кысаларга сыя алмый иде. Ирек, иркенлек килгәч, ул ашыгып язды да язды.

Ашыкты...

Үзенең «Сугыш ятимнәре» исемле беренче китабы чыгарга бер ай кала Мияссәр ага дөнья куйды. Казанда яшәүче бертуган энесе Миргасыйм (Миргаз) ага Хафизовта аның мирас итеп калдырган архивы, моңа кадәр беркайда да басылмаган повесть-хикәяләре саклана. «Ике җәһәннәм» («Миллионнарның берсе») — шулар арасында аерым бер урын алып тора.

**Марсель ГАЛИЕВ.**
*1992 ел.*

# ШИГЪРИЯТ

## Ренат Харис

## ӨЧ ҮБЕШҮ

ЭРОТИК ПОЭМА

### 1. Кичке үбешү

*Синең җаның бәнем корбаным улсын,*
*Кулың ястык, сачең юрганым улсын!*

Г. Кандалый

Алар икәү генә калды
авыл читендәге өйдә...
Җир шары әйләнә бирде
күнегелгән җайлы көйгә.

Кайдадыр көн, кайдадыр төн,
ә кайдадыр таң беленә...
Кайдадыр туй... Кайда кайгы —
кемдер үлә, кемдер бөлә...

Кайдадыр бөек ишектән
чыгып килә яңа кеше.
Мильон хатынның үзәген
шакый гына ире төше...

Ә бередә өй эченә
тула гына әле эңгер.
Эңгер сөюнең йөгәнен
салдыра ул, дигән кемдер.

Һәм ул кемдер бик хаклыдыр:
ир һәм хатынны биләде
сөюдәге азатлыкка
ирешеп карау теләге.

Әллә кайдан килде бер өн:
тик сөюдә генә кеше

---

Ренат ХАРИС (1941) — *шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән күпсанлы китаплар авторы. Ул — М. Җәлил исемендәге бүләк лауреаты. Казанда яши.*

дөнья гаменнән котыла,
ялган әхлак бавын чишеп!

Сөю үлемдәй ләззәтле,
үл яшәү кебек газаплы...
Тик йөгәнсез гашыйкларга
килә илаһи азатлык!..

...Сагынычлы жылы сүзен
әйтәм генә дигән иде,
ирнең дәртле иренена
хатын иреннәре тиде —

утка ялкын, суга дулкын,
балга колмак тигән кебек...
Түшәм ботаклары күрде
үбешү касәсе төбен...

Энҗе эзләүчеләр сыман,
чоңгылларга чумды телләр.
Алар ни тойганны белсә,
һәркем тел булырга теләр...

Чоңгылдан чыгам дигәндә,
телне ала тешләр кысып.
Нәкъ шул чакта аңа иңә
иң татлы сүз яралгысы:

ләззәткә чыдаша алмый
дулаган сүз, котырган сүз,
шагыйрьләр теленә күчеп,
жырга әйләнә торган сүз...

Ялгыз өйдә ике гашыйк
бер-берсенең кочагына
сеңделәр дә эләктеләр
дәртләренең ут чагына.

Эределәр дә чүктеләр,
авып киттеләр идәнгә,
сүзсез генә уфтандылар
катлы-катлы киенгәнгә.

Хатынның түш төймәләрен
ирнең елгыр бармаклары
эһ иткәнче үк чиштеләр,
сихерчедәй кармаланып.

Хатынның кайнар куллары,
әйтерсең лә ялгыш кына,
әллә нәрсә эзләделәр
ирнең тар бил каешында...

Буйлары буйлап дулкыннар
йөгереште, тынды, шашты...
Ә идәннең такталары
шундый итеп ыңгырашты —

тәрәз төбендәге гөлләр
бер-беренә үрелделәр,
аң югалтып, караваттан
авып төште ап-ак мендәр.

Хәтта кояш кире керде,
яман эштер, диеп уйлап...
Хатынның төз аяклары
йөгерә иде түшәм буйлап...

Гашыйкларның дәртле хисе
ярларыннан тулып ташты...
Ә идәннең такталары
кеше булып ыңгырашты,

бу мәҗүси тән биешен
үз өстендә тоя-тоя...
Көнләшүгә чыдамыйча
чыгып качты өйдән кояш.

Идәннең аһы-уһына
кушылды хатын да, ир дә.
Бу мизгелдә фәкать бәхет
хөкем сөрә иде Җирдә...

Бәхет тәхеткә күтәрде
ике түземсез кешене...
Кичке шәфәкъҗтә үбешү —
тәвәккәлләр үбешүе!

* * *

Такта идән... Йомшак келәм...
Ике гәүдә җәйрәп ятты.
Яман күздән саклап, кояш
өсләренә эңгер япты.

Ялгыз өйдә ни булганын
бер генә кем дә күрмәде.
Караңгыда ишетелде:
— Чишенеп тә өлгермәдек...

— Карават та менә генә.
Без оныттык аның барын...
— Тилекәем, бердәнберем,
түземле бул моннан ары.

Мин дә бит сине сагындым
яңгыр көткән бакча кебек,
ачып йөрәгемә баксаң,
яргалана язды кибеп...

— Мин инде сүнгән куз идем,
санаулы иде минутым,
син дәртемә тын өрдең дә,
дөрләттең яшь чаклар утын.

Син мине җәннәткә керттең...
— Соң, ачкычы синдә иде...
— Һәм мин анда аңым җуйдым,
ләззәтнең төбенә тиеп.

Анда тәнсез идем, ахры,
җан гына тик, җан гына тик!
Сиңа мәдхия җырладым
бар җәннәтне яңгыратып...

— Юк, кадерлем, син ялгышма,
тәнле идең... Тәнле идең.
Син фәрештә түгел ласа,
шагыйрь идең, тәмле идең.

Мәдхияне мин җырладым
мәхәббәткә, назлы ярым,
син ишеттең генә аны,
һәм кушылдың гына бары...

Тукта әле... Чәй куйдым бит,
чәйнегем бит утта күптән...

Хатын аш ягына чыкты.
Чәйнектә су кайнап беткән,
комсызланып гөжләп тора:
тизрәк су салыгыз, тизрәк —
юкса, идәндә аунаган
ир кебек төшәрмен изрәп!..

Һәм чәйнеккә салынды су —
әйдә, кайна ташып-ташып!
...Хатын кендеге өстендә
ирнең учлары тоташты,
ефәк эчке күлмәк буйлап
өскә таба шуыштылар...
Ә хатын, аркасы белән
ирнең йөрәк чаңын тыңлап,
торды тын да алалмыйча,
беравыкка өнсез калды,
һәм ир аның ике Аен
кайнар учларына салды.

Бармаклары капшап тапты
Айларның биек үрләрен...
Тетрәп куйды шунда хатын,
күзләре берни күрмәде,

колаклары ишетмәде,
чак-чак ачылды авызы...
— Мин сүнеп тә өлгермәдем,
ә син яңадан кабыздың...

Үз учлары белән хатын
тотып алды ир учларын,
пышылдады башын борып:
— Кыс очларын, кыс очларын...

Ир үтәде... Хатын иргә
аркасы белән сыенып,
аның иреннәрен тапты.
Комачау мени кыенлык?!.

Иреннәр, җилемнәр кебек,
беркетте ике кешене.
Аһ бу кичке үбешүләр —
түземсезләр үбешүе!

Аһ бу кичке үбешүләр!
Тәннең аңсыз чагыдыр ул —
мәхәббәтнең ләүкәсенә
менми генә чабынудыр...

## 2. Төнге үбешү

*Илаһи, ошбу матурга*
*Насыйб ит бергә ятырга,*
*Үбеп агызны татырга...*

Г. Кандалый

Авыл читендәге өйдә
түшәк түши гүзәл хатын.
Хатын-кыз җәйгән ак япма —
һәрбер ирнең яшәү хакы.

Әйтерсең лә ул — ак кәгазь...
Дулап илһамлана хыял —
җанын рәссам итә дә ир,
җәннәт багы ясап куя

чишмәләре, күләгәле
җылы аланнары белән,
баш өстендә бәллүр гөмбәз,
аяк асты хәтфә келәм —

ят та ауна теләгәнчә,
йә теләгәнеңне аунат!
Ике дөньяның берсендә
табалмассың мондый аулак.

...Әйтерсең лә ул ак япма —
бер шагыйрьнең дәфтәр бите,
һәм ул аңа шигырь яза,
һәм дә яза шундый итеп —

Үзе яза, үзе елый,
Үзе елый һәм ялвара:
йа ходаем, сөю җибәр —
гомер зая узып бара,

тау елгасы кебек сөю! —
агызсын ул бәрә-суга,
шашкын судан ялкын керсен
минем йөрәк ярасына,

янгын кабынсын анарга,
янсын да әйләнсен гөлгә —
судан ялкын алган йөрәк
гөлгә әверелә беләǃ...

Ул гөлне алышмас идем
алмазларга һәм алтынга,
бирер идем сөйгәненә
ак түшәк җәйгән хатынга...

Ә авылда, ялгыз өйдә
түшәк түши гүзәл хатын.
Бу күренеш, бу вакыйга
һәрбер иргә шундый якын,

ул моны үз гомерендә
мең күргән һәм мең оныткан...
Тик истә зөфаф төнендә
эзләгәне бер тамчы таң...

Хатынның һәр хәрәкәтен
карап торды ир шаккатып...
Арслан кук ташланырга
омтылса да вакыт-вакыт, —

үзен тыярга көч тапты,
сынса да түзәр тәкате...
Ул көтте төнге үбешү
бирәчәк бәхет сәгатен.

Ә ул сәгать якын иде...
Һәм менә килеп тә житте,
дип уйларга өлгермәде,
тәрәзәгә кемдер чиртте.

Борылсалар-карасалар
сискәндергеч шул тавышка —
ирнең балачак күршесе
күзләре белән ябышкан

тәрәзә пыяласына,
елмая һәм нидер ымлый.
Ир уфтана, чырай сыта...
— Нишлисен, кертмичә булмый...

* *
*

Күрше шактый салмыш иде —
сүзне учлап чәчә генә:
— Хатынга әллә ни булды —
һич кундырмый чәчәгенә...

Тиздән, малай, бер ай була,
ничек, дим, түзәргә кирәк,
әнә, майтәм, ботакларын
жиргә керткән хәтта тирәк.

Мин инде бер ай авырлы,
дигән була, ну булса соң!
Мин ач, ә ул бирми тора
пешергән майлы сумсасын —

башларым әйләнеп китә
ул яныма килгән чакта...
Ярый ла аеры йоклыйбыз —
ул түр якта, мин почмакта.

Китап шулай куша, врач —
түзә күр, ди, бер-ике ай,
дүрт кыз таптым, бу юлыга
алып кайтам, ди, бер малай...

Малай хакына түзәмен.
Ә үзеңнең малай бармы?
— Бик тугарылып сөйлисең,
разве, күрше, алай ярый —
хатын-кыздан яхшы түгел,
тәлинкәне алмаштырыйк...
— Була, була, агай-эне
кергәчтен дә берүк сорыйм
дигән идем: бу хатының
элеккесеме, яңамы?
Элеккесе сары иде,
әллә шунсы буянганмы?

— Сүз ул хакта бармый, күрше,
авыл ничек яшәп ята?
— Ничек яшәсен ди авыл,
ул тиз караңгыга бата,

күп өйләрдә телевизор
җимерелгән. Кем төзәтсен?
Мачтыр үзәктә һәм килми,
барып аңа кем сүз әйтсен?!.

Халык нишли? Ятып йоклый...
Дер селкенә юрган асты —
түзсен генә имән диван,
түзсен генә мамык ястык!

Минем, күрше, әфсен укып,
өйләрнең һәр бүрәнәсен
пыяла итәсем килә —
ну, гыйбрәткә өйрәнәсең,

эчтәге хәлләрне күреп,
патамушты һәрбер өйдә
бөдрә чәчле җылы бүрек
кидертелә таза чөйгә...

Икәү бергә карар идек
шаклар катып, таңнар калып.
Хәзер бездә дә китапча
ду китерә инде халык.

Төрле-төрле брошюра
алып кайталар каладан...
Сөешү дигән һөнәрдә
булганбыз без чеп-чи надан.

Мин дә күрдем рәсемнәрен.
Адәмнәр тәмам шашканнар —
әкәмәт әмәлләр белән
әллә ничек тоташканнар...

— Синең, күрше, патефоның
гел бер көйне әйләндерә...
— Ач әтәч төшенә, малай,
тавык белән тары керә...

— Кибетләрдә нәрсәләр бар?
Шулар турында да тыңлап
китик инде — беләсең ич,
без авылда сирәк кунак,

әллә нигә бер кайтабыз,
менә көзләр җиткәч кенә...
— Әнкәң өч ай өй саклады,
син кайттың ул «киткәч» кенә.

Серле кайттың... Ә чәчең чал...
Ә күзләрең майлы-майлы —
күрәсең әле һаман да
дәртең көчле, каның кайный.

Карале, онытып торам —
авыл гадәте буенча
мунчага әйтергә кердем,
сезне көтеп тора мунча.

Без инде эссесен алдык
хатын белән... Әйтсәм әйтим —
хатыным була торып та
мин мунчада калдым «ятим».

Ә хатыным минем шәпле,
дүрт бала тапкан бу диеп,
билләһи, беркем дә әйтмәс,
һич тә туеп булмый сөеп.

Ләүкәгә менгәнен күрсәң!..
Ник мин рәссам түгел икән?
Шул кыяфәт аны күрсә,
Урманче да һуштан китә...

Түзалмадым... Миңа шунда
әллә нәрсә генә булды —
кулым белән ялгыш кына
чәчәгенә барып кундым.

Күбәләк шикелле генә...
Дәртем кызуында пешеп...
Күрәсеңме, кул күгәргән,
бу — себерке сабы эше...

Бер чиләк салкын су белән
кызган дәртемне шиңдердем,
чыгып яртыны эчтем дә,
менә, яныгызга кердем...

* *
*

Күршеләре чыгып китте.
Кабат ялгыз ике гашыйк.
Алар өчен бик шәп булды
төнге үбешүләр башы.

Тәмам курыкканнар иде
күрше белән җил керер, дип,
хиснең инде дөрләп киткән
утын өреп сүндерер, дип...

Баксаң, киресенчә булды.
Җил утны дөрләтте генә,
ир-егетнең һәр төшенә
ялкынны үрләтте генә.

Хатынның җаны кайнады —
чәчрәп очты тамчылары,
күзләренә төн иңдерде,
йөзләренә таң чыгарды.

Аңа әллә эссе иде,
әллә суык иде аңа —
Үзе эчтән чартлап яна,
үзе тыштан калтырана.

— Кадерлем минем, тәтием,
бу дөньяда син бердәнбер,
яктылык җанны җәберли,
сүндер утны, тизрәк сүндер...

Һәм ут сүнде ялгыз өйдә.
Тышта, шәмахә гөмбәздә
тик көмеш Ай янып калды...
Салкын нурлары тәрәздә

кызыксынучан күз булып
ялтырады шактый озак,
керфекләрен чаршау аша
ак түшәккә суза-суза.

Ә түшәктә... Йа ходаем,
матур сүзләр алыйм кайдан? —
иң азартлы уен кыры
булып калган ап-ак мәйдан.

Адәм һәм Хавага гына
тәтегәндер мондый ышык!
Гашыйклар янбаш ятканнар
сыенышып, уралышып...

Хатын бармаклары ирнең
һәр төк чәчен барлап йөри...
Мөгез арасын кашыткан
үгез мени, ир мөгери.

Күзләре йомык... Ә үзе
ярым төштә, ярым өндә.
Аңа берни кирәк түгел —
ул татлы дулкын иркендә

изрәп ята онытылып,
бәхет йөзен күрмәк булып,
ләкин аны урап ала
әллә нинди кайнар болыт,

җанның кайсы төшендәдер
күтәрелеп һәм куерып,
тәннең һәр күзәнәгенә
күндәм булырга боерып.

Һәм ир күндәм... Хатынның ул
буйсына һәр сыйпавына...
Менә аның иреннәре
сутлы ут булып кабына,

куллары шуышып төшә
хатынның бил үзәненә,
аннары иң йомры, йомшак
калкулыкларына менә,

таеп төшә түбәнгәрәк,
тез асларын ала тотып...
Калтыранып куйды хатын.
Әллә шунда микән коты?!

Чәчләреннән чолгап-чорнап,
хатын тартты ирнең башын...
Үбешү аша тоташты
исерешкән икс гашыйк —

иреннәр ирен эчтеләр,
эчкән кебек өр-яңа бал —
йоттылар да туймадылар,
ябырылдылар яңадан.

Ниһаять, талып калдылар...
Тешләр тиеп китте тешкә.
Аларны каерып ачып,
телләр керештеләр эшкә.

Чәбәкләшеп, назланышып,
алар иң татлы куышта
йөрделәр пешкәк кебек,
күбәләктәй куыштылар,

тәмле итеп тешләнделәр,
юри генә, иркәләшеп,
җандагы барлык куәтне
тәннең үзәгенә дәшеп.

һәм иреннәр аерылышты...
һәм өзелде тел дә телдән...
Ирнең кайнар иреннәре,
әйтерсең лә әкәм-төкәм,

хатынның гәүдәсе буйлап
шуыштылар үбә-үбә.
Менә битләр. Менә ияк.
Менә муен... Аннан түбән —

иңбашлары, умрау сөяк,
көрән очлы ике курган —
күзгә ләззәт, учларга наз,
йөрәккә дәрт сала торган.

Иреннәр кысып алдылар
бер курганның көрән очын...
Әллә ни түләргә әзер
хатын-кызлар моның өчен,

чөнки курганның тамыры
тән үзәге белән тоташ...
Мондый ләззәткә түзалмый
хатын була күпме туташ!..

Бу хатын да чыдамады —
сөлек кебек боргаланды,
тыштан каз тәне чыгарды,
эчтән янартаудай янды.

Көрән очка тел кагылгач,
Аһ итте ул, җуйды аңын...
Ә ирене пышылдады:
— Бердәнберем, тагын, тагын...

Ә дөньяны яңа сауган
сөт хуш исе күмгән иде.
һәм бу хуш ис ир-егетнең
үзәгенә барып тиде —

горурлыгы, көч-куәте,
матурлыгы, батырлыгы
укмашкан изге үзәккә,
кузгатып җаны орлыгын.

Кабат ачылды җәннәтнең
шаһзадә көткән капкасы.
Ир-егеткә, ходай кушып,
анда керү булды насыйп...

Бер җылылык анда ирнең
бөтен тәнен кысып алды
һәм түрендә дулкынланган
ләззәт дингезенә салды.

Дулкын арты дулкын үтте
киерелгән тәне буйлап,
сыйпап башын, һәр тамыры
белән кети-кети уйнап.

Кайчагында муеныннан
алды аны буып-буып...
Кайчагында кайнар таулар
арасында йөртте куып.

Кайчагында каерылып
бөгеп карарга тырышты.
Кайчагында янбашларын
уттай итә язды ышкып.

Ә җәннәткә керә алмый
калган ике игез туган
капкага һөҗүм иттеләр,
гөрзи белән суга-суга...

Кайчагында бөтен тәне
йотмак булды эчке кочак...
Җәннәт уты, җәннәт суы
тоташтылар бугай шулчак —

Тоташты ике рәхәтлек —
гөл тамыры, язгы болыт,
ике сусау, ике шәраб
кушылдылар ләззәт булып.

Тетрәнде барлык тарафлар,
җан дулкыны акты дулап...
Талгын тавыш пышылдады:
— Бәхет менә шушы була!..

Ирнең хәтта хупларга да
калмаган иде әмәле
инде җилфердәми иде
дәрт-дәрман дигән әләме,

ялкынланмас чагы иде
куз эченә иңгән утның...
Аһ бу бөек хәлсезлекнең
алла биргән бер минуты!

Синең хакка туа кеше,
яши сине татыр өчен,
фәкать сиңа тапшырырга
әзер һәрчак соңгы көчен.

Синнән авыз итәргә дип
эзләп таба мильон чара.
Синең хакка мең газапка,
бер үлемгә хәтта бара...

Колың булып, хәлдән таеп
җәйрап яткан чакта кеше —
ул падишаһ, император,
ул чиксез көч, алла ише...

Ир кымшанды... Әкрен генә,
хәтта күзен ачып тормый,
хатынның ирениәреннән
ирне белән куәт сорый,

тәне басса да сусынын
жаны әле туймый калган...
Аһ илаһи бу комсызлык!
Аһ мәҗүси бөек ялган!

Бер йөрәктә бергә кайнап,
шулар безне көчле итә.
Ирне хатынга тартмаса,
яшәүнең мәгънәсе бетә...

Сөю сусыны басылмас
эчелеп бетсә дә күле!
Ә басылса — шул мизгелдә
сөю үле, кеше үле...

Әкрен генә, хәтта күзен
ачып та тормастан, хатын
ирнең үбеп иреннәрен,
кабат айгыр итте атын...

Атланды да, ап-ак ятак
кыры буйлап җилде генә,
ләззәт угын җиткергәнче
үзәгенә, җелегенә...

Таулар аша үткән чакта
егылмас өчен ялгышып,
иреннәре белән ирнең
иреннәренә ябышты.

Үзәннәрдә киерелде,
күккә төбәде ияген.
Дөньяны йотарлык булып
киңәйде оча сөяге.

Үзәгендә рәхәтлекнең
шартлагачтын янартавы
яралы коштай тартышып,
ак түшәккә төште авып...

Шул мизгелдә аны кабат
татлы, җылы бизгәк тотты...
Аһ бу бөек хәлсезлекнең
ходай биргән бер минуты! —

гомер буена сузылса
түзәр микән кеше, нишләр?!
Аһ бу төнге йөгәнсезлек!
Аһ бу төнге үбешүләр! —

чакыруга чыдый алмый
күкләрнең Җиргә төшүе!
Аһ бу төнге үбешүләр —
илаһилар үбешүе!

Аһ бу төнге үбешүләр!
Җанның тәнсез чагыдыр ул —
мәхәббәтнең ләүкәсендә
ташка ятып чабынудыр...

## 3. Иртәнге үбешү

*Әгәр калсам сине алмай,*
*Ки куйныңа керә алмай,*
*Ботыңны ботыма салмай,—*
*Фида җаным сиңа, җаный!*

Г. Кандалый

Гашыйкларның битләренә
таңның якты нуры ятты.
Хисле бу нур иң әүвәле
күз керфекләрен уятты.

Ачылды ирнең күзләре...
Дөнья әллә нинди, яңа.
Иске төшәм дә сокланып
карап тора кебек аңа.

Сокланмаслык та түгел бит
дәртенә аның, көченә —
жайдак булып, йә аргамак,
ләззәт давылы эчендә

төне буе бәйге тотты
һәм яулады бөек бүләк —
хатын тәненең рәхмәте
алды аның аңын биләп.

Монардан да олы бүләк
ир-ат өчен бармы тагын?!
Йа ходаем, еш кабатла
гомерләрнең шундый чагын.

Төннән таңга, таңнан көнгә
сеңгән иде ләззәт тәме...
Һәм күрәсе килде ирнең
аңа рәхмәт әйткән тәнне.

Учлар, ирennәр күзенә
төне буе бәхет тиде.
Инде маңгай күзләрен дә
бер сыйлыйсы килгән иде.

Өсләрендәге ябманы
ир шунда ук тибеп атты,
сылу гәүдәне күрде дә
ничәнче кат шаклар катты.

Югыйсә ул инде күпне
күргән һәм татыган кеше!
Ай-һай вәсвәсәле иде
ул гәүдәнең һәрбер төше —

кагыл һәм үп, үп һәм иснә
диеп азындырып тора,
күз нурлары гына түгел,
бөтен әгъзалар котыра.

Телнең кагыласы килә
алсу колак йомшагына —
бәрхет сыман бу җимешне
бер татыган мең сагына.

Ике күкрәк арасына
сыенасы килә битнең,
чөнки төнге кагылуы
хәтереннән һаман китми.

Кендегенең упкынына
омтыла күк бөтен гәүдә —
кендеккә батып үлүдән
баш тартмас Җирдә берәү дә.

Бөдрә әрәмә эчендә
килә адашып каласы —
шунда җәннәт капкасына
юлыга адәм баласы...

Күзнең болай капшавына
түзмәде хатын, түзмәде —
ир тәне дөньясы буйлап
үзе гиздерде күзләрен.

Күз нурлары ир-егетнең
яңагына кагылдылар,
рәхәтләнеп тарандылар
аның каты камылында.

Күкрәгенең даласына
иртәнге тынычлык кунган.
Уянмаган иде әле
көмешләнеп килгән кылган.

Түбәндәрәк — алтын үзән,
уртасында — тирән кое,
кое тирәсе — камышлык,
авып үскән, ләкин куе.

Ә астарак, бөдрә ятак
уртасында (әллә сынган)
бакыр ачкыч аунап ята,
ачкыч — җәннәт капкасыннан.

Әллә нишләп китте хатын,
тартышты бөтен үзәге.
Пышылдады:
— Миндә җәннәт,
синдә җәннәтнең бизәге...

Капланды ирнең өстенә...
Кипкән иреннәре белән
эчте ул ирнең иренен,
рәхәтлектән үлә-үлә,

күкрәгеннән ирексездән
чыккан өнне тыя-тыя...

Һәм шуңда хатын астында
күтәрелде кайнар кыя —

яшәешкә куелачак
бөек һәйкәл пьедесталы!
Андый һәйкәлне бар дөнья
кабул итәчәк таң калып...

Хатынны сурәтле уйлар
чөйделәр зәңгәр күкләргә.
Кичекмәстән тотынды ул
хыялын үзе үтәргә —

авып төште ак ятакка,
менгерде аунатып ирне...
Тетрәттеләр караватны,
өйне, авылны һәм Җирне...

Ватылмады Җирдә берни,
кимемәде бернәрсә дә —
ике тәндә янартаулар
ургып атып җибәрсә дә.

Рәхәтлек силе акса да
тирән ярларыннан ташып,
беркайчан да булмаганча
тыныч иде ике гашыйк.

Беркайчан да булмаганча
азат иде алар, азат —
ике дөньяның чигендә
тукталып калган гали зат.

Бу — үлем дә, бу — яшәү дә
түгел иде, ә яңа бер,
өченче халәткә күчеп,
вакыт эчә иде гомер.

Беркайчан да булмаганча
сыенышып, сөенешеп,
тәгәлләделәр дөньяда
иң илаһи булган эшне.

Ә уйласаң, мөмкин иде
җан көюе, бит пешүе!...
Аһ иртәнге үбешүләр —
куәтлеләр үбешүе!

Аһ иртәнге үбешүләр!
Аның иләс чагыдыр ул —
мәхәббәтнең ләүкәсендә
себеркесез чабынудыр...

...Колак йомшакларын үбеп,
пышылдады хатынга ир:
— Синнән генә бала телим,
зинһар, кадерлем, табып бир!

Пышылдады хатын:
— Бәгърем,
үптең дә мине эреттең —
үзәгемә кояш керде,
төерләнде һәм... беректе!

Хәзердән үк инде сизәм:
төзәлде язмыш хатасы —
син бүгеннән тәнемдәге
җанлы кояшчык атасы...

Син бары минеке генә!..
Беркемгә дә сине бирмәм —
хәтта бөек Үлемгә дә...
Без анда да икәү бергә...

*
* *

Җир шары кояш тирәли
әйләнгәндә җайлы көйгә,
менә нинди хәлләр булды
авыл читендәге өйдә.

Һәр авылда, һәр шәһәрдә
алар һәрчак була тора...
Ләкин кешенең аңында
яши мәңгелек бер сорау:

бу — гөнаһмы, бу — савапмы?
Һәм җаны бар һәрбер кеше
бердәнбер хак җавап бирә:
— Сөешү — мәңгелек эше!

Башка, хәтта бөек эштә
сула гомер гөлчәчәге,
фәкать сөешүдә генә
кешелекнең киләчәге.

Сөешүсез узган гомер
җанны теләчәк үкенеч!
Әй җанлылар, үбешегез
төнлә, иртән, көндез һәм кич!

Онытмагыз, үбешү ул —
сөю алласының ашы!
Ходай табындашы була
үбешкәндә ике гашыйк!..



**Гариф Ахунов**

# ТИМЕРХАННЫҢ ЯШЬЛЕГЕ

ПОВЕСТЬ

## Беренче бүлек

Тимерхан абзый төш күреп уянды.

Төше шулхәтле дә матур, шулхәтле дә дулкынландыргыч һәм чын иде ки, Тимерхан абзый әле уянгач та, җанын тутырган ләззәттән арына алмыйча, күзләрен йомган килеш ятты. Ул белә: уяну белән күзне ачып, тәрәзәгә карадыңмы — төш онытыла. Шул хакта аңа үги әнисе кат-кат әйтә торган иде. Барлык үги аналар төсле үк, Тимерханның да үги анасы аңа назлы караш ташламады, аны үз итеп аркасыннан сөймәде, авызыннан өзеп соңгы телем ипиен бирмәде, күнелдә ул кылган игелекләр никтер торып калмаган, ә менә төш күргәннән соң тәрәзәгә карамаска кушканы гел дә хәтердә.

Әйе, төш күрде Тимерхан абзагыз. Болыннан бара, имеш. Атка атланып бара. Яз, имеш. Күзләрне камаштырырлык кояш болындагы ямь-яшел үләннәргә, аллы-гөлле чәчәкләргә көлтә-көлтә нурын сибә. Тимерхан атланган Тимеркүк, башын чайкый-чайкый, болын чәчәкләре арасыннан бара, чапмый да, юыртмый да, атлап-атлап кына бара.

Ул да түгел, болында иңенә көянтә-чиләк күтәргән бер кыз пәйда була. Тукта-тукта, бу соң Миңлеасия түгелме? Шул бит, шул үзе. Башына ак яулык бәйләгән, кыска җиңле зәңгәр күлмәк кигән, шундый да җинел гәүдәле, шундый да нечкә билле. Алма бизәкле көянтә аның иңнәрен баскан, көмеш төсле ак чиләкләре мөлдерәмә суы белән атынгалап бара. Суын түкмәс өчен Миңлеасия бии-бии атлый. Һай аның ул атлаулары! Әллә нишләтә Тимерхан дигән егетне, җаннарын айкап ала. Аның тизрәк Миңлеасияне куып җитәсе, ат өстеннән сикереп төшеп, кыз белән янәшә атлыйсы килә башлый.

Тик... Миңлеасияны куып җитәрлек түгел. Ул һаман ерагая, ерагая, ерагая. Тимерхан дигән үсмер егетнең атын чаптырып, аны куып җитәсе

Гариф АХУНОВ (1925) — *әдип. Татар, рус һәм башка телләрдә чыккан дистәләрчә китаплар авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты.*

килә. Аты чапмый, аты туктый, киреләнә. Миңлеасия дигән нечкә билле, шаян табигатьле кызны — инде менә ел буе күңелен кытыклап, күкрәк турыларын сызлатып, моңсу сагышларга юлыктырган кызны югалтудан куркып, ыңгырашып җибәрә Тимерхан һәм үз тавышыннан үзе куркып, уянып китә...

...Их, картлач, картлач! Синә бит инде алтмыш биш яшь, син әле һаман унҗиде яшьтәге чакларыңны, Вәрәшбашта шәфкать туташы булып эшләгән Асияңны күрәсең. Атка атланып, аны куып җитәргә исәп тотып төшләр күреп азапланасың. Әнә бит ул Миңлеасияң, ике кулын яңагына куеп, мыш-мыш йоклап ята. Ул, бәлкем, сине уена да кертеп чыгармыйдыр. Ә син әле һаман аның белән саташасың. Бар икән гомер буе сине исертеп, сине мавыктырып яшәгән кадерле җан...

Тимерхан абзый, Миңлеасиясының йокысын бүлмәс өчен, шыпырт кына урыныннан торды, ваннага кереп, битен юды, сакал-мыегын кырды, бер җиргә барасы булмаса да, бакчада кия торган иске курткаларын түгел, чытыр ак күлмәген, кешелеккә кия торган куе зәңгәр төстәге яңа костюмын киде.

Шуннан соң ике кулы белән иягенә таянып, яшьлек хатирәләренә чумды. Ә хатирәләр күп, хатирәләр хәтәр, һәм алар яшь чактагы кебек үк җанны кайнар дулкын белән тутыралар иде.

— Бу ниткән бәйрәм әле бүген? — дип шаян-мәзәк итеп дәшкән тавышка башын күтәреп карады.

Каршысында гомер кичергән хатыны басып тора икән ләбаса! Аны күргәч, Тимерхан абзый кинәт дулкынланып китте. Миңлеасиясы әле һаман җор табигатьле, әле һаман зифа гәүдәле, чыраенда әле һаман уенчак-мутлык, мәзәкчәнлек...

Тимерхан абзый, ләм-мим бер сүз дәшмәстән, карчыгы каршысына торып басты, аны җиңелчә генә иңеннән кочаклап:

— Слушай, Миңлеасия, мин сине төшемдә күрдем бит әле...— диде.

— Ничек итеп күрдең, картлач?

— Бик матур итеп күрдем.

— Булмас. Шаяртма. Кая инде ул хәзер матурлыклар?

— Хәзерге чагыбыз итеп күрмәдем шул мин аны. Яшь чагыбыз икән, дим. Син алмалы көянтә, мөлдерәмә сулы көмеш чиләкләр күтәргәнсең, чәчәкле болын уртасыннан атлыйсың, ә мин атка атланганмын, тик мин сине куып тота алмадым. Ерагайдың син миннән...

— Их, Тимерхан-Борһан, оныкларың үсеп килә инде, ә син һаман гашыйк булудан туймыйсың,— дип Асия ханым иренең пеләшен сыпырып рәхәтләнеп көлде:— Ә бит монда кайчандыр кап-кара көнҗәлә чәч иде. Кемнәр генә кызыкмагандыр ул бөдрә чәчкә.

Шундук, шаян табигатенә хас булганча, Асия ханым җыр такмаклап алды:

Биек тауның башларында
Помидор түтәлләре.
Ал булса да, гөл булса да,
Кирәкми бүтәннәре.

Тимерхан абзый гомер иткән карчыгының җиңеллегеннән, уенчаклыгыннан гөлдерәп кенә бер көлеп алды:

— Карале, Миңлеасия, мин күргән төшне нәрсәгә юрыйк икән?

— Бернәрсәгә дә юрамый торыйк. Кичкә тикле сабыр итик. Кичен мин үзем сиңа ул төшнең ник кергәнлеген аермачык кына итеп әйтеп бирермен,— диде Асия ханым һәм шундук кухня ягына кереп югалды.

Пенсиягә чыкканына байтак еллар булса да, Тимерханның Миңлеасиясы әле һаман эшләп йөри, акча җитмәгәнлектән түгел, чуар җанлы булганга күрә эшли, эшләми торса, ул хастага сабыша.

Хатыны иртәнге ризыкларны әзерләп, иренең тамагын туйдырып эшенә китеп баргач, Тимерхан абзый соңгы ике елда үзе төзегән музейга барып килмәкче иде, хат ташучы хатын аңа зур бер конвертта хат кертеп бирде. Хат «заказной» итеп язылган иде, шуңа күрә хат ташучы аны почта ящигына гына салмаган, үз кулы белән тапшырып, почта кенәгәсенә кул да куйдырып китте.

Тимерхан абзый үтә дә дулкынланып, бу нинди әкәмәт булды тагын дип уйлап, хатны кат-кат әйләндереп карады, пакетта Мөслим районының Вәрәшбаш авылы язылган һәм аңа Тимерханның яшьлек дусты Сәйделгыйлем Зарипов кул куйган иде.

«Ә-ә-әәә, менә хәзер аңлашылды: Тимерханның яшьлеге, атка атланып йөрүләре юкка гына кермәгән икән төшенә. Яшьлек дустыннан хат аласы булганга икән. Биоток дигән нәмәстәкәйне, күрәсең, галимнәр тикмәгә генә әйтмиләр икән. Әкәмәт, әкәмәт...» — дип, күңелле уйларын уйлый-уйлый, Тимерхан абзый хатны ачты. Шакмаклы дәфтәр битенә ике яклап бик вак хәрефләр белән бик озын итеп язган хатны ул йотлыгып укый башлады.

*«Исәнмесез, Тимерхан һәм Асия! Сезгә сагынычлы сәламнәребезне җибәрәбез һәм якынлашып килә торган яз бәйрәме — Беренче Май, аннан ары килеп, барлык бәйрәмнәрнең дә бәйрәме — Җиңү бәйрәме белән котлыйбыз. Дәхи дә сезнең пар күгәрченнәр кебек тигез пар булып гомер кичерүегезне, балаларыгызның да, оныкларыгызның да бәхетле вә тәүфыйклы булып үсеп, файдалы кешеләр булып яшәвен телибез.*

*Теләкләрдән соң, авылдашларым, сезнең икегез белән генә уртаклашасы уй-фикерләрем дә бар. Иң әүвәл, Тимерхан, бик тә эчтәлекле, миңа карата бик тә җылы хисле хат язып җибәргәнең өчен рәхмәтләремне кабул ит, яме. Безнең бер-беребезгә турылыклы, бер-беребезгә теләктәш булып яшәвебез дәвам итсен.*

*Безнең яшәештә, мөгаен, безнең кебек тә үтә якын кешеләр юктыр. Мин сине белгән көннән үк иң якын, иң талантлы, намуслы вә кешелекле дустым итеп санадым, хәзер дә шулай саныйм. Ник? Нилектән? Нинди генә авыр чакларда да син боекмадың, борыныңны салындырмадың. Таш кыяда үскән үсемлек кебек нык холыклы, шайтан таягы төсле яшәүчән малай идең син. Үзеңә дөрес юлны, җаның теләгән юлны сайлый белдең син, Тимерхан. Мондый сыйфат бар кешедә дә булмый бит. Үз бәхетеңне син күкрәк көчең белән, чамасыз тырышлыгың белән яулап алдың. Шунлыктан картлыгыңны бик тыныч, көр күңел белән үткәрергә хаклы син. Совет аппаратында, дәүләт органнарында эшли алырдай шәхес булып җитештең, министр урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелә алдың. Уйлап баксаң, син әле алай гына да булып калырга тиеш түгел идең. Синең үсүеңә Вәрәшбаштагы, Мөслимдәге, тагын әллә кайлардагы вак җаннар, наданнар, хөсетле кешеләр аяк чалды. Әтиең Борһан абзыйны мулла итеп күрсәтеп! Ул кешеләр хәзер юк инде. Хәер, булып та әллә ни кыра алмадылар. Син җиңдең! Синең иман, синең ныклык җиңде. Синең шундый булуың өчен горурлануым хак. Оста гармунчы, җир җимертеп биюче, һәммә кешене авызыңа каратып тота ала торган оратор, иң әйбәт каллиграфия белән яза алучы. Син андый язуың белән, ихтимал, патша заманында да югалып калмас идең. Тирә-юньдә дан алырлык писер чыгар иде синнән. Мин синең әтиең Борһан абзыйны да, әниең Гатифә апаны да кешеләрнең дә кешесе итеп беләм. Берзаман син урамда калдың, үги ана кулында мескен булып торырга теләмәдең. Сиңа шул чагында юл күрсәтергә кирәк иде. Мин ул эшне эшли алдым шикелле. Үзең дә молодец инде — сүзне тыңлый белдең. Авылыбызның баш хисапчысы Гайфуллин Хуҗа абзый янына эшкә урнашып син уңдың. Нәкъ шул чагында дөньяны таный белергә, булган хәлләрне үз бизмәнеңә салып үлчәп карарга, бизмәннең кайсы тәлинкәсе авыррак тартканны һәм ни өчен тартканны аңларга өйрәндең. Бәләкәйдән зиһенле булгансыңдыр, ахрысы, шайтан малай! Нәрсәгә генә тотынма —*

*барысын булдыра идең бит син. Күр инде, гармунчы Шәрифҗан абзыйдан, ялынып-ялварып, клубка тальянкасын алып төшә торган идем. Ә син әллә ни арада өйрәнеп тә өлгердең. Сиңа ходай музыкантлык сәләтен дә биргән шул! Тагын кабатлыйм: син үз юлыңны, үз бәхетеңне таптың. Синең уңышыңа гомер юлдашың Асияның да ярдәме тими калмагандыр. Асия Вәрәшбашта кешеләр бик ихтирам иткән шәфкать туташы иде. Минем алар өендә булганым бар. Асияның әнисе белән әтисе алтын кешеләр иде. Әйе, сез бәхетле пар булдыгыз, гел шулай яшәргә насыйп итсен.*

*Мин хәзер, картайгач, үземә тәнкыйть күзлегеннән карыйм. Үкенгән чаклар да, ялгышканымны таныган чаклар да була. Тумыштан эгоист булу мине һәлак итә язды. Шуңа куанам: мине урындагы кешеләр (хәзергечә әйтсәк, җитәкчеләр) югалтмадылар. Эшли торган эшем — укытучы булу — миңа популярлык китерде. Шуның өстенә каләм тибрәтә белү, газитләргә мәкаләләр язып тору мине халык арасында танытты. Күпме әрәмтамакны, булдыксызны, бушбугазны алып ташларга булышты минем язганнарым. Мактана дип уйлый күрмә, Тимерхан, мактану түгел бу, яшьлек дустым белән шатлыкларны уртаклашу. Мин бит барлык иптәшләрне дә сине якын иткән кадәрле якын итә алмыйм. Минем чын дусларым бармак белән генә санарлык: Харисов Габделхак, Фәйрушин Заһитхан. Аларга хат-мазар яза калсаң, миннән дә сәлам тапшыр.*

*Үзем әле һаман укытам: немец теле, химия. Җәмәгать эшләреннән дә баш тартмыйм. «Белем» җәмгыятендә рәис, «Авыл утлары» газитенең хәбәрчесе. Иптәшләр судында да катнашам. Газиттә бастырган бер язмамны хатка салып җибәрәм, вакыт тапсаң, укып карарсың. Ул очерктагы геройның язмышы синең язмышка бик тә туры килә. Арттырмадым-киметмәдем, куңел кушканча яздым. Тормышта ничек бар, шулай. Җиңү көненә тагын бер язмам дөнья күрәчәк, анысын Асылов Дәүләтгәрәй мәрхүм хакында яздым.*

*Гаилә хәленә килгәндә, зарланырлык түгел. Җиде бала үстердек. Бишесе үз тормышларын кордылар инде. Бездән аерым, үзбаш, мөстәкыйль яшиләр. Бер кызым медицина институтында, улым пединститутта укый. Өйдә Әминә белән икәү генә торып калдык. Әйе, картайдык. Саулык-сәламәтлек чүкеч кебек дип әйтмәс идем. Шулай да корыган усак төсле шыгырдап утырырга ният юк. Тырышып-тырмашып яшәп ятабыз.*

*Авыл үзгәрде, нык үзгәрде, Тимерхан! Утыз йортның тәрәзәсенә такта кадакланды. Үзгәртеп кору дигән сүз модада, ләкин аны Вәрәшбашлар белерләрме, күрерләрме — әйтүе кыен. Аренда вә арендатор дигәнен дә күп сөйлиләр, анысын да безнең авылда белүче юк әле. Кадрлар кирәк, кадрлар. Син, Социаль тәэминат министрлыгының музеен төзим, дип язгансың. Ул эшеңә кул куям, Тимерхан. Бик тә изге эшкә тотынгансың. Ул музейга барлык сәләтеңне сал, исемең мәңге югалмас. Теге заманда эшләгән наркомнарның, ялгышмасам, күбесен төрмәгә утыртып, атып бетергәннәр бугай, ул хакыйкатьне дә киләчәк буыннарга ачып бирсәң, иллә дә шәп булыр иде.*

*Хатны мин сиңа соңгарак калып яздым, гафу итәрсең инде, бу арада шөгыльләрем күп булды. Бөек шагыйребез Тукайга карата әдәби викторина оештырдык, шуның сорауларына җаваплар эзләдем. Җиңел булмады — 22 сорауга җавап таптым. Һади Такташ, Фатих Әмирхан, Муса Җәлилләр хакындагы сорауларга да җавап бирдем. Шушы дүрт олы шәхес турында бик күп укыдым, белемем тирәнәйде, шул шатлыгымны сиңа да хәбәр итәм. Кызыклы хәл: Муса безнең мәктәптә иптәшләре белән кунып киткән икән. Юк, кунмады, дип бәхәсләшүчеләр дә табылды. Ул хәлләр, Тимерхан, синең исеңдә калмадымы? Мәллә аркылы узганмы Муса Җәлил, әллә Вәрәшбаш аркылымы? Минә шуны исбат итәсе бар. Мин белгәне шул: Муса 1941 елның 7 ноябрендә безнең мәктәптә куна. Муса Җәлилнең әнисе белән бертуган абыйсы Таһир Корбанов нәкъ шул елны безнең мәктәптә укыта. Мин хәтерлим аның укытканын. Идрис Туктар дигән язучы да укытты бездә. Идрис абый белән кул буена төшеп, күңел ачып йөрүләребез дә хәтердә.*

*Тормыш-көнкүреш якларына килгәндә, авылда кытлык. Магазиннарда (авыл кибетләрендә) ит, сөт, май, шикәр, кәнфит — берсе дә юк. Кер юу порошоклары да каядыр китеп югалды, әле күптән түгел генә тау-тау өелеп яталар иде бит алар. Шундый шартларда авыл кешеләренә, бигрәк тә пенсионерларга ничек яшәргә? Вәлиәхмәт абзый кызына — Саимәләргә китте. Гражданнар сугышы ветераны бит ул. Беркөнне урамда, тыкрык буенда очраттым, чын күз яше белән җылап тора, өч көн инде ипи ашамаган, кибеткә килми, бүген менә тагын юк, ди. Әй итне, майны күрмәгәнгә ике ел була инде, ди. Казаннан халык контроле вәкиле килгән иде, Вәлиәхмәт абзыйны шуның янына алып кердем, сөйләттем, үзен күрсәттем, шуннан соң авылга ипи китерә башладылар. Менә шундый хәлләр, кордаш, бездә. Әллә ниләр яздым, гафу итәрсең, дөресен язмыйча күңел чыдамады. Хәзер авылда кешечә торыйм дисәң, пенсионермы син, 80-90 яшьтәме, бары тик терлек-туар асрап кына көн күреп була. Бу — хакыйкать! Авылда ирен, малаен югалткан, сугыш җирендә үлеп калганнарның гаиләсенә, тол һәм ятим карчыкларга аеруча кыен, бик кыен! Әнә шуларны күрсәм, түрәләргә нәфрәтемнән җаным кайный башлый.*

*Үземә килгәндә, зарланырлыгыбыз юк, сыер-сарык асрыйбыз.*

*Ярый, пока шуның белән тәмам итәм. Сөйләр сүзләр шулай да бетмәде әле. Калган гомердә, авылдашларым Тимерхан вә Асия, сезнең икегез белән дә бик иркенләп сөйләшеп утырасы бар. Фикерләрем буталчык булса, гаеп итмәссез. Күңелдәге уйлар да, тойгылар да бик күп, барысын тәртип белән генә, көйгә салып сөйләп бетереп булмый.*

*Сезгә тагын бер мәртәбә кайнар сәламнәр күндереп, эчкерсез ихтирам белән яшәүче Сәйделгыйлем Зарипов дип белерсез.*

*23 апрель, 1989 ел, Вәрәшбаш авылы».*

...Тимерхан Борһанов, хатны укып бетергәч, ике кулы белән иягенә таянып, бик озак тын утырды. Үзе үскән чактагы ямь-яшел урамлы Вәрәшбашның утыз йортына, тәрәзәләренә аркылы такта кагылган итеп күрү аның өчен ифрат авыр иде. Йөрәктән кан тамар дәрәҗәдә авыр иде. Авылның урта бер җиреннән агып яткан инештә йөзгән каз-үрдәкләр, җәйге челләдә шул инештә су коенулар, дусты Сәйдел белән шул инештә ат йөздерү, таң вакытында шул инештән балык каптырулар, егет булгач, шул инеш буендагы аулакта Миңлеасия белән очрашулар, шәфкать туташы булып эшләгән ул нәфис һәм назлы кызыкайның кайнар сулышын, тын алуларын тоеп торулар, аның калку, матур йомры күкрәкләре, аның ике толым булып җилкәсенә төшкән чәчләре, аның көмеш тәңкәләр сибелгәндәй яңгыравыклы тавыш белән рәхәтләнеп көлеп җибәрүләре — барысы, барысы Тимерхан абзыйның күз алдыннан узып киттеләр. Аның күңелен сагыш басты. Сабакташы Сәйделгә ул күңеленнән бик тә рәхмәтле, ул аңа хатындагы төгәллек, теге заманнарны һәм авылның бүгенге хәлен түкми-чәчми сурәтләп бирүе белән, яшьлеген кабат күңелдә тергезүе белән әллә ниткән көтелмәгән бүләкләр биргән шикелле булды.

Тормышта күпне күргән, шатлык-кайгыларны баш түбәсеннән чүмергән, инде өлкәннәр яше белән баручы бу кеше барлык уйлары, күңел җилпенүләре белән туган-үскән якларына, Мөслимгә, Вәрәшбашка кайтып китте. Җанында аның мәңге сүнмәс, мәңге сүрелмәс яшьлеге янарды.

## Икенче бүлек

Вәрәшбаш инеше ямьле, мул сулы Ыкның бер култыгы микән, башланган бер очы микән — алты яшьлек Тимерхан аны белерлек түгел иде әле. Ул инеш үзе әллә ни зур булмаса да, бик олы ермак ясаган, ә олылар аны бик тирән, диләр. Әллә ялган, әллә чын: имеш, биш дилбегә төшерсәң дә аның төбенә җитеп булмый! Күз дә

йоммыйча, шулай дип сөйли авыл кешеләре, инешне мактаган чакта хәйраннар калып, тел шартлатып торалар. Бераз үсә төшеп, мәктәптә исәп-хисап таный башлагач, белде Тимерхан, бер дилбегә алты метрлы булса, биш дилбегә утыз метрлы була ич. Ай-һай, утыз метр тирәнлектә диген, ә, Вәрәшбаш суы?! Ул чаклы тирәнлеккә кем генә төшеп житә алды икән? Ул исәптән әллә ничә метрлы чуртаннар ята торгандыр аның төбендә. Ай-һай-һай!

Авыл малае кая да булса читкә киттеме,— иң әүвәл әнә шул инешен сагына башлый. Җәен балык тоткан, су коенган, ат йөздергән, кышын тимераяк шуып, дөнья рәхәтен татыган урыннары бит ул аларның! Андагы күңелләлек, андагы чыр-чу... Боларны Тимерханның үлгәндә дә онытасы юк.

Вәрәшбашны тирә-ягыннан урманнар чолгап алган. Авылдан ике-өч чакрым гына ары Дәүләт урманы, аңа каршы якта Митрәй урманы, югары якта Пажба урманы, аңа тоташыр-тоташмас Бояр урманы. Нихәтле урман, ничаклы хозурлык. Җаның кай урманга барырга тели, рәхим ит, иренмә генә. Язын каен җиләге пешкәннән башлап, көзен чикләвек җитешкәнче авыл малае урманнан кайтып керми. Ә ул җәйге чилләләрдә көннән көн буе урманда әлсерәп йөргәннән соң, муенга бау белән аскан әбат чиләгенең авырлыгыннан муеннар каерыла башлаганнан соң, инештә су коенулары — әйтеп бетергесез рәхәтлек бит ул...

Җидедә микән, сигез яшендәме, Тимерхан, иптәш малайларыннан күрмәкче, чабата ясарга өйрәнде. Вәрәшбашта, ул үскәндә, чабата ясый белмәгән малай юк иде. Аякка бар киеп йөргәнең чабата булгач, ничек өйрәнмисең. Үзеңә ясау белән генә бетми әле ул, базарга алып барырга, налогын-мазарын, һәртөрле салымнарын түләр өчен дә чабата ясап сатарга туры килә. Чабатаны Вәрәшбашта ир-атлар гына түгел, хатын-кызлар да ясый иде. Шулай да чабата өчен кирәкле юкәне урманнан ир-ат алып кайта. Урманны саклаучы каравылчы бар, аңа эләгә-нитә калсаң, беттең, ул сиңа дөбердәтеп штраф салдыра, ә ул штраф дигәнен түләр өчен кимендә бер йөз кием чабата ясап сатарга кирәк булачак.

Авыл малайлары юкә курсы алырга язын-җәен йөриләр. Кешеләр татлы йокыда чакта, төннәрен.

Бервакыт шулай дөм караңгы төндә Вәрәшбашның өч малае — Тимерхан, Сәйдел, Гыйбадулла — урманга, Бояр урманына юкә төшерергә килделәр. Көндездән үк сайлап-барлап куйган бер аланда яшь юкәлек бар иде, авылда андый яшь урманны чаукалак диләр. Яшь туйраларның бер дигәннәрен сайлап, астан һәм өстән үткен чалгы пәкесе белән боҗра ясап куясың да, аннары юкә кабыгын пәке белән турыга ярып җибәреп, шөшле белән салдырып аласың. Көч-хәл белән күтәреп кайтырлык кабыкны аркага салып, урман авызына чыкты малайлар. Ни күз белән күрсеннәр — авыл ягында кеше шәүләсе. Мөгаен, каравылчыдыр. Шул имансыз сагалап торгандыр Тимерханнарны. Боларның урманга кереп киткәнен күреп калган инде, бер дә бүтән түгел. Эләктереп алса, беттеләр: штрафын җәй буена да түләп бетерә алмассың...

Малайлар, бер-берсенә сүз дәшәргә дә куркышып, арыш арасына кереп яттылар. Теге шәүләнең киткәнен, штраф сала алмый калганын көтәләр.

Яктырганчы көттеләр. Яктыргач, карасалар, ялгыз үсеп утырган имән икән. Имәннең кәүсәсе юан, ботаклары нечкә, караңгыда күренми. Шул имән, каравылчы булып, боларның котын алып торган икән. Көлештеләр дә, юкәләрен җилкәләренә күтәреп, кызу-кызу кайтып киттеләр. Алдануларына үкенделәр, әлбәттә. Шул имәнгә алданмаган булсалар, яктырганчы ук кайтып җитәселәр икән. Инде менә урман каравылчысының юлда тотып алуы да ихтимал. Бәхетләре бар икән, очрамады каравылчы, ә теге имәнне шул көннән башлап малайлар «Каравылчы имән» дип йөртә башладылар. Берәр төрле сер бүлешәселәре булса, яки көзге кичләрдә, сыер сакларга чыккан чакларда, «Каравылчы имән»

янында очрашырбыз! — дип кенә сөйләшәләр иде. Шул имән янына алар ат сакларга бардылар, ничәмә-ничә төннәрен шунда учак ягып, көлдә бәрәңге пешереп, караңгы һәм шомлы күк йөзенә утлы кадаклар кебек кагып куйган йолдызларга карап, әкият сөйләшеп яттылар.

Их, безнең яшь чаклар,
Әткәй шикәр ваткан чакта
Без ялаган пычаклар!..

— дигән кайсыдыр шагыйрь.

Кайларда, нинди еракларда, күксел томаннар артында калдың син, балачак?!

Әнә Сәйделгыйлем илле ел буена мәктәптә балалар укытты, авылның данлы вә дансыз кешеләрен район газите битләрендә яктыртып, аларның исемнәрен Мөслим төбәгенә билгеле итте. Гыйбадулла сугышта булды, җир йөзендә ашар ризыгы, эчәр суы бетмәгәч, утлы өермәләр эченнән исән кайтты, гомер буена трактор белән җир сөреп, инде лаеклы ялга чыкты. Пенсионер булды Гыйбадулла!

Дүрт-биш еллар чамасы элек, министр урынбасары булып эшләгән чагында, Тимерхан Борһанов Вәрәшбашка машина белән кайткан иде. Замандашларын, сабакташларын дигәндәй, машинага төяп, су буе әрәмәләрен, малай чагында җиләк җыйган урман аланнарын, балан белән миләшкә, шомыртка, карлыганга, кыргый чиягә, чикләвеккә йөргән урыннарын караганнар иде. Нинди яшерен сукмаклар, нинди серле юллар бар иде бу урыннарда. Күпме яшь йөрәк шул сукмаклар янында, шушы әрәмәлекләр буенда икенче бер яшь йөрәккә иң газиз тойгыларын, иң кадерле сүзләрен әйтмәгәндер дә, нинди кайнар иреннәр шушында кушылмагандыр. Беткән ул сукмаклар, әрәмәләре дә гарипләнеп калган, кемнәрдер яккан учакларда тал-тирәкләр көлгә әйләнгән...

Ә бит Тимерхан малай чакта, тормыш хәзергедән җиңел булмаса да, ачлы-туклы гына яшәргә туры килсә дә, кешеләрнең күңелләре көр, рухлары бай, ул язгы чәчүләр тәмамлангач башланган сабан туйлары, җыеннар, елга тугайларында шаулап торган яшьләр уеннары, үзәннәргә сибелеп, шаңдау булып кайткан тальян моңнары...

Их, шул яшь чаклар!
Вәрәшбаш тугайларында
Без кабызган учаклар...

Сабан туе Вәрәшбашта Тимерханнарның ындыр артында каз бәбкәсе үләне түшәлгән тугайда уза торган иде. Анда бик олы, юан, мул ябалдашлы каен бар иде. Каен астыннан чишмә агып чыга, ул чишмәне кешеләр Олы каен чишмәсе дип атыйлар иде. Тимерханның сабакташлары бермәлне дәррәү җыелып, әлеге каенны кочаклап караганнар иде. Җиде малайның колачы җитмәгән иде ул каенны кочакларга. Кырыгынчы еллардан башлап ул чишмәне Тимерханның әтисе Борһан абзый карый торган булды. Улакларын рәтләде, суы җыелып торсын өчен ташлар тезеп, кырыен кәс белән каплады. Шуңлыктан чишмәнең «Борһан чишмәсе» дигән икенче исеме барлыкка килеп, халык күңеленә кереп урнашты. Әтисе чишмәне бик нәхтә итеп тотканга күрә, ана сукмак өзелмәде. Хәзер ул олы каен юк инде, сугыш елларындамы, аннан соңракмы, каен корый башлагач, аны кисеп алып, кышын мәктәп мичендә яктылар.

Чишмә бар, чишмә һаман челтерәп агып ята. Шәһәрдән авылга җәйге матур айларда ялга кайткан Вәрәшбаш кешеләре иң элек шул чишмә янына киләләр, чишмәнең көмештәй чиста салкын суын кушучлап алып эчәләр, салкын су белән аһылтый-аһылтый битләрен юып, яшьлек истәлекләрен яңартып китәләр...

Менә бит әле Тимерхан абзыйның яшьлек хисләре, чишмәнең үзе янында булмаса да, кинәт кабынып киттеләр. Кем уйлаган сабакташы

Сәйделнең бер хаты, дустанә итеп, эчкерсез сөйләгән сүзләре шулхәтле дә истәлекләрне актарып чыгарыр дип? Шулай инде, саламга утны бер төртеп кенә җибәр, аннары аны сүндерермен дип уйлама. Дөрли дә дөрли инде ул аннары... Вакытында туктата, тыеп кала алмасаң, уттан көлгә әйләнгән салам эскерте кебек, җанында да истәлекләрдән җылы көл өеме генә торып калырга мөмкин. Тимерхан, дөрес, моңарчы тойгылар ташкынына бик бирелеп яшәгән кеше булмады, ул аларны тыя, туктата, йөгәнли ала иде. Ә менә бүген... әллә нишләтте аны дустының хаты, бөтен барлыгын, хәсрәт-сагышларын, ерак томаннар артындагы яшьлеген актарып чыгарды.

Каравылчы имәннән шүрләп, малайлар арыш басуында яткан көнне Вәрәшбашта искитмәле хәлләр булды.

Авыр йөк машинасы алып кайттылар.

«Полуторка» дип хәзерге заманда ирен читен кыйшайтып кына әйтелә торган үзе бәләкәй, үзе көчсез бер нәмәстәкәй булгандыр инде ул, әмма утызынчы елларда ул Вәрәшбаш кешеләренә могҗиза булып күренде. Авылның ул чактагы 247 хуҗалыгыннан кешеләр барысы диярлек урамга сибелеп, машинаны күрергә йөгерделәр. Тимерхан ише бала-чага капка-койма башларыннан, тал чыбыклы читән өсләреннән урамга коелды.

Авылга машина кайткан!

Атсыз арба кайткан авылга!

«Полуторка»ны шундый ук машинага тагып китергәннәр иде, аны китерүче шофер, Мөслим егете, тагып килгән чылбырны ычкындырып, колхоз рәисеннән нindidер бер кәгазьгә кул куйдырды да үз юлына китеп барды.

«Татар акылы тау төшкәч»,— ди халык. «Татарның тау төшкәч килгән акылын мең алтынга сатып алыр идем»,— дип әйтүчеләр дә бар. Шофер китеп күздән югалгач, авыл яшьләре ах иттеләр. Туктале, нигә дип алар шоферның Вәрәшбаш машинасын йөртеп күрсәтүен таләп итмәделәр? Таләп итәргә кирәк иде ләбаса! Бәлкем, ул машина икенче бер машинага тагканга күрә генә йөридер, бәлкем, ул «атсыз арба» бер тиенгә дә ярамаслык чипухадыр? Китте шуннан бәхәс, китте тел көрмәкләштерү, тик... күпме генә акыл сатмасыннар, «полуторка» дигәннәре урыныннан кузгалмады, колхоз кәнсәләре каршысында йокыга талып утыра бирде.

Яшьләрнең җаны тынгысыз, яшьләрнең машинаны йөртеп карыйсылары килә. Их, шайтан алгырысы, нишләп соң әле алар машинага дәррәү төялеп, «урак-чүкеч» турындагы җыруларны җырлап урам әйләнмәделәр? Шаулаша торгач, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә бәхәсләшә торгач, тәки бер фикергә килеп өлгерделәр. Туктале, чабата башы чыктале, дигәндәй, авылда бит тимерче Ләксәндер бар. Тирә-юньдәге авылларның атларын бер дигән итеп дагалый, хәтта Мөслим хәтле Мөслимнән «начальстуа» үзе килеп аргамакларын аңардан дагалата икән, нишләп әле ул машина йөртә белмәсен ди?

— Чакырырга, ниприминны чакырырга Ләксәндерне!

— Әйләндерсен Вәрәшбаш егетләрен урам!

— Җырулар җырлатып әйләндерсен!

— Калхузга тихника кайтартылганны Вәрәшбашның олысы-кечесе күрсен! Күрмәскә нисмеет правы!

Чакырып китерделәр тимерчене. Килде теге. Кешеләрнең, бигрәк тә яшьләрнең күзләре Александрда; авылча әйтсәк, Ләксәндер тимерчедә. Булдырса, ул булдыра, булдырмый икән инде, кемне дә булса бер булдыклы егетне Минзәләгә җибәреп укытып кайтарырга кала. Ләкин ул егет кайчан табыла, кайчан укып кайта бит әле...

Ярый, хуш, шундый уйлар, тормышка ашачагын белмәгән хыяллар белән ду килгән чакта, Ләксәндер машинаны әйләнеп чыкты, кабина ишеген ачып, нәрсәсенәдер баскан иде, машина, бөтен кешене таң калдырып, бик моңлы итеп кычкыртып җибәрде.

Менә шунда инде тимерче Ләксәндернең машинаны чыннан да үзенә буйсындыра алачагына, урамнар буйлап йөртәчәгенә тәмам ышандылар.

— Әйләндереп кил безне, әйләндереп кил, Ләксәндер Иванич, дип ялына-ялвара башладылар.

Тимерче нык холыклы булып чыкты, машина белән яшьләрне урам әйләндерергә ул бернчек тә риза булмады.

Тимерчелектә каешланып каткан картузын арткарак чигереп, зәңгәрсу-яшькелт күзләрен җиргә төбәп һәм аннары күккә төбәп, беравык дәшми торганнан соң, өзеп кенә әйтте:

— Юк, туганнар, кыстамагыз мине, булмый! — диде тап-татарчалатып. Озак еллар татар авылларында яшәгәнгәдер, татарчаны ул су урынына эчә, тәмле теле белән хәтта кайбер тел бистәләрен дә уздырып җибәрә иде.

— Йә инде, Ләксәндер Иваныч, яшьләрнең өметләрен кисмә инде, бер мәртәбә инеш буйларыннан әйләндереп кил инде! — дип авылның акыл иясе картлары да сүзгә кушылды. — Йөртеп күрсәт инде, күреп торабыз, йөртә беләсең бит...

— Йөртә белмим дип әйтмим мин, ил картлары, йөртә беләм, әмма дә ләкин минем машина йөртү өчен правам юк.

— Ниткән права ул тагын, без сиңа праваны үзебез бирәбез, — дип халык арасыннан алгарак чыкты колхоз председателе Низамов, авылдагы иң зур хокуклы кеше.

Тимерче Ләксәндер, башны кырын салып, аз гына уйланып торгач, кабина ишеген тагын ачып, эчкә кереп утырды, тагын бер мәртәбә, бу юлы сузыбрак, гудок бирде.

— Ярар, аллага тапшырдык, урыс әйтмешли, с богом, тәялегез! — диде.

Яшь-җилкенчәк, утызлап кеше, минут эчендә машинага менеп тәялде. Ул хәтле кешегә утырып барыр урын юк иде, бер-берсенә тотынып, җилкәләреннән кочаклап, тыгызланып бастылар.

Машина, пытыр-пытыр килеп, әче зәңгәр төтен бөркеп, кузгалып киткәч, сөенеп кычкыруларның, урамда басып калганнарның кул чабуларының чиге-чамасы булмады.

Ләксәндер Вәрәшбаш инеше янына җиткәч, машинаны туктатты.

Машинадан калышмаска тырышып, җан-фәрманга чапкан малайлар күпер төбенә килеп өелделәр.

Шулчакны Ләксәндер тимерче, кабинадан чыгып, аның баскычына баскан килеш, бик тыныч тавыш белән әйтте:

— Инде төшегез, иптәшләр, күпер бик начар, мин сезне үлем авызына кертеп тыга алмыйм.

Тимерханнар күрде: машина өстендәгеләр кымшанып та карамый.

— Ярый, алайса, баскан килеш тора бирегез, мин киттем, — диде тимерче.

Машина өстендәгеләр ялына, безгә пычагым да булмас, күпер дә чыдатыр, диләр. Нәсел айгырын тарантаска җиккән Низамов килеп житте. Машинаны кай тирәгәрәк куярга икәнен чамалау өчен ат җигеп чыккан булса кирәк. Кулына чыбыркысын тоткан хәлдә тарантастан сикереп төште дә машина кырына килде.

— Ни булды? Нәрсәдә аңлашылмаучылык?

— Егетләр төшәргә теләми. Ә мин аларны күпер аркылы алып чыгарга теләмим, аварияле күпергә кеше төягән килеш барып керергә минем башым ике түгел, — диде тимерче.

Низамов Кыям абзый бик тәвәккәл кеше иде. Малайлар аның тәвәккәллегеп колхозның кыяр бакчасына урлашырга кергән чакта үз сыртларында татыганга күрә, ни буласын көтеп, авызларын ачып тора башладылар.

Низамов Кыям абзый бу юлы да артыгын сөйләшеп тормады, кабина баскычына басып, машина кузовына бер генә сикерде. Сикереп

менүе булды, төшәргә теләмичә киреләнгән егетләрнең аркасына каеш камчы белән тамыза башлавы булды. Егетләрнең кайсысы кычкырып, кайсылары көлешеп, машинадан «ә» дигәнче җиргә коелдылар. Машинада иң батыр, иң куркусыз өч-дүрт кенә егет торып калды.

«Полуторка»ны күпер төбендә калдырып булмый, аны йә амбарлар янына, йә киредән кәнсәләр йортының ишек алдына илтеп куярга кирәк иде. Тимерче Ләксәндер тагын кабина эченә чумды, тагын бер мәртәбә кыска гына итеп кисәтү гудогы кычкыртты, аннары артыннан зәңгәр төтен төргәкләре ыргытып калдырган машинаны сайгаклары дыңгырдыңгыр килеп торган күпер аша алып чыга башлады. Ничек итсә итте, күпердән алып чыгып җиткерде ул аны, әмма күпернең теге ягында көтелмәгән бер хәл килеп чыкты. Машинаның алгы тәгәрмәчләре килеп керүгә, ярның балчыгы ишелә башлап, «полуторка»ны үзе артыннан сөйрәде, күпер төбендә өелешеп калган яшьләр аһ итәргә дә өлгермәделәр, машина бер-ике тапкыр мәтәлчек атып, су эченә кереп утырды.

Машинада басып торган өч-дүрт егетнең кайсылары ауды, кайсылары ярга сикереп өлгерде, ыңгырашкан-кычкырган тавышлар ишетелеп калды. Чырае көл кебек агарган Ләксәндернең берме-икеме кабыргасы сынган, егетләрнең бите сыдырылган, кулы-аягы каймыккан, әмма... үләр дәрәҗәгә җитеп яраланган кеше юк иде.

Әлеге фаҗигале хәлне районга-мазарга җиткермәделәр. Ул чакта бит аның хәзерге төсле ГАИ дигән оешмалары да юк, тикшерүче-фәлән дә килмәде. Яраланган егетләр атна-ун көн эчендә савыктылар, булып узган күңелсез хәлне, еллар узгач, көлеп кенә искә ала торган булдылар. Ә менә хәзер ул Тимерхан абзыйның күңеленнән әллә кайчангы кадерле бер истәлек булып узды...

Вәрәшбашта заманында моннан хәтәррәк хәлләр дә булган. Ихтимал, машина маҗарасы ул хәтәр хәл алдында бик кечкенә күренгәндер кешеләргә.

Вәрәшбаштан биш чакрымнар ары Ольгино дигән урыс авылы бар. Бик яхшы хәтерли әле аны Тимерхан. Үсә төшкәч, кешеләрдән шул авылның бер аянычлы вакыйгасын да ишеткәне булды. Андагы җирләр, урманнар революция чыкканчы Хвощинский дигән алпавытныкы булган. Алпавыт үзе Санкт-Петербургта яшәгән, җәйләрен — ял итәр өчен — бу яклардагы утарына кайта торган булган. Андагы конторлар, ат абзарлары, хезмәтчеләр яшәгән йортлар, бигрәк тә алпавытның резиденцияләре революциядән соң бик хәтәр җимерелүләргә, кыргыйларча котырынып ватуларга дучар ителсәләр дә, әле һаман кирпеч стеналарын, гөмбәзле түшәмнәрен саклыйлар; аларны хәтта җил-давыллар да алтмыш-җитмеш ел буена җимереп бетерә алмаганнар. Аларны, борынгы картлар әйтүенә караганда, булыр-булмас цемент белән, бармак төртсәң ишелергә торган коры ком белән өеп куймаганнар, махсус базларда кыр ташыннан яндырылган сүнмәгән известь белән, күкәй агы кушып, катырганнар. Аларны хәтта кувалда дигән бер потлы тимер чүкеч белән дә ватып алырлык түгел. Байлар сала белгәннәр йортларын!

Халык бу йортларны, бу биналарны, каралты-кураны таң калып сөйли, әмма аннан да бигрәк, алпавыт белән булган бер аянычлы хәлне куркыныч итеп сөйли иде.

Алпавыт Хвощинский уналтынчы елның азагында бер хезмәтчесен, үзенә каршы сүз әйтергә батырчылык иткәне өчен, этеннән талаткан булган. Февраль революциясе башланган көннәрдә әлеге эттән таланган кеше алпавытның үз утарына кайтачагын ишетеп, аны юл кырыендагы кушкаен артына яшеренеп саклап торган һәм тройка атларда киерелеп кайтып килүче алпавытны ике көпшәле ау мылтыгыннан атып үтергән.

Үчлекле хезмәтче янә ике мәртәбә һавага гөрселдәткән, монысын ул тройканы алып кайтучылар һәм алпавытны озатучылар качып китсенгә эшләгән, азактан җан тәслим кылып апа-ялгызы кан эчендә яткан алпавытның янына мылтык күтәреп килгән, аның күзләренә батырып

карап, мылтыгын төбәгән килеш, алпавыт өнсез калганчы басып торган...

Әнә шул куркыныч вакыйга, еллар узган саен куркынычлыгы арта барган вакыйга белән чагыштырганда, яр астына тәгәрәгән машина мәзәк бер хәл булып кына күңелдә торып калган, ә кешеләр аны Тимерхан үсеп буй җиткән чакта онытып та бетерә язганнар иде инде. Балачакта күргәннәр, ишеткән-белгәннәр адәм баласының хәтеренә уелып кала, бәлки, шуңадыр, Тимерхан абзый аны шушы көнгә тикле күңелендә саклый...

## Өченче бүлек

Тугыз яшендә чакта Тимерхан әнисез калды.

Ихтимал, бу — Тимерхан дигән нечкә күңелле малайның йөрәгенә китереп суккан беренче удар булгандыр. Ятимлек берәүнең дә башыннан сыйпамый. Әнисе Гатифә, халык аны Бибигатифә дип йөри иде, 1936 елның августында вафат булды.

— Иртә дөнья куйды мәрхүмә, әле илле биш яшендә генә иде бит, — дип күршеләре, аның җеназасына җыелган карчыклар бик офтандылар. Тимерханның әнисен дә, әтисе Борһанны да, олы уллары Баһау белән кече уллары Тимерханны да бик кызгандылар.

Әнисе бик ягымлы кеше иде. Авыз ачып бер авыр сүз әйтмәс, тиргәмәс-каргамас, йомшак кына итеп әйткән бер үгете мәңге онытылмаслык булып хәтердә кала иде. Догаларны күп белә, аларны улларына әйтеп яздыра, бисмилла әйтмичә бер эшне дә эшләмәскә куша иде. Зурайгач, бигрәк тә сугыш утларында йөргән чагында, Тимерхан аңлады, бисмилла әйтеп тотыну, ул, баксаң-күрсәң, күңеленне үзең башкарган гамәлгә беркетеп кую, җаныңны чуарламау икән.

Бибигатифә — Борһанның беренче хатыны түгел, ул аңа соңыннан, ире Әгъләмнән тол калгач, кияүгә чыга. Ә Әгъләм дигәннәре Минзәлә якларының бик тә хәлле, исеме тирә-яктагы авылларга таралган кеше була. Өч ташлы тегермән, үзе өчен дип кенә җигелә торган аргамаклар, келәм белән тышланган тәрәкле чаналар, шомырт карага буялган тарантаслар — Әгъләм бай узып киткән чакларда якын-тирә авыллардагы ярлы-ябагай күзләрен ут яндырып карап кала һәм, авыр көрсенеп: «Менә, ичмасам, кешеләр дөньяның җәннәтендә яши»! — дип үзара сөйләшә. Үз ягының кешеләре аны кайчан карама ак нәфис перчаткадан итеп күрергә күнеккән булалар. Менә шушы олы дәрәҗәле, бик тә абруйлы кеше нииндидер бер ат бәйгесендә чаптар аттан егылып төшеп, Бибигатифәсен тол калдырып, үлеп китә. Гатифә бикәгә дөньяның җәннәте бетә. Зур кайгы бит әле ул үзе генә йөрми, артыннан кечерәк кайгыларны да ияртеп килә. Бибигатифәнең олы улы, Әгъләмнән туган беренче баласы ярман сугышында һәлак була. Икенче улы, егерме беренче елның ачлыгында, урманга киткән җиреннән кайтмый, унбиш яшьлек сөлек кебек үсмер, дөньяда бөтенләй дә булмаган төсле, эзсез-башсыз югала. Бердәнбер төпчеге белән, авыр кайгысы белән торып калган Гатифә бикә Вәрәшбаш мужигы Борһан йортына килә. Үги малай Баһаветдин яңа әтисе Борһан йортында озак яшәми, затлы нәсел баласына Баланлы авылының данлы кешесе Хәсән байның күзе төшә.

Өстенә затлы тун, башына йөнтәс затлы бүрек кигән Хәсән бай адәм балалары ачлыктан кырылган егерме беренче елның зәһәр суык кышында, бизәкле кашавай чанада, кара туры айгырны Борһаннар капкасы төбенә туктата:

— Гатифә бикә, мин синең хәлеңә керергә дип килдем. Ирең Әгъләм минем якын танышым иде, илә дә әгъвә кеше иде. Кайгыларың күп булды, мин аларны уртаклашам, тагын да бер кайгың булмасын. Баһа-

ветдинынны миңа биреп җибәр син, аллага тапшырып. Мин аны балигъ булганчы үземдә тотып, дөнья күтәргә өйрәтермен, миңа атларыма ышанычлы бер кеше кирәк. Балигъ булгачыннан да, мин улыңны җигүле бер ат биреп, сиңа кире кайтарырмын. Аның үги әтисеннән ник сорамыйсың дип үпкәләмә, Баһаветдинда синең хакың зуррак, чөнки ул синең үз балаң, газиз балаң...

— Газиз балаң дип тә, үз балаң дип тә бик дөрес әйттең, хөрмәтле Хәсән бай, газиз баламны бит мин сагынырмын, ул бит минем хәзер бердәнбер юанычым.

— Гатифә бикә, бер дә борчылма, Баланлы бит Вәрәшбаштан унбиш кенә чакрым, сагынган саен килерсең, улыңның тәрбияле кулларда икәнен күрерсең, җаның канат кагып кайтыр, минем дәү бер кунагым булырсың. Килештекме, аллага тапшырып?

Килешми кая барасың? «Заманалар авыр, еллар ябык...» — ди бит әнә халык. Бибигатифә бердәнбер улын, Әгъләменең төсен Хәсән бай кулына тапшыра.

Барганмы Гатифә бикә улын сагынып, бармаганмы — анысы Тимерханга караңгы, ул турыда беркем дә сөйләмәде аңа, әмма шунысы хак: байлар сүзләрендә тора белгәннәр дә соң! Хикмәте хода, Баһаветдин дигән үсеп буй җиткән егет Хәсән байлардан тарантаска кола бия җигеп әнисе йортына кайтып төшә. Әмма дәхи бик тә вакытсыз чакта кайтып төшә. Атларны күмәк хуҗалыкларга талап ала торган чак була бу. Менә монда инде вәгъдәләрендә тора белә торган байларны кабат исеңә төшерми хәлең юк. Вәгъдәдә тору ул — **йөз тоту** дигән сүз. Ихтимал, ул төшенчә төрки халыкларына кытайлардан кергәндер. Хуннар, сөннәр — безнең бик борынгы бабаларыбыз — кайчандыр кытайлар белән янәшә яшәгәннәр бит. Кытай халкында йөз тоту — байлар өчен дә, ярлылар өчен дә бердәй фарыз. Кеше йөзен югалттымы, үзен-үзе үтерә торган була кытайларда. Ә безнең илдә җитмеш ел эчендә дәүләт башлыклары да, урыннардагы түрәләр дә ничәмә-ничә тапкыр — санап бетергесез! — йөзләрен югалттылар инде, әмма берсенең дә үз-үзен үтергәне булмады.

Тимерханның әнисенә ияреп килгән Баһау (Баһаветдин), озак еллар байлар йортында яшәп, атлар карап, әлеге гаиләдән йөз тоту төшенчәсен аңлап кайткан иде булса кирәк, Вәрәшбашның партячейка секретаре белән авыл Советы башлыгы Борһан абзыйны колхозга яздырырга дип килгәч, Минзәлә ягына аты-ние белән чыгып тая. Ул белә, ул күрде: ул еллар буе эшләп тапкан кола бияне дә, тарантасны да, каеш дирбияларны да күмәк хуҗалык ихатасына илтергә кушачаклар. Кушмый торсыннар! Баһау Минзәлә ягының Иске Мажын исемле урыс авылына килә, уптым иләйһи, барысын, җаннан кадерле атын да, тарантасларын да сатып җибәрә.

Баһау абыйсының ул тәвәккәллегенә Вәрәшбаш активистлары нинди бәя биргәннәрдер, Тимерхан ул чакта әле биш яшьлек кенә малай иде, ул аларның берсен дә белмәде, әмма үги абыйсының атларны шулкадәрле дә яратканын аның колхоз ат абзарында эшләгән чагында күрде, димәк, колхоз башлыклары аның ул сыйфатын күргәннәр, аңардан бик оста файдаланганнар. Вәрәшбашта ул заманнарда нәселле атлар фермасы булдырганнар иде.

...Әнисе Бибигатифә үлгәч, тугыз яшьлек Тимерхан үкси-үкси елады. Кара гүр, әнисенең кәфенгә төреп төшергән гәүдәсе, әллә ничә кәрәкнең кабергә берьюлы балчык ташлавы, аннары кабер почмагына тезләнеп, әтисенең, тагын кайсыдыр авыл картларының кул күтәреп дога укулары бик озак вакытлар Тимерханның күңеленнән китми тордылар. Ул әнисен ел буена төшендә күреп, уянгач өйдәгеләргә күрсәтми генә елый торган булды...

Бу вакытта абыйсы Баһау өйләнеп башка чыккан иде инде. Әтисе Борһан — ни кушсалар шуңа риза була торган «Ярар Борһан» — кичләрен сарык фермасына каравылга китә, Тимерхан өйдә япа-ялгызы

торып кала. Куркыныч аңа, күзенә йокы керми, кайдадыр орчык зырылдап әйләнгән тавышлар ишетелә, кемдер йорт бүрәнәсендә тырмаша, өй чормасындамы, чоландамы — җен-пәриләр шыбырдашып йөри...

Акылдан яза язган иде Тимерхан ул чагында.

Әтисе беркавым үз алдына гына карап, сөмсерләре коелып йөрде дә Гайшә исемле хатын алып кайтты. Бер дә, бер дә бәхете юк икән әтисенең хатыннардан. Гайшә дигән үги әнисе белән дә бер йортта озак яшәргә туры килмәде Тимерханга; ә бит ул инде аңа ияләшкән иде. Лапастан утын алып кереп бирү, сыер абзарын чистарту, кышын өй тирәләрендәге карны көрәү Тимерханга берни түгел, Гайшә әнисенең йомышларын үтәү, аның сүзен тыңлау малайга рәхәт кенә иде. Холыксыз кеше дә түгел иде шул аның бу үги әнисе, тик бахырның гомере генә озын булмады, «Ярар Борһан» белән никахлашып бер ел тордымы-юкмы, йөрәк чиреннән вафат булды.

Шуннан соң Тимерхан, җаны борчылып, зарыгып, хәлдән таеп, тагын бер үги ананы көтеп алды. Монысы Бибисара исемле иде. Тазагайрәтле хатын, бер кизәнеп баш түбәңә утыртса, сынсыз калдырырлык! Иманыңны очырырлык усал, хәтта ки явыз хатын иде. Бичара, юаш әтисенә каян килеп юлыккан диген шундый адәм тәганәсе?!

Тимерханның зирәк бала, зиһенле бала икәнен мәктәптәге укытучылары барысы да танырдылар. Өченче сыйныфтан башлап ударник. Зәңгәрсу төстәге оекбаш белән бүләкләделәр. Ул заманда, сугышка кадәрле, директор чирек саен авыл халкын — ата-аналарны — клубка җыеп, мәктәп хәлләрен сөйли, кемнең баласы үзен ничек тота, алгы көндә аңардан кем чыгачагын яшерми әйтә иде.

Габдулла абый Халитов — бик оста итеп, өздереп кенә сөйли белүче каты куллы, әмма гадел холыклы директор — клубка җыелган ата-аналар алдында исемлек укып бара:

— Борһанов Тимерхан. Уналты фәннән уналтысы да отличнo. Тәртибе — начар.

— Нишләп алай булсын? Ул бит үзен бик акыллы тота. Олылар янында әрсезләнми,— дип, авыл апалары бәхәскә керешеп китә.

Директор бирешми:

— Борһанов Тимерхан, әгәренки беләсегез килсә, үзен укыта торган укытучылар белән өзлексез бәхәсләшеп тора. Шуңа күрә һәрбер укытучы аның белеменә «биш»лене, тәртибенә «ике»лене куя. Аңладыгызмы инде, иптәшләр?

— Аңладык,— дип баш селкиләр авыл апалары.

Мондый җыелышларга «Ярар Борһан» йөрми, ул фермада каравылда була, үги әнисе Бибисарага — ике дөнья бер, уртасы камыр. Тимерханда эше бармыни аның!

Ихтимал, авыл апалары Тимерханның мәктәптә укытучылары белән нигә бәхәсләшкәнен директорга караганда күбрәк аңлыйлардыр. Өендә ул бәхәсләшә алмый бит, әтисе бик юаш, ә үги әнисенә каршы бер генә сүз әйтеп карасын, теге мәлгунь баш түбәсенә берне генә кундырачак.

Җиденче сыйныфта чакта Тимерхан берничә мәртәбә укуын да ташлап карады, шундук укытучылары килеп үгетләде, аны бик тә үз иткән өч кыз, өйләреннән ипи сыныклары алып килеп, аның тамагын туйдырып тордылар. Ачлык, ялангачлык, үги әнисенең ямьсез кыланышлары Тимерханны шулхәтле дә туйдырган иде, аның күңеленә: «Бу дөньяда минем кемгә кирәгем бар, әллә юк булыйм микән?» — дигән уйлар да килгәләде...

Аларның ишегалларында кое бар. Тирән кое түгел, биш метрлар чамасы гына. Тимерхан шул кое янына килә дә түбәнгә карап тора. Кое суында аның бите күренә. Кулын югары күтәргәне, түбән төшергәне күренә. Ике кулың белән кое бурасының читенә ныгытып таянасың да — башың белән түбәнгә төшеп китәсең. Бу дөньяда мыскылланып яшәгәнче, үги ананың тукмагыннан куркып, кан калтырап торганчы, кое

төбендә җан биргәнең мең өлеш артык... Ләкин, менә-менә баштүбән ташланам дигәндә генә, малайның күңеленә икеләнү килә. Аның бит коега төшеп киткәнен берәү дә күрмәячәк. Берәү дә күрмәгәч, төшеп тору кирәкме соң? Ялгыш егылган диярләр, кызганырлар, шуның белән — вәссәлам! Ә менә үги анасына үч итеп үзе коега сикерде, дисәләр, ул чагында инде, авыл халкы Бибисара кортканы каргаячак. Аннары бит... яхшымы-яманмы, әтисе бар. Үз әтисе бит ул аның: улының үле гәүдәсе янында ясин чыга-чыга, күз яшьләрен йота-йота, тавышсыз гына елап утырса... Баһау абыйсы, атларың карарга кирәген онытып, хәсрәтеннән нишләргә белми йөрсә, сабакташлары җыелышып елашсалар?..

Тимерхан кире дән уйлый, кое яныннан, башын иеп, әкрен генә китеп бара...

Өметсез шайтан, ди халык. Кичләрен сукыр лампа яктысында Тукайның ятимлеге турында елый-елый укып утырулар, сукыр музыкантларның бәхетсез язмышларын җиңел чыгуларын белү Тимерханның китек күңеленә дәва булып, җанында өмет уты кабыза торган иде. Ничек кенә авыр булмасын, ул җиденчене «биш»ле билгеләре белән тәмамлап, Мактау кәгазе алып чыкты. Монысы ярады. Халыкта: «Борһан малае булдыра!» — дигән фикерне куәтләргә ярап куйды. Әмма бер гаделсезлек аның ятим җанын тагын кимсетергә җитә калды. Бер сыйныфта бергә укыган иптәш малаен, яхшы укыганы өчен дип, Казанга экскурсиягә җибәрделәр. Бу хәл Тимерханны бик гарьләндерде. Ул, озын-озак уйлап тормастан, тотты да Мөслимгә, мәгариф бүлегенә китте.

Хәзер, күп еллар узгач, ул мөдирнең исем-фамилиясе истән чыккан. Кинчә бите, игътибарлы кара күзләре дә ягымлы итеп сөйләшүе генә хәтердә торып калган.

— Безнең мәктәпкә иң зур белемле укытучыларны җибәрегез. Алар минем дә, теге малайның да белемен тикшерсеннәр. Тикшерсеннәр дә әйтсеннәр: ул хаклымы Казанга барырга, мин хаклымы?

Мөдир абый Тимерханның фәкыйрь генә өс-башын күздән кичергәч, аяк өсте басып, малайның җилкәсенә кулын салды:

— Ярар, энем, бар син, өеңә кайт. Бу мәсьәләне карарбыз, киңәшербез, хәл итәрбез, — диде.

Вәрәшбашка Мөслимнән бер укытучы да килмәде. Әмма авылга бер путевка килгән. Аны Вәрәшбашның комсомоллар башлыгы Сөләйманов Нурлыгаян абый Тимерханга тәкъдим итте. Казанга бару өчен урын дәгъвалап йөргән чакта Тимерхан бернәрсәне онытып җибәргән: аның кешегә күренерлек киеме юк икән бит. Әнә ни өчен мәгариф бүлеге мөдире аның өс-башын баштан-аяк күздән үткәргән икән. Җимерелде өметләр, төтен кебек юкка чыкты.

Теләк белән генә булмый, терәк тә кирәк икән шул. Ә бит Тимерханның ул заманнарда бер генә яктан да терәге юк иде. Әнә шунысы үзәккә үтте, әнә шуңа күрә дә ул сигезенчедә октябрь ахырларына кадәр генә укыды да мәктәпне бөтенләй ташлап чакты.

Хәзер инде ул үз көнен үзе күрергә тиеш.

Икенче көнне үк аның янына бригадир Хөснимәрдән килде. Озаклап сөйләшмәде.

— Мин синең укуыңны төгәлләгәнеңне белдем. «Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?» — ди халык. Ярар, укымыйсың икән инде, эш эшләрсең, энекәш Тимерхан. Мин сине юк-бар эшкә йөртмәм, җиде сыйныф белеме булган кешене атлы эшкә генә йөртермен. Син шуңа ризамы?

Риза булмаган кая! Атлы эшкә. Күңеленә хуш килә иде Тимерханның мондый эш. Ничәмә-ничә мәртәбәләр ул Баһау абыйсы янына барып, аның абзардан аргамаклар чыгарганын, аларны озын бау белән «зыр круглый» әйләндереп йөрткәнен күргәне бар, исләре китеп карап торганы бар. Ул менә хәзер инде үзе ат җигеп, зуп-зур кеше булып, колхозда эшләп йөриячәк. Ул чагында инде аны үги әнисе Бибисара да әрәмтамак

дип тирги алмас! Сабакташлары аңа көнләшеп карарлар. Үзе җигеп йөри торган атка ул, Баһау абыйсы төсле, ягымлы булыр, чыбыркы белән аның сыртын ярмас.

Тимерхан дүрт ай буена сарыклар фермасына мичкә белән инештән су ташыды. (Йа ходай, шундый заманнар да бар иде бит, нинди зур ферманың сарыкларын инештән мичкә белән су ташып эчертәләр иде, моңа баш селкеп утырмый нишлисең инде!)

Аннары аңа бәрәннәр торагын җылыту өчен урманнан ботак-сатак ташырга куштылар. Ташыды Тимерхан. Баһау абыйсы урманга аны беренче мәртәбә үзе алып барды, ботакларны ничек җыярга, балта белән тырпаеп торган чыбык-чабыгын ничек кисәргә, арбага ничек төярга, ничек итеп аркан белән аны бәйләргә үзе өйрәтте. Тимерхан олылар сүзен тыңлый белә иде, олылардан өйрәнүне үзе өчен мәртәбә саный иде, шуның өчен аны олылар яраталар иде.

Көннәрдән бер көнне аның янына колхозның баш хисапчысы (сугышка кадәр авылларда «бухгалтер» дигән сүз булмады), әйе, баш хисапчысы Гайфуллин Хуҗа абый килеп керде. Тимерханның үги әнисе Бибисара белән салкын гына, баш кагып кына исәнләшкәч, Тимерханны урамга чакырып чыгарды.

— Энекәш, минем сиңа сүз бар.

— Нинди сүз, Хуҗа абый?

— Син, Тимерхан, башлы малай. Мәктәптә гел «биш»легә генә укыдың. Мин менә уйладым-уйладым да, укыганың синең болай ат җигеп йөреп кенә әрәмгә китә дигән фикергә килдем. Әйе, әйе, шундый төпле фикергә. Мин сине гел күзәтәм, кешеләрдән сорашам, син минем күңелгә отыры ошый барасың бит, апаем. Мин хисапчы булып эшләүдән бик арыдым. Минем агротехник буласым килә. Ә шулай да үземнең урыныма хисапчы итеп намуслы кешене калдырасым килә. Менә мин, баш вата торгач, каеш түбәтәем белән киңәшә торгач, яшьләр арасында Вәрәшбашта синнән дә намуслырак кеше юк дигән фикергә килдем бит, әй... Син минем урынга кил әле, акыллым.

Тимерхан югалып калды. Ык-мык килде. Җүнле-рәтле җавап бирә алмады Хуҗа абыйсына. Ул бит мондый хәл булыр дип башына да китермәгән иде, гомер буе атлы эштә йөрермен инде дип язмышы белән килешкән иде.

Иртәгесен Тимерханны кәнсәләргә чакырдылар.

Килде Тимерхан кәнсәләргә. Өстәл янында ике кеше утыра: колхоз башлыгы Низамов Кыям, колхозның баш хисапчысы Гайфуллин Хуҗа. Хисапчы абый озын чандыр буе белән өстәл яныннан торды да төп-кебек нык таза гәүдәле председательгә әйтте:

— Менә, Низамов иптәш, Борһан абзый малае шушы була инде...

— Ну-ка, Борһан малае, бүрегеңне сал әле,— диде председатель, дорфа гына итеп.

Салды бүрекне Тимерхан. Күпереп торган кара чәч.

Бу юлы колхоз башлыгының түгәрәк кызыл битенә ягымлылык бәреп чыкты.

— Һи-ии, Гайфуллин, коеп куйган писер бит бу.— Тимерханга төбәлеп, карчыга сыман үткен карашын аның күзләренә батырды:— Карале, энекәш, без сине кәнсәләргә алабыз. Хуҗа абзаң ни куша, шуны үтәрсең. Килештекме?

Тимерхан, килешүен белдереп, баш какты.

— Бик яхшы, килешсәк! Менә шулай, во-оот. Иртәгә сәгать сигездән штубы-ты кәнсәләрдә утырган бул.

Сүз шуның белән тәмам. Ул заманнарда озын-озак сөйләшеп, әгъвалап тормыйлар иде. Тимерханга, атлы эшен бер якка куеп, колхоз кәнсәләренә килергә туры килде. Аңа кәнсәләр бүлмәсенең мич буеннан урын бирделәр. Урындыктан өстәлгә буе житмәгәч, калын бер папканы астына салып утыра торган булды «Ярар Борһан» малае.

Кәнсәләрдә Мәйсәрә Гыйздуллина эшли иде. Дөньяның бер гүзәле. Ходай яратса да яратыр икән адәм баласын күзләр камашырдай гүзәл итеп! Үзе тагын хушыңны алырдай җырчы. Эшли-эшли арыгач, саннардан, мәгълүматлардан күз аллары әлҗе-мөлҗе килә башлагач, Хуҗа абзый торып баса да кулын баш артына куеп киерелә, аннары зерә дә ягымлы итеп Мәйсәрәгә дәшә:

— Сеңелкәем, әллә бер музыкаль тәнәфес ясап алабызмы?

Дөньяның гүзәле Тимерхан ягына сөрмәле матур күзләрен сирпеп ала, үсмер егетнең яңаклары алсулана барганны күреп, аны тагын да оялтмас өчен, Хуҗа абзыйга таба борыла һәм күкрәк түреннән чыккан назлы да, күгәрченнәр гөрләве төсле талгын-куе да тавыш белән «Минзәлә»не җырлап җибәрә.

Мич буенда Тимерханга эссе, ләкин ул сырмасын салмый, моның бик житди сәбәбе бар: сырма астында Тимерханның күлмәге юк, сырманы ул ялантәнгә киеп килә. Әйе, эссе Тимерханга мич буенда, Мәйсәрәнең җырыннан аңа тагын да эссерәк булып китә. Болай да битләре алсуланып, аркасы тирләп утыра иде, Мәйсәрә җырыннан ул үзен гел дә ут эчендә итеп сизә...

Мәйсәрә моны аңлады, җырлап бетергәч, ул Тимерхан янына килеп, аның сырмасының төймәләрен чишәргә дип үрелде, аны бу авыр һәм кыен хәленнән чыгарырга теләде, Тимерхан курыкты, сырмасына чытырдап ябышты.

Мәйсәрәне, күрәсең, кара бөдрә чәчле үсмернең аның белән әвәрә килүе азартка кертеп җибәрде, ул үзенә ярдәмгә янәшә утырып эшләгән тагын ике кызны чакырды. Тегеләре көлә-көлә килделәр дә берсе Тимерханның бер кулын, икенчесе икенче кулын тотып торды. Мәйсәрә үсмернең сырмасын чишеп җибәрде дә куркуыннан телсез калды. Хуҗа абзый бик оялчан кеше икән, ул коридорга ук чыгып китте, ә Тимерхан, күз яшьләрен коеп, кызларның аяусызлыгына рәнҗеп, елап җибәрде.

Башта каушап калган, үсмер егетне ничегрәк бәхилләтергә белмәгән Мәйсәрә:

— Гафу ит мине, апаем, кичер мин ахмакны, үскәнем...— дип сөйләнә-сөйләнә, Тимерханны кайнар тыны белән исертеп, аны шомырт кара күзләреннән, ирennәреннән үбәргә тотынды...

...Шулар күңелендә яңаргач, алтмыш биш яшьлек бүгенге Тимерхан абзый авыр итеп бер көрсенде.

Гүзәл кыз Мәйсәрәнең язмышы бик фаҗигале булды. Аны авылга кино куярга килгән механик урлап китә. Өч айдан аера. Шуннан соң тагын бер моряк алып аера. Исерек чагында, көнләшүенә чыдаша алмыйча, син өегеп йөрисең!—дип кычкыра-кычкыра, күкрәгеп таптый. Мәйсәрә имгәнә, булнис юлларында йөри торгач, савыга алмыйча үлеп китә.

И дөньялар—кемнәрнең генә гомере кайларда өзелми. Гүзәллек белән талант ник соң адәм балаларына бәхет китерми икән?

## Дүртенче бүлек

1940 елның декабре. Кыш иртә килде. Җилләре белән, бураннары белән килде кыш. Иртә белән капка өсләрен күмгән кар көртләрен азаплана-азаплана көрәргә туры килә, шунсыз урамга чыгып булмый иде.

Шул буранлы кышның бер көне Тимерханның аеруча хәтеренә уелып калган.

...Бураннар өйгән тау-тау кар көртләре арасыннан тычкан уты төсле генә сары ут күренә. Өйгә кергәч, бөтенләй дә аптырап, гаҗиз булып калды Тимерхан. Ул үзләре өенең ярлы икәнен белә иде, аңлый иде, әмма

жир йөзендә алар өеннән дә ярлырак өйләр дә бар икән әле. Биш-алты тактадан сәке. Колгада бер тастымал эленеп тора, шүлтикле дә тузган, тотар җире дә калмаган. Өстенә ямау өстенә ямау тутырган киндер күлмәкле Гайнелҗинан түти кунакларга бер стакан тары ярмасы чыгарды. «Өйдә бүтән ризык юк»,— диде. Шул бер стакан ярманы суда гына пешереп алды. Абыйсы Баhау, Тимерхан, Гайнелҗинан түти, өчәүләп тотынгач, әлеге ботка һәркайсына бераз кашык тиде...

Тимерхан Борһанов, байтак еллар узгач, ул түтине кызганып, аларга тагын бер мәртәбә барды. Әтрәкле дигән авылда яши иде ул. Барды һәм исе-акылы китте: ул йортлар, ул каралты-кура! Бер дә, бер дә сөйләп бетерерлек түгел. Та-ма-ша! Балалары үсеп җиткән, зур урыннарга урнашкан, әниләренең картаймыш көнен матур итеп муллыкта уткәрәселәре килгән.

— Гайнелҗинан — кулак ул хәзер,— диделәр авылдашлары Тимерханга. Кешенең язмышы, баксаң-күрсәң, әнә нинди дә булып китә ала икән.

Тимерхан колхоз идарәсендә сигез ай эшләде. Аны күрде Кыям абыйсы, аның төпле егет икәнен аңлады. Пучы дигән зур авылга хисапчылар курсына җибәрде. Хуҗа абыйсы Гайфуллин аның бик тырышып укуын үтенде, кайту белән мин сине баш хисапчы итеп куйдыртырмын, диде.

... Курслар курслар инде ул — вакыт-вакыт дәртләнеп, вакыт-вакыт, канатлар сынгандай, нәүмизләнеп, барысын да баштан кичерә торгач, биш ай укып, зиһен туплап, Тимерхан Борһанов, хисапчылар курсын бик яхшы тәмамлавына язу алып, Вәрәшбашка кайтып төште.

Хуҗа абзыйсы шуны гына көтеп торган икән, колхоз башлыгына сүз ката бу:

— Карале, Кыяметдин иптәш, менә яшь белгеч, фәһем җыеп, авылыбызга кайтты. Син мине, пнимаеш, зинһар дип әйтәм, баш хисапчы булу вазифасыннан коткар инде.

Председатель Низамовтан Тимерхан бераз шүрли иде. Теге чакта колхозга кайткан беренче «полуторка»дан кешеләрне камчы белән сыдырып төшергәне өчен генә түгел, ул юлы дөрес эшләде Низамов, юкса утызлап кеше бер-берсенең өстенә авып, машина астында гарипләнеп беткән булырлар иде. Низамов Кыям абзый — аз сүзле, усал. Нәсел айгырларын танавыннан боргычлап ала торган кеше. Район түрәләре алдында да бил бөкми, тәлинкә тотмый, алар белән тиң булып, тавышны бөердән чыгарып сөйләшә. Әйе, нык адәм, тешләгән җиреннән өзә торган. Менә хәзер Тимерханга шул тимер куллы кешенең уң кулы булырга кирәк. Бер-берсен аңлап, ярашып эшли алырлармы алар?

Тимерхан әйле-шәйле уйлары белән әвәрә килгәнне Низамовның белергә дә нияте юк икән. Укыдыңмы колхоз хисабына — эшлә. Әле уналты яше дә тулып җитмәгән, өстәвенә буйга да әллә ни үсеп китә алмаган кара бөдрә чәчле үсмерне баш хисапчы постына ничегрәк килеп керергә икәнен сүганлап-борычлап өйрәтте.

— Сиңа, Борһанов, колхозның эш планын халыкка сөйләргә туры киләчәк. Матри, не подкачай. Аяк очларыңа басып, кычкырып-кычкырып сөйлә. «Менә булдыра, ичмасам!» — дип әйтерлек булсын. Караны, тишек борын, матри, әгәр сине баш хисапчы итеп сайламыйлар икән, мин түгел, үзең гаепле буласың. Аңлата алдыммы? Әллә булмаса, тагын бер мәртәбә аңлатып чыгыйммы?

Аңлаган иде Тимерхан. Ул, бәйрәм трибуналарында торгандагы кебек, кычкырып-кычкырып сөйләде. Тын да алмыйча сөйләде. Планны ул яттан диярлек белә иде. Әмма аның артыграк тырышканын очлы күзле кызлар да, акны карадан аера белә торган ил агалары да сизделәр, ахрысы, алгы рәттәге хатыннар, эш сайлауларга барып җиткәч, түзмәделәр:

— Без каршы, Низамов. Яшь бит. Нәрсә, син бу бәләкәйне ярты елдан өтерменгә илтеп тыкмакчы буласыңмы? — дип тавышландылар.

Председатель өстәл яныннан торып басты, иренен кысып, каш астыннан зәһәрле күзләре белән залны сөзеп чыкты:

— Бәләкәй дә не колякай! — дип кычкырып җибәрде. — Йомыгыз авызыгызны, катыннар! Алдан ала карга кебек каркылдап утырмагыз. Мин әйткәнчә булыр. Патамушты Борһан малае Тимерханны без колхоз хисабына укытып кайтардык. Озак вакытлар эшләсен дип укыттык. Башы да бар, зиһене дә, тырышлыгы дисәң тагын... Йә, кем дә кем, «Динамо» колхозының баш хисапчысы Тимерхан Борһанов булсын ди, рәхим итеп газиз кулларыгызны күтәрегез. Тәк-тәк-тәк! Пачти бер тавыштан. Рәхмәт сезгә, җәмәгать, ышанычыгыз өчен, ә сине, Борһан абзый малае Тимерхан энекәш, яңа вазифага сайлануың белән котлыйм! Бүгеннән башлап син дәүләт кешесе, колхозның авыр йөген җилкәңә салган комсомол!

Әйе, әнә шул көннән, 1941 елның март аеннан Тимерхан дигән үсмер егетнең бик тә җаваплы, абруйлы, авыр һәм четерекле зур хезмәт юлы башланды.

Инде шуннан соң кимсетелүләр булмас дип, мин дә кеше арасында кеше булып йөрермен, дип исәп тота иде Тимерхан ул чакта. Ләкин... тормыш ул син дигәнчә генә бармый. Эшеннән канәгать иде Тимерхан Борһанов. Артык намуслы-гаделле булгангамы, аңа баш хисапчылык янына әле колхоз пекарьнясының мөдире, МТС буенча колхоз ягыннан куела торган үлчәүче вазифасын да тактылар. Болар Тимерханның көндезләрен бөтенләй дә буш вакытын калдырмыйлар, шунлыктан аның көндез тамак ялгап алырга да вакыты булмый торган иде. «Тамак ялгау» белән бәйле бик ямьсез бер хәл аның күңелендә утырып калган.

Тимерхан шулай бер көнне пекарьнядан бер бөтен күмәч, бер кадак май алып, кеше артыннан үги әнисе Бибисарага җибәрде. Ул тиз генә кереп чыгар, әнисе чәй кайнатып куйсын. Чын күңеленнән ышанып, күмәчкә яккан май белән кайнар чәй эчүнең рәхәтлеген алдан ук тоеп, өйләренә кайтып керде Тимерхан. Кайтса, ни күрә — үги әнисе Бибисара, аның ике кызы шаулап кайнап утырган самавыр янында чәй эчәләр. Ул җибәргән ризыклар белән.

— Әни, минем эшем бик тыгыз, миңа тиз генә бер чокыр чәй яса да мин китәрмен, кызлар миннән соң эчәрләр чәйне, — дип үги ананың бер кызы алдыннан чынаякны үзенә таба тарткан иде Тимерхан, үги ана киерелеп утырган җиреннән, ләм-мим бер сүз дәшмәстән, бала башы чаклы йодрыгы белән Тимерханның авызына кундырмасынмы!

Авыздан-борыннан кан китте. Тимерхан елый-елый урамга чыкты, Баһау абыйларына барып, елый-елый, әлеге вакыйганы сөйләп бирде.

Баһау абыйсы да, аның хатыны Фәрхеҗиһан түти дә бик озак дәшми утырдылар. Аннары абыйсы Баһау, Тимерханның җилкәсенә кулын салып, энесен бик тә кызганган тавыш белән әйтте:

— И үксез ятимем... үземнең дә өем тулы бала-чага... Ни хәлләр итмәк кирәк, ул явыз катын сине сыйдырмый икән, мин сыйдырырмын, үзебездә торырсың, эштән кайтуга кием-салымыңны, китап-мазарыңны алып кил, яме, — диде. Мин дөрес сөйлимме, әнисе? — дип Фәрхеҗиһан түтигә таба борылды.

— Бәк дөрес сөйлисең, Баһаветдин. Тимерхан белән син бер ана балалары, әтиләрегез генә башка. Тимерханның үзе тапканы үзенә җитәр, ичмасам, бездә гарьләнеп яшәмәс, — диде.

Баһау абыйсы белән түтәсенең ул чактагы яхшылыкларын Тимерханның гомердә дә оныктасы юк. Аның ятимлектә боегып узган балачагын артта, еракта калдырдылар бу изге җанлы кешеләр.

Баһау абыйларына күчкәннән соң, авыл халкы алдында да бәясе күтәрелде Тимерханның. Ул хәзер чиста-пөхтә йөри, Фәрхеҗиһан түтәсе аның күлмәк-ыштаннарын гел юып-киптереп, кырлы бәләк белән тәгәрәтеп бирә, ул хәзер колхоз кәнсәләрендә ялантәнгә сырма киеп утырган чактагы тәсле, кешеләрдән тартынып сөйләшми. Тимерхан хәзер «Ярар

Борһан» малае дип кимсетеп әйтелә торган сүзләрдән югарырак, ул хәзер үзбаш уйлап, ятимлектә узган елларыннан сабак-гыйбрәт алырдай ушлы егет иде инде. Һәрхәлдә үзе шулай уйлый, ник дигәндә, авыл кешеләре белешмә-мазар кирәк булса да, киңәшләр сорап та аңа киләләр, аны олылап, хөрмәт белән сөйләшәләр. Әмма аңардан өстен, аны магнит кебек үзенә тартып торган бер кеше бар — Низамов Кыям абыйсы. Аның өрәге каты. Ул әйткән сүз — закон! Усал итеп тә, йомшак итеп тә сөйләшә белә ул.

Авызыннан ут чәчә торган булдыклы бер җиңги килгән.

— Туктап тор, чибәр җиңги,— ди аңа Кыям Низамов.— Син кайчан әле минем сүзне колагыңа элмичән Минзәләгә китеп барганыең? Былтырмы әле ул, өченче елмы?

Авызыннан ут чәчә торган булдыклы җиңги бирешмәскә тели:

— Ярарсана, персидәтел булдым дигәч тә, әллә кайчангыларны, Тукай бабай әйтмешли, «былтыр кысканнарны» искә төшереп утырма инде.

— Юк, искә төшерәбез, чибәр җиңги. Бу — бик принципиаль мәсьәлә,— ди председатель Низамов,— шул чагында, халык алдында син мине тыңламыйча китеп бардың. Нинди эшлек эшләгәнеңне бик яхшы белеп торасың, син минем бер еллык авторитетымны юкка чыгардың ул чагында. Карап-күреп торучылар әйтте: «Йа ходай, колхоз башлыгына төкереп тә бирмичә китеп бардылар. Бәлкем, аның үзенең дә безнең калхуздан китәр заманы җиткәндер инде, ул бит безнең авыллыкы түгел, ул бит әллә каян, Минзәлә ягыннан килгән килмешәк»,— диделәр. Синең мине тыңламыйча китеп баруың әнә нинди кыйбатка төште!

Тимерхан игътибар итте: авызыннан ут чәчә торган «чибәр җиңгинең» теле тотлыга башлады, ул оялып кына:

— Ярар инде, Кыям абзый, Тимерхан алдында оятлы итмә инде мине, әллә кайчангы гөнаһларымны казып чыгарма инде,— диде.— Аннан соң инде мин үзебезнең калхузга мең төрле яхшылык эшләдем инде...

— Нинди яхшылыклар эшләдең әле син?

— Нинди дип инде... Белмәгән төсле кыланып утырмасана, Низамов абый! Син кайтарткан сипаратта калхузның сөтен кем аерта? Көннәр буе, кайчагында бертоташтан атналар буе аертам бит сөтне... Ул гынамы? Син салдырган тегермәнне ел саен он тарттыра торган итеп чишмә суларын җыеп буган чагында, буа эшенә җыелган күрше авыл кешеләренә һәр яз саен, алланың бирмеш көне кем аш-су әзерләп тора?

— Яхшы, яхшы, бик хуп, бик хуп,— дип баш селкеп, гозер белән килгән җиңгәнең сүзен хуплап утыра колхоз рәисе Кыям Низамов. Берәү дә аны педагогик тактларга өйрәтмәгән, әмма ул бер белешмә генә биргән чагында да авыл кешеләренең яхшы сыйфатларын да, кимчелекле якларын да, үзләре онытмаслык итеп әйтеп чыгара.

— Тимерхан энем, җиңгинең әйбәт яклары ул эшләгән начар яклардан күбрәк икән, справкы дисеңме әле, белешмә дисеңме, син аларның барысын да беләсең, язып бир, мөһерен сук, үзем кул куярмын,— ди, гозер белән килгән кешенең йөзе тулган айдай балкый, ул инде иләбөгелә рәхмәтен әйтеп китә.

Колхоз кәнсәләренә Кондратьев Александр керә, авылның атаклы тимерчесе. Ул дагалаган төсле итеп Мөслимнең бөтен районында да ат дагалаучы кеше юк. Иң пырдымсыз, иң чикылдык усал атлар да аның кулына эләккәч, юашланып калалар, ат станында, әйтерсең, иң рәхәт минутларын кичерәләр. Аңа ат дагалатырга район хәтле районнан зур түрәләр килә. Александр Иванович ат тоягындагы һәр сеңгерне, җепне, җепсәне, йомшак-каты урыннарны биш бармагы кебек белә, аны «Динамо» колхозында тимерче дип кенә түгел, ветеринар дип тә йөртәләр, аның теге елларда инеш төбенә төшергәннән соң да «полуторка»ны исән калдыруын могҗиза итеп сөйлиләр.

Кәнсәләргә ул юк-бар йомыш белән кермәс. Җирән каты чәчен «керпе» итеп алдырган, дала кешесендәй киңчә кызыл битле, сәламәтлеге ташып торган кыска юан муенлы бу урыс абзые татардан да уздырып татарча сәлам бирә:

— Әссәламәгаләйкүм, кардәшләр, чибәр туташлар, җитәкче түрәләр! Исән-сау гына кышлап чыктыгызмы?

Аның җәен-кышын яланбаш йөрүе кешеләрне аптырата. Аның һәрчак ягымлы, нечкә күңелле булуы халыкны йомшарта.

Тимерхан белеп тора: колхоз башлыгы да, кәнсәләргә йомыш белән кергән кызлар да аны аягүрә басып каршылыйлар.

Кыям Низамов, урыныннан торып, ике куллап күрешә тимерче Кондратьев белән, кулларын җәеп җибәреп аңа урын күрсәтә.

— Юк, утырмыйм. Вакыт юк,— ди тимерче.

— Ә йомыш? — ди Низамов, аныңча кыска итеп.

— Йомыш бик җитди: үзегез укыган иске гәҗитләрне бирсәгез иде,— ди тимерче.

— Гәзит белән нишлисең? — ди колхоз рәисе.

Кондратьевның дала кешесендәй киңчә табак бите тагын да җәелә, ул ирен чите белән генә елмая:

— Дага төрергә кирәк.

Кыям абзый, колхоз башлыгы икәнен онытып, кызларны сискәндереп шаркылдап көлеп җибәрә: тимерчегә гәзит дага төрергә түгел, тәмәке төрергә кирәк. Аның шундый матур итеп шаяртуы колхоз башлыгының күңеленә хуш килә, һәм ул, тимерчене җилкәсеннән кочаклап, коридорга тәмәке тартырга алып чыгып китә.

Бераздан алар әйләнеп керәләр.

— Тимерхан энем, тимерче абзыеңа язу язып, мөһерен сугып бир: дуңгыз фермасыннан аңар ике дуңгыз баласы сатып җибәрсеннәр,— ди ул.

Мондый юмартлыкны Низамов теләсә кемгә эшләми. Күрәсең, Александр Иванович (халык телендә Ләксәндер!) аңа бик тә кирәкле киңәшен әйткәндер.

Һәм ул шулай булып чыга да.

Тагын бер атнадан, тимерче Кондратьев киңәше белән, Низамов кәнсәләргә тальян гармун алып кайтты. Бу могҗизага сокланмаган кеше калмагандыр. Бәясе — 750 сум. 21 телле. 18 бакалы. Мехлары аллыгөлле, бизәкләре гел җиздән.

Тимерханның үз авылларында бер генә гармун күргәне булды. Сафин Хәернас абыйда Саратский яшел гармун, кыңгыраулы гармун бар иде. Ул аны зәңгәр яулыкка төреп йөртә, клубка бик сирәк кенә алып чыга — аена бер мәртәбә генә! Уйнатуын да беркемгә дә уйнатмый, үзе генә уйный. Сафин абыйның үз принцибы бар: «Хатын белән гармунны чит кешегә ышанырга ярамый»,— дип кенә җибәрә ул.

Ә монда кәнсәләргә көмеш телле тальянка кайтып утырды.

Кыям абыйны бик оста гармунчы, диләр, әле колхозлар чыкканчы ук, яшь егет чагында, Минзәлә ярминкәләрендә гармун уйнап дан ала торган булган, имеш. Кеше ни сөйләмәс, Тимерхан аның гармун уйнаганын күрмәде, ул аның нык куллы, көрәшчеләр кебек таза бәдәнле, сүзен өзеп, кыска итеп сөйләшә торган җитәкче итеп кенә белә иде.

Колхоз кәнсәләренең төрле бүлмәләрендә эшләгән кызларны чакырып кертергә кушты ул Тимерханга.

Кызлар кереп, урындыкларга чүмәшкәч, ниндидер зур бер тартма алып керде, тартманы ачып, аннан күз явыңны алырдай гармун тартып чыгарды. Аның җиз тәңкәләрен кулы белән сыпырып, аларның чынлыгына ышангач, гармунны Тимерханга тоттырып карады.

— Матурмы? — диде.

Өнсез калган Тимерхан, көч-хәл белән иреннәрен кыймылдатып:

— Бу... безнекеме?..— диде.

— Безнеке бу, энем, безнеке! Авылда, карап йөрим, яхшы тальян гармун юк. Ә гармун бит ул — оештыручы. Музыка да тыңлата алмагач, яшьләрнең күңелен без ничек күтәрә алабыз? Җырсыз — дәрт юк, дәртсез эш, пешүе җитмәгән чи ипи төсле бит ул.

Кыям абый гармунның киң каешын ике як иңбашына киде, җайлап кына, ашыкмый гына урындыкка утырды. Юк, Казаннан килгән артистләр төсле урындыкка берекмәде, башны ул гармун өстенәрәк кыегайтып, гүя аның моңын күңеленә салырга теләгәндәй, ниндидер Тимерхан белмәгән бер моңлы көйне сыздырып җибәрде. Кызларның йөзенә алсу бер моңсулык йөгерде, күзләргә сагыш тулды, бүлмәдә булган өстәлләр, шкафлар, урындыкларда утырган кешеләр, хәтта гармунчы үзе дә оныттылды, җаннарны урап, әллә кайчангы хатирәләрне кузгатып, моң гына агыла, моң үзенең йомшак канатлары белән күңелләргә кагыла, язгы сулар кебек, ашкынып — тулып, ярларга килеп кагыла, күкләргә аша, каядыр әйди, чакыра һәм ятимлекнең ачы сагышлары булып түгелә иде.

Ихтимал, Тимерхан музыканың кодрәтен, жанны сафландыра, күңелләргә пакьлек өсти ала торган куәсен шунда аңлагандыр...

Кыям Низамов ул көнне кичнең кич буе уйнады гармунны, кызларны тәмам иләсләндерде, дөнья гамьнәрен, тормышта очраткан ямьсезлекләрен оныттырды. Аның шулхәтле дә зур һөнәрен әле моңарчы күрмәгән кызлар да, Тимерхан да таң калдылар.

Низамов Кыям абзыйлары ул кичне аларның туганнарына, иң-иң якын кешеләренә әйләнде.

Уйнап туктагач, ул гармунны җилкәсеннән салып, Тимерханга тоттырды:

— Менә, Борһан абзый малае, Тимерхан энекәш, гармунны мин синең карамакка тапшырам. Күзләреңнән күрдем, гармунга син тыныч карый алган егет түгелсең. Өйрән, уйна, җилкендер яшьләрне...

Йа хода, Тимерхан алдында өр-яңа дөнья ачылды.

Эшкә ул вакытыннан бер сәгать алданрак килә, бер-ике сәгатькә соңарыбрак китә. Эштән буш сәгатьләрдә аның кулында гел гармун булыр иде. Әмма ул гармун уйнаганын кызларга да, Кыям абзыйсына да күрсәтеп эшләмәде. Бу — аның өчен серле бер дөнья, бу — аның күңел авазы, йөрәк тойгылары, аны әле үзеннән башка бер генә кеше дә ишетергә тиеш түгел. Юк әле, иртә әле аның гармун уйнаганын тыңларга. Ярамый, бу — мөмкин нәрсә түгел әле...

— Кичләрен гармунны клубка алып чыгарсың, ямме,— дип Кыям абзыйсы Тимерханга кызлар алдында әйтә торган булды.

Тимерхан андый көннәрдә кич җиткәнен көч-хәл белән көтеп ала, гармунны зур кара тартмасына салып иплэп кенә күтәреп килә дә Кыям абзыйсына тапшыра.

— Гармунчы Тимерхан килә, юл бирегез! — дип үртәшәләр иптәшләре.

Тимерханның андый үртәшүләргә дә исе китми, гармунны күтәреп килү дә, Кыям абзыйсының уйнаганын тыңлау да аңа әйтеп бетергесез рәхәтлек бирә, барлык арганнарын, моңарчы кичергән барлык кимсетелүләрен алып ташлый иде.

Кичләрен, атнасына ике тапкыр булса кирәк, Кыям абзыйлары тальянны сайрата, бию көйләрен ул бик күп белә, яшьләр ул уйнаганга рәхәтләнеп бииләр, моңлы көйләр уйнаганда әйлән-бәйләнгә җыелып, түгәрәк ясап җырлап йөриләр иде.

Сугышка кадәрле авыл урамнары күңел ачу кичәләреннән шаулап торды. Җидееллык мәктәпкә дә,— үрнәкчедән күрмәкче,— тальян гармун алдылар. Тимерхан сабак баласы булган елларны анда ике кеше директор булды — Хәйруллин абый белән Галимәрдәнов абый. Алар икесе дә гармун уйныйлар, тик нигәдер Галимәрдәнов абыйның уйнаганы ныграк истә калган, чөнки ул моңарчы Тимерхан ишетеп тә карамаган ниндидер «сирбиянка»ны сиптерә, ә аның хатыны — маржа Наталья апа шул көйгә

жир җимертеп бии, ул бию татар кызларының күлмәк итәген чеметеп тотып, оеп кына биеп йөрүләренә охшамаган була, моң-сагышларны алып ташлап, ниндидер җиңеллек, тәвәккәллек дөньясына алып китә, авыл яшьләре марҗа Наталья апаның күбәләкләр кебек лепердәвен, идәндә ефәк оеклы төз аяклары белән нәкыш чигеп йөзүен авызларын ачып, дөньяларын онытып карап торалар; ул да булмый, Галимәрдәнов абый, үз алдына, тиктомалдан кычкырып җибәрә дә «цыганочка»ны сиптерә башлый, түгәрәк уртасына Мосифуллин дигән укытучы абый чыга — ул институт тәмамлаган, армия хезмәтендә булган, ул кайчан карама гармун күрүгә төсле итеп сыдырып төшергән хром итектән, галифе чалбардан булыр, аның ул хром итекле аяклары әллә тия идәнгә, әллә тими, әмма, гармун аккордларына кушылып, алар шундый бер тыпырдау-тукылдау китереп чыгаралар, яшьләр баскан урыннарында тора алмыйча, үзләре дә сизмәстән, бию ритмында яши башлыйлар.

Шулай да... Кыям абзыйларына чыкмый. Хет үтер, әллә кемнәр дип макта Галимәрдәновның «сирбиянкаларын», «цыганочкаларын», Кыям абый Низамов кулына гармун алдымы — дөнья ойый, дөнья дөнья булудан туктый — һавада моң гына йөзә, йөрәкләрдә моң ташый, Низамов дигән илле яшьләрендәге баһадир абзый юкка чыга, моңга кушылып, эреп бетә...

Тимерхан моң эчендә эреп беткән гармунчыны үз гомерендә беренче тапкыр күрде, яшьлек хыяллары алсу томаннар, зәңгәр күкләр, чишмәнең көмеш сулары челтерәгәнне бөтен җаны белән тойган заманда күрде һәм... ул моң Тимерханны, гүяки, ярлары күренмәгән иксез-чиксез диңгез уртасына китереп ташлады...

Гармун белән кушылу хәзер Тимерханның ирешеп булмас хыялы иде.

## Бишенче бүлек

Еллар уза, кара бөдрә чәчләр агара, аннан коела башлый, адәм баласының картайганын, битләрен үрмәкүч җепселләредәй вак кына нурлы җыерчыклар телгәләп узганын синең белән озак еллар күрешмәгән кешеләр бик тиз күреп алалар, ә кеше дигәнең, адәм баласы дигәнең үзенең картайганын әле алтмышларга җиткәнче сизми. Сизә ул аны, тик сизәргә, танырга, икърар итәргә теләми.

Адәм баласының йөрәге һаман яшь, күңеле һаман да мөлдерәмә. Мондый җилкенчәк уйлар, Тимерхан Борһановны олыгаймыш көнендә радиога, телевидениегә чакырып, тальян гармунда, саратский яшел гармунда яшь чагындагы көйләрне сайраттыргач, аннан да бигрәк яшьлек дусты Сәйделгыйлемнең хатын укыгач, яңарып киттеләр.

«... Син оста гармунчы, жир җимертеп биюче, һәммә кешене авызыңа каратып тота ала торган оратор, иң әйбәт каллиграфия белән яза белүче. Син андый язуың белән, ихтимал, патша заманында да югалып калмас идең. Тирә-юньдә дан алырлык писер чыгар иде синнән...»

Тимерхан абзый, алтмыш биш яшьлек өлкән кеше, кеткелдәп кенә көлеп куя. Аннары Вәрәшбашның урамнары, су буйлары, мәктәпне, клубны шаулаткан уеннары, җыр-биюләре, «Галиябану», «Аккалфак» спектакльләре күңеленнән узып китә.

Авылда яшьләр-кызлар бик күп иде. Алар көндезләрен эштә булалар, кичләрен клубка килеп тулалар. Кышларын — бигрәк тә! Драма түгәрәкләре гөр килә, яшьләр ялындырып тормый, театр уйныйлар, концертларда катнашалар, Галимәрдәнов белән Хәйруллин абыйларга ярдәмгә яшь гармунчы Тимерхан килеп кушыла, ул иренми, спектакльләрне музыка белән бизи, кирәк чакта сәхнә артыннан яки идән астыннан суфлер булып әйтеп тора, пьесалардагы рольләрне бик матур

язуы белән көчереп бирә, концертларда үзе гармун уйный, үзе биеп тә җибәрә торган иде.

«Ярар Борһан» дигән юаш кына бер кешенең, аның өченче хатыны булган явыз Бибисараның шул чагында эчендәге мәкере тышка бәреп чыкты:

— Сиңа әйтәм, мүкләк сыер булып, телеңне тешләп ник йөрисең син, Борһанетдин? Улың кәнсәләрдә дәү түрә, баш хисапчы, намусы булса, әтисен төнге каравылчы итеп тотмасые, дәрәҗәлерәк бер эшкә куярые, дәү улың Баһаветдин әнәтерәк нинди гайрәтле нәсел айгырлары үрчетеп тирә-юньдә дан алды, минем ике кызыма, багалмаларыма булышса, матур күлмәкләр алып бирсә, яңа капка ясаса, кулы корымасые. Ник дәшмисең? Ник дип әле син авызыңа су кабып утырасың, балан бәлеше кебек изелеп?

«Әй син аларга бер генә мәртәбә булса да, якты йөз күрсәттеңме? Улларың итеп, хет үги бала булсалар да, тәмле ризык пешереп ашаттыңмы? Тимерхан балам, синең явызлыгыңа чыдый алмыйча, Баһаветдиннарга күчеп китте. Ә бит Баһаветдинның үзенең дә өй тулы бала-чагасы, өстәвенә хатыны тазалыкка туймый...» — дип әрнүле сүзләрен тезеп чыгарга теләгән Борһан абзый, әмма нинди ямьсез сүзләр, нинди чәрелдәүләр ишетәсен белгәнгә күрә, телен тешләп, авызына су капкан көе, төнге каравылына китеп бара.

Үги ананың зәһәрле сүзләрен Тимерхан белән Баһаветдинга да ирештерен торалар.

Ул хакта Тимерхан Баһау абыйсы белән киңәшеп тә караган иде, тегесе авызын ачты да күзен йомды:

— Син, энем, теләсәң нишлә, ул убырлы карчыкка хет чәчең белән идән себер, ә минем аңа күтәрелеп тә карыйсым килми. Иң яхшысы — кадереңне җибәрмәү! — дип кырт кисте.

Моңлы кичләрдә, күңеле гармун моңнарыннан канатланган чакларында Тимерхан үги әнисенең кылган явызлыкларын онытырга, аңа якты күз белән карарга дип тә күңеленә беркетеп карады, тик ул аның үзе амбардан биреп җибәргән күмәче һәм мае белән тиз генә чәй эчәргә кайтканнан соң, хакын даулый башлагач, бала башы кадәрле йодрыгы белән авызына сугып җибәргәнен, ике җубалгы кызы белән өстәл янында җәелеп чәй эчеп калганын исенә төшергәч, тәннәре чымырдап китә иде.

Әтисенә тиешле ашлыкны, саламны, утынны ул вакытында аларга кайтарттырды, бакчаларын колхоз аты белән сукалаттырды, әмма үзе ул йортка аяк басмады. Кирәк булса, ул үзе әтисе белән аның төнге каравылында торган җиренә барып сөйләшә ала иде.

Тимерхан, яшь кенә булса да, «Динамо» колхозының бер җитәкчесе, аның колхоздагы алты бригада белән эш йөртәсе бар, абыйсы Баһаветдин карап үстергән нәселле йөк атларын бригадаларга гадел итеп бүлеп бирүдә дә катнашырга тиеш ул, язын, кыр эшләренә чыгар алдыннан, урта урамга тезеләчәк чәчкечләрне, сабан-тырмаларны, арбаларны, кыр эшенә җигеләчәк атларны барлауда да аның күзе үткен булырга тиеш, көндәлек шул мәшәкатьләр, шулар өстенә аның җилкәсендәге төп эше — керем-чыгымнарны үз вакытында кәгазь битләренә, таблицаларга теркәү, колхозның «Авыл утлары» исемле стенгазите өчен материаллар биреп бару да аның өстендә.

Эш күп, эш муеннан. Район мәгълүматлар таләп итә. Язгы чәчүгә әзерлекнең барышы, симәнә орлыгын күпме салганнар, ничә баш терлек исән, сыерлар күпме сөт бирә — барысы аның кулыннан уза, гадәти хисапчылар кулыннан узар иде, аның төсле матур итеп, Сәйделгыйлем әйтмешли, каллиграфияле итеп яза белүче юк.

Болары — көндезге эшләр.

Кичен Тимерхан — музыка дөньясында. Баш хисапчысы тальян гармунны җиренә җиткереп уйнарга өйрәнгәннән бирле Кыям абзый Низамов ул эшне Тимерханга тапшырды. Үзе берәр туй булганда, язгы чәчүгә

әзерлекне барлаганда, сабантуе көннәрендә генә гармун белән күңел ачып ала.

Башка көннәрдә — 21 телле тальян гармун Тимерхан кулында. Авылның иң беренче егете — күз өстендәге кашы булган Әхмәдиша кичләрен Тимерханны өйләреннән кереп алып чыга да клубка алып китә. Анда әле спектакль куючылар җыелып бетмәгән. Укытучы апаларның дәфтәр тикшерәсе, савымчы кызларның сөтлебикәләрен савып, сөтен сепаратта аертасылары бар. Минзәләгә нәселле йөк аты белән задание икмәге илтеп кайткан Әхмәдиша буш. Бер тонна ашлыкны ул төп-төгәл илтеп кайтып, квитанциясен Тимерханга тапшырды. Ул эш киемнәрен инде салып аткан, өстенә кара постау пәлтә, башына кара сарык мехыннан теккән зәңгәр бәрхет түбәле кубанка, кулына язгы сарык йоныннан кызлар бәйләп биргән юка ак перчатка киеп алган, ә аягында... аягында юка киез итек, авыл телендә йөргәнчә әйтсәк, чүчинкә. Балтыры ике-өч мәртәбә бөкләп, аска кайтарылып куйган булыр ул чүчинкәнең, өстеннән елкылдап торган өр-яңа калош киертелгән булыр, чалбар балагы, хохолларныкы төсле, өске яктан бераз әйләнеп төшәр. Сугыш алдыннан да, сугыш чорында да буй җиткән егетләрнең иң затлы киеме шул иде. Ә муенда — бер кат ураганнан соң җилкәгә кайтарылып салынган ап-ак озын шарф була иде.

«Агач күрке — яфрак, адәм күрке — чүпрәк!» — дип юкка гына әйтмәгән борынгылар. Авыл кызларының күзе Әхмәдишага төшү белән балкып, нурланып китә. Кемнәрнең яры булыр икән бу асыл сөяк?!

Егет горур, егет сер бирми торганнардан! Табигать чибәрлекне дә, тавышны да кызганмаган: алсу түгәрәк йөз, иркенәеп үскән шомырт кара кашлар, каш астыннан өздереп, томыраеп карый торган сөрмәле якты күзләр. Яшькелтме алар, коңгыртмы, берәү дә ул хакта уйламый, шул күзләр сиңа томыраеп бер карадымы — әллә кай тамырларыңа кадәр барып җитә инде.

Томыраерга, кемнедер бәхетле итәргә ашыкмый Әхмәдиша. Бер аякны алгарак куеп, күкрәкне киерә төшеп, Тимерхан каршысына килеп баса. Әллә кайдан, йөрәк түрләреннән назланып чыккан ягымлы, моңлы күкрәк тавышы белән дәшә:

— Йә, яшьти, сыздырып җибәр, булмаса...

Тимерхан яшьтие башны көмеш телле гармун өстенә сала, Кыям абыйсы кебек, гүяки, аның моңын җаны аша уздырып, «Галиябану» көен уйный башлый. Бу минутларда ул клубка кемнең кергәнен дә, кемнең чыкканын да оныта, үзен дә, гармунын да оныта, аның өчен моң бар, үзенең җиңел канатларында отыры биеккә, күккә, еракка алып киткән җыр бар.

Тимерханның күз алдында ачык тәрәзәнең ак пәрдәләрен лепердәтеп җиләс җил йөри, шул тәрәзәгә киләчәк гүзәл ярны чакырып, урамнарны, су буйларын иңләп җыр агыла:

Урам аша чыккан чакта
Бүрәнәгә абындым...
Минуты ай, сәгате ел,
Галиябану-сылуым иркәм,
Шул кадәрле сагындым...

Әхмәдиша сугыш чыкканга кадәрле Хәлил булып уйнады. Ничәмәничә мәртәбә уйнагандыр ул аны, аның Исмәгыйль кулыннан һәлак булган вакытында Вәрәшбаш халкы күз яшьләрен түгә, иртәгәсен Минзәләгә нәселле йөк аты белән тимерле арбага, йә зур чанага бер тонна задание ашлыгын илтергә чыккан тере Хәлил, үлмәгән Хәлил-Әхмәдиша белән очраша, аңа шаян сүзләр әйтә, тәмәке төреп тарта, икенче мәртәбә Исмәгыйль пулясыннан җан биргән Хәлил-Әхмәдиша өчен тагын җан ачысы белән елый...

Әхмәдишадагы төсле моңлы, жанны эретеп жибәрә торган ягымлы күкрәк тавышын консерваторияләрдә гомер буена укып та алып булмый, андый тавышны табигать бик сирәк кешеләргә генә бирә.

Тимерханның беркемнән дә, беркайчан да көнләшкәне булмады, дисәк, ялгыш булыр. Ул үз гомерендә ике кешедән көнләште. Берсе — баһадир гәүдәле, нечкә күңелле колхоз башлыгы Кыям абыйсыннан, аның да каты куллы председатель булуыннан түгел, көмеш телле гармун белән бер жан, бер тән булып кушыла белүеннән. Үз гомерендә залны күкрәткән виртуоз гармунчыларны, баянчыларны, аккордеончыларны күргәне булды аның, әмма Кыям абзыйсы Низамов кебек тылсым иясе гармунчыны очратканы да, тыңлаганы да булмады. Икенчесе, әлбәттә, Әхмәдиша. Андый жырчы була ала микән? Андый үзәк өзгеч жырчыны табигать тагын тудырыр микән? Әхмәдишаның моңнарында күкрәк тавышы гына да, түгел, Тимерханның үзе төсле үк, ятимлектә үсүе, әнисенең аны ташлап, үзбәкме-казакъмы якларына китеп баруы да сәбәпче булгандыр, бәлки... Тавыш бугазда ярала, моң йөрәктә туа, дип кайсыдыр язучы әйткән. Дөрестер ул, тавыш чыннан да йөрәктә ярала торгандыр... Шулай булмаганда, шулхәтле дә ягымлы, шулхәтле дә жанны-бәгырьләрне телгәли ала торган моң Әхмәдишага каян килсен ди?

## Алтынчы бүлек

Сугыш башлану көне Тимерхан абзыйның хәтеренә велосипед рәвешендә кереп калган. Ниндидер бер велосипедлы кеше 1941 елның 22 июне көнендә Вәрәшбаш инеше буенда, халык сабантуе үткәреп яткан чакта, дөбердәп килеп туктады да:

— Персидәтелегез кайда? — дип сорады.

Тимерхан белән тагын бер малай велосипедлы кешегә Кыям абзыйны табып китерделәр.

Велосипедлы кеше, Кыям абзыйны читкәрәк алып китеп, аның колагына нидер әйтте.

Тимерхан күреп торды: Кыям абзыйсының бите бурлаттай кызарды, сул күзе янында бер тамыры дерт-дерт итеп тора башлады.

Велосипедлы шундук китеп күздән югалды.

Колхоз председателе сабантуендагы халыкны жыеп:

— Иптәшләр! Яман хәбәр килде: германнар безгә каршы сугыш башлаган! — диде.

Халык башта, үз колагына ышанмагандай, өнсез калды. Аннары шаулау, йөгерү, елау-сыктау белән дөнья тулды. Болын тугайлары, йортлар, әрәмәлекләр менә шунда халык иңрәвен ишетте.

Сугышның беренче билгеләре дә Вәрәшбашка килеп житте: икенче көнне үк «полуторка»ны, нәселле йөк атларын районга алып киттеләр. Көн саен авылның жиде-сигез кешесен фронтка чакырган кәгазьләр килеп тора башлады: елый-елый күзләр кызарды, урамнарда арбага утырган яшьләрнең гармунга кушылып жырлаган тавышлары өзелеп тормады:

Атландым атның биленә,
Киттем Герман иленә.
Герман иле кара үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм...

Ярты ел уздымы-юкмы, авылның кыр эшләрен башкара торган таза беләкле ир-атлары фронтка китеп беттеләр.

Авылда бала-чага, карт-коры, хатын-кыз өелеп калды. Инде менә барлык авыр эш, өлкәннәр эшли торган эшләр һәммәсе дә үсмерләр жилкәсендә.

Сугыш башланганда Тимерханга уналты тулып кына килә иде әле. Бер елдан аңа унҗиде тулды.

Бер елдан... Әйтүе генә ансат аны «бер елдан...» дип. Сугыш вакытындагы бер ел, ихтимал, ун елга торгандыр ул. Кыям абыйсы инде иллене узып барган кеше булганга, аны фронтка алмадылар, әмма ул Вәрәшбашта аз була, йә аны яшьләрне озата барырга, йә сугыш барган яклардан качып кайткан хатын-кызларны, картларны каршыларга Бөгелмә станцасына җибәрәләр, ул да түгел, каядыр Идел аръягына окоп казырга җыйган хатын-кызларга башлык булып китеп бара ул. Колхозның нәрәт бирүләре дә, исәп-хисаплары да, амбарларга, симәнә ашлыгына күз-колак булулар да — барысы, барысы Тимерхан өстендә. Җитмәсә әле Мөслимнең прокуратурасы составында ул штаттан тыш тикшерүче дә булып катнаша. Авылда үсмерләр белән эшләүне дә район җитәкчеләре аңа тапшырды.

Җаваплылык шундый да зур — Тимерханның ник соң әле мин фронтта түгел, дигән чаклары да була иде. Дөрес, аның әле фронтка китәрдәй яше тулмаган, әмма авылдан шахталарга, хәрби заводларга үсмерләрне гел дә чүпләп торалар.

Еллар авыр, законнар аяусыз. ФЗӨдан, яки башка берәр төрле мәҗбүри җибәрелгән урыннан качып кайтсалар хөкем карары алдан ала кәгазьгә язып куелган — биш ел төрмә! Суд-мазар да ясап тормыйлар, әлеге карар басылган бланкка исем-фамилияңне теркиләр дә таш капчыкка илтәләр дә тыгалар. Бәладан башаяк! Ходай күрсәтмәсен андый хурлыкны!

Эш тә бик күп, җаваплылык та зур, әмма фәкыйрьлектә интегеп үскән еллар түгел инде бу. Кара костюм, кара пальто алды Тимерхан, гармун күреге кебек сыдырып кия торган хром итекле дә булды. Кара костюм белән ак күлмәкне тагын да матуррак итеп күрсәтер өчен галстук та тагып җибәрде. Шунсыз ярамый. Аны әледән-әле районга чакыртып алалар, башлыклары сугышка киткән колхозларга еллык исәп-хисап докладларын ясашырга булышуын үтенәләр. Мөслимнән яки Казаннан килгән белгечләр, вәкилләр турыдан-туры Борһановка мөрәҗәгать итәләр.

Мең төрле мәшәкать белән ду килеп йөри торгач, 1943 ел да килеп җитте.

Сигезенче гыйнуар көнне иртән иртүк Мөслимгә барырга чыкты Тимерхан Борһанов. Әйләнә-тирәдәге авылларга билгеле, яшьләрнең күзен яндыра торган кара айгыр, иң яхшы кашавай чана, җиз таңкәләр тезгән каеш дирбиялар! Җилләр уйнатып Мөслимгә килде, районның җир бүлегендә булып, барлык йомышларын йомышлап, киредән кайтырга чыккан иде, күңеле күтәренке, әкрен генә кар явып тора, күбәләк кар, ямьле көнен тагын да ямьлерәк итәм дип парикмахерга кереп, чәчне тигезләтте, дөнья бетереп исле май сиптеләр, инде менә шул хушбуй исләренә исереп, авыз эченнән генә «Шахта» көен җырлап кайта. Атны кумый, беркая да ашыкмый.

Вәрәшбашка җитәрәк, каядыр бик күп кешенең бергәләп җырлаганы сыман бер гүләү ишетелә башлады. Бераздан ул «Алмагачлары» көенә әйләнде, үрәчәле биш чанага төялгән егетләр килеп чыкты.

Айгыр турысына җитеп туктадылар.

Егетләр чаналардан җиргә сикерде. Тимерхан шунда гына аларны озата баручы кызлар да утырганын күрде. Шуннан соң Тимерхан да чанасыннан төште.

— Кая киттегез, малайлар?

Тимерхан белән бергә колхоз кәнсәләрендә хисапчы булып эшләүче Гайшә апасы Тимерхан чанасына килеп утырды да дилбегәне кулына алды, аны никтер чорнап тотты:

— Болар сугышка китәләр, энем. Сиңа да повестка бар. Егетләр янына күчеп утырырга туры килә инде сиңа, апаем. Үги әниең Бибисара

сиңа бер ипи капчыгы сохари җибәрде. Баһаветдин абзый хатыны Фәрхежиһан да ризыклар китерде. Әнә иптәшләрең бирерләр. Әтиең дә, Кыям абзыең да сиңа изге теләкләр теләп калдылар. Сау бул, Тимерхан. Барыгызга да исән-имин кайтырга язсын. Йа раббем, ашыйсы ризыкларыгыз, эчәсе суларыгыз бетмәсен...

— Әйдә, Тимерхан, үзең теләгән чананы сайлап утыр,— диештеләр егетләр.

Тимерхан бишенче бригада егетләре утырган чанага барып чүмәште. Аңа шундук гармунны тоттырдылар.

Мөслимгә юл Иске Вәрәш аша уза иде. Колхоз идарәсе янында туктап, белгән-күргәннәр белән саубуллаштылар. Аннары Тимерхан, гармунны бөтен күрегенә тартып, ярсынып уйнап җибәрде. Бу аның үзенчә туган яклары белән саубуллашуы иде.

Иске Вәрәштән атларны атлатып кына чыктылар. Егетләр аяк өсте басып, бер-берсен җилкәләреннән кочып, кычкырып-кычкырып җырлыйлар, ул заманнардагы «Шахта» көе яңгырый иде.

Капка төпләренә чыккан апалар, кулларын каш өсләренә куйган ак сакаллы картлар күзгә чалынып калды.

Әбиләр яулык почмагы белән күзләрен сөртәләр, кызлар:

— Исән-сау кайтыгыз,— дип кул болгыйлар, үрәчәле биш чана яныннан көтүләре белән малайлар чаба, этләр капка төпләрендә елыйелый өрәләр иде...

Мөслимдә сугышка китәсе егетләрне комиссия аркылы уздырдылар. Авыл Советы җибәргән мөһерле исемлектәге унҗиде кешедән унбише яраклы дип табылды.

Хәрби комиссар лейтенант Дороднов егетләр янына чыкмаган иде әле. Тимерхан янына авыл Советы рәисе Шиһап абзый килде:

— Сине, Тимерхан энем, районның кайбер колхозларында еллык отчетлар төзешү өчен дип өч айга бронь белән калдырырга булдык,— диде.

Ул арада яшь-яшь бер лейтенант ачы тавыш белән:

— Выходи строиться!— дип кычкырып җибәрде.

Вәрәшбаш егетләре, аларга кадәрле килеп каралган тагын кайсыдыр авыл егетләре бер генә мәлгә умарта күчедәй тузгынып алдылар да бер рәткә тезелделәр.

Яшь лейтенант хәрби комиссарга рапорт бирде.

Хәрби комиссар урысчалатып:

— Борһанов кайсыгыз, алга чыксын!— диде.

Тимерхан ике адым алга чыкты.

— Син каласың,— диде комиссар.

— Юк, мин калмыйм. Мин иптәшләрдән калмыйм,— диде Тимерхан.— Мин фронтка китәм.

— Ярый, алайса, сафка бас,— диде комиссар.

Башка командалар килеп җиткәнче Тимерханнарны хәрби комиссариат белән янәшә район клубына кертеп тутырдылар. Клуб, гадәттәгечә, суык, ишек төбендә солдат киеменнән мылтыклы бер кеше басып тора иде. Командада булмаган кешеләрне ул клубка кертми, кергәннәрнең берсен дә клубтан чыгармый — сакчының чырай бик житди. Азактан, хезмәт итә башлагач, егетләр әлләни гомер көлеп сөйләделәр, бик кырыс чырайлы сакчының мылтыгында хәтта затворы да булмаган икән...

Кичен буран чыкты. Бу юлы күбәләк кар түгел, юеш ябалак кар ява, җиле дә көчәя төште, кайбер авыллардан кешеләр килеп җитә алмады. Ягылмаган суык клубта яшьләрне төн кундырырга командирлар уңайсызландылар бугай, шул сәбәпле Вәрәшбаш егетләрен, иртәнге алтыга килеп житү шарты белән авылларына кайтарып җибәрделәр.

Тимерхан инде, сохари капчыкларын күтәргән килеш, үги әнисе Бибисараларга барырга да, Баһаветдин абыйларына кайтып керергә дә кыенсынды, үзенең бик якын абый кешесе Абдуллин Миңнәхмәтләргә

китте. Ул аларның тормышлары авыр түгел икәнен белә, чөнки Миңнәхмәт абыйсы МТСның трактор бригадасында бригадир булып эшли иде. Өйдә икән абыйсы, хатыны Мөгаллимә түтәй дә өйдә булып чыкты.

Көрештеләр.

Тимерханның менә шунда беренче мәртәбә күңеле тулды.

— Менә, китәбез дә инде, абый! — дип әйтте дә елап та җибәрде.

Миңнәхмәт абыйсы да, Мөгаллимә түтәй дә мышык-мышык борын тарта башладылар.

Тимерханның ул абыйсына керүе күңел сиземләве булдымы икән әллә? Соңгы күрешүләре булган икән, Миңнәхмәт абыйсы Тимерханнан соң озак та тормый фронтка китә һәм шунда үлеп кала...

Үз гомерендә өч тапкыр елаганы булды Тимерханның. Күз яшенә түелеп, әкрен генә түгел, кычкырып елаганы, кешеләр алдында яшь түккәне булды. Беренчесе — әнисе үлгәч, Тимерхан бик яшь иде; икенчесе — хисапчылар курсына кабул итү комиссиясендә («Үскәнем, курсларга без унсигез яшьтән алабыз, сиңа бит әле унбиш кенә яшь»). Өченчесе — менә туган-үскән авылы Вәрәшбаштан сугышка киткән чагында...

Кичен бөтен авыл яшьләре клубка җыелдылар. Тимерхан гармун уйнады, егет-кызларны җырлатты, биетте. Колхоз гармунында, кем белә, бәлкем, аның соңгы мәртәбә уйнавыдыр, шуңа күрә ул йокысыз калам дип тә, иртәгә таң башыннан юлга чыгасы бар дип тә тормады, уйнады да уйнады.

Тимерхан янына колхоз рәисе Кыям Низамов килде. Каты итеп, кул кысышып күреште, әйтте:

— Туктале, мәйтәм, ничек була әле бу? Тимерханның минем белән, әтисе белән, абый-җиңгәләре белән саубуллашмыйчан ут эченә кереп китәргә хакы бармы? Не смеет правы! — мәйтәм. Ул әбәзәтелни Вәрәшбашка кайтырга, чин-чинарем, безнең белән яхшылап күрешеп, сөйләшеп, гармун уйнап китәргә тиеш. И шулай булып чыкты да! Рәхмәт, энем, акылың җитеп кайткансың, туган-үскән җиреңне чит-ят итмәгәнсең. Сезне, бишенче бригат егетләрен иртәгә әтиең Борһан абзый илтә барыр, әгәренки, стал быт, кирәк дип тапсалар, Бөгелмәгә хәтле үк озатып куярга да рөхсәт бирәм. Миңа синнән аерылу, уң кулымны кисеп алган белән бер, Тимерхан. Синдәй яшь, булдыклы баш хисапчыны мин тагын каян табам? Хуҗа абзый картайды, сине осталыкка өйрәткән хисапчы, ни хәл итмәк кирәк, аны җигәрбез инде, аңа Гайшә апаң булышыр. Заманасы шундый, әнә бит югарыдан әйтәләр, «Родина требует!» — диләр. Авыр сулап беркавым тын торды, аннары әйтте: — Төрле чак булгандыр, авыр сүз дә ишетергә туры килгәндер, миңа рәнҗеп китмә, беребез дә фәрештә түгел. һаман-һаман изгелек кенә эшләп йөреп булмый...

Икенче көнне иртәнге биштә үк хәрби комиссариатта иде инде алар. Бу юлы, чыннан да, бишенче бригада малайларын Тимерханның әтисе илтә барды. Мөслимгә дә, Бөгелмәгә дә. Дүрт егет иде алар: Яппаров Әсгать, Хафаев Хәмәй, Сәрвәров Саях, Борһанов Тимерхан.

Әтисе Борһан абзый гомуми команда эчендә Бөгелмәгә китереп җиткергәч, ияген сыпырып, аннары иренен кысып бераз егетләргә карап торды да әйтте:

— Балакайларым, барыгыз да исән-имин йөреп кайтыгыз. Дәхи дә мин ышанам, сез барыгыз да исән-сау булырсыз. Миң сезне кара айгырны җигеп каршы алырмын әле. Исән кайтырсыз, ийе, исән, ник дигәндә, сез минем чанама утырып килдегез. Минем кул-аягым җиңел...

Күңелләрне дәрләтә, өметләрне уята торган сүз әйтте Тимерханның әтисе. Ни генә димә, авыл үзенең сафлыгы, өметләре белән матур. Шул сафлык югалмаса, өмет канатлары сынмаса, авыл яшәр. Мәңге исән булыр.

Бөгелмәгә аларның командасын өлкән политрук Кузьмичев озата килде. Мөслимнең Михайловка авылыннан икән. Сугышта булган, ахрысы. Бик яшь тә, бик чибәр дә йөзле, зәп-зәңгәр күзле бу урыс егете

аксабрак атлый, таякка таянып йөри әле. Өр-яңа хәрби киеменә таяк бигүк килешеп бетми, таякны авылда картлар йөртә торган була. Ләкин ул егетләргә карата командир булып, әтәч пәхри булып кыланмый, үзен тыйнак һәм әдәпле тота иде.

Авыл егетләренең гадәттә бер нәрсә яки бер кеше тирәсендә озак тукталып торырга вакытлары юк. Алар, мәсәлән, Кузьмичевның Михайловка кешесе, димәк, якташлары икәнен зиһеннәренә салып куйдылар, өр-яңа хәрби киеме аларның күңелләренә хуш килде, таякка таянып йөргән картларга охшаттылар да калганын оныттылар.

Тимерхан унбиш яшенә җиткәч, беренче мәртәбә Минзәләне күргән иде, инде менә аның каршысында кар күмгән йортлары, биек ташпулатлары белән борынгы купец каласы Бөгелмә җәелеп ята.

Команданы Сталин исемендәге ике катлы таш клубка кертеп тутырдылар. Вакыт кич, караңгы иде. Мөслим егетләренә икенче катка менәргә әмер булды. Ут юк, бернәрсә күренми. Капшана-капшана, баскыч култыксаларына тотына-тотына гына атлыйлар иде, менә бервакыт таш баскычка шыбыр-шыбыр нәрсәдер коела башлады. Китте тавыш, китте кычкырыш!

— Егетләр, пәке белән капчыкны кисәләр.

— Егетләр, сохари коела!

— Бөгелмә ышпаналары сохарины талый!

Баксаң-күрсәң, Тимерханнар ише үсмерләр бихисап булып көн саен бирегә киләләр, шушы яшькә җитеп тә авылдан башка җирне күрмәгән егетләрнең соңгы азыгын талап алып китәләр икән.

Бер көн узды, кич җитте. Клубта электр да, керосин лампалары да юк. Дөм караңгы. Көндезен бер-ике малай, кулларын кесәләренә тыгып, «разведка» ясап киткәннәр иде, кичен очлы тимерләр белән коралланган Бөгелмә шпаналары тагын килеп җитте.

Көндез бер-ике Мөслим егете:

— Ичмаса, тизрәк фронтка җибәрсеннәр иде инде, югыйсә бу ышпаналардан котылыр хәл юк, йә эчне тишәрләр, йә күзне чыгарырлар,— дип зарланып та алганнар иде.

Шулчакны Хәернас исемле егет Тимерханнар янына килеп басты. Чүкечтәй нык, күкрәкләр калку моның. Ул пар ат белән Минзәләдән Курьяга йөри икән. Хәернасны белүчеләр сөйләп тордылар: егет шулхәтле дә кыю-усал, юл бирергә тиешле берәрсе кыбырдап маташа башласа, ул атларга чыбыркы белән берне генә тамыза, ул чагында кыбырдык адәмнең арбасыннан чәкүшкәсе очкан яки тәртәсе сынган дип сана инде!

Менә шул Хәернас бүген, Тимерханнар төркеме янына килде дә, киерелеп басты:

— Мин бу гарьлеккә түзә алмыйм, егетләр. Мин бүген Бөгелмә каракларының берсенең башына җитәм.

Мөслим егетләре куркуга калды, Хәернасны әгъвали, зинһар, ямьсезлек эшли күрмә, барыбызны да берьюлы өтерменгә ябып куярлар,— дип үгетли башладылар.

Кич булды. Тагын караңгы. Тагын Бөгелмә малайлары караңгыда шыбырдаша башладылар. Болар авыл малайларын үрти, урысчалатып: «Айда, малай, чапчара!» — ди, тагын ниндидер татарча ямьсез сүзләр кыстырып җибәрәләр.

Шулвакыт Хәернас шыпырт кына:

— Егетләр, мин тәвәккәлләдем! — диде.

Шулвакыт аның калын тавышы урысча яңгырады:

— Долой бугульминской шпаны!

Һәм шул минутта ук аргы почмактан: «Убили! Убили!» — дип ачыргаланып кычкыра башладылар. Стихиядән дә хәтәр нәрсә юк икән ул дөньяда, бөтен команда берьюлы: «Убили!» — дип акырып җибәрмәсенме?!

Бераздан тавышлар тынды. Шылт иткән дә тавыш юк.

Тимерханнарга Хәернас шыпырт кына әйтеп тора:

— Курыкмагыз. Берәү дә үлмәде. Бер ышпананың бот итенә мин чалгы пәкемнең очын гына тидереп алдым.

Мөслим «малайлары» Сталин исемендәге клубта тагын сигез көн тордылар, әмма инде аларны бүтән килеп борчып йөрүче дә, сохарыйларын талап алучы да булмады. Исән калган сохарыйларны алар солдатларча тигез итеп бүлештеләр.

Көн артыннан көн үтә. Булачак сугышчыларның тизрәк бу ямьсез, шыксыз, утсыз клубтан чыгып ычкынасылары килә. Төрле сүзләр йөри. Имеш, станцага буш товарняк китереп куйганнар. Шул товарняк белән фронтка озатачаклар.

Ниһаять, 21 гыйнуар көнне команданы сафка тезеп, станцага таба алып киттеләр. Анда килгәч, алтмышар кеше итеп төркемнәргә бүлделәр дә вагоннарга кертеп утырттылар. Егетләр сәке рәвешенә китереп җәелгән калын идән сайгакларына менеп утырдылар. «Паровозны кайсы яктан китереп тагарлар икән? Хикмәт бит менә шунда!» — ди Хәернас.

Төнге сәгать уннар иде. Паровозны составның көнчыгыш башына китереп тактылар. Паровоз вагоннарга нык кына бер суктырып, җанланып сөйләшә башлаган егетләрне бер аударып алды да, сузып кына, мөгрәп кенә бер кычкырткач, команданы ерак юлга, көнчыгыш юнәлешенә таба алып китте.

Өлкән политрук Кузьмичев, Мөслимдә чакта хәрби комиссарга рапорт ясаган яшь лейтенант — икәүләп — команданы озата баралар икән. Булачак сугышчыларга әйттеләр:

— Составның шартлы исеме — «10-10», шуннан башка бернәрсәне дә сез белергә тиеш түгелсез.

Вагоннар, ритмлы тукылдап, чуен юлдан чаба башлагач, яшь лейтенант күңелле итеп:

— Ну, салаги, поехали! — дип кычкырып җибәрде.

Урысчаны ул Кузьмичев төсле өздереп сөйләшми, ничектер көйле итеп, җырлагандай сөйләшә, өлкән политруктан егетләр аның украин икәнен белеп алдылар. Еллар күп узган, украинча моңлы вә көйле сөйләшә белгән лейтенантның исеме хәтердә калмаган, ә менә Кузьмичевны әле байтак еллардан соң да очратырга туры килде Тимерханга.

Ул елларга ерак иде әле. Юллар озын, юллар бормалы иде. Вагоннарда бик озак селкенеп барырга туры килде аларга. Тукталыш ясаган станцаларда көнбатышка солдатларны илтүче эшелоннар очрый. Мөслим малайлары бу хәлгә аптырашып:

— Боларны көнчыгыштан көнбатышка кадәрле тарттырганчы, безне генә Бөгелмәдән фронтка озатсалар, ни була иде инде? — диләр.

Лейтенант сүзгә кесәгә кереп тормый:

— Вы еще зеленые капусты! — дип кенә җибәрә.

Бара торгач, ритмлы тукылдауларны тәүлекләр буена ишетә торгач, егетләр бер-берсе белән танышып беттеләр. Мөслимнең Метрәй, Тойгелде, Мәлләтамак, Ольгино, Баек, Баланлы, Дусай, Салауз-Мухан авылларыннан, Шөгер, Ютазы, Югары Ослан, Әлмәт якларыннан егетләр бар булып чыкты. Һәркем үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен, һөнәрен күрсәтеп калырга тели, берәүләр әкият сөйли, берәүләр кәрт суга, кайберләре бик тә матур итеп җырлап җибәрә, ә ул җырлар туган яклардан ерагая барган саен отыры җанга ятышлырак, кадерлерәк була баралар иде.

Әкәмәт — Дусай белән Баекта икән җырчылар. Гәрәев Салих авыл көйләрен, «Шахта»ны әкрен генә, иреннәрен ачар-ачмас кына җырлый, кайвакыт вагон ишеге ачык чагында, станцаларны күздән кичерә, берәү белән дә ул хакта сөйләшми, мөгаен, аның авылда өзелеп яраткан кызы калгандыр...

Ә карап барырлык, тамаша кылырлык ничаклы шәһәрләрне, станцаларны уздылар инде алар. Уфа, Чиләбе, Курган, Петропавел, Омск, Новосибирск, Улан-Удэ, Иркутск, Чита...

Азык пунктларында туктап, кайнар аш ашадылар, шәһәр мунчаларында юындылар, Байкал күленә сокландылар, таш кыяларны тишеп ясаган туннельләр аша чыктылар.

Сугышка кадәрле елларда Мөслимнән дә, Минзәләдән дә Чита каласына чүен юлда эшләргә язылып китәләр иде кешеләр. Ул калаһы да күрергә насыйп булды Тимерханга. Аны узгач, егетләрне алып барган состав көньяк-көнчыгыш юнәлешендәге бер юлга кереп китте. Шулай итеп, Бөгелмәдән кузгалуга егерме тугыз тәүлек тулганда, Мөслим егетләре 1943 елның 18 февралендә Маньчжуриядән якында гына, җиде генә чакрым ераклыкта урнашкан Мациевская станцасына килеп туктадылар. Маньчжурия ул чакта японнар кулында иде әле.

Егетләрне бередәге бер күренеш бик сәерсендерде. Якын-тирәдә бернинди дә каралты юк, кешеләр дә күренми. Нигә дип алар буш далага килеп төштеләр соң әле? Станца янында өч-дүрт тупыл үсеп утыра. Мөслим-Бөгелмә якларында инде кар бураннары уйный, ә бередә карның әсәре дә юк; җир өсте, салкынга чыдый алмыйча, арба тәгәрмәче төшеп китәрлек булып яргаланган. Салкын җил исә. Андый җилне Тимерханның коры кар биткә бәргән чакта гына тойганы бар иде. Җил биткә бәрелә, тырный, битне умыра, әйтерсең, кемдер тимерчыбыктан үргән битлек-җәтмә белән синең битеңә өзлексез сугып тора.

Әллә каян гына ике хәрби кеше килеп чыкты, поездтан төшкән егетләрне сафка тезеп, ярылгалап беткән шәп-шәрә юлсыз даладан алып китте.

Егерме чакрымнан артык араны җәяүләп атладылар. Кешеләр дә, кош-корт та, тереклек ишарәсе дә сизелми. Дүрт-биш сәгатьләп баргannan соң, хәрби начальник:

— Туктарга! Килеп җиттек,— диде.

Йа хода, бу ни бу? Килеп җитүен җиттек тә бит, ә кайда казармалар? Кайда хәрби корылмалар? Бу нинди җир соң?

Ул да түгел, аннан-моннан, җир асты тишекләреннән килеп чыккан төсле, офицерлар, сержантлар пәйда була башлады. Алар җир астына казып ясалган землянкалардан — солдат казармаларыннан чыгалар икән ләбаса! Японнар чигенә бик якын булганлыктан, землянкаларны җир өстеннән генә түгел, һавадан да күренмәслек итеп ясаганнар. Идәне җир, түшәме җир, киртә өстенә тезеп чыккан кәсләрдән гыйбарәт, тәрәзәләре бәләкәй, җир өстенә чыгып тормый, беренче мәртәбә анда кергән кеше караңгыда кала, күзләрем нигә сукырайды дип аптырарга да мөмкин.

Бер меңнән артык яшь-яшь егетне егерме көн чамасы шундый җир казармаларда тотканнан соң роталарга, батареяларга бүлә башладылар. Татарстаннан килгән 180 егетне укчы полкның өченче ротасына билгеләделәр. Ул чагында ротада барлыгы 200 кеше була торган иде, димәк, әлеге рота урысча белми торган татарлардан гына тора булып чыкты.

Ротаның старшинасы Долбышев, бик усал чырайлы, ябык яңаклы, берәүгә дә туры карамый торган, аска карап кына команда бирә, өзлексез йөгертә һәм — шулай ук өзлексез! — бер нәрсәне кабатлый: «Белмисең — өйрәтербез, теләмисең — мәҗбүр итәрбез!»

Кем ничек өйрәнә торгандыр урысчага, Мөслим егетләренең телләре устав укып, хәрби терминнарны ятлап ачылды.

— На караул!

— На стрельбище!

— На полигон!

Көн дә саен гына түгел, көненә унар мәртәбә кабатланган ул сүзләрне солдат төнлә уянып сораса да әйтеп бирер. Әмма шулар янында әле «Час досуга», «отдых на привале», «прием пищи» дигән күңелгә ятышлы сүзләр дә бар. Аларын ятлап торасы юк, бер ишетү белән күңелгә кереп калалар.

Рота бердәм тормыш белән яши. Әйтергә теләгәнеңне аңлата алмау, дөрес, эшне кыенлаштыра кыенлаштыруын, ашханәгә барганда сафка

тезелеп, җырлап барырга кирәк. татар егетләреннән урысча җыр белүче юк. Бу кыен хәлдән чыгу өчен рота командиры әйтте:

— Кем татарча җыр белә, татарча җырлап барыгыз,—диде.

Тимерханнар, марш атлаганга туры китереп, «Алмагачлары»н җырлап җибәрделәр.

Су буенда бакалар
Баталар да калкалар,
Шушы көйне матур итеп
Әйтә Мәрьям апалар,
Шушы көйне матур итеп
Әйтәләр Бишбалталар.
И-их, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары!

Рөхсәт бирелүдән файдаланып, малайлар әрсезләнә үк башладылар. Оятрак сүзләр кушылган җырларны да такмаклыйлар, андый чакта җырны бөтен рота күтәреп ала, урыс егетләре гаҗәпләнеп тыңлыйлар:

Сандугачлар усакта,
Китмиләр бит кусак та,
Кочсаң акча түләтәләр,
Почет бетте... ботакка!

«Ботакка» сүзен, әлбәттә, еш кына аңа рифмадаш сүз белән әйтеп җибәрә егетләр, рота шуны күтәреп ала.

Шулай бервакыт ашханәдән «строевой» җыр җырлап кайтканны майор Вәлишин ишеткән. Рота командиры Московскийга ротаны туктатырга куша бу.

— Сез, өлкән лейтенант, ротагызның нинди җыр җырлаганын беләсезме?

— Юк, иптәш майор.

— Алар ямьсез җыр җырлыйлар. Туктатыгыз андый җырларны!

Соңыннан татар егетләреннән урыс көйләрен дә бик оста җырлый белүчеләр килеп чыкты. Тимерхан белән бер олауда юлга чыккан Вәрәшбаш егете Яппаров Әсгать урысча җырлау буенча урыс егетләренең үзләрен дә таң калдыра иде.

## Җиденче бүлек

Егетләр әкренләп хәрби техниканы үзләштерделәр. Уставта язганнарга төшенделәр. Урысчаны да белебрәк сукалыйлар хәзер. Кичен, йокларга ятар алдыннан рота старшинасына яки взвод командирының ярдәмчесенә рапорт бирергә кирәк.

Вәрәшбашның бик тә шаян егете Гәрәев Гарифҗан юрамалый урысча белән татарчаны бергә кушып бутый:

— Иптәш-тавариш старшина, красный әрмис Гәрәевның боевойлары һәм вещевойлары барысы да пурәдектә! — ди.

Старшина Долбышев башны кырын салып тыңлап тора.

— Я ничего не понял. Повтори снова,—ди.

— У красноармейца Гараева боевое и вещевое имущество все в порядке! — дигәч кенә ул тынычлана һәм Гарифҗан Гәрәевкә йокларга ятырга рөхсәт итә.

Вәрәшбашның Гарифҗан аның белән генә тынычланмый, иртәгесен тагын бер шаянлык уйлап чыгара. Кырдан кайтып винтовка чистартканда, ул мылтыгына дары гына тутырып ясаган «холостой» патрон куя, авылдашы Кашапов Хәмискә әйтә:

— Мылтыкның көпшәсенә кулыңны куеп кара әле, кайнармы? — ди. Хәмис, беркатлы егет, көпшә башына кулын куя, әлбәттә. Гарифҗан мылтыкның төбәлдерегенә китереп басмасынмы!

Хәмиснең уч төбе кара кан була, ә үзе: «Үлдем, беттем!» — дип кычкырып җибәрә.

— Җүләр син, Хәмис,— ди Гарифҗан.— Кем инде кеше әйтә дип мылтык көпшәсенә кулын куя? Техниканы сезгә шул рәвешле генә өйрәтеп була, юкса ул сезнең исегездә калмый,— ди.

Вәрәшбашның Гарифҗанга мондый «шаяруы» өчен ничә көндер гауптвахтада утырып чыгарга туры килсә дә, ул һаман шаянлыгын ташламады.

Бар иде заманнар, урысча белмәү гаеп санала иде. Хәзер татарча белмәү — гаеп. Ротада тоташ татар егетләре булганга, көннәр гел татарча сөйләшеп уза. Ә урысчаны белмәү — Тимерхан өчен үлем белән бер. Беркөнне ул, иптәше Әгъләмов Мияссәр белән сүз куешып, күпчелек составы урыслардан торган пулемет ротасына күчерелүләрен сорап батальон штабына барды.

Күчерделәр аларны.

Отделение командиры таулы-алтай егете Ядомыковның, акцент белән сөйләшсә дә, урысчаны су кебек эчүе таң калдырды Тимерханны. Даржезапов Бадмажап дигән бурят егетенә исе китте аның. Монысы бөтенләй акцентсыз сөйләшә, бик тә белемле, өстәвенә Тимерханнан биш яшькә олырак та иде.

Армия тормышы, солдат тормышы әкрен-әкрен егетләрне үз калыбына салды. Килгәндәге беренче көннәрнең сагышы юк инде аларда, кыюлана да төшteләр, өстәвенә ял көннәрендә башка частьларда хезмәт итә торган районадашлары яки авылдашлары янына барып килергә дә рөхсәт итәләр.

Тирә-юньдә халык яши торган пунктлар юк. Бер йөз чакрым узсаң да андый пункт таба алмассың. Чикнең икенче ягында, көнчыгышка таба биш-алты чакрымнар ары солдат казармалары бар.

Йөри торгач, сораша-белешә торгач, бернәрсә ачыкланды: Тимерхан Борһановлар хезмәт итә торган полкта атаклы шахматчы Рәшит Нәҗметдинов та бар икән. Полк комиссарының ярдәмчесе икән әле үзе. Якшәмбе көннәрендә ул бер үзе бер якта, егерме офицер икенче якта шахмат уйныйлар. Аның белән бер генә уйнаучы да ничьяга бетерә алмый иде үенын. Рәшит абый гәүдәгә озын, шинеле кыска булганга ул тагын да озынрак күренә. Ач яңаклы, күзләре бик тә нурлы, берәүгә дә ул усал итеп карый белми иде бугай. Татарчаны ул коеп куеп сөйләшә, шуның белән татар егетләрен үзенә карата белә иде. Бераздан аны кайсыдыр шәһәргә хәрби-политик укуга җибәрделәр. Тимерхан да, Вәрәшбашның башка егетләре дә аны үзләренең полкларында бүтән очратмадылар.

Тимерханнар хезмәт итә торган полк японнар белән чиктәш булганлыктан, аларны һәр елны май аеннан башлап җәйге лагерьларга чыгаралар, шулай булгач, табигый, октябрь башларына кадәр җир землянкалар онытылып тора.

Җәйге лагерьда эш бик авыр. Чик буенда озын-озын окоплар казыталар. Ә монда йомшак җир түгел, тау-таш. Ә андый ташлар кәйлә белән дә, кувалда белән дә бик зур көч куйганда гына ватыла. Ә шундый ташны — адәм әйтеп, адәм ышанмас — көненә өч кубометр чокырга кирәк. Бик көчле, нык бәләкле таза карт солдатлар арасында да ул норманы үти алучы табылмады.

Көннәр буе кувалда — зур авыр чүкеч — селтәп кайтканнан соң беләкләр сызлый, арка бөкрәя, иртән торган чакта әле ял итеп, көч туплап та өлгермәгән буласың, кыйнап ташланган, изрәгән гәүдәне кузгатып, командага басуларың — үлем белән бер! Зарланырга ярамый — сугыш («Ватан таләп итә!»). Югары Осланнан килгән Мирханов, окоп эченә чалкан

яткан килеш, авырлыкка түзә алмыйча, үксеп-үксеп җылый, күрәсең, аның сәламәтлеге Тимерханныкына караганда азрак, көч-куәте кимрәк булгандыр...

Яшь солдатларның күбесе сугышка җибәрүне таләп итә. Җавап бер генә: японнар безгә каршы сугыш әзерли, барлык кеше көнбатыш фронтка китеп бетсә, бу чикләрне кем саклар? Туган җирнең, Ватанның һәр карышы кадерле.

Шулай да көнбатышка дивизияләр агыла. Дөресрәге, ул хәл 1943 елны күп булды. 1944 тә инде сирәгәйде.

Сугышка җибәрүләрен ачынып-ачынып гозерләнүче яшь солдатларга офицерлар җавапны кыска тоталар: «Без вас обойдутся!» Татарчага әйләндереп карый ул сүзне Тимерхан, аныкы бик сәер килеп чыга: «Башны катырып йөрмәгез әле, анда сездән башка да ерып чыгарлар!»

1944 елның июль-август айларында Тимерханнар хезмәт итә торган хәрби берләшмәне тайгага печән чабарга җибәрделәр. Печән артиллерия атларына, йөк ташучы подразделение атларына әзерләнә. Биредә дә задание адәм ышанмаслык: сиңа сазлыгы-ние, түмгәге-мәзары белән бер гектарга якын җир бүлеп бирәләр. Син анда үлән әсәре калдырырга тиеш түгел. Чалгы тотып чаба белмәсәң, хет эскәкләп җый. Алай да бу кәйлә белән таш вату түгел инде. Саф һава, кошлар тавышы. Авылда Вәрәшбаш болыннарында йөргәнеңне хәтерләтә.

Ике ай эчендә хәрби берләшмә үзләренең тирәсендәге аланнарны ялап чыккандай итте. Элек тә кулына чалгы тотмаган кеше түгел иде Тимерхан, әмма ике ай буена тоташтан чалгы селтәү аны шул эшнең остасына әйләндерде.

Бик күп печән әзерләнде. Тик аның исәбен ала белүче юк. Исәбен алмый ярамый, чөнки ул мөлкәтне дивизиянең интендант бүлегенә тапшырырга кирәк. Кем печән күләмен үлчи белә дип баш ваталар. Колхозда чакта Тимерхан Борһанов өч ел рәттән Имәнле болынындагы кибәннәрне үлчәп кайткан иде. Аны бу эшкә бәләкәйдән үк остасы Хуҗа абзый өйрәтте.

Серне чиште Борһанов. Хәер, сержантлар әзерли торган батальонда да аның язу-сызуга осталыгын, счет сала белүен яраталар иде. Үзе ул стройдагы курсант булса да, аны штабка чакырып, ара-тирә эш кушалар иде. Печән үлчәүдә бу юлы лейтенант Савиновны өлкән итеп, курсант Борһановны эш башкаручы итеп куйдылар. Солдатлар землянкаларга кайтып киткәч, алар икәүләп печән кибәннәре үлчәп йөрделәр. Дивизия чапкан печән ифрат та күп иде, аны үлчәү үзе генә дә ай ярымга сузылды. Шуның өчен алар өлкән командирларның рәхмәтен алдылар.

Курсант Борһанов сизә, аңа начальство якты күз белән карый. Сержантларны өйрәтү батальонында, укулар бетәр алдыннан Борһановны штабка чакырдылар. Комбат Валуйский кабинетына рөхсәт сорап керде курсант Борһанов. Анда Тимерхан танымаган капитан утыра.

— Борһанов менә шушы була,— иптәш капитан,— диде комбат.— Янә өстәп тә куйды:— Безнең иң тәртипле курсантыбыз.

Кабинетта — бер капитан, бер майор. Кыяфәтләр бер дә галәмәт: ул аркылы-торкылы каешлар, ул чырайдагы бөркетләр кыюлыгы! Алар каршысында гимнастеркасы һәм сырган чалбары майланып беткән, кыска буйлы, ялваручан карашлы авыл малае басып тора. Борһанов ул минутларда үзен никтер гайрәтле егет итеп түгел, йолкыш кына бер малай итеп сизде.

Капитан бил каешын сыпырып җибәрде, йолдызлы биек фуражкасын чигереп, чәчләренә кагылып алды, аннары өзеп кенә:

— Мин саперлар батальонының штаб начальнигы капитан Коровичев булам. Штабта эшләү өчен безгә эш башкаручы кирәк. Сезне менә, курсант Борһанов, иптәш майор бик яхшы яктан телгә алды. Безгә килергә ниятегез юкмы?

Сорау, әлбәттә, бик йомшак итеп әйтелде. Армиядә: «ниятем юк»,— дип ничек әйтеп торасың?

Рядовой Борһанов бер дә икеләнмичә:

— Мин риза, иптәш капитан!— диде.

Бер атнадан укулар бетте. Рядовой Борһановка сержант дәрәҗәсе бирделәр. Комбат белән сөйләшү буенча Тимерхан Борһановны үзе хезмәт итә торган дивизиянең саперлар батальонына җибәрү турында приказ чыгарып, азык һәм әйбер аттестатлары биреп, яңа урынга җибәрделәр.

Батальонга килгәч, штабка керде Тимерхан, юк, инде Тимерхан түгел, сержант Борһанов. Анда таныш капитан Коровичев һәм Тимерхан белмәгән бик ыспай киемле старшина Макаров каршы алдылар. Старшина Ульян өлкәсеннән икән, ул Борһановны кочаклап ук алды һәм шундук:

— Якташ иҗәнсез, бергә-бергә эшләрбез,— диде.

Старшина Макаров шушы көнгәчә батальонның эш башкаручысы булган, аны хәзер финанс бүлеге башлыгы итеп күчерәләр, сержант Борһанов аның урынына эш башкаручы булып калачак.

— Николай Дмитриевич, мине сез хәрби документлар белән эш итәргә өйрәтәсезме, әллә, йөзәргә үзең өйрән, дип диңгез уртасына ыргытасызмы?

— Борчылмагыз, якташ, мин сезне ул эшнең серләренә төшендереп җитмичә туктамам.

Тимерхан үсмер малай чакта колхозның баш хисапчысы Хуҗа абзыйга ничек ышанып караса, ул әйткәннәрне ничек бирелеп башкарса, старшина Макаров әйткәннәрне дә шундый ук тырышлык белән башкара торган булды.

Штабта ике язу машинкасы бар икән. Тимерхан беренче эше итеп аларда баса белергә өйрәнде. Сержантның тырышлыгы, документларны пөхтә итеп тутыра һәм саклый белүе Николай Дмитриевичка ошады. Ул Тимерханнан җиде яшькә олырак иде, штабта эшләүче тагын биш-алты кеше дә — ике Себер татары, бер Ульян мишәре, Шантала станцасыннан бер мордва егете, тагын берничә урыс — барысы да яшь ягыннан Борһановтан өлкәнрәкләр иде, унтугыз яшь белән егерме биш яшьнең аермасы бик тиз сизелә торган була, ул кешеләр Тимерханга баласытыбрак карамакчылар иде, финанс бүлеге башлыгы старшина Макаров аларның барысын да үз урыннарына утыртты һәм Тимерхан Борһанов әзерләгән документларны майор Коровичевка үрнәк итеп күрсәтте.

Шулчагында Тимерханның түбәсе күккә тиде, ә штаб егетләренең борыннары әзрәк аскарак салынды.

Тимерхан алардан уңайсызланды, бик нык оялды. Батальон инженерлык хезмәтләре өчен билгеләнгән булганлыктан, офицерларның барысы да зур мәгълүматлы, физика, химия, математика ише фәннәрне, сызымнарны, карта белән эш итүне бик яхшы беләләр, чөнки аларга һәртөрле исәпләр ясарга, урысчалап әйткәндә, төгәл расчетлар чыгарырга кирәк бит.

Алар арасында Казан химия-технология институтын тәмамлаган Яровых (хәрби дәрәҗәсе буенча лейтенант), Мәскәүнең архитектура Академиясен бетергән өлкән лейтенант Шейкман, Краснодардан педтехникум бетергән Шахматов, Уфадан Осин, Красноярдан Обрезковлар бар. Югары уку йортларын бик мактаулы бетергән белгечләр генә түгел болар, өстәвенә махсус хәрби белем алган офицерлар.

Алар ничектер Тимерханны якын иттеләр. Аеруча старшина Макаров аны комбатка мактаганнан соң. Аннары алар үзләре дә сержант Борһановның тырыш һәм намуслы икәнен күреп торалар, аларның да кайбер документлары аның кулыннан уза. Батальонда хезмәт иткән Мәскәү офицерлары арасында нишләптер гитара уйный белүчеләре дә, гармунчы-баянчылары да юк. Тик алар җиңел арияләрне, романсларны

оста башкаралар, чечетка дип аталган биюне тыпырдаган чагында бишалты бәләкәй чүкеч белән берьюлы ритмлы итеп кадак каккан төсле тоела иде Тимерханга.

Мәскәү офицерлары белән бергә килгән Норлат-Октябрь егете Тухфитулов Гайфулла бар. Гәүдәгә — Алып батыр, 120 килограммлы, җитмәсә буйчан да әле. Урысчасын урысларны уздырып сөйләшә. Тик аның иң бөек сыйфаты ул түгел әле. Солдатларга бирелә торган паек бик аз, фәкыйрь — Гайфулла солдатларга бирелә торган паек ботканы кашык белән каерып алып бер генә кабып җибәрә дә:

— Их, егетләр, минем ашыйсы килә бит,— ди...

Хикмәтләре күп солдат халкының, берсе «холостой» патрон белән, дары тутырып, иптәшенең кулына ата, икенчесе тамагы туймаудан зарлана, өченчесе... чечетка тукылдата.

Тырышып-тырмашып хезмәт итә торгач, Германия белән сугыш та бетеп куйды. Кайберәүләр моңа сөенде, шөкер, исән калдык, диделәр, кайберләре өйләренә күкрәк тулы медаль тагып кайтмаганга кәефсезләнеп йөрделәр.

Тимерханга хәбәр килде: Кыям абзыйсы язган, халыкны үкертеп елата торган җырчы егет Хәлил-Әхмәдиша сугыш кырында башын салган, Тимерханның абыйсы, аны иң авыр вакытларда үзенә сыендырган Баһау сугышның беренче елында ук һәлак булды.

Вәрәшбашның гүәрдин күк күпме егете яу кырында ятып калды.

Тимерхан Борһанов хезмәт иткән хәрби берләшмә егетләренә дә, исән калдык, дип кычкырырга иртәрәк булган әле.

Солдатларны тагын җәйге лагерьларга алып киттеләр. Бу юлы тау-таш ватарга да, печән чабарга да түгел. Чик буена китерделәр. Палаткалар корып, инженерлык-саперлык һөнәрен камилләштереп яталар. Солдатларны ашатуны да беренче нормага куйдылар. Ябык кына егетләрнең битләре тулып, чырайларына алсулык йөгерде. Гайфуллабаһадир да хәзер: «Ашыйсы килә, их, егетләр!»— дип сөрән салмый, күз генә тия күрмәсен, ул хәзер мәйдан тоткан батыр-көрәшче кебек сизә үзен... Тимерхан Борһанов аны күргән саен шатлана.

«Татар баласының тамагы туйды...»— дип уйлый.

## Сигезенче бүлек

Аргунь елгасы.

Маньчжурия белән безнең илнең уртасында, елганың икенче ягында япон солдатлары. Алар совет солдатларыннан сакланып йөрми, маска-халатлар да кими, иелеп-бөгелеп тә узмый. Алар ачыктан-ачык йөриләр, чөнки самурайларны, Тимерхан белүенчә, иң батыр, иң куркусыз солдатлар дип саныйлар.

Безнең яктагылар аларның нишләгәнен күзәтә, йөрешләрен, кыланмышларын карап тора, аларның сөйләшкән тавышлары бу якка ишетелә.

Тимерханнар да алардан курыкмый, шикләнми, тик алар тыйнак, алар үзләрен устав кушканча тоталар.

8 август, 1945 ел. Өлкән офицерларны югары штабка чакырып алдылар. Тимерханнар батальоны командиры капитан Косюченко армия штабына вакытлыча инженерлык хезмәте начальнигы итеп билгеләнде. Батальонда аның урынбасары калды.

Тимерхан Борһановны батальон штабына эш башкаручы итеп алган капитан Коровичев, тумышы белән Новгородныкы, Армия хезмәтенә кадәрле Ленинградта яшәгән кеше, офицерлар арасында, ихтимал, иң демократы булгандыр. Югары штабтан кайтып керүгә ул Борһановны үз янына чакырып алды:

— Борһаныч, иртәгә сәгать дүрттә японнар чиген узып чыгабыз, штаб хезмәтен әзерлә, мин дивизион инженеры булып китәм, генерал Замахаевның приказы шундый,— диде.

Иртәгесен нәкъ әйтелгән вакытта, сәгать дүрттә солдатлар Аргунь елгасы буена, төнлә корылган понтон күперләрдән чыгу өчен төзелгәннәр иде инде. Иң әүвәл машиналарга төяп җәяүлеләрне чыгардылар, аннары туплар, танклар, алардан соң гына «катюшалар» узды.

Менә шунда Тимерхан Борһановның хәтеренә мәңгегә сеңеп калырлык бер хәл булды.

Нәк шул көннәрдә тәүлекләр буе, өзми-куймый, яңгырлар явып торган иде. Җир бик йомшаган, хәтта сыекланган иде. Монда бит Байкал артының чуер ташы түгел, әйбәт уңдырышлы туфрак — Маньчжурия кырлары башлана. Күпер төбендә зур гына сазлык-баткаклык хасил булган. Тар гына булып сузылган юл уртасына йөк төялгән бер «Студебеккер» кереп батты. Ул исә «катюшалар»га юлны бикләп куйды. Машина янына офицерлар, солдатлар җыелды, этттерә-тарттыра торгач, «Студебеккер» бөтенләй туктап калды. Йөкне озата барган капитан ары чаба, бире чаба, нишләргә дә белми.

Алдагы машинада барган полковник, күкрәгенә Советлар Союзы Герое медале таккан кара гимнастеркалы, галифе чалбарлы кеше җиргә сикереп төште дә батып яткан машина янына килде, капитанга приказ бирде:

— Юлны чистартыгыз. Биш минут сезгә. Приказны үтәмәсәгез, үз кулым белән, шушы урында атып үтерәм!

Менә нинди икән ул сугышчан приказ! Чәчеңне йолкып, нишлим икән дип утырырга вакыт юк икән монда.

Җыелды солдат, җыелды офицерлар,— машинаны тәки чыгардылар.

Полковник бу хәлне ахырынача карап торды.

«Катюшалар»га юл ачылды.

Шул мәлне Тимерханның исен-акылын китәрерлек тагын бер хикмәт булды. Полковник төсләре качкан капитан янына килде дә, аның каршысына басып, кулын кысты:

— Капитан, мин сезнең туган якларыгызга исән-сау кайтуыгызны телим,— диде, башка бер генә сүз дә әйтмәстән, каушап-хушы китеп басып калган капитанны калдырып, машинасына утырды, «катюшалар» колоннасын алып китте.

Батальонда кирәк- яракларны ташу өчен ун ат бар. Тимерхан, аның белән батальон штабындагы башка офицерлар, «катюшалар» артыннан күперне чыккач, Хайлар шәһәре юнәлешенә юл тоттылар. Унбиш-егерме чакрым юл узгач, алар каршысына йөк машинасы белән капитан Коровичев килеп туктады. Штабның сейфларын, батальонның байрагын, берничә штабистны, шул исәптән сержант Борһановны да алып, сугыш кырына китерде.

Совет гаскәрләре чикне чыкканда, анда бер генә дә япон солдаты калмаган, алар эшне алдан ук сизеп, качып киткәннәр иде. Ат абзарларында атлар кешни, утарларда сыерлар мөгри, әмма җан иясе күренми.

Бераз баргач, яралы солдатларны төяп кайтып килүче санитар машиналары очрады. Яралыларның башлары, аяк-куллары калын итеп марляга уралган.

Хайлар шәһәренә җитәрәк, анда җир җимертеп шартлаган тавышлар ишетелде, ярты күкне иңләп ялкыннар, төтен баганалары күтәрелде.

Безнең туплар японнарның корал складларын шартлаткан икән, моны батальон Хайлар кырыена килеп җиткәч кенә белә алды.

Алгы сызыкка килеп җитеп, бер иңкүлектә саперларны машинадан төшерделәр.

Сержант Борһанов батальонның байрагын бик әйбәтләп, кечерәйтеп, ак кәгазьгә пөхтәләп төреп, сейф төбенә — иң ышанычлы урынга салып куйды.

Рота килеп житүгә, сугыштан хәвефле хәбәрләр кайта башлады. Рота командиры лейтенант Шахматов һәлак булган. Өлкән лейтенант, Архитектура Академиясен тәмамлаган кеше Шейнкман, солдатларны атакага күтәргәндә, японнар пулясыннан егыла. Норлат-Октябрь егете Гарифуллин Салих, Кемеровадан Сафин, тагын берничә урыс егете сугышның беренче сәгатьләрендә корбан булалар.

Батальон килеп төшкән урыннан бер-ике чакрымдагы калкулыкта каен урманы бар иде. Төннең төн буена аны «катюшалар» дөмбәсләде. Иртән карасалар, калкулыктагы каеннардан кара күмер генә торып калган. Бу урын японнарның ундүрт ел буена кытайлардан төзеткән ныгытмалары булган. Авиация, туплар, танклар ул хәрби ныгытмаларны, япон гаскәрләрен ут астында тоталар.

Сугыш хакындагы әдәбиятта Маньчжуриядә төзелгән «Хайларский укрепрайон» дигән сүз бар. Бу район, японнар Маньчжурияне басып алгач, 1931 елдан башлап 1945 елга тикле төзелә. Әлеге хәрби ныгытмаларның жир өстендәге өлеше — алдавычлар гына. Урман, куаклыклар, вак-төяк каралтылар. Аның иң зәһәре — жир астында икән әле. Тимер-бетон казармалар, кабинетлар, ату полигоннары, электр станцалары, икмәк пешерү заводлары, азык-төлек келәтләре... Гомумән алганда, бөтен бер хәрби кала.

Жир өстендәге ДОТлары, ДЗОТлары шундый да куәтле бетоннан эшләнгән ки, авыр туплар жибәргән снарядлар да аларга килеп бәрелгәч, стенага бәрелгән борчак кебек кенә чәчрәп китәләр иде.

Япон солдатлары бетоннан корылган жир асты ныгытмаларына кереп яшеренделәр. Аларны аннан куып чыгару өчен инженер-саперларга әллә ниткән тактик ысуллар кулланырга кирәк булды. Саперлар, төркемнәргә бүленеп, танк экипажларына беркетелделәр. Алдан танклар, алар артыннан танк утына ышыкланган саперлар бара. ДОТларның, ДЗОТларның бетоннан койган тәрәзәләре турысына барып житкәч, саперлар тәрәзә төбенә шартлаткыч толларны куялар, берничә минуттан тәрәзә турысында тәрәзә ишарәсе — зур кара тишек кенә торып кала. Шул алым белән жир асты каласына керү юллары, ишекләр, капкалар, бункерлар шартлатылды.

Японнарның сугышсыз биреләселәре килми. Алар үлемгә баручылар. Моның мәгънәсе шулдыр — армия хезмәтендә самурай бөтен өстенлекләрдән файдалана, шул сәбәпле ул сугыш вакытында теләсә нинди үлемгә барырга әзер. Үлемгә баручылар беренче көннәрдә совет танклары астына ташланып, шартлаткычлар белән бергә һәлак булдылар, танкларның да байтагын эштән чыгардылар. Японнарда әсирлеккә төшү тыелган. Япон солдатының гимнастерка якасына агу тегелгән. Үлем куркынычы яки әсир төшү куркынычы янау белән ул якасын чишеп жибәрә дә агуны тешләп үлеп тә китә.

Япон солдаты кыска буйлы, әмма йомрандай житез, чыдам, һәркайсында махсус пычак. Кул сугышында аларны жиңүче бар микән?

Япон солдаты дошманының иң нечкә жирен кисеп алырга өйрәтелгән. Бу сугышта Тимерхан телләре киселгән солдатларыбызны күреп тетрәнде. Ә иң фажигалесе — Тимерхан да, башка саперлар да, гомумән бөтен батальон яратып өлгергән Алып-батыр, Гайфулла-баһадир белән булды.

Отделение командиры өлкән сержант Тухфитулов Гайфулла, 120 килограмм авырлыгындагы кеше, сугыш кырында берүзе жиде япон солдаты белән сугыша. Японнар аны тере килеш алырга ниятләнәләр. Гайфулла көчле, Гайфулла — озын буйлы, таза. Ул япон самурайларының кайсысын мылтык түтәсе белән мәтәлдерә, кайсысына штык белән кадый, берничәсен бер-бер артлы жиргә дөмектерә. Шунда самурайларның берсе, пычак тотып, Гайфулланың женси әгъзасына һөжүм итә, Гайфулла хәлсезләнеп ава. Батальон солдатлары Гайфуллага ярдәмгә килгәндә соң була инде.

Батырлыгы өчен Гайфулла Тухфитулов «Дан» ордены белән (үлеменнән соң) бүләкләнә. Фронт газитләреннән шул заманда Тимерхан Борһанов аның турында басылган очерклар укыды. Әле озак вакытлар ул Гайфулланың фаҗигале үлемен, японнарның мәкерлелеген онытa алмыйча, кара кайгыга калып йөрде.

Үз-үзләрен аямаган сугышчылар Тимерханнар батальонында да күп булды. Ул батальонда сугышларда катнашкан солдатларның туксан проценты орден-медальләр белән бүләкләнде. Алар белән берәүнең дә исен китәреп булмый, сугышта һәлак булганнар бик кызганыч иде. Вәрәшбаш кешесе Исрафилов Җәүдәт хезмәт иткән ротадан, бер сугыштан чыкканда нибарысы унөч кеше калган иде.

Беркөнне шулай көндезен ике кеше, разведканың әйтүенә караганда, кытайлар, велосипедка атланып, Тимерханнар батальоны урнашкан урыннан узып киттеләр. Нигә кытайлар, ник японнар түгел? Мәсьәлә бер көннән соң ачыкланды. Кытайларны японнар сатып алып, разведкага файдаланалар икән.

Кичен, караңгы төшкәч тә, батальон штабына һәм хуҗалык взводына японнар һөҗүм итте. Вак-төяк һөҗүм генә түгел, нык әзерләнгән һөҗүм. Моңа батальон әзер иде. Капитан Логинов җитәкчелегендә унөч кеше батырларча сугыштылар. Штаб документлары, җаннан кадерле булган байрак саклап алып калынды. Дошманның тигезсез көчләрен җимереп, качып китәргә мәҗбүр иткән өчен сугышчылар медальләр белән бүләкләнде.

Тимерхан Борһанов хезмәт иткән дивизия, японнарны җиңүдә катнашканы, сугышчыларының батырлыгы өчен Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнеп, Краснознаменный дигән исем алды. Менә хәзер сугыш юлларын искә төшереп, сугышчан иптәшләренең хатларын укып утырганда, әллә кайчангы истәлекләре яңара Тимерханның, ул гүя яшьлегендә кунакта булып кайта.

Хайлар шәһәрендәге хәлләрне күреп, аның тирәсендәге сугыш операцияләрендә тагын берничә көн катнашканнан соң, хәрби берләшмә Зур Хинган сыртын үтеп, Чжалантунь дигән шәһәрдә квартирларга урнашты. Анда бер айга якын торганнан соң, Байкал артына, «кышкы квартирларга» кайтырга фәрман булды.

Капитан Коровичев, Тимерханны үзенә эшкә алган офицер, йөк машинасы китертеп, штаб сейфларын, төрле документларны төяттерде.

Тимерхан аның да бүләк алганын ишеткән иде. Ул кыюлыгын җыеп:

— Иптәш капитан, Ватан сугышы ордены алуыгыз белән котлыйм! — диде.

— Рәхмәт, сержант, миңа моны сугышчан иптәшемнән, коралдашымнан ишетү рәхәт, — диде, аннары бик җитди итеп: — Бу машинада солдатлар, тагын бер хатын-кыз да бар. Аның ире полк командирының урынбасары булган, ул хатын иренең каберен күрергә килгән, аның белән, үзегезне иплерәк тотыгыз, яме, — диде.

«Иплерәк тотуның» нәрсә икәнен Тимерхан башта аңлап бетермәгән иде, туганнар кабере янына туктагач, аңлады.

Бу хатын иренең каберен табу белән кабер өстенә ауды, аны тырныйтырный, акырып еларга тотынды. Үтә дә кызганыч, түзеп булмас дәрәҗәдә кызганыч иде бу хәл. Солдатлар үзләренә урын таба алмас дәрәҗәгә җитеп, кыбырдаша башладылар.

— Тыныгыз чыкмасын, — диде капитан Коровичев.

Шулчакны машинаның кабинасыннан полковниклар киемендәге бер хәрби төште.

— Ул хатынның ире шушы полковникның урынбасары булган. Иптәш полковник тынычландырса тынычландыра инде аны, — диде капитан Коровичев.

Полковник кабер кырыена килде, йомшак, тынычландыру тавышы белән әйтте:

— Ярый, берни дә эшләр хәл юк. Сугыш кешеләрне кызганмый
ул,— диде.

Әмма ирен югалткан хатын һаман да каберне тырный, һаман
үксеп-үксеп елый иде әле, күрәсең, полковникның сүзләре аның аң
барып җитми иде.

Шунда карт полковник тураеп басты да ачы тавыш белән:

— Встать!— дип кычкырып җибәрде.

Әлеге хатын кабер өстеннән ничек торганын да сизми калды.
гафу итегез, мин сезне борчыдым, дип машинага менеп утырды.

Капитан солдатларга полковникның ник кычкырганын аңла
бирде:

— Әгәр полковник кычкырмаган булса, торырга боерык бирм
без вакытында китеп өлгермәсәк, аллам сакласын, ул хатынның да х
бик мөшкел иде, йөрәк белән шаярырга ярамый,— диде.

## Тугызынчы бүлек

Сугыш көнбатышта да, көнчыгышта да безнең гаскәрләр
җиңүе белән бетте. Солдатларны армиядән кайтару башлан
Кешеләр авылларын, йортларын, гаиләләрен сагынганнар.
җиде яшь ярымда армиягә киткән үсмер егет чын егеткә әйләнде хә
Аның да Вәрәшбашка кайтасы бик килә. Тик сугыш вакытында ике
ярым хәрби хезмәттә булып та, япон самурайлары белән сугышла
катнашып та тиз генә өйгә китә алмаячагын белми иде әле ул.

Аңа тагын бик-бик озак, нәкъ биш ел армия хезмәтен узарга ки
иде әле. Ул чакларда андый эшләрне киңәшеп эшләмиләр иде.

— Ник безне өйләребезгә җибәрмисез?— дигәнгә җавап әзер: «Ва
таләп итә!» Менә шуннан үзең нәтиҗә яса.

Авыр заман. Ирекле сүзләр күңелгә килсә дә авыздан чыкм
торган заман. Нишләргә?

... Тимерхан абзыйны яшьлек хатирәләре бик еракларга алып к
теләр. Сугышчан иптәшләренең хатларын алып укыйсы килде аның.

*«Исәнме, кадерле Тимерхан Борһанович!*

*Кадерле иптәшем һәм сугышчан дустымнан шатлыклы хәбәр ки*
*Мин синең хактагы истәлекләремне 30 ел буена йөрәгемдә йөртт*
*Очраклы рәвештә миңа синең якташың Ибәтуллин мөрәҗәгать ит*
*Мин аңардан синең хакта — армиядәге дустым хакында белешүен ү*
*дем. Ниһаять, менә синнән хат килде. Хатыңнан күреп торам, с*
*тормышың дөрес юлдан киткән. Мин әле теге заманнарда, сугыш еллар*
*да ук Тимерханның акыллы икәнен, шул заман өчен белемле дә кеше икә*
*аңлаган идем. Армия хезмәтендә җиде ел буена бергә булу. Ба*
*артының кырыс шартларына түзү, сугыш һәм Зур Хинганны кичү ав*
*лыклары — болар барысы безнең дуслыкның авыр сынауларын узган хәл*

*Шушыларның чынлыгына шаһит итеп фотомны җибәрәм, синнә*
*фото көтеп калам. Калганын икенче хатымда тәфсилләп язармын.*

*Ихтирам белән Н. Дубинин.»*

Хатка «1981 елның 23 марты» дип кул куелган һәм бу хат Кемер
шәһәреннән килгән.

Старшина Николай Петрович Дубининны күз алдына китереп, а
фотодагы өлкән чыраена карап озак утырды Тимерхан, сугышта йөр
чакларын, ә үзе армия хезмәтеннән азат ителгәч, Коля Дубининның
1950 елның 21 мартында тимер юл станцасына кадәр озатып кун
исенә төшерде.

... Шилка елгасы аркылы күпер юк. Паром дигәне боз китеп беткәч кенә кузгала. Әле боз исән, тик аның инде кайбер урыннарына су чыккан. Поездга утыру өчен аргы якка чыкмыйча булмый. Коля Дубининга ярның бу ягында гына саубуллашып калса да булыр иде кана, әмма солдат дуслыгы — шундый да бер дуслык ул, бары бергә, югы уртак дигәндәй, булгач-булгач ахырга кадәр булсын инде дип, теге як ярга ук чыгарып куярга булды старшина дусты.

Су чыкмаган урыннарны сайлап, чемоданнарны яткырып куеп, боз өстеннән түш белән шуышырга булдылар. Бераз шуыштылар, хәвеф-хәтәр юк. Елганың яртысын узгач, боз шытырдый башлады. Кирегә китәрләр иде, алар узган төштәге бозларның исән-сау калган булуларына өмет юк, алга шуышырга кирәк, әнә алда, бер урында инде су да килеп чыкты боз өстенә. Нишләргә? Ярга, бары тик ярга, суга төшкән сурәттә дә йөзәр урын күп түгел. Йа ходаем, үзең сакла! Соңгы минутларны шуышканда арттагы бозлар ишелеп, суга ук төшә башладылар. Бетүләре микәнни? Җиде ел буена чиккән газаплардан соң, сугыш утларыннан исән калганнан соң салкын боз астында һәлак булырлармы? Бәхетләре бар икән, ярга сикергән чакта, соңгы метрдагы боз убылды да су бөтен елга өстенә ургыла башлады.

Яр буенда төсләре качкан, аяк буыннары дерелдәгән старшина белән сержант, кочаклашып, тын калып тордылар.

Язмыш аларны бу бәладән дә коткарды.

## Фронтташ дуслар бер-берсен таба

**«Без барыбыз да полковник Дубининны яхшы беләбез. Кем генә килми аңар ярдәм сорап! Николай Петровичның вазифасы шундый, ул һәркемгә кирәк. Аның кабинетының ишекләре бер дә ябылып тормый. Иң мөһиме шул: теләсә нинди очракта да ул ярдәмчел, тыныч-сабыр, акыл белән эш йөртүчән. Полковник Дубининны без шундый итеп күрергә гадәтләнгән.**

**Менә безгә саргая төшкән солдат фотосыннан япь-яшь һәм чандыр бер үсмер карап тора. Күз карашы балаларча саф, гаҗәпләнүле, әмма иреннәре кысылган, монысы инде балаларча түгел. Тәвәккәллек бар, кыюлык бар кысылган иреннәрдә. Әлеге Дубинин 43-нең ноябрендә унҗидесе тулар-тулмас солдат булды, Ватанны саклады. 45-нең августында Байкал арты фронтының 36 армиясе төп юнәлешкә чыкты. Япон милитаристлары белән сугыш озакка бармады, әмма ул тиз һәм аяусыз булды. Беренче көненнән башлап соңгы көненә кадәрле Коля Дубинин авыр һәм куркыныч саперлык язмышы — сугышның ару-талуны белмәс хезмәтчесе язмышы эләкте.**

**Беренче хәрби бурыч — кыты агымлы Аргунь елгасы аркылы понтон күпер салу. Бу күпер безнең гаскәрләргә елганы кичеп, Маньчжуриянең башкаласына, японнар хакимлек иткән Хайларга төп көчләрне ыргыту өчен кирәк иде.**

**124 нче аерым сапер батальонының икенче талпынышы, икенче һөҗүме Хайлар каласының үзенә. Язылмаган законнар буенча беренче булып минерлар бара. Алар гаскәрләргә юл ярып баралар, елга-инешләрдән сугышчыларны чыгаралар, дошманның мина яшергән кырларын чистарталар.**

**Маньчжуриянең башкаласында өч атнага сузылган дәһшәтле сугышлар — туплардан, танклардан, сугыш алласы «катюшалардан» тетрәнгән җир, актарылып ташланган тимер-бетон казармалар, җир асты каласы. Ялкын сулап торган күк йөзе, түтеннәргә уралган офыклар, тоташтан миналангаң кырлар, ут көлтәләре чәчкән мина**

**шартлаулары, сугышчан иптәшләренең кыелган җаннары. Кыска вакытлы, дәһшәтле, үлемнең үзе төсле үк аяусыз бу сугыш күпме яшь гомерне һәлак итте.**

**Аларның саперлар батальоны Зур Хинган сырты аша узып, Чжаланьтунь шәһәренә чыкканда, алар ротасыннан бик аз гына кеше исән калган, ә исәннәр арасында Николай Дубинин белән Тимерхан Борһанов та бар иде. Бередә аларны Җиңү көтә иде. Чыннан да бу «күзләргә яшь тутырган шатлык» иде. Югалтулар ачысы белән бергә җиңүнең шатлыгын татып яшәделәр ул чакта фронтовик дуслар.**

**Бик озакка — җиде елдан артыкка сузылса да, хезмәт чоры узды. Егетләр өйләренә таралды, югалдылар. Әмма аларның солдат еллары, дуслыклары йөрәкләрендә яшәде, югалмады.**

**— Мин озак вакытлар, еллар буе Тимерханны эзләп табу уе белән яшәдем,— ди Николай Петрович Дубинин.— Ниһаять, таптым. Ул миңа хат язган: «Исәнме, кадерле дускай! Адресымны җибәрәм, кунакка чакырам!» Хат астына кулын куйган: Татарстанның социаль тәэминат министры урынбасары Тимерхан Борһанов.**

**Йөрәкләр йөрәкләргә хәбәр итә — фронтовик дуслар бер-берсен таба. Шулай итеп, Байкал арты фронтының 36 армиясе 124 нче аерым сапер батальоны солдатлары, хәзергесе көндә берсе милиция полковнигы, икенчесе министр урынбасары бер-берсен таптылар».**

Бу зур булмаган хәбәр Кемерово гәзитендә басылып чыккан. Гәзитнең исеме дә, елы-көне дә билгеле түгел. Милиция полковнигы бик дулкынланган булса кирәк, даталарын, исемнәрен куярга оныткан. Саперлар батальонының эш башкаручысы сержант Борһанов җибәргән булса, ул төгәллекләр, һичшиксез, булыр иде. Төгәллеге, пөхтәлеге, аек акылы аны зур юлга алып чыкты бит.

Алтмыш биш яшьлек Тимерхан абзый шулай да кара исәп белән чутлап чыгарды, гәзит ул әле министр урынбасары чакта чыккан булгач, сиксәненче еллардыр инде. Ник дигәндә, аның пенсиягә чыкканына да хәзер ничә еллар узып китте...

## Унынчы бүлек

Тимерхан абзый иртәләрен радиодан концерт тыңларга ярата. Телевизордан җырчыларны күрсәтә башласалар, ул янә дә телевизор төбендә.

> Су буенда учак яна,
> Хатирәләр төсле якты,
> Туган авылым, сиңа кайтсам,
> Табармын күк балачакны...

— дип өзгәләнә бер яшь йөрәк. Дөрес өзгәләнә, сабырсыз җан. Балачакның, яшь чакларның истәлеге йөрәкләргә уелып калган инде ул...

Сержант Тимерхан Борһанов, армия хезмәтеннән кайтканда, нәкъ бер аен юлда уздырды. 21 апрельдә өйдә, туган авылы Вәрәшбашта иде инде ул. Ә тагын сигез ай да ун көннән 1951 елның гыйнуарында никахларны теркәү бүлмәсендә Миңлеасия исемле кыз белән икәүләп каушап вә дулкынланып тора иде. Аларны котладылар, моңарчы ишетмәгән матур сүзләргә төреп, озын, бәхетле, тигез гомер теләделәр. Колак ишетә ул сүзләрне, күңел тоймый, сизми, бары тик аларның игелекле сүзләр икәнен генә аңлый. Күңел илаһи бер ашкынулар, моңнар белән тулган...

Никах теркәү кәгазенә беренче итеп Асияның исем-фамилиясен яздылар. Исемен тутырып, барлык шартын китереп «Миңлеасия» дип куйдылар, фамилиясе Борһанова түгел, Җәмилова булды. Миңлеасияның әтисе Җәмил исемле...

Җәмил.

Иске Вәрәш авылының атаклы кешесе ул Җәмил. Даны тирә-як авылларга таралган. Баһадир кеше. Баһадир дигәч тә буйга озын түгел, гәүдәгә дә чандыр гына. Әммадәһи тимер кебек нык, имән кебек чыдам, ат кебек түзем. Тәүлекләр буена эшләр, эһ тә итмәс. Арыталуны белмәс бу адәм унтугызынчы гасырның җитмеш тугызынчы сәнәсендә дөньяга килгән. Урыс-япон сугышында катнашкан. Аннан кайткач, Вәрәшбаштан, ягъни Тимерханнар авылыннан Мөнәздәһә исемле кызга өйләнеп, үз көнен үзе күрмәкче булган. Вәрәш авылы ул заманда елга ярына сыенып, бик озын урам булып сузылган. Бер генә, нибары бер генә урам! Икенче урамны, шундый ук озын урамны Җәмил солдат барлыкка китерә. Инешнең икенче ярына чыгып, казык кага ул. Менә шушында Җәмил солдатның нигезе булачак. Тукта, туганкаем, аллаһы боерса, дип әйтмәдең бит әле! Иртән торса, казыклар очкан. Бу ни хикмәт бу? Кемгә ошамый Җәмил солдатның үз нигезен корырга теләве? Ошамый, авызын корт чаккыры! Ошамый!.. Солдатның кан кызу — урысчалатып бер сүгенеп ала да казыкларны тагын кагып чыга. Ни хикмәттер — тагын алып китәләр. Өченчесендә инде Җәмил солдат алдатмый — төнгелеккә шунда кала. Яр читенә поса да килүчеләрне сагалый. Ай болыт астына кергәч, күренә бер шәүлә. Җәмил солдат «по-пластунски» шуышып килә дә казык суырып ятучының колак төбенә берне тондыра. «А-а-а!» — дип кычкырган тавыш кына ишетеп кала Җәмил солдат — казык суыручыны ай күрә, кояш ала!

Иншалла, шуннан соң казыкны суыручы юк.

Йортны ул 28 яшендә салган.

Мөнәздәһәсе белән 68 ел гомер иткән. Менә бу гомер дисән дә гомер! Җәмил солдат сугышка тикле катлаулы сугу машинасына көлтә тыгып тора. Таза беләкле дүрт-биш килен көлтә биреп өлгертә алмый аңа.

Җитмеш биш яшендә әле ул Вәрәшнең янгын сүндерүчеләр командасында беренче кеше иде. Шулай бервакыт Мөслимгә йомыш белән килгән чакта үзләренең авылы Вәрәштән куе төтен күтәрелгәнне күрә. Ык буена ташлана, Ыкны йөзеп чыга, Мөслим янгынчыларының тачанкасы артына баса. Авылда «Пожарный» турысыннан узганда, тачанкадан сикерә, тәртәләрен күтәртеп куйган арбага атларны җигеп, инештән су ташырга керешә. Янгын бик тиз сүндерелә. Җәмил солдатның бу батырлыгы легенда булып тарала.

... Тимерхан абзый исенә төшерде: Җәмил карт туксанны узгач та аяк өстендә иде әле. Тик үләсе көнне генә ул, олы кызын чакырып, үлем сәгате сукканны әйтә. Ләгән белән комган сорап ала, тешләрен чистарта, авызын чайкый, бәхилләшә дә дөнья куя...

Җәмил солдат хатынга да кемне сайларга икәнен белгән. Мөнәздәһә — алты бала анасы: өч малай, өч кыз. Укымышлы, дип сабагын яхшы белә. Зиһен ягы түрәрәк. Җәмиле белән алар бик озак, бик тату яшиләр. Җәмил 96 яшендә, Мөнәздәһә 100 яшендә якты дөньядан китәләр.

Менә шушындый легендар кешеләрнең төпчек кызы Миңлеасияга өйләнде Тимерхан. Шул заманда ук, 1951 елны, Җәмил карт белән Мөнәздәһә әбинең кемнәр икәнен белеп өйләнде. Әйе, белеп! Хәзер генә ул бер көнне танышалар, икенче көнне ЗАГСка йөгерәләр. Тимерханнар башлы-күзле булган заманнарда егет-җилән дә, кыз-кыркын да, күзебашы акаеп, теләсә кемне гомер юлдашы итми иде. Сайлап кына, уйлап-тикшереп кенә чәчне чәчкә бәйлиләр иде.

Үзе гармунчы, үзе биюче, үзе тел бистәсе, үзе инде сугыш утларында да булырга өлгергән Тимерханга яр булырга теләүче аз түгел иде ул заманда. Өстәвенә егерме бишенче елгылар кырылып беткән заманда!

Алданмады ут-суларны кичкән егет. Буш кармакка капмады. Сайлый белде кызны...

Хәер, сайлый белде дип... Ул да башкалардан уздыра торган эшләр эшләмәде, хәйлә-мазар кормады.

1950 елның апрель азакларында, сыерчыклар килгәч, елгалар ташып, ярларына кайтып төшкән чакта, Армия хезмәтеннән туган авылы Вәрәшбашка кайтты. Киткәндә унсигезе дә тулмаган яшел авыз иде, кайтканда егерме бишне тутырган, сугыш ялкыннарын кичергән гайрәтле егет булып кайтты.

Сугыштан соң да әле аны биш ел тоттылар, моның сәбәбе ул чакта Тимерханга бигүк ачык түгел иде, хәзер инде ап-ачык: нинди гүәрдин ирләр кырылды фронтта, булачак офицерлар вакытсыз китеп бардылар, Тимерханнарга алмашка килүчеләрнең тап-таза егетләр булып үсеп житүен көтәргә кирәк булган икән. Хезмәтен башкаруга гына риза түгел иде Тимерхан, алгы көннәрен дә кайгыртып яшәде ул солдат хезмәтендә: ятимлектә чагында укый алмый калган елларын да кайтарып алырга кирәк иде. Укыды, төннәр буе укыды: 8—9—10 класслар өчен имтихан тапшыра алды. Авылга кайтканда инде аның урта белеме, солдат тәҗрибәсе, сержант дәрәҗәсе бар, тормышны белүе, кемнең кем икәнен танып белерлеге бар иде.

Кайтты. Үз кадерен үзе белән торган дәрәҗәле егет булып кайтты.

Кайтса күрә, сугышка китеп барганнарның күбесе яу кырында ятып калган. Әхмәдиша да юк, Баһау абыйсы да юк. Тимерхан белән бергә кузгалган унҗиде кешенең нибарысы бишесе әйләнеп кайткан, уникесе үлеп калган.

Хикмәти хода, әтисе Борһан Бөгелмәгә кадәр илткән егетләрнең дүртесе дә исәннәр. Менә шунда күңелен телгәләп, бәгырен өзеп, җанында үкенү туды, Вәрәшбашның данлы җырчысы Әхмәдишаны ник аның әтисе илтмәде икән. Хәер, ул Тимерханнардан олырак, гармун уйнарга дәшкән чакта да ул аны олы итеп күрсәтер өчен генә яшьти дип дәшә иде бит...

Авыл бетешкән, ачлык-ялангачлык. Шулай да халыкның алгы көнгә булган ышанычы да, өмете дә сүнмәгән иде әле.

9 май көнне кичен клубка барды. Солдат киемнәрен бик пөхтәләп, ак якалар тегеп, «энәдән-җептән генә чыгып» барды. Клуб тулган үсмерләр тартынып кына фронтовик янына, сугыштан соңарып кайткан Тимерхан абыйлары янына килделәр. Нигә тартынуларын баштарак аңламаган иде, соңрак аңлады, болар бар да ул югында үсеп житкән яшьләр икән.

Колхозның 21 телле тальян гармуны, сугышка киткәнче Тимерхан уйнаган көмеш телле гармун ник күренми? Ә-ә-ә алай икән, аны, колхоз сипаратын төзәткән өчен акча булмагач, Синәкәевкә биреп җибәргәннәр. Йөрәгенең әллә ничә тамыры берьюлы өзелгәндәй булды Тимерханның. Дөньяларны яңгыраткан көмеш телле гармун юк. Беркайчан да булмаячак! Аны Синәкәевкә биргәннәр. И заманалар, и гомерләр, Тимерханның үсмер чагын чит-ят кешегә биреп җибәргәннәр. Гармун юк, җыр юк. Моңсулык бар, яшьлек юк...

Клуб эргәсендә генә яшәгән Нуриәхмәтнең тальянкасы бар икән. Элдертеп кенә аны китерделәр.

— Уйна әле, Тимерхан абый,— диде Нуриәхмәт.

Яшүсмерләр чолгап алды сержантны, уйнавын үтенделәр, ялвардылар. Тимерхан бераз гына ялындырып, дәрәҗәсен саклап, тын утырды да, башны гармун өстенә салып, «Минзәлә»не сыздырып җибәрде. Аннары «Шахта»ны китереп куйды. Кичен клубка чыккан саен калмый торган авыл көйләрен ялгап алып китте. Җанда моңсу, күңелдә әллә кайчангы истәлекләр, ятимлекләр баш күтәрә, сагышлардан җан жылый иде.

Яшьләр дә тынып калган, берсе дә дәшми, берсе-бер җырламый иде.

Керфек төпләрен дымландырып, кызышып килгән күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, Тимерхан, башын күтәрмичә генә, бию көен сыздырып җибәрде. Яшьләргә кинәт җан керде, алар, кыстатып-нитеп тормастан, сугыштан соңгы ярым караңгы клубны ашкыну белән тутырып, рәхәтләнеп биергә керештеләр.

Алар арасында Миңлеасия исемле кыз да бар икән. Яшьләр аңа үзләре Асия дип кенә дәшәләр. Шул Асия-Миңлеасия барлык уеннарны оештыручы, үзе иң алдан уртага чыгып биюче, җиңеллеге, сүзгә тапкырлыгы, күңел көрлеге белән авыл яшьләрен кузгатучы булып чыкты. Вәрәшбашта ул шәфкать туташы булып эшли, шул ук вакытта колхоз комсомолларының башлыгы да икән әле.

Кичәдән соң Тимерхан, аның янына килеп, бик кызык итеп әйтте:

— Миңле Асия туташ, полк командирыннан өлкән сержант Борһановка сезне өегезгә кадәр озатып куярга фәрман килде. Рөхсәт итәсезме?

Миңлеасияның күзләре зураеп китте:

— Юк, иптәш өлкән сержант, мин сезгә үземне озатырга рөхсәт итмим,— диде ул.

Тимерхан коелды да төште. Кая китте аның фронтовиклыгы, сержантлык гайрәте?!

— Нишлибез соң алайса?— диде ул юаш тавыш белән.

Миңлеасияның тавышы һаман да көр, ул тавышны бөердән чыгарып сөйләшә иде.

— Ә сез, иптәш өлкән сержант, полковник фәрманын үтәп, мине рөхсәтсез генә озатыгыз!

Аларның сөйләшүенә колак салып торган яшьләр, комсомол башлыгының кыюлыгын хуплап, кул чаба-чаба көлделәр.

Хурлыкка кала язган сержант, урамга чыккач, үзен кыюрак тотты. «Ничава» егет икәнен күрсәтәсе килеп, үзе озата барган кыз белән өстәнрәк торып сөйләште. Күп укыганлыгын, командир булганлыгын сиздерергә тырышты.

Авыл җирендә кемнең кем икәнлеген бер чакрымнан күреп торалар. Шәфкать туташы Миңлеасия үзе янында борчакны бик эредән ярып барган фронтовикның нинди кеше малае икәнен ул кайтканчы ук белеп алган иде инде. Белмәскәни! Вәрәшбаш белән Иске Вәрәшнең арасы дүрт чакрым, өстәвенә Миңлеасияның әтисе Җәмил карт кайчан карама сүзне Борһан картны мактаудан башлый. Янәсе, ул бик итагатьле, янәсе, аның фронттагы малае Тимерхан сугышка кадәрле колхозда баш хисапчы булып эшләде. Булдыклы да, ушлы да малай.

Болай булгач, Миңлеасиябыз Тимерхан дигән өлкән сержантны ерак яклардан тыны белән тартып кайтармадымы икән әле? Нәрсәгә кирәк аңа синең әдәби китапларның геройлары турындагы сүзең?

Бу хәтлесен Тимерхан абзый хәзерге алтмыш биш яшьлек акылы белән аңлый, ул чакта, бәлкем, аңлап та бетермәгәндер әле...

— Без, Тимерхан, алай күкләргә менеп сөйләшмик. Син миңа туптуры әйт: иртәгә дә клубка чыгасыңмы?— диде Асия. Бу юлы төртмәле итеп түгел, күкрәк түреннән чыккан ниндидер назлы тавыш белән әйтте.

— Ә нигә?— диде Тимерхан аны сынап карар өчен.

— Нигә? Нигә? димә син, чыгасы булсаң, өзеп кенә әйт!

— Өзеп кенә әйтәм: син чыгасы булсаң, чыгам.

— Менә монысы егетләрчә!— дип Асия шаулатып көлеп җибәрде. Тимерхан аның көлү рәвешеннән рәхәт минутлар кичергән чакта сизми дә калды, Миңлеасия туташ инде капкадан кереп тә югалган иде.

Кичләрен алар көн саен клубка чыга торган булдылар.

Тимерхан аны көн саен озатып куя торган булды. Алар инде хәзер китап геройларын сөйләшмиләр. Тимерхан да үзенең «ничава» егет икәнен күрсәтергә тырышмый, алар бик гади сүзләр сөйләшәләр, капка

төбендә бер-берсенә сыенып торалар, бер-берсенең тыннарын, сулышларын тоялар, башлары җиңелчә генә әйләнә, күңелләрендә, рәхәт-рәхәт булып, сафлык, якынлык, ниндидер илһамлы яңа бер тойгы уянуын, шул тойгының бер дә бетмәвен, мәңгелек булуын телиләр.

Бер айлар чамасы озатып йөргәннән соң, июнь башларында Тимерхан кызны капка төбенә кадәрле озатып куйгач, Асияга якын ук килеп, кызыкайны биленнән кочаклап алды, бу халәттән чиксез дулкынланган кызыкайга тартылырга-нитәргә ирек куймыйча, колагына пышылдады:

— Асия, бәгырькәем, беләсеңме, мине Мөслимгә, районның авыл хуҗалыгы бүлегенә эшкә чакыралар...

— Ә мин?.. —диде Асия, ни әйткәненә хисап бирмәстән.

— Нәрсә син?

— Мине кем озатып куяр? Кем соң миңа, Миңлеасияуу дип, назлы итеп дәшер? Кем яшьләрне клубта гармунга биетер?..

Сораулар күп иде. Аларга җавап биреп кенә бетерерлек түгел иде. Тимерхан эшләрнең җитдигә киткәнен, райүзәктә эшләсә дә ул инде Асиядан башка яши алмаячагын аңлый иде.

— Син борчылма, җаным. Урнашу белән хәбәр итәрмен мин сиңа. Мөслим бит безгә җиде генә чакрым, сагынган саен кайтып та йөрермен...

— Сагынган саен дигән була. И мактанчык! Сиңа ышансаң, сагына да белмәссең әле. Сайрап торган буласың...—диде Асия һәм үзен үбәргә дип үрелгән Тимерханның иреннәрен кулы белән каплады.

Тимерханга кинәт фронттагы кыюлыгы кайтты, ул кызыкайның ике кулыннан берьюлы тотып алды да ирексездән үзенә таба авышкан сөйгәненең кайнар иреннәреннән суырып үпте...

Бу үбешүнең тәмен аңа атна буена күңелендә сакларга туры килде. Асия янына кайтырга ул күпме генә ашкынмасын, берничек тә форсат тими, аны өзлексез колхозларга җибәреп торалар иде. Авыл хуҗалыгы бүлегендә ул инструктор-бухгалтер вазифаларын башкара, сугышка кадәрле үк хисапчылар курсын тәмамлап, колхозда эшләп киткәнгә күрә бу эш аңа авыр тоелмый, армия хезмәтендә чактагы урысчага өйрәнүе дә бик ярап куя, әмма Асияны күрмичә көн артыннан көнне үткәрүе аны сагышка сала иде.

Сугыштан соңгы еллар бигрәк мәшәкатьле иде шул: ял көннәрен белгән дә юк инде, өстәвенә аңа беркетелгән унҗиде авылның күпчелеге районның иң аргы башларында, күпчелеге әле урыс авыллары иде. Мөслимнән ерак булу сәбәпле алардан кайтып җитмәгән көннәр еш була иде.

Шулай беркөнне чираттагы командировкадан район үзәгенә кайтыр алдыннан, комсомол райкомына шалтыратып, икенче секретарьга әйтте Тимерхан:

— Карагыз әле, Әгъләмов, мин бүген Мөслимгә кайтам. Вәрәшбашка кайтырга вакыт тимәячәк, иртәгә иртүк тагын чыгып китәсе бар. Дустым бул, Асияны бүген кичке алтыларга райком бюросына дип чакырт әле. Тимерхан чакыра дип әйтсәң, килмәс, кирәк булсам, үзе кайтсын, дияр, бик үз сүзле кызый бит ул.

Асия Вәрәшбаштагы комсомол эшенең торышы хакындагы докладка әзерләнгән—нәкъ әйткән сәгатькә төп-төгәл килеп керде райкомга. Тимерхан шунда утыра. Күз сирпеп кенә алгач, бик җитди итеп рәсми рәвештә генә исәнләште.

— Нишләп йөрисең?—диде Тимерхан, аның янына килеп.

Кул сузып исәнләшергә дә әйткән иде, тегесе, кул бирмичә генә:

— Бюрога чакырткannар. Килдем әле,—диде.

Чырае караңгы. Тимерханга үпкәләгән, ахрысы.

«Үпкәләтергә ярамый аны. Дәрәҗәне нык саклый торган кыз. Эшне ничек тә җайларга кирәк»,—дип уйлады Борһанов.

— Карале, Миңлеасия, сине бит райкомол чакыртмады, мин чакырттым. Сине өзелеп сагындым, үлеп тә күрәсем килде. Кайтырга бер дә җай чыкмагач, егетләр аша әйттердем мин сиңа...

Асияның алсу түгәрәк йөзе көл кебек агарды, әмма ул үзен бик тиз кулга алды.

— Слушай, Борһанов, мин мондый уеннарны бер дә яратмыйм. Дус булсак, дус булыйк, мин ялынып йөрүчеләрдән түгел.

Тимерхан аны, кулыннан кысып тотып, райкомолдан урамга алып чыкты.

— Карале, Асия, юкка-барга авыз турсайтмыйк әле. Чынлап торып әйтәм, минем бер генә минутымны да буш калдырмыйлар. Син минем кайта алмавымны да, сине сагынуымны да аңларга тиеш. Мин яшьләй ятим үстем. Үз көнемне үзем күрдем. Хәзер инде егерме алтынчы яшем белән барам. Сугыштан соң кайтармый асрауларына мин гаепле түгел. Безгә ялгыз-ярым яшәүнең кирәге юк...

Асия аның тел төбен аңлагандырмы-юкмы, анысы билгесез, тик ул Тимерханга бүтән каш җыерып карамады, «слушай» дип ачуы кабарган чакларда әйтә торган бердәнбер урыс сүзен дә кыстырмады, алар ул кичне уртак тел таптылар шикелле.

Тик... менә шул кичне Тимерхан өйләнешү хакында сүз кузгатмаганына бик үкенде. Кузгатыр иде, курыкты: бердән, гаилә корып, яшәр урын юк, икенчедән, матди фәкыйрьлек бик җанга тия.

Вәсвәсәләнеп, хәсрәткә батып йөри торгач, шулай да Тимерхан бер көнне Миңлеасия белән тәгаенләп сөйләшергә кирәк дигән ныклы уйга килде. Бу вакытта аларның танышканнарына ярты ел чамасы булган иде бугай.

— Ай бу аерым яшәүләр! Өзә үзәкне, телә бәгырьне! — диде ул Асия-җанкисәгенә.— Инде бер-беребезнең холыкларны да беләбез. Берберебезне аңлыйбыз да кебек. Йөрмик әле ялгыз каз булып. Оя корырга вакыттыр ич инде безгә.

Асия, гадәтенчә, башын кырын салып, елмаеп кына куйды да болай диде:

— Синең белән минем танышлыкны Сәрби җиңгәчәй әнкәйгә җиткергән инде. Әгәр ниятең изге икән, минем әткәй-әнкәй белән үзеңә сөйләшергә туры килер...

Вакытын билгеләделәр. Тимерхан Асияларның төп йортына — Иске Вәрәшкә китте. Беренче мәртәбә аларның ишегалдына керүе булгандыр, каушады, аптырады, ишек тоткасына тотынырга кыюлыгы җитми торды.

Ниһаять, ишекне ачып керде.

## Унберенче бүлек

Тимерханның ишектән керүе булды, ак бөрчекле кызыл яулык бөркәнгән кырык яшьләрендәге бер апа туп кебек тәгәрәп кенә ишек янына килеп тә җитте.

— Рөхсәтме? — диде Тимерхан карлыгыбрак киткән тавыш белән.

— Әйдүк, әйдүк, кунак егете, рәхим ит, түрдән уз,— дип, ак бөрчекле кызыл яулыклы апа бик тиз сөйләп алып китте.— Әбкәй, син кайда? — диде ул, артына борылып.— Кунак килде бит әле. Олы кеше, мәйтәм, әллә үзең каршы аласыңмы?

Беренче башлап ишек төбенә туптай тәгәрәп килеп җиткән апа — Миңлеасияның җиңгәчәсе Сәрби түтәй, әбекәй дигәне йортның хуҗасы, булачак киленнең әнисе икәнен абайлап алды Тимерхан.

«Әбекәй» — җитмеш яшьләрдәге бик мөлаем карчык, алты баланың әнисе — яулык белән битен дә капламады, уңайсызланып та тормады, ике

куллап күреште, куллары бик йомшак, бик җылы иде, Тимерханны түргә таба алып та китте.

— Җәмил бабай кайда, өйдә күренми? — дип беренче соравын бирергә җөрьәт итте Тимерхан.

— И бәбкәм, картларның мондый эштән ераграк торганнары яхшы,— дип әйтеп, ул Тимерханның йомышын чишеп бетерә язды.

«Әбкәй буласы кеше бик уңган күренә бит әле»,— дип уйлап өлгерде Тимерхан.

Ул арада Мөнәзҙәһә әби Тимерханны сәке буена алып килеп, аңа утырырга киез куйды:

— Шушында утыр, бәбкәем,ату исә сарыгыбыз йонсыз булыр,— дип ул авылның йолаларын да искә төшереп алды. Аннары ул Тимерханның аркасыннан сыйпады, түшендәге сугыш медальләрен тотып карады, йөзенә текәлеп карап торды:

— И бәбкәем, гел дә менә Борһанетдин төсле икәнсең. Тавышың да, сөйләшү рәвешләрең дә, буй-сының да гел дә атаңныкы. Әйбәт кеше, дөньяның бер мәхлугы инде ул Борһанетдин. Аның бәхетсезлегенә синең анаң Бибигатифә бигрәк иртә вафат булды. Урыны җәннәттә булсын. Без аның белән бәләкәйдән үк бик тә дус иек. Унбер ел мәдрәсәдә бергә укыдык, унбер ел бер мендәргә башларыбызны куеп йокладык...

Сәрби апа чәй өлгертте.

Табынга, еллар авыр булуга карамастан, кызыл эремчек, бавырсак, ак май, кәрәзле бал куелды, буларын бөркеп, табагы белән бәрәңге килеп утырды.

Табынга Сәрби апа утырмады.

— Чәйне иркенләп, үзегез генә чүкердәшеп бер эчегез әле. Минем абзар-кура тирәсендә эшләп бетерәсе эшләрем бар,— дип, ул ишектән үк чыгып китте.

Мөнәзҙәһә әби шаулап утырган самавырдан чәйнеккә су агызды, чәйнекне тастымал белән бераз томалап торгач, Тимерхан алдына бизәкле чәшке белән чәй ясап куйды.

Әллә табындагы ризык муллыгыннан, әллә парларын бөркеп утырган самавыр җылысыннан Тимерхан тирләп чыкты, кесәсеннән кульяулыгы чыгарып, озаклап битен, муеннарын сөртергә тотынды.

— Ай аллам, хур була яздым бит, бәбкәм, сые бар, хөрмәте юк, дигәндәй, кунак алдына тастымал куярга да оныткканмын лабаса! — дип шакмаклы зур тастымалны кунакның тезенә китереп салды.

— Картусыңны сал, булмаса, Тимерхан. Тирләп-пешеп утырма,— диде ул, кунагының икеләнүен күреп. Тимерхан йолдызлы биек фуражкасын салып, янына куйгач, янә дә бер мәртәбә үзенең кирәкмәгән эш эшләвен тоеп, югалып калды.— И бәбкәем, картусыңны сал дибәйтеп әйттем дә бит, түбәтәең юк икән, безнең халык бит аш-су янында башына кимичә утырмый. Шәригать китабында әйткән: башка кимичә утырсаң, ашка чәч төшүе бик ихтимал, аш янында түбәтәй киеп утырырга боерган,— дип, ул урыныннан торып чөй янына барып килде, чөйдән Җәмил картның кара бәрхет түбәтәен алып килеп, Тимерханның башына кидертте.

— Менә әйбәт булды, менә малачина! — диде ул, үзе эшләгән изге эшкә шаккатып.

Ул сөенгәч, Тимерхан да торып, стена буендагы көзгедән карады һәм рәхәтләнеп көлеп җибәрде — гимнастеркалы, медальле, түбәтәйле бравый солдат аңа көзгедән карап тора иде.

Тик Мөнәзҙәһә әби генә аның нигә көлгәнән аңламыйча, дин-шәригатькә бәйле сүзен дәвам иттерүне кирәк дип тапты:

— Син, бәбкәм, нигә көлгәнсеңдер, белмим, әтиең Борһанетдин сугыш елларында бик изге эш эшләде — сугышта үлеп калганнарга корьән чыкты, үлем-җетем килгән чакларда безгә ни эшләргә икәнен аңлатып бирде. Бик изге эш эшләде Борһанетдин, бик саваплы эш,

бәлкем, шуңа күрәдер, син дә, ул чанасына утыртып Бөгелмәгә чаклы илткән никрутлар да исән кайткандыр. Сез үзегез соң, Тимерхан бабкаем, сугышта чакта дога укыйдырыегызмы? Бик куркыныч чаклар булгандыр бит анда, бәбкәем? Әллә дога белүче берәү дә югыемы арагызда?

— Сугышта анда көнелгә әллә нәрсәләр килә, әбкәй! Мин үзем әнием Бибигатифәдән отып калган догаларымны укый торган идем. «Безне дә өйрәт әле»,— дип ялынучылар да булды, аларны да өйрәттем. Аяк астында җир убыла, офыкта ялкын өермәләре, якында гына туплар шартлый, анда, әбкәй, иң динсез кеше дә динне иске төшерә...

— Рәхмәт, бәбкәем. Әнинең Бибигатифә дә бик инсафлы кеше ие, әтиеңнән дә игелек күрдек, дөнья рәхәте игелек күр.

Шул сүзләрдән соң Тимерхан да кыюланып китеп, нинди йомыш белән килгәнен Мөнәзләһә әбигә әйтеп бирде:

— Әбкәй, без Асия белән бер авылда бит хәзер...

— Асия дигәнең кем була, бәбкәем, Миңлеасиямы?

— Шул үзе, әбкәй, синең төпчек кызың Миңлеасия. Без аның белән ярты ел буе таныш инде, күрешеп-сөйләшеп йөрибез. Менә без икәү киңәштек тә, башлы-күзле булыйк, дидек. Сездән, Миңлеасияның әти-әнисеннән, мин ризалыкларыгызны сорарга дип килдем. Әгәр Җәмил бабай белән сез риза булсагыз, без, аллага тапшырып, бер-беребезгә хәләл җефетләр дә булыр идек.

Мөнәзләһә әбинең иреннәре дерелдәп куйды, маңгай турысына чыга башлаган чал чәчләрен ул яулык астына яшерде, аннары йомшак, сагышлы тавыш белән әйтте:

— Бәбкәем, мин ризамын, картым Җәмил дә риза булыр. Бибигатифә белән Борһанетдин малаена төпчек кызыбыз Миңлеасияны бирү — безнең өчен Аллаһы Тәгаләнең олы насыйбы. Бибигатифә дә исән булса, шушы зур вакыйгага бихисап сөенгән булыр иде, бичаракаем... Син миңа, бәбкәем, улым да, киявем дә булырсың, аллаһы боерса.

Тимерхан аның сүзләренә исе китеп утырды. Элеккерәк чакта булса, бәлки ышанмас та, исе дә китмәс иде, мәктәп дәресләрендә әхлакның гел киресен сөйләп килделәр бит, кешеләрне «динсез», имансыз иттеләр; сугыш ялкыннарында көеп, изелгән-сытылган язмышларны, туганнар каберлекләренә тутырылган солдатларны күреп кайткач, ул Мөнәзләһә әбинең сүзләренә таң калып утырды. Менә кемнәрдә икән әхлак, менә кемнәрдә икән намус-вөҗдан, менә кемнәрдә икән ул сафлык...

Өлкәннәрнең хәер-фатихаларын алганнан соң алар ЗАГСка барып язылдылар, Вәрәшбашның, Иске Вәрәшнең урамнарын кашавай чаналы атларда әйләнделәр, заманына күрә туй ясадылар.

Болар барысы 1951 елның 1 гыйнуарында булды.

Аннары алар тагын аерылдылар.

Тимерхан Мөслимгә китеп, үз эшенә чумды. Миңлеасия Вәрәшбашта, Тимерханнарның төп йортына күчеп, авылдагы эшен дәвам итте.

Миңлеасия белән Сәрби җиңгәсе Мөслим базарыннан җиз самавыр сатып алып кайттылар. Ул тугыз урында эретеп ябыштырылган, ерактан караганда кургашлы ул урыннар бу самавырның халыкара күргәзмәдә яулаган медальләре төсле күренә иде. Әлеге самавыр гомер буе аларның юлдашы булды, хәзер дә ул алар нигезендәге изге әйбер булып санала. Икенче әйбер — бер елга әҗәткә алган баян. Кибетче, Тимерхан Борһановның өздереп баян уйнаганын күргәч, аңа баянны бер ел эчендә түләп бетерү шарты белән, мөһерле бер кәгазьгә кул куйдырып биреп җибәрде.

Алар өенә самавыр керде — кайнар чәй.

Алар өенә баян керде — музыка.

Кешеләр күпме өмет итеп мал артыннан кумый иде ул чакта, бернинди сугыш юк елларда бер-берсен үтерми иде, дөнья малы — дуңгыз каны өчен җанын сатмый иде.

Һәммә кешенең авызында да, көнелендә дә бер сүз кабатлана:

— Шөкер, еллар иминләнде. Еллар имин булса, калганы булыр,— ди иде кешеләр.

*Казан — Идел буе дачасы.*
*1991—1992.*

**АВТОРДАН:** «Тимерханның яшьлеге» тәмам. Алда аның тагын да зуррак тормышы, тагын да зуррак авырлыклары бар әле. 15 елдан артык колхозлар белән интегәсе, ун елдан артык Социаль тәэминат министрының урынбасары камытын киеп, авыр йөк тартасы, пенсиягә чыккач, музей төзеп, ничаклы наркомның кара елларда атылганы белән очрашасы бар. Алары әсәрнең икенче кисәгендә булыр инде. Әдәби әсәр авыр языла, бүгенге кебек, әдәбият әһелләре фәкыйрьлеккә, кимсетелүләргә дучар ителгән дәвердә бигрәк тә. Ярар, зарланмыйк, хәзер күпчелек кешенең, аеруча хезмәт кешеләренең тормышы авыр, кимсетелүле.

Укучыга әйтәсе тагын бер сүзем бар икән. Җае чыкканда әйтеп калыйм: бу әсәрдәге геройларның берсен дә автор уйлап чыгармады. Тимерхан да, Миңлеасия да, сугышларда һәлак булганнар да, Вәрәшбаш егетләре-кызлары да — барысы да чын, документаль. Бары тик Вәрәшбашның данлы җырчысы Әхмәдишаның гына исеме үзгәртелде — аның чын исеме Гайнемөхәммәт (истә калдыру өчен авыр), фамилиясе Әхмәдишин. Фамилиясен мин аның исеме итеп алдым. Ватан сугышында һәлак булган ул моңлы егет миңа рәнҗеп ятмас дип өметләнәм...

# КЫРЫМ ТАТАР МАНӘЛӘРЕ ҺӘМ ЧЫҢНАРЫ

Манәләр һәм чыңнар, безнең татар халык җырлары кебек үк, кырым татарлары фольклорында назым (поэзия) жанрының иң киң таралган төрләреннән булып, үзләренең әдәби эшләнеше буенча камиллеккә ирешкән халык авыз иҗаты җимешләреннән саналалар. Кырым татарлары арасында, мәсәлән, манәләр белән чыңнарны яттан белмәгән кешене гомумән очратуы читен. Туйларда, кунак-төшем вакытларында, шулай ук башка мәҗлесләрдә һәм күңел ачу кичәләрендә әйтелә торган бу манәләр вә чыңнарның сан ягына килгәндә, әлегәчә аларның исәбе-хисабына чыга алган берәү дә юк! Кырым татар койларында (авылларында) чың әйтеп йөрүчеләр — кедайлардан берәүсе, мәсәлән, бу турыда менә болай ди:

*Юрга мендем, тай җиктем, Орны кичтем,*
*Йөз алтмыш чувал[1] чыңымның берсен чиштем.*

Чынчылар, шулай ук чыңнарны башкаручылар бу шөгыльне фәкать тамаша кылу дип кенә санамыйлар, ә кеше акыл-зиһене мәргәнлегенең һәм халык авыз иҗаты җәүһәрләренең мәһабәт бер матур үрнәге, әхлак сафлыгының вә вөҗдан пакълыгының өлгесе итеп карыйлар. Чыңнарның берсендә болай диелә:

*Чыңнаганда акылың җыеп чыңна,*
*Сүзләреңнең мәгънәсен белеп чыңла.*

*Чың әйткәннең авызы бер данәдер,*
*Ә тыңлаучы колаклар мең данәдер!*

Чыңнар үзләренең килеп чыгышлары ягыннан — Кырым ярым атавының чүл һәм дала районнарында, манәләр исә Кара диңгез яр буйлары белән тау итәге төбәкләрендә туган саналалар. Чыңнар, асылда, егетләр һәм кызлар белән икс арада уздырылган ярышлар вакытында уйлап чыгарыла. Соңыннан, арадан иң уңышлы дип табылганнары һәм иң җор булганнары тирә-якларга, халык арасына тарала. Мондый «ярышлар» аеруча туй тантаналарында, бәйрәм табыннарында, ә гадәти вакытларда кыз белән егет арасында бара. Бу очракта алар егетләр, кызлар арасында чиратлашып әйтеләләр. Манәләр исә, чыңнардан аермалы буларак, кызлар тарафыннан — бәйрәм җыеннарында, бию шәкелендә кулларны иңбашка сугып, Коръән-кәримне укыган көйгә — хор белән җырланып уйнала.

Чыңнарның да, манәләрнең дә эчтәлекләре кыска һәм ачык, сүзләре мәргән һәм мантыйклы булып, мәгълүм бер фикер белән тыгыз бәйләнгән була. Күләме ягыннан зур булмаган ике юлдан гыйбарәт булган бер чыңда яисә дүрт юлдан торган бер манәдә тулы бер лирик сима (образ) күз алдына килеп баса. Һәм аларга абстракт фикерләр, аңлау өчен читен булган гыйбарәләр бөтенләй ят булып, тасвирлау чараларыннан — чагыштырулар, охшатулар, гиперболалар кешеләрнең хәяткә карата мөнәсәбәтеннән чыгып кулланылалар. Чыңнардан аермалы буларак, манәләрдә 1-2-4 мисрагълардагы ахыргы сүзләре һәрчак үзара кафияләшеп килүләре үзенә хас бер үзенчәлек вә канунн күренеш булып санала. Чыңнар белән манәләрнең бу үзенчәлекләрен ачыграк күзаллау өчен, без аларның үзләренә мөрәҗәгать итик:

---

[1] Чувал — капчык.

*Эчем ялкын, тышым ут, күз яшем мөлдер,*
*Дошманым булсаң, як, үлтер, дус булсаң — сүндер.*

Чыңнардагы беренче, манәләрдәге беренче белән икенче мисраглар, эчтәлек җәһәтеннән икенче, ә манәләрдә исә өченче һәм дүртенче мисраглар белән тышкы яктан үзара бәйләнешле кебек күренсәләр дә, асылда, алардагы тасвирлаулар кайбер очракларда тыңлаучы һәм укучыга аннан соң әйтеләсе төп фикерне ачыклауда ачкыч хезмәтен үтиләр һәм тыңлаучыда билгеле бер тойгы, хис уяталар:

*Дәрья ташкын, су салкын — бирми кичү,*
*Син картаймый, мин үлми — юк ваз кичү!*

Чыңнар белән манәләрне әйтүдә дә кайбер аермалыклар яшәп килә. Чыңнар, мәсәлән, кара-каршы утырышып (йә басып), төркем яисә ике кеше тарафыннан (егет белән кыз) башкарылса, манәләр исә җыеннарда бергә эш арасында йә булмаса (мәсәлән, тәмәке басуында, йөзем плантациясендә уңыш җыйганда) ял араларында ялгыз — кызлар тарафыннан әйтеләләр. Манәләрдә, гомумән, кызларның лирик кичерешләре, кәеф-сафа корулары, сөю-мәхәббәтләре, садә тойгылары чагылса, чыңнарның диапозоннары тагын да киңрәк булып, аларны егетләр һәм кызлар катнашлыгында кумәкләшеп, йә булмаса нәүбәт белән башкаралар.

Чыңнар һәм манәләр турында, өстәп, тагын шуны әйтмичә калу ярамастыр. Чыңнарны, манәләрне яратучы (тудыручы) кырым татар кедайларын, мәсәлән, кыргыз халкының манасчылары белән тиңнәргә мөмкин булыр иде. Кыргыз халык манасларыннан аермалы буларак, кырым татар чыңнары белән манәләре беркем тарафыннан да фәнни нигездә җентекләп өйрәнелмәгән һәм тулысынча җыелып тупланмаган. (Бу өлкәгә караган фәкать бер генә хезмәт мәгълүм безгә.)

Борынгы Шәрекъ классик назмында «фәрдләр»дип атап йөртелгән — ике юлдан торган бер жанр бар. Чыңнар да үзләренең шәкел җәһәтеннән, тышкы яктан күпмедер дәрәҗәдә әнә шул фәрдләргә якын торалар. Аерма тик шунда, фәрдләрне шагыйрьләр иҗат итсә, ә чыңнар халык арасыннан чыккан «исемсез кедайлар» тарафыннан экспромт белән, ягъни алдан әзерлексез-нисез әйтеләләр.

Инде кырым татар манәләре һәм чыңнары турында сүзне шушы урында тәгәлләргә дә булыр иде. Әмма ләкин, ике икең — биш дип дәлилләргә маташучы, баштанаяк коммунистик диктат тәртибенә корылган торгынлык елларында төрки халыкларның,шул исәптән, кырым татарларының да мәдәнияте, әдәбияты һәм үткәндәге тарихы арасында һәрвакыт үзара тыгыз бәйләнеш булуына ничек тә күз йомарга, күрмәмешкә, белмәмешкә салышырга тырыштылар. Әгәр бу турыда авыз ачып, дөресен әйтүче җәсүрләр — кыюлар табылса, аларны шунда ук «милләтче» диярге ашыктылар. Ләкин кояшны уч белән каплап булмаган кебек, хакыйкатьне дә яшерү мөмкин түгел. Канкардәш төрки халыкларның гореф-гадәтләре, тел вә дин уртаклыкларыннан тыш, югарыда күрүебезчә, чал гасырлар дәвамында иҗат ителгән — төрки ата-бабалардан безгә кадерле мирас булып калган халык авыз иҗаты җәүһәрләре арасында да тыгыз, борынгы рухи бәйләнешләр яшәп килә икән!

Без бу санда журнал укучыларын кырым татар манәләре вә чыңнарыннан үзебез тәрҗемә иткән кайбер үрнәкләр белән таныштырып китүне лазем санадык.

**Әдхәт СИНУГЫЛ.**
Симферополь — Ташкент.

## МАНӘЛӘР

*Манә — манәне ачар,*
*Манә белмәгән качар.*
*Кил, бер манә әйтим мин,*
*Манә күңелеңне ачар.*

Кыя кыяга багыр,
Кыядан силләр агыр.

Борма мыек булганда,
Сакаллыга кем барыр!

Бакчаларда нармыдыр[1],
Сөтнең агы кармыдыр?
Ярым, синең кальбеңдә
Миңа урын бармыдыр?

Күзләрегез күмерме,
Кичкән көннәр — гомерме?..
Бер мәктүпчек язмыйсыз,
Йөрәгегез тимерме?

Канәфер алачаксың,
Саргаеп сулачаксың.
Анаң белән сөйләштем:
Минеке булачаксың!

Ай туар Аестаннан,
Көн туар Көнестаннан...
Минем җаным карбыз теле
Яр үстергән бостаннан.

Шау урман томан булса,
Кулымда лимон булса,
Син мине еглатмас идең,
Эчеңдә иман булса!

Йөзегемдә ике каш,
Берсе алмаз, берсе таш.
Сөйгән кызым сорасагыз,
Камыш буй ул, каләм каш.

Шәфталы[2] агачлары,
Төрле чәчәк башлары.
Тартылган җәягә охшаш
Минем ярның кашлары.

Кыя төбен ут[3] басты,
Алтыннарым тут[4] басты.
Килермен диден, килмәдең,
Йөрәкне кайгы басты.

Кыядан үрләр идем,
Сызгырсаң, дүнәр идем.
Утта калдым кайгыңнан,
Өф! дисәң, сүнәр идем.

Ятьмә кордым байгышка,
Килмәсен дип арышка.
Миннән башка яр сөйсәң,
Эчем тулыр каргышка.

[1] Нармыдыр — гранатмадыр.
[2] Шәфталы — персик.
[3] Ут — үлән.
[4] Тут — тутык мәгънәсендә.

Шул тауларда бер кош бар,
Канатында көмеш бар.
Киткән ярым килмәде,
Әлбәт, монда бер эш бар!

Кара казан эчендә
Пешергәнсең ашыңны.
Уйнатма, кыз, кашыңны,
Атаң кисәр башыңны!

Аймысың, йолдызмысың,
Киленмесең, кызмысың?
Мин бу төн киләчәкмен,
Өеңдә ялгызмысың?

Ай түгелмен, йолдызмын,
Килен түгел, мин кызмын.
Төнлә килмә ялгызың,
Көндез өйдә ялгызмын.

Армут далда[1] салланыр,
Саллангачтын балланыр.
Егет күпме батыр булсын,
Кыз каршында ялварыр!

Бакчаларда гиздерден,
Кемлегеңне сиздерден,
Мин сине сөяр идем,
Син үзеңнән биздерден.

Бер далда ике алма,
Берен ал, берен алма.
Җаным, Газраил баба,
Малым ал, ярым алма!

Күктә йолдыз йөз алтмыш,
Кашларың каләм чатмыш[2].
Бар галәмне — туфрактан,
Сине — нурдан яратмыш!

Су өстендә фонарем,
Янармын да, сүнәрмен.
Яр капкасын какканда,
Егъласам да, көләрмен.

Китәм дисең, җаным, кит,
Китсәң, мине алып кит.
Әгәр алып китмәсәң,
Утка мине ягып кит!

Диңгез томансыз булмас,
Егет парәсез[3] булмас,
Яры гүзәл егетнең
Башы бәласез булмас.

---

[1] Армут далда — груша агачында, ботакта.
[2] Чатмыш — сызылган.
[3] Парәсез — акчасыз.

Кыш көне кар татлыдыр,
Җәй көне нар татлыдыр.
Кардан, нардан да бигрәк,
Валлаһи, яр татлыдыр!

Таштан былбыл үтәрме,
Чүлдә дә гөл бетәрме...
Җандай күреп сөймәсән,
«Сөям» дию җитәрме?!

Бакчаларда саз булмас,
Кышлар үтми, яз булмас.
Күршедән кыз сөйгәннең
Йөрәгендә яг[1] булмас!

Бакчаларда гөл булыр,
Сайрарга былбыл булыр.
Сөйгән ярын алмаган,
Яна-яна, көл булыр!

Кулыңдагы сәгатең
Уртасыннан бүленсен.
Миннән гайре яр сөйсәң,
Елан булып күренсен!

Дам[2] өстендә бер гүзәл,
Дамны тирәли гизәр.
Кулында бер кызыл гөл,
Үзе гөленнән гүзәл.

Күктә очкан кошларның
Канатлары кайрылмас.
Картлар сүзе бик тугъры:
Тырнак иттән айрылмас.

Куллары көмеш кебек,
Бераз өшемеш кебек.
Сөеклем килде, китте,
Әйтерсең бер төш кебек.

Бакча тарлыктан еглар,
Айва нар өчен елар.
Бүген туган балалар
Ярең яр өчен елар.

Сөюем алай түгел,
Алтындыр, калай түгел,
Морадка җитмәк өчен,
Көтүе кулай түгел.

Мендем чия далына,
Ботаклары салына.
Мин ярымны бирмәмен
Бөтен дөнья малына!

---

[1] Яг — май.
[2] Дам — дамба.

Иркемне пычакладым,
Өемне чәчәкләдем.
Ярым искә төшкәндә,
Ястыгым кочакладым.

Капкалары калындыр,
Күршеләре залимдер.
Анасы ни дисә дисен,
Кызы минем малымдыр.

Тәрәз төбең гөл булсын.
Эче тулы су булсын.
Әгәр мине алдасаң,
Гөлләрең корып сулсын.

Бер йөзегем бар минем,
Бармагыма тар минем.
Үлү бар, аерылу юк,—
Шундый кальбем бар минем.

Меним дисәм, атым юк,
Алыйм дисәм, рәтем юк.
Ал битеңә чебен кунган...
Чебен кадәр бәхтем юк!

Кил карлыгач, карлыгач,
Канатларың җәеп ач.
Алачак булсаң син мине,
Ятка бирмә — алып кач!

Кашларың уйды мине,
Күзләрең суйды мине.
Орды — үтералмады,
Тик яралады мине.

Башыңдагы такыяң,
Борма-борма кыегы.
Мин күргәндә бик яшь иде,
Инде үскән мыегы!

Ат алсаң, налына[1] бак,
Аннан соң ялына бак...
Ярыннан айрылганның
Бер күнлек хәленә бак.

Алма дисәм, нар икән,
Боз дигәнем — кар икән.
Күз алдымнан хыял кичте,
Хыял түгел, яр икән!

Диңгез өстендә каек,
Чыгың дуслар, багаек.
Эчендә ярыбыз булса,
Ал яулыклар болгаек.

Ай туар, ат атланыр,
Бу эшкә кем шатланыр.

[1] Налына — дагасына.

Минем хәсрәт-зарымнан
Һавалар болытланыр.

Күземнең карасына,
Гөл чәчтем арасына.
Сөюем сихәт булсын
Йөрәгең ярасына.

## ЧЫҢНАР

### Чың турындагы — чыңнар

— Чың дигәне нидер ул? — Килештерсәң,
Чыңнан чикмән тегәрмен, ирештерсәң!

— Картка, яшькә чыңламак түгел гаеп,
Бераз бәет әйтәем, күңлең табып.

— Ачы җавап бирсәң дә, һич моңаймам,
Мин гел чыңлап яшәгән — чын нугаймән.

— Шайтанга чарык кидерттем, калсын данга,
Чыңчы икәнең белим, чык мәйданга.

Чың белмәгән җыеннан иртә качар,
Шулай байгыш үз серен үзе ачар.

Әүвәл яшьләр чың әйтеп, таң аттырган,
Үзләренә дус-иш шулай арттырган.

Чыңлаганда аклыңны җыеп чыңла,
Сүзләреңнең мәгънәсен белеп чыңла.

Чыңчымын дип, чит якка алып качма,
Чәчкәләп, үз сереңне үзең ачма.

Чың әйткәннең авызы бер danәдер,
Аны ишеткән колак мең данәдер.

Кар яуганда, һәрбер җир бияз[1] була,
Берәүләргә чың нәкъ тә пияз[2] була!

Туй җыйнында чыңлашмак бик кирәктер,
Чыңның кайнар чишмәсе гик йөрәктер.

Чың белмәсәң, чигенер җир тапмассың,
Әгәр белсәң, үбәр яр син тапмассың!

Чыңнарга килгәнмен, чыңлаячакмын,
Йә елатып, йә елап кайтачакмын.

Шайтан мендем, җен җиктем, гаскәр кичтем[3],
Унике чувал чыңымның берен чиштем.

[1] Бияз — ак.
[2] Пияз — суган.
[3] Кичтем — киттем, үттем.

Мур кыргыры, чал аты алып качты,
Унике чувал чыңым юлга сачты.

Ай туса, ахшам була, көн туса, саба,
Чың әйтешик дисәң, җил, я мәрхаба!

Чың белмәсәң, чык монда, өйрәтермен,
Чыңнан озын җеп ясап, терәтермен!

Туйдан-туйга менгәнем бер җирәнчек[1],
Чыңнап чыңчы тумый, яңа өйрәнчек.

Өннән чыккан еландай укталасыз,
Чың белмәгән яшьләрдәй, тукталасыз.

Безгә иләшкән сау калмас, телен тешләр,
Чың белмәгән егетләр бүген нишләр?

Чыңчы егет икәнсең, чык, мин күрим,
Акылыңны үлчәп бер, чөйгә элим!

Чыңчы хатын булсаң син, әйдә, күрим,
Чыңыңа җавап сорсаң, әйтеп бирим.

Менгән атым кан-җирән, тимгелле-күк,
Чыңчылар белән чыңнаган көнем күп.

Ачы алма, татлы армут ашамыйм,
Алтмыш чувал чыңым бар, тик башламыйм!

## Җаваплы чыңнар

### 1

Е г е т: — Әйдәгез, кызлар, чыңлыйк, чың гөрләсен,
Дошман күзе биш булсын, пәрдәләнсен.
К ы з: — Мин ризамын сүзеңә, әйткәнеңә,
Татлы бәлзәм булыйм дәрт-куәтеңә.
Е г е т: — Кара айгыр иярләп, койыңнан[2] кичтем,
Төшемдә синең кулыңнан ширбәт эчтем.
К ы з: — Кара айгырың өстендә койымнан кичтең,
Ширбәт эчми, кулымнан гыйшык эчтең.
Е г е т: — Бер күрүдә, мин сине җандай сөйдем,
Чибәрем, сине кайгыртып, яндым-көйдем.
К ы з: — Ятсам, ястык чылатам, торсам — яулык,
Морадыңа җитәрсең, телә саулык!

### 2

Е г е т: — Мона, сәлам-аләйкум өегезгә,
Ат атланып, ерактан килдем сезгә.
К ы з: — Мәгаләйкүм әс-сәлам, аһ, бер данәм,
Атың кайда бәйлим, кадерле лаләм?
Е г е т: — Кадерлеңнең чәчәге — майның гөле,
Син булгансың бакчамның ямь, былбылы.

---

[1] Җирәнчек — җирән атчык мәгънәсендә.
[2] Койыңнан — авылыңнан.

К ы з: — Асылда мин һәвәсмен кызыл гөлгә,
Син карлыгач, мин былбыл, очыйк бергә.
Е г е т: — Кафтаныңны кем кисте, билен уймый,
Көн дә сине күрсәм дә күзем туймый.
К ы з: — Пәнҗәрәмнең[1] пәрдәсен җил күтәрер,
Син күтәрми, күңелем кем күтәрер?
Е г е т: — Биш пароход, биш көймә, ялгыз каек,
Син Ай булсаң, мин Йолдыз — кавышаек!

3

Е г е т: — Мин бу якка килдем, йөрәгем янып,
Кайсы талга кунаем, канат язып?
К ы з: — Мәгаләйкум әс-сәлам, ди икәнләр,
Чыннап сәлам биргәннәр — кем икәнләр?
Е г е т: — Каракчура койыбыз, Күл өязе...
Белмим чынның исен дә, күңелем язы.
К ы з: — Актыр койның тавыгы, күктер казы,
Белмим ятлар теләгән, мин бай кызы.
Е г е т: — Суда күрдем сурәтең, юдым ярмам,
Күләгәңә газизмен, үзеңә — зармән.
К ы з: — Ул биш бирсә, мин алты, ун бирсә — унбиш...
Мин бер җавап биралмыйм, атамнан белеш.
Е г е т: — Чыдамым чыгырдан чыкты, сорап белешим,
Әгәр риза булмаса, ул чак нишлим?
К ы з: — Чыдамлык пылавы майлы, туймас карын,
Һәркем үзе белә үзенең зарын.
Е г е т: — Сораткандa, бирмәде анаң, бабаң,
Инде миңа булмасаң, хәлләр яман.
К ы з: — Мин касә ясадым ал чаганнан,
Егет булсаң, ал да кач карчыгадан.
Е г е т: — Ал кадифә ясыйм көн ачылганнан,
Чык: мин алыйм да качыйм карчыгаңнан!

## Төрле чыңнар

1

Аһ дигәнче янында мин булырмын,
Битең сыйпап, күзеңне йомдырырмын.

Алтынлы фәс башыннан авып тора,
Кыз дәверең чигәңнән уңып тора.

Дошманнарым сөймәсә, инде сөйми,
Айдан якты йолдызым өчен көнли.

Ил авызын илле ыштан да япмас,
Якыннардан кем генә сереңсатмас.

Сөйли бирсен сөйләгән, тыя алмыйм,
Син бит минем каршымда туган аем.

[1] Пәнҗәрәмнең — тәрәзәмнең.

Суда күреп, күләгәдә алдандым,
Күләгәң дә газиздер, сиңа зармын.

Димче юллап, бирсә атаң, алырмын,
Җаның сөйгән җирләргә өй салырмын.

Тәрәзәңнең пәрдәсе ак сатиннан,
Якма мине утка, аер ялкыннан.

Сукбай дигән имансыз билен буар,
Хәйләкәр күп белер, сусыз юар.

Акыл синдә — аккан су, фикер — дәръя
Күренмисең, килмисең, ни булды, йә?

Акыл алтмыш, беләсең, фикер җитмеш,
Ал кушаклы кулымнан бер кош китмеш.

Туйда давыл дулаттык һәм дә зурна,
Табыннарны бизәде майлы бурма[1].

Давыл, даре, дөмбәләк һәм киманә,
Тирә-якка таралды чың вә мәнә.

Өй алдымда миләүшә, нәркис, нанә,
Син анаңа төпчек, мин дә — бер данә.

Ялган дөнья кайгысы йөзне сарган,
Авыр башы үлчәүнең безгә ауган.

2

Йә бисмилла, йә алла, чыгыйк юлга,
Бер-ике сүз бар әйтәсем, син тыңла.

Син әйткәнче, мин әйтәм, тыңла элек,
Яр буеннан су ага таудан килеп.

Кулдагысы сау булсын, дөньяң уңсын,
Хозыр Илъяс йортыңда дога кылсын.

Алла, дигән ач калмас, айва тешләр,
Ике йөрәк бер булса, дошман нишләр?

Әйтә бирсәм күп була, итәм сабыр,
Мин үлгәнне җир тоймас, алмас кабер.

Бик ерактан килгәнсең, кунак егет,
Тормыш дустың булырмын, булма җебек!

Әйдә, кызлар, чың әйтик, булмасын соң,
Өскә яумас ут — битәр үлгәннән соң.

Кара мыек, чал калпак көлемсери,
Безне лаек күрмиме — күр, ни сөйли?!

---

[1] Бурма — кырым татар милли ашы.

# ШИГЪРИЯТ

**Габбас Хафизов яшь кеше түгел.**
**Гомумән,**
**соңгы елларда Татарстан Язучылар берлегенә,**
**әдәби консультация бүлегенә**
**кульъязмалар, яшьләрдән бигрәк,**
**күбрәк өлкәннәрдән килә.**
**Татар әдәбияты мәйданында**
**мондый хәл килеп чыгуга төрле сәбәпләр бар.**
**Шуларның берсе барыбызга да мәгълүм:**
**безнең яшьләр туган телдән нык читләштеләр,**
**моны без яшәгән чор,**
**безнең тормышка туры килгән**
**тарихи шартлар тудырды.**
**Ә туган тел аркылы белем,**
**тәрбия алып калган кырык яшьлекләр,**
**илле яшьтәгеләр**
**һәм**
**аннан да өлкәнрәкләр — татар теленә**
**тугрылыклы хәлдә яшәгәннәр,**
**әдәбиятыбыз белән кызыксынганнар,**
**үзләре дә иҗат итәргә омтылганнар икән.**
**Араларында**
**моңарчы фәкать әнкә тел сферасының тараюы,**
**«автоном» республикабыз ярлылыгы,**
**нәшрият мәйданыбыз тарлыгы һәм башка мөһим**
**сәбәпләр аркасында гына зур әдәби мәйданга**
**чыгып җитә алмаганнары,**
**әмма күңелләрендә (сүндермичә саклап!) һаман милли моң,**
**әдәби, шигъри матурлык уты йөртүчеләре дә бар.**
**Габбас Хафизовны**
**мин шундыйлардан саныйм.**
**Ул Апас районының Әҗем авылында**
**игенче гаиләсендә туган.**
**Шуннан хәрби хезмәткә алынган.**
**Хәрби хезмәттән соң да**
**игенче эшенә тугрылыклы булып калган — авылына кайткан**
**һәм иҗат газабын да**
**гомерлеккә үзенә юлдаш иткән.**

**Рөстәм МИНГАЛИМ**

## Габбас Хафизов

### Иртә

Җәйнең ямьле көне туа —
Сызылып килә таң алды...
Үзәннәргә чык төшереп,
Сизрәп томан таралды.

Агым суларына карап,
Тал-тирәкләр утыра.
Алларында яшьлегемне
Алып киткән юл тора.

Әйләнеп кайталмаса да,
Ул чакны сагын икән.
Тал-тирәкме, әллә минме,
Кайсыбыз сабыр икән?

## Ялгыз йорт

Сукмак тирәләре тал-тирәксез,
Урамнарның югалган яме.
Йөрәкне әрнетеп кычкыралар,—
Таң әтәчләре калган әле.

Мөлдерәмә сөтле чиләк тоткан,
Сыерын үзе сауган әле:
Бу әбине назлап уятырга
Таң әтәчләре калган әле.

Сыңар чиләк белән чишмәсенә
Суга ул ялгыз барган әле,
Изге догаларын ишетергә
Таң әтәчләре калган әле.

— Кайтыгыз, газиз балаларым,— дип
Хат яздырып салган әле...
Йөрәкне әрнетеп кычкыралар,
Таң әтәчләре калган әле.

## Тегермән

*Җил тегермәннәре торсын*
*Истәлеккә булса да!*

«Оныкларыма» дип бабай
салган васыять итеп:
кырда канатлы тегермән
тора сәҗдәгә китеп.

Очасы килгән кош сыман
тегермән канатлары —
искән җилләрнең артыннан
шыгырдап карап калды.

Алты канатлы тегермән:
— «Бәхил»,— дип кабатлама!
«Искән җилләр файдасыз» да —
хатирә кабатлана.

Үтә мыеклы болытлар
чәчәкләрне кытыклап.
Җил сызгырып, болытларны
куалый кысырыклап.

* * *

Елларның очкыны булып
Сибелгән көннәр.
Шуңа очкыннардан җыела
Безнең гомерләр.
Бар инде сүнгән очкыннар,
Югалганнары,
Бар яктырып, сагындырып,
Гел янганнары.
...Уза гомер, әрни йөрәк,
Хәерле булсын.
Туар көнгә барганнарның
Юллары уңсын!


## Агайлар

Ике дөньядан буш калган
Дәвернең Агалары! —
Юк уңыбыз, сулыбыз юк,
кемнәр соң алдалады?

Уңга карап сәлам бирсәк,
Юк аны алучылар,
Сулга таба борылсак та
Юк хәзер танучылар.

Үкенүдән ни файда бар,
Телләр бозга ябышкач,
Акны кара дип әйтерлек
Чиккә кадәр ялгышкач.

Җитмәде шул ана сөте,
Әби-баба иманы.—
Имансызлар инандырган
Чор иде бу дөньяны...



**Өйрәнчек хикәяләрне матбугатка тәкъдим итәргәме, әллә юкмы? Әлбәттә, бу — авторның үз эше. Бу намәләр минем йөземә кызыллык китерми, дип санаса, язучы аларны бастырырга тиеш. Ләкин минем бу хикәяләремне «өйрәнчек»ләр рәтенә кертәсем килми. 1963 елда һәм аннан бераз соңрак язылган булсалар да, аларның матбугатта дөнья күрергә хокуклары бар, дип саныйм. Ни өчен соң алар дөньяга чыкмаган? Сәбәбе бер генә: мин бу «бичараларны» гәзит-журналларга, җаваплы кешеләре алышынган саен, китерә тордым, бастырырга теләдем. Әмма кара язмышлы бу әсәрләремне һәрчак китапларымнан, вакытлы матбугат битләреннән куа-сыза тордылар. Инде кайбер мөхәррирләр: бу әсәрләрең инде искергән, кызыгы калмаган, диделәр. Шулай ук, туарга да өлгермичә, болар үләргә мәхкүммени? Юк! Ә сез ничек уйлыйсыз, хөрмәтле укучылар?**

АВТОР

*12 февраль, 1993 ел*

# Батулла

## МОҢ

Operaга артык билет сорап торучылар трамвай тукталышына кадәр барып җиткән. Кайбер остарганнары алдагы тукталышта трамвайга утырып, театрга баручыларның кесәләреннән билетларын чәлдерергә өйрәнеп алганнар. Билетларын югалту кайгысыннан берничә тамашачы һуштан язып, әш-мәшә килеп беткәннәр, ди. Хәтта капитан Дафарның да билетсыз калган чаклары булгалады. Бу гадәттән тыш вакыйгаларда җиде-сигез кыз билетсыз калу хәсрәтеннән трамвай астына ташлангач, артык билет сорап торучылар тугыз-ун әбекәйне ялгыш таптаганнан соң тукталышларга, театр төбенә дружинниклар нәрәте куя башладылар.

---

БАТУЛЛА (1938) — *әдип, җәмәгать эшлеклесе, күпләгән проза һәм драма әсәрләре — «Әкият сөйлим сезгә», «Кичер мине, әнкәй», «Су буенда зәңгәр чәчәк», «Сөембикә» һәм башка татар вә рус телләрендә нәшер ителгән китаплар авторы.*

Капитан Дафар кысыла-кысыла эчкә узды. Увертюра башланган иде инде. Ничәмә-ничә еллар шыр ялангач булган опера театрының залы һәркөн шыгрым тулы була. «Опера» сүзен ишетү белән тотлыга торган әбиләр, операны яратканга салынып кына әллә нидә бер театрга йөрүче яшьләр дә агылышмы-агыла театрга. Иртә таңнан театр кассасы янында шау-шу. Кемнәрдер, каяндыр билетлар юнәтеп, артык бәһага сатып, сәүдә оештырып җибәрде. Музыка, культура белән дә сату итә башладылар. Һаман милициягә мәшәкать.

Хикмәт нәрсәдә соң? Башкаручылар да, репертуар да, дирижерлар да шулар ук. Сәбәп нәрсә соң? Музыка белгечләре дә, газета-журнал әһелләре дә, психологлар да монын сәбәбен әйтә алмадылар... Хәер, сәбәбен әйттеләр әйтүен. Сәбәбе — моң! Моң тарта тамашачыны театрга, моң! Соңгы ике атна эчендә җырчылар да, музыкантлар да үз партияләрен гаҗәп моңлы итеп башкарырга тотындылар. Исләрең-акылларың китәр, валлаһи. Ә моңарчы кайда булган аларның моңнары? Нигә шушы арада гына шулай моңлыга әйләнеп киттеләр соң алар — монысы әлегә сер булып кала килде.

Вакыт үтә торды. Тамаша залының тулы булуы гадәти хәлгә әверелде. Музыка белгечләре дә, психологлар да бу сәер хәлне әкренләп оныттылар шикелле. Әйтерсең лә электән гел шушылай булган. Артистлар да, композиторлар да әле күптән түгел генә ике-өч сәгать буе буп-буш залга җырлаганнарын онытып, мактанасы килгән чакларында: «Эһем, мамма-миа!» — дигән булып, итальян җырчыларына охшатып кылана башладылар.

Ләкин бу иллюзия озакка бармады. Көннәрнең берендә кичке спектакль башлану белән зал сызгыра, үкерә, аяк дөбердәтә башлады. Кемдер:

— Халтура! Туктатыгыз бу халтураны! — дип кычкыра.

Кемдер оркестр чокыры янына килеп дирижерны, музыкантларны тирги, кемдер җырчылар тарафына әче сүзләр сибә. Спектакльне дәвам иттерү мөмкин түгел иде. Тамашачы сүгенә-сүгенә таралып бетте.

Икенче көнне дә, өченче көнне дә шушы ук хәл кабатланды. Инде тагын бер атнадан соң опера театры хуҗасы ташлап киткән, тәрәзәләре кадакланган ялгыз йорт кебек, берүзе тырпаеп калды. Бу хурлыкка түзалмыйча, берничә артист үзләре теләп пенсиягә китте, баш дирижер бүтән театрга күчәргә мәҗбүр булды.

Шул ук репертуар, шул ук башкаручылар... Сәбәп нәрсәдә соң?.. Барча кеше бердән:

— Моңсыз башкаралар... Моң юк, моң! — диделәр.

Ни сәбәптән кинәт кенә юкка чыкты соң әле ул моң дигәннәре?

Бу хәлне музыка белгечләре дә, психологлар да, артистлар үзләре дә аңлата алмадылар. Атна-ун көн узды. Айлар үтте. Әкренләп бу хәл онытылды. Әйтерсең лә, гел шушылай булган.

Ләкин бу могҗизаны бер кеше генә онытырга теләмәде. Атаклы тикшерүче капитан Дафар табышмакның җавабын тапмыйча тынычлана алырлык хәлдә түгел иде инде. «Гомер буе янып килгән театрның кинәт кенә шөһрәт яулый алуын аңлатып була инде...— дип уйлады ул.— Әйтик, театр тарихында мондый хәлләр еш очрый. Иҗади күтәрелештән соң иҗади ярлылык, түбән төшү дә сәнгать тарихына ят нәрсә түгел. Ләкин бит ул күренеш болай ук сәер булмый торган иде».

Дафар һәр артист белән сөйләшеп чыкты. Биш йөз кешенең биш йөзе дә бер үк сүзне кабатлый:

— Теге көнне репетициягә килгәч, күкрәгем кинәт киңәеп киткәндәй булды. Сулышым иркенәйде. Әллә нәрсә эшлисе, зур эш майтарасы, җырлыйсы килә башлады...

— Мин килгәндә бөтен театр җырлый иде. Оркестр искиткеч итеп уйный... Дирижер илһамланып, рухланып оркестр белән идарә итә иде...

Д А Ф А Р. Ә хәзер... теге... тамашачы сызгырган көнне ничегрәк булды?

АРТИСТ. Ул көнне гаять авыр иде. Сәхнәгә чыгасы килми, чыксаң, җырлыйсы килми.

ДАФАР. Сез театрда бер-бер үзгәреш күрмәдегезме соң? Әйтик, ят кешеләр...

АРТИСТ. Ул көнне театрда кешеләр күп иде бит...

ДАФАР. Мин иң беренче көн турында сорыйм... Сезгә, театрга моң һәм илһам килгән көнне әйтәм... Беренче көнне тамаша залы тулы булмагандыр бит...

БАШ ДИРИЖЕР *(нидер хәтерләгәндәй уйланып торгач)*. Ул көнне... иртәнге репетиция башланыр алдыннан бер карт минем янга килеп: рөхсәт итсәгез, мин репетициягезне тыңлап утырыр идем, диде. Мин аңа игътибар итмәдем. Берәр карт музыкантның, яшь чакларын сагынып, репетициядә утыруы гаҗәпмени?!. Шул көнне кичке спектакльгә сигез тамашачы килгән иде. Алар елый-елый безгә рәхмәт укыдылар. Аларга опера шулкадәр ошаган. Менә шул көннән театрга халык агыла башлаган иде...

ДАФАР. Кичен әлеге карт бар идеме?

БАШ ДИРИЖЕР. Бар иде... бар... Ул балкон уртасындагы кәнәфидә утырды бугай... Гаҗәп карт иде ул. Күзләре хәтердә калган. Сихри нур чәчеп торалар иде...

ДАФАР. Кабат сез аны театрда күрмәдегезме?

БАШ ДИРИЖЕР. Күрдем... һәрвакыт шул урында утырыр иде.

ХОРДА ҖЫРЛАУЧЫ КАРЧЫК. Җырлаганда мин дирижер таягына карамыйм да. Таякны мин аны күз кырыем белән дә күрәм. Мин, иптәш капитан, залны күзәтәм. Әлеге бабайны гел балконда күрә идем... Бик матур карт иде ул... Чиккән кәләпүш кигән... Ләкин соңгы көнне ул күренмәде... ие, күренмәде шул... Хәтерлим әле, башланыр алдыннан урта урын буш иде...

Артистка ханым картның килеш-килбәтен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Кабатлап сораштырганда тагын берничә кеше репетициягә, спектакльгә көн саен йөри торган картны күргәннәрен әйттеләр.

Картны эзләп табуы кыен булмады. Чиккән кәләпүш киеп йөрүче чиста картлар күп түгел бит хәзер. Ләкин карт үлем түшәгендә ята иде.

Аны машина бәргән булып чыкты.

— Утызынчы июль көнне китерделәр,— диде кизү врач.— Шул көннән бирле аңына килгәне юк.

«Нәкъ шул көнне аның урыны буш булган!» — дип уйлады капитан.

Дафар, кадаклап куйгандай, көне-төне авыру янында утырып чыга. Бала гәүдәсе чаклы бәләкәй карт Дафарга иң кадерле, иң якын кеше булып әверелде. Яраланып беткән, җыерчыклы йөзле шушы бабай әчтән илаһи нур белән балкый кебек. Врачлар да, шәфкать туташлары да, Дафар да картның сихри мөлаемлыгын, матурлыгын сизделәр.

— Озак тормас, ахрысы! — диде врач соңгы карау вакытында.

Көннәрнең берендә бабай ыңгырашып куйды. Күзләрен ачты, башта түшәмгә, аннан гаҗәпсенеп Дафарга карады. Бабай кул ишарәсе белән капитанга үзенә таба иелергә кушты. Дафар колагын бабайның иреннәренә якын китерде.

— Улым...— диде карт, чак ишетелерлек итеп.— Әманәтем бар... Мин китәм инде... Сиңа калдырам... Күзләремә кара...

Дафар бабай күзләренә туры карады.

— Менә шулай... балам...— диде бабай.

Бабай күзләренең нуры Дафар күзләренә килеп кадалды, күзләр аша үтеп, нурлар мигә, мидән йөрәккә, хәтта җилекләргә тишеп керә... Күңел сыкрый башлый. Сыкрау илһамга әверелә. Дафар күкрәге киңәйгәнен сизә. Аның тәнендә, миендә, йөрәгендә нindидер куәт арта башлый. Бу — илһам! Илһам әллә нинди олы эшләр башкарырга өнди. Дафарның урамга чыгып йөгерәсе, кычкырып җырлыйсы килә. Күкрәге тулы олы

сөенечен халыкка җиткерергә тели. Ләкин ниндидер эчке тавыш аңа сабыр итәргә, сак булырга куша.

Нурлар Дафарга күчеп бетте. Бабайның ярым ачык калган күзләре җансыз, нурсыз иде инде.

Билгесез бабайны хөрмәтләп татар зиратына җирләделәр. Күпме генә тырышса да, Дафар аның кем икәнен белә алмады. Үзе белән булган сәер хәлне капитан беркемгә дә сөйләмәде.

Дафар көн саен театрга йөри. Ул һәрвакыт балкондагы урта урынга утыра.

Театр ишеге төбендә тагын билет өчен сугыш. Зал тагын шыгрым тулы.

— Сәбәп нәрсәдә соң? — дип сорый ниндидер бер егет күршесеннән.

— Моң! Моң тарта тамашачыны театрга, моң! — дигән җавап ишетелде.

Дафар, сөйләгәннәргә игътибар итмичә генә, кысыла-кысыла эчкә узды.

Икенче кичне театрга килгәндә, шулай уйланып барганда, аны чак кына машина бәреп екмады...

*1971*

## ӘЙТСӘҢ, КОНФЕТ БИРӘМ

Әтием коммунист иде минем... Күрше абый да коммунист иде... Әтием үлде инде... төрмәдә үлде... Күрше абый исән...

Бала идем... Ята идем юрган астында... Чикерткәләр чырлый иде мич артында... Әти белән әни йокламый, пышылдашалар... Җил сызгыра капка ярыгында... Төн шомлы... Әтләр өргәли... Кемдер өй артында йөргән шикелле...

— Бала ятим кала...— ди әтием, тирән көрсенеп.— Столыпин чоры килде илгә, сүз әйтергә түгел, уйларга да куркыныч...

Әнием дәшми... Беләм инде, ул елый. Һәркөн төнлә шулай елый...

Икенче көн иртән күршеләргә иләк сорап кердем.

— Иләккә су тутырдык! — ди күрше абый, үзе елмая.— Йә, егеткәй, сөйләп җибәр, нәрсәләр ди синең атаң, нәрсә эшли өйдә, ниләр яза?.. Конфет бирәм... сөйләсәң...

Конфет тәмле инде үзе...

— Әти бүген Оста Липин турында сөйләде әнигә... Оста Липин безгә килде, ди... Оста Липин абый үзе күренмәде тагы... Балта остасыдыр инде ул...— дидем мин конфетка карый-карый.

— Син акыллы, үскәнем...— диде күрше абый һәм миңа бәләкәй мендәрчек шикелле кызыл конфет бирде...

Суырырга куркып, тиз бетмәсен дип, көне буе әвәләп йөрттем мин ул конфетны. Кесәгә салган идем, ипи валчыкларына, тузанга уралып чыкты, идәнгә төшердем ялгыш, каз мамыгына буялды...

Икенче көнне әтине утыртып алып киткәндә дә конфетым исән иде әле... Әни үкси-үкси елый, мин лычык-лычык итеп пычрак конфет суырам.

Сабый идем... Каян белим соң мин каһәр суккан Столыпинны!

Хәзер үзем әти... Ә күрше абый һаман исән... Авылга кайткан чакларымда күзен терәп, безгә килеп керә.

— Менә,— ди ул миңа.— Син язучы булдың инде, мәкаләләреңне укып барабыз... Карале, мин менә күпме хезмәт иттем халыкка, хөкүмәт-

кә, пенсияне персональныйны бирмәделәр, шул турыда, минем заслугалар турында язып чыксаң иде...

Түзәлмадым... Сикереп тордым, кычкырдым... Күзләремне кан басты... Төкерекләрем чәчелде... Үз тавышымны үзем танымадым... Мин барысын да әйтеп салдым аңа...

— Миңа боердылар... чоры шундый иде...— дисең... Кандала син! Затсыз Җаһил! Ялганлыйсың!

Кушмадылар сиңа! Гаепләмә үткән заманны!

Ахмак замана ахмак кешеләрне тудырмый, киресенчә, ахмаклар тудыра ахмак замананы!

Кызыл комач арасына яшермә куркак җаныңны!

Әтием коммунист иде... Син дә... Әткәм уен синнән яшерсә дә, фикерләрен аның аңладың... Мин яшерми әйтәм уйларымны... конфетың үзеңә булсын! Үзең суыр... Фикеребез бер безнең атам белән!

Син коммунист түгел!

*1963*

## УЯНУ

Көне-төне буран дулый...

Самолетлар очмый...

Вокзалда халык дыкма-дык. Атна буена куна-төнә яталар. Чит кешеләр бер-берләренә күптәнге танышлардай якынаеп бетеләр.

Инде әнә барысы да изелеп йоклый... Яшь ана күкрәгән кульяулыгы белән каплап, баласын имезә. Бала, оятны-нине белмичә, шәп-шәрә ботларын селки-селки йотлыгып сөт имә. Ана, ике бармагы белән күкрәген йомшата-йомшата, балага имәргә булыша.

Кара-каршы бер егет белән бер кыз утыра. Алар нишләптер йокламый. Сөйләшмиләр дә. Үзләре бер-берләренә карарга куркалар шикелле. Читкә караган килеш, кыз — егет турында, егет кыз турында уйлый.

Кинәт аларның күзләре очрашты...

Егет тәне буйлап кырмыскалар йөгереп узды, йөрәге деңке-деңке тибә...

Кызның күкрәк очын нииндидер аңа билгесез хис чеметеп алды. Егет аның тыгыз күкрәкләренең еш-еш калкынганлыгын сизде. Күзләр берберен эчә... Инде күзләр оялмый, күзләр бер-берләренә чумган.

Кыз да күңеле белән егеткә тартыла... Егет тә аңа тартыла... Ләкин икесе дә сүз башларга кыймыйлар.

Егет кыз гәүдәсен күзләре аша, киемнәре аша күрә...

Кызның күзләрен эчеп туйгач, егет карашы белән аның чәчләрен сыйпап-назлап узды. Кызның колак очлары алсуланган. Караш күкрәк турысында озак кына тоткарланып торды. Бәйләгән кофта аша күз бораулары кызның күкрәк төерләренә кереп кадалды: баягы билгесез, аңа таныш булмаган тойгы кызның йөрәген тагын чеметте, кыз куырылып куйды. Кыз түзә алмады, битен учлары белән каплап, кресло култыксасына башын салды да күзләрен йомды... Ләкин ул йокламый иде... Ул чак сизелерлек калтырый, эчке тарсыну белән ояла, әмма чиксез ләззәт татый.

Егет кызның хәлен аңлый. Егет үзе дә илаһи тәм татый иде.
Ләззәтне йокы рәхәте алыштырды. Егет төш күрде.
Егет уянды. Кыз утырган кәнәфи бушаган.
Самолетлар оча башлаган иде инде.
Күршедәге әби егеткә:
— Хатыныңмы ул, сеңелеңме, сине уятырга теләмичә озак кына карап торды, аннан маңгаеңнан үпте дә самолетка китеп барды,— диде.
Егет бер мизгелдә никадәр ләззәтнең, матурлыкның табылып җитмичә үк юкка чыгуын тойды...

*1969*

## ЯӘҖҮҖ—МӘӘҖҮҖ

Сабый чактан ук аны җен-албасты-шайтаннар,— яәҗүҗ-мәәҗүҗләр, убырлар, аждаһалар, өрәкләр белән куркытып үстерделәр. Бигрәк тә төн җиткәч йөрәгенә курку төшә, аңа һәр җирдә җен-пәри поскандыр төсле, һәр шәүлә аждаһа булып күренә башлый, һәр кыштырдау шайтан кебек тоела. Шуның аркасында ул, үсә төшкәч тә, төннәрен тышка чыгарга шүрләп, өйдә чиләк тота иде. Бу турыда сеңелесе дус кызына сөйләгән: имеш, аның абыйсы куркак, төнлә чиләккә утыра, дигән. Дус кызы моны башкаларга җиткергән, шулай итеп, аңа Чиләкбай кушаматы тагылып калды.

Үскән саен караңгыдан курку арта барды. Утызны тутырып килүенә карамастан, ул һаман шүрли. Университет бетерде. Тарих укытып маташа. Диссертация яза. Мәшәкатьләре муеннан югыйсә. Башкалар төнлә дә яза, эшли. Ә Чиләкбай алар кебек төнлә эшли алмый шул. Караңгы төшү белән шым була. Ялгызы бер бүлмәдә яшәп, коты алынып беткән инде. Кич җиттеме, эштән кайта да баштанаяк юрган бөркәнеп ята, тәне буе калтырап чыга; краннан су тамса да, аңа җен эше кебек, кибеп-бирткән беткән сайгак-идән шыгырдаса да, кемдер йөри сыман тоела. Акылы белән ул җен-пәриләр юклыгына да ышана, ләкин канга сеңгән курку-өркү-сагаю үз эшен башкара. Врачка барыр иде — оят. Утыз яшьлек ир кеше, бия егардай егет, җеннән куркам, дип әйтә алмый бит инде. Чыннан да, ул өрәкләрдән, җеннәрдән түгел, аңлатып бирә алмаслык билгесез нәрсәдән курка бугай. Кеше талаучыларданмы, йорт басучылардан мы — үзе дә әйтә алмый. Алай дисәң, ул бишенче катта тора. Уң як күршесе — чекист, органнарда эшли. Кем әйтмешли, аны үз милициясе саклый! Сул як күршесе — бандит. Мәгълүм булганча, юлбасарлар үз күршеләрен таламый. Аннан соң Чиләкбай аның белән яхшы мөгамәләдә. Ул яктан куркыныч юк. Шулай да нәрсәдән шүрли соң Чиләкбай?

Ничә мәртәбә ул, куркуының сәбәпләрен ачып, фәнни нигездә дәваланып карады. Ләкин барыбер очына чыга алмады. Эчтә, күңелдә, канда, гадәттә, нәселдә ул курку. Күңелендә нидер пышылдый кебек: сине алда бәла көтә, аңлатып биргесез кайгы сагалый сине, син һәлакәткә дучар, син харап булачаксың!

Кайдандыр ерактан килә бу тавыш. Тора-бара ул бу халәтенәияләнә башлады. Шулкадәр күнекте ки, хәтта әлеге билгесез куркынычның тизрәк килүен тели башлады. Билгесезлектә интеккәнче, килсен иде ул җен, албасты, Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ, башкисәр. Килсен иде дә әйтсен иде: «Менә, Чиләкбай, ниһаять, мин килдем, әйдә, киттек!» — дисен иде.

Нинди кыяфәттә булыр икән ул? Ак кәфен бөркәнгән яки чалгы тоткан булырмы? Пистолет-пычак тоткан булырмы? Әй, барыбер түгелмени! Яманлык яшел булса да, көрән булса да, кызыл булса да — җен булса да, яхшылык эшләргә килгән кеше сыйфатында булса да барыбер түгелмени соң? Тизрәк килсен генә.

Чыпчык котырса, ябалакка ташлана, ди. Чиләкбай да Аны көтә. Көтә-көтә көтек булды, тизрәк күрәсе иде шул Куркынычны!

Ләкин Куркыныч барыбер килмәде. Чиләкбай инде күптән фән докторы булды. Гыйлем тавына менеп җитте. Инде саклык белән генә таудан төшә дә башлады. Ләкин Ул һаман күренмәде.

Шулай бервакыт Чиләкбай эштән арып кайтты. Арымаслыкмыни?! Кафедра мөнбәреннән торып, үзе уйлаганның нәкъ киресенә ышандырырга тырыша-тырыша, йөзләгән яшьләргә нотык сөйләде бит. Шулкадәр арыган иде Чиләкбай, хәтта гомер юлдашы — теге Куркыныч турында да онытып җибәргән иде. Ул үзе дә белештермичә ут кабызды, ишек катына юынырга китте. Бер уч су алып битенә сирпегән генә иде, арка ягындагы бүлмәдә җиңелчә кыштырдау, шыгырдау ишетелде! Чиләкбай тораташ булып катты калды. Аннан соң бүлмәдә ниндидер гөрелте ишетелә башлады, шуннан соң кемдер:

— Кая яшергәнеңне әйт, дуңгыз! — дип кычкырды.

Чиләкбайның теле әйләнмәде, борылырга теләде, гәүдәсе тыңламады.

— Ишеттеңме, такырбаш, кая яшердең? — дип кабатладылар арттан.

— Нә-әрсә-ә кирә-әк сезгә? — диде Чиләкбай.

— Боргаланма, безгә ни кирәген син яхшы беләсең! Җә!

— Минем бернәрсәм дә юк! — диде Чиләкбай.

— Җә! — дип акырды әлеге зат.

Чиләкбай тагын нидер әйтергә теләгән иде, ләкин аның өчен кемдер сөйләшә башлады.

— Алыгыз, кабахәтләр, алыгыз! Эскерт астында, талагыз! — дип кычкырды берәү.

Шуннан соң ниндидер ыгы-зыгы башланды. Музыка үкерергә тотынды, Чиләкбай эшне сизенеп, кинәт борылды да бүлмәгә керде. Куркыныч урынына ул телевизор экранын күрде: экранда беләгенә тасма бәйләгән кешеләр печән кибәнен актаралар иде.

Чиләкбай кайтып кергәч, үтеп киткәндә, үзе дә белештермичә, телевизорны кабызганлыгын хәтерләде...

— Талагыз, кабахәтләр, талагыз! — дип кычкыра кибән хуҗасы.

Тасмалылар кибән астыннан биш-алты капчык чыгардылар да «талагыз» дип кычкырган кешене кибәненә терәп аттылар. Кибән хуҗасына аткан ядрә... Чиләкбайга килеп тиде. Чиләкбайның төсе качкан иде, ул, авып китмәс өчен, ишек яңагына сөялде, аяклары сыгылып китте.

Чиләкбай, тыны чыгып шиңә башлаган куык-шар кебек, салмак кына идәнгә шәлперәде.

... Уйнаучы бала,— әллә дөнья үзе булдымы — ишек янында яткан тишек шарны, җирәнеп кенә, ике бармагы белән тотып, чүплеккә чыгарып ташлады да яңа шар белән уйнарга тотынды...

*1972*

Туган апам!

Ниһаять, мин үземне бәхетле саныйм. Егерме яшемнән алып көткән бәхет бүген килде. Мин яңа йортка күчтем. Хәтерлисеңме, мин сиңа язган идем, бер ун-унбиш еллар бардыр, безнең шәһәрдә биш катлы йорт төзелә башлаган гына иде әле ул чакта. Их, әгәр дә шул йортның бишенче катыннан миңа бүлмә бирсәләр, бәхетле булыр идем, дип хыяллана идем. Йорт төзелеп бетте, мин бәхетле була алмадым. Ихтимал, син мине аңламассың, апам, ләкин ошбу хатны язарга мәҗбүрмен, чөнки минем хатны берәү дә укымас, укыса да аңламас иде, аңласа — дәшмәс иде. Бәлкем син, апам, мине аңларсың, дип өметләнәм. Миңа төрле җирдән фатир биреп карадылар, бирсенә дә күчә алмадым. Үз теләгәнемне көттем. Беләсең бит, апа, минем биеклекне яратканымны. Бәләкәй чакта да мин гел, кыр кәҗәсе кебек, тау башында йөрер идем, иң биек агачка менәр идем. Бала чактагы бу гадәтемне һич ташлый алмадым. Инде балигъ булгач, калага күчкәч тә гел биеклеккә үрли башладым. Биек йорт салсалар, их, иң югары катыннан миңа бер бүлмә бирсәләр, дип куя торган идем. Биш катлыны төзеделәр, Шварцман белән Захаренкога бирделәр, миңа эләкмәде. Тугыз катлыны җиткерделәр, Сидорова белән Иванова күченде, мин коры калдым. Ничә еллар узды, мин һаман бер әбинең чоланында яши килдем. Шуннан соң мин кран йөртүчелеккә укыдым, кранчы булдым. Һәй, апа, кранга менгәндәге рәхәтлекне белсәң иде, баскыч саен күңел кытыклана, кулларны, аякларны җибәреп, ычкынып-очып китәсе килә башлый. Ләкин кран биеклеге генә мине канәгатьләндерми шул. Инде һич булмагач, Сөембикә манарасына мендем. Их, апа, шулвакытта нинди хисләр биләгәнне белсәң иде. Һәр баскыч саен күз алдында бер тәрә арта, тәрә арткан саен бер чиркәү арта, чиркәү арткан саен өскә менү кыенлаша бара. Төтен болыты каплаган Бишбалтаны, сөрем кунган Яңабистәне күреп, күзгә яшь килә, ми томанлана. Башым әйләнеп, егыла яздым. Әгәр дә мин шулчакта, баш әйләнеп, егылып төшеп һәлак булсам, ни булыр иде икән, апа? Манара чайкала да чайкала, Казан каласы янтая да янтая, ләкин, ни гаҗәп, мин егылмадым. Егылып төшсәм, төрле гайбәт, имеш-мимешкә юл калыр иде. Егете алдаган, шуңа күрә сикергән, дип сөйләүчеләр табылыр иде. Мескен хатын-кыз. Бүгенге заманда егете алдаганга түбәдән сикергән кызның никадәр мескен, сай акыллы, чүпрәк икәнен күреп, мин эчем катып көләм генә. Үз ризалыгың белән яткансың икән, ничу егет халкына суд аша тагылып йөрергә. Әгәр дә мин Сөембикә манарасыннан егылып төшеп үлгән булсам, ихтимал, икенче берәүләр «Замана Сөембикәсе» дигән бәет чыгарырлар иде. Юк шул, мин беркайчан да Сөембикә манарасыннан сикермәмен! Моңа ике сәбәп бар. Сөембикәне урысларга әсир төшерәсе килмичә, халык аны манарадан ташланып үлгән, дип сөйли. Бәс, халык шундый риваять сөйли икән, нигә әле мин шул риваятьне бозып, тагын икенче бер Сөембикә ясыйм, ди.

Мин моннан унбиш ел элек уйлап куйдым инде . Юк, краннан та, манарадан да сикермәячәкмен. Мин шәһәрнең иң биек йортының иң өске катыннан, үзем яши торган балконнан ташланачакмын!

Менә быел миңа ундүрт катлы йортның соңгы катыннан бүлмә бирделәр. Моннан да биек йорт та, башка бер бина да юк калабызда. Һәм булмаячак та. Инде бу мин көткән биеклекнең иң югары ноктасы, апам. Бүген күчендем. Ваннасына кереп юындым. Чиста киемнәремне кидем. Өйне җыештырдым, утка, фатирга бер елга алдан түләп куйдым, бирәсе бурычларымны биреп бетердем. Бик тәмләп, каты итеп мәтрүшкәле чәй эчтем дә сиңа хат язам. Бу минем соңгы эшем булыр. Шушы хатны язып бетерәм дә, аллага тапшырам! Апам, зинһар, ачуланма, шулай кирәк! Мин бәхетлемен, яхшы фатирымның кыйблага карап тор-

ган балконыннан яшел күлмәк очып төшеп киткән кебек булыр! Юк шул, апам, күлмәк кенә булмас, шул күлмәк эчендә мин дә бар!

И мескен, и бәхетсез бала, дип мине кызганма. Бәхетсез кешеләр генә асылынып, суга батып яки кыектан сикереп үлә торган булсалар, дөнья тулы бәхетлеләр генә шырык-шырык көлеп йөрерләр иде. Юк бит!

Шулай булгач, бары тик бәхетлеләр генә үлә булып чыга. Гомер буе бәхет көтә-көтә картаеп үләләр андыйлар, апа. Әгәр бәхет килсә, шундук егылып үләрләр иде. Шулай булгач, син бу хәбәрне алгач һич тә хафаланма.

Хуш, апам, бәхил бул! Теге дөньяда очрашырга язмасын! Әгәр дә очрашабыз икән, димәк, теге дөнья бар, дигән сүз. Әгәр теге дөнья бар икән, ул чакта инде дөньядан китәсең килсә дә, кыектан сикереп кенә котылып булмас...

Сеңлең Хаят булыр.

*1972*

## ТАШ БАСКЫЧЛАР БУЙЛАП МЕНГӘНДӘ...

Матбугат йорты баскычлары буйлап язучылар, журналистлар, редакция хезмәткәрләре тыз да быз чабып йөри. Кемдер:

— Җыелышны башлыйбыз, өске катка менегез, иптәшләр! — дип кычкырды.

Баскыч янына җыелган язучылар шаулаша-шаулаша өскә менә башладылар.

Култыксага таянган килеш баскыч бусагаларын күзәтәм.

Күпме шагыйрь таптады икән бу күтәрмәләрне! Көнлекче шагыйрьне дә, исеме баш хәреф белән язылырга тиешле бөек шагыйрьне дә — кемнең кем булуына карамастан — бу тупсалар кешеләрне әле өскә менгергәннәр, әле аска тәгәрәтеп төшергәннәр.

Исән чакта шөһрәт эчендә кайнаган шагыйрь дә шушы тупсага басып менгәндер. Үзе үлгән көнне үк аның шигырьләре дә вафат булганнар. Бу баскычлар аның эзен хәтерләми.

Исән чакта читкә тибәрелгән шагыйрьнең әсәрләре дә шушы баскычлар буйлап яңадан өскә күтәрелгәндер. Үлгәч яши башлаган ул Шагыйрь. Баскычлар аның эзен күкрәкләрендә уеп саклый.

Исән чакта да, үлгәч тә сүгелми-макталмый торган өченче төр шагыйрьләр дә шушы ук баскычларга басып йөри.

Давыллар, гарасатлар булды бу Җиһанда.

Давылларга каршы давыл булып чыкты олуг Шагыйрь.

Актарылды, кыйналды олуг Шагыйрь. Ләкин сынмады.

Шагыйрьләрнең күбесен йотты упкын, күбесен сыкты тормыш, күбесен талкыдылар, күбесен саттылар дуслары.

Еламыйм мин аларны искә төшергәндә, гәрчә хөрмәт итсәм дә. Чөнки Каф тавыдай мәгърур басып калган әсәрләрен яттан беләм.

Мәрхүм шагыйрьләрне исән чакларында күрү миңа насыйп булмады. Мин аларның шигырьләрен укып җылыйм. Исән калган олуг Шагыйрьнең үзен күргәч, күңелем тула. Дымлы күзләрем күрсәтмәс өчен, мин Шагыйрь алдында башым иям.

Язучылар төркеме инде күптән өске катка менеп җиткәндер, дип уйлыйм.

Карт Шагыйрь баскыч култыксасына тотынган килеш берүзе артта калган... Бигрәк таушалган шул. Яз көне булса да, йончылган, бетерешкән, көчкә-көчкә менә баскычтан. Шагыйрьгә ярдәм итмәкче булып,

терсәгеннән тотам. Ютәл аша көлә Шагыйрь һәм ишарә белән ярдәм кирәк түгеллеген әйтә.

«Күтәрәмгә калган Шагыйрь булмас!» — дип уйлыйм.

Бераз сулу алгач, Шагыйрь тагын бер баскыч өскә атлый. Мин аның белән янәшә барам.

Каршыбызга шигырь язгалаучы бер кеше очрады. Бу адәмне мин һәрвакыт матбугатта очратам. Ул кызу-кызу аска төшеп бара. Ә без карт Шагыйрь белән баскыч саен туктый-туктый өскә менәбез. Безнең яннан үткәндә әлеге кеше кыйммәтле коньяк һәм кыздырылган дуңгыз ите исе бөркеп китте. Тук, бераз кызмача, кәефле кешенең канәгать чыраен күреп, җен ачуым чыкты. Рәхәт яши, дип уйладым, язган бер әйбере калын-калын китап булып басылып бара. Тиргәүче юк аны, хәер, мактаучы да юк. Ашый-эчә, бәлки, без кочасы кызларны да коча торгандыр әле.

Әллә мин аннан көнләшәмме соң? Үзем дә аның кебек дөньяның арткаена тибеп яши алмаганга көнләшәмме?

Тәүбә, тәүбә! Ашарга әпәкәем бар, эчәргә шәрабым җитәрлек. Тик нишләптер шул адәмгә кушыласым килми.

Икенче катка менгәч, Шагыйрь тәрәзә борысына сөялде. Урамда яз яңгыры коеп түгә. Шагыйрь дә, мин дә меңләгән тамчыларны күзәтәбез.

— Бөҗәкләр яңгыр вакытында гөмбә калфагы яки әрекмән астына качып котылалар,— диде Шагыйрь үзалдына сөйләнгәндәй.— Җил-яңгыр уздымы, поскан җирләреннән чыгалар да дөнья бетереп безелди башлыйлар...

Тагын кузгалабыз...

Карт шагыйрьгә ияреп, өске катка менеп барам.

Ул миңа әйтә:

— Беләсеңме, энем,— ди.— Мин какшадым инде... Дөнья битенә караганда, сыртын күбрәк күрсәтте миңа... Шулай да мин уйлыйм әле... Дөньяга яхшы кешеләр күбрәк туа... Дөнья яралганнан бирле яхшы кешеләрне кыерсытканнар, эзәрлекләгәннәр. Үтергәннәр... Джордано Бруно... Галилей... Линкольн... Пушкин... Тукай... Ибраһимов... Җәлил... Әмма тормыш бара... Халык үлми... Мәхәббәт торып кала... Дөньяга яңа Тукайлар, Ибраһимовлар өстәлә тора...

Шулчак башка бер шагыйрьнең әйткән сүзләре кылт итеп исемә төште:

— Яңа буын шагыйрьләрен көтә.

Җәлилләрдән бушап төрмәләр,— дигән иде ул.

— ...яхшы кешеләр күп,— дип дәвам итә Шагыйрь.

— Шулай да бит Җәлил юк, Ибраһимов юк...

— Яхшы кешеләрнең яхшылыклары йоклаганга юк алар, энем... Яхшылыгы йоклаган кешене гамьсез, битараф, ваемсыз, куркак кеше, диләр... Мәкер йокламый. Мәкер тәвәккәл, мәкер ашыга... Мәкер әле һаман почмак сагалый, тәрәз шакый кара төндә, донос яза... Мәкер Яхшылык кыяфәтенә кереп, кеше күңеленең иң түренә менеп утыра ала... Мәкер Яхшылык чикмәнен бөркәнеп, ата-бабаңа хәнҗәр күтәрергә өнди. Ә бит Яхшылык икейөзле була алмый... Йоклаган яхшылык — мәкернең юлдашы. Уятырга кирәк аны.

Кыяфәтем минем таза — арысландай. Шагыйрь ябык, бәләкәйләнеп калган. Тик шулай да Шагыйрь алдында үземне арыслан янындагы песи баласы сыман хис иттем.

Шулчак өч баскычны бер атлап, йөгерә-йөгерә теге шагыйрь кисәге безне узып китте.

— Тизрәк менегез! — дип кычкырды ул безгә.— Җыелыш башланды инде.

Карт Шагыйрь тагын өскә таба атлый.

Мин аның белән янәшә барам. Өске катка менеп җитәргә бик күп баскыч бусагаларын үтәсе бар шул әле...

*1966*

**Тәлгат Галиуллин**

# ҮТКӘНЕҢНӘН ГЫЙБРӘТ АЛ...

Мөмкинлек бирелгәнне көтеп кенә торгандай, татар язучылары тарихка кереп-китте, үткәннең онытылып торган, югала барган буыннарын ашыга-ашыга укучыга ирештерә башлады. Бу табигый омтылыш иде. Чөнки М. Галәү, Н. Исәнбәт, Ә. Фәйзи, М. Җәлилнең кайбер әсәрләрен санамаганда, безнең элегрәк язылган һәм «тарихи» дип аталган әйберләребезнең төбендә 1917 ел һәм аннан соң килгән вакыйга-хәлләр генә ятты.

Тарихи роман жанрына Н. Фәттах белән М. Хәбибуллин яңа рух өреп, татар тарихының башы бик еракта икәнен — халкыбызның заманында көчле дәүләтләргә ия, бихисап олы шәхесләр биргән, бик борынгы милләтләрнең берсе икәнлеген искәрттеләр. Хәзер тарихи темага алынмаган, үткәннән гыйбрәт алмаган язучы сирәк, Кубрат хан, Сөембикә, Колшәрифләр янына Батырша, Солтангалиев кебек мөхтәрәм исемнәр өстәлә тора. Әйе, татар халкы олы һәм фаҗигале тарихи юлында бик күп зыялыларын, батыр улларын югалткан. Күбесе эзсез югалган. Без аларны чынлап барламыйбыз, диярлек.

Без — үз милли тарихыбыздан мәхрүм ителеп, Болотников, Разин, Пугачев кебек, башка халык пәһлеваннарын мактаган китапларда тәрбия алган буын. Злобин, Чапыгин, Шишков кебек язучылар каләменнән төшкән романнарда, юл уңаенда гына, әлеге крәстиән кузгалышларында, татар, башкорт, чуваш кебек «инородецлар»ның катнашуы, фетнә җитәкчеләренең аларга үз телләрендә мөрәҗәгать-чакырулар язулары турында әйтелә. Табигый ки, бу «вак-төяк» халыклар патша хәзрәтләренә каршы мөстәкыйль чыгыш ясау дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган. Дөрес, Пугачев эзләп тапкан һәм үстергән Салават Юлаев, Бәхтияр Канкаевлар булган. Мәгәр алар да кушканны, әмерне кыю башкаручы буларак кына тасвирлана.

Елдан-ел тулырак ачыла барган тарих көзгесе империянең кыл уртасында калган татар халкының коточкыч изүгә, көчләп чукындыруга каршы туктаусыз күтәрелеп, сугышып, көрәшеп яшәвен күрсәтә. Бер гасырны гына алыйк: 1704—1708 елларда Алдар-Күчем җитәкчелегендә җитди чуалышлар булып ала. 1735—1741 дә Акай батыр халыкны көрәш юлына алып чыга. 1744 елда Тирсә авылында чукынган, явыз алпавыт Тәфкилевкә каршы бунт күтәрелә. Бераз соңрак, әмма шул ук гасыр уртасында (1755—1756) Батырша Алиев Уфа, Оренбург, Казан губерналарына шом сала... Башка халыкта шулчаклы батырлар булса, аларның образлары сәнгатьтә күптәннән мәңгеләштерелер иде.

Иншалла, татар халкының бер батырына әдәби һәйкәл куелды. 1992 елда Җәмит Рәхимовның «Батырша» исемле романы дөнья күрде.

Белүемчә, Батырша яшәгән тарихи чорны язучы бик күптәннән өйрәнеп килә. Язылган өлеше белән укучыны вакытлы матбугат та таныштыра килде.

«Батырша» әсәре тулаем алганда, XVIII гасырның дөньяви, дини, әхлакый атмосферасын, татар халкының баш-аягы фаҗига белән тулы аяныч язмышын төгәл күзәтүләр, ачык буяулар аша күрсәтүгә багышланган. Шул тынчу хәятта үз

урынын таба алмыйча җәфаланган, олы йөрәкле, шагыйрь җанлы шәхес тормышын ышандырырлык итеп күз алдына бастырган ул.

Карыш авылының мишәр мулласы гаиләсендә туган Габдулла — авыл малае, әмма ул яшьтәшләреннән һәрнәрсәнең төбенә, нигезенә төшәргә омтылуы, һәммә күренештә эчке мәгънә эзләве, вакыйга-хәлләрне тудырган тирәлекнең үзен тикшерергә яратуы белән аерылып тора. Тынгы белмәс холкы, аң-белемгә омтылуы аны Ташсуган, Ташкичү кебек шул чорның күренекле мәдрәсәләренә алып килә. Мөгаллимнәре дә — чорның алдынгы шәхесләре. Үзе дә катнаш губерналарның танылган мулласы, мөдәррисе, изге әүлия дәрәҗәсенә күтәрелә. Даны, мал-мөлкәте, хөрмәте җитәрлек, рәхәтләнеп бәлешен ашап, мунчасын кереп, дини-схоластик бәхәсләрдән тәм табып яши бир дә бит, әмма юк: гадел холкы, тирә-юньдәге рәхимсез җәбер-җәфаны күргән үткен күзе, сизгер җаны аны көрәш юлына алып чыга. Табигый, күпчелек адәм баласына тыныч тормыш кирәк. Бик азлары гына рәхәт, татлы, баллы нигъмәтләрдән баш тартып, фаҗигале юлга чыга. Соңгысын сайлаган шәхесләр — көчлеләр. Батырша шундыйлардан.

1755 елның яз айларында ул үзенең атаклы мөрәҗәгатьләрен язып тарата. Бу хатларның иҗат ителү күренешен автор тәфсилләп тасвирлый. Батырша үткен, туры сүзгә ышана, татар, башкорт һәм башка изелгән милләтләрне дини әләм астында гына күтәреп буласын аңлап эш итә. Анда да, ул тулаем урысларга каршы орышка чакырмый. Аның дошманы — йомышлы һәм гаскәри урыслар, көчләп чукындыру эшен рәхимсез алып барган Лука Каратуннар.

Батырша үз чоры кешесе буларак, гадел патшага ышана һәм Елизавета Петровнага шактый күләмле хат белән мөрәҗәгать итә. Әмма ул хат сенат һәм канцелярия түрәләре кулында югалып кала. Романда хатның эчтәлеге шактый тулы яктыртыла, авторның хокук, инсафлык, кешелеклелек мәсьәләләрен тирәнтен аңлавына игътибар ителә. Батырша үз язмышы, милләттәшләре турында сөйли, ярдәм, аңлау көтә.

Шулай да, Батырша — чирү башлыгы һәм сугышчы түгел. Елан-Эткол аңа дөрес әйтә: «Юк инде, Батырша, юкка тел кашудан туйды халаеклар. Без иртәгедән кузгалабыз! Әйдәгез!» Үзе кабызган утны дөрләтәсе, көчәйтәсе урынга, Батырша восстаниегә күтәрелгән фикердәшләрен ташлап, берничә шәкерте белән урманга кача, табигый ки, тотыла һәм Шлиссельбург атавындагы төрмәгә озатыла, биш елын шунда үткәрә, соңгы батырлыгын шунда эшли.

Батырша — гыйсъянчы йөрәкле, «байроник» каһарман, холкы, кабатланмас фигыле булган үзенчәлекле шәхес. Язучы, аңлы рәвештә, аны тормыш-көнкүреш ваклыкларыннан азат итә, язмышы өчен хәлиткеч якларны гына сурәтли. Үзәктә: әхлакый сафлык, дини хөрриятә бирелгәнлек.

Батырша — олы максатлар куеп (татарның дәүләтен кайтару кебек), аңлы рәвештә көрәшкә күтәрелгән пәрвәр түгел. Аны тынгысыз җаны үзе артыннан сөйри, акыл-зиһен куәте, дини гаделлеккә табынуы көрәшкә күтәрелә. Кемгәдер шәхси үпкәсе дә бар аның. Бу тойгының да кешелек җәмгыяте үсешендә мөһим урын тотуын онытырга ярамый. Батыршаның соңгы бәхете — аның фаҗигасендә. Ул — балта белән «җансакчыларының» башларын хәл кылып, үзенең җирдәге тормышын каһарманнарча төгәлли. Шуңа аңлы рәвештә бара ул. Оҗмахта алма капкан борынгы бабабыз төсле, Батырша да үз холкына турылыклы кала, бәзда сөрсеп үлми, сугышып, аягүрә җан тәслим кыла.

Тәнендә чәнечкеле агач кадалгач, бердәнбер һәм соңгы илаһи җырын башкарган мифик кош шикелле, Батырша да үзенә бирелгән кушаматын аклап үлә.

Галимнәр, тарихчылар Батырша язмышына күптәннән игътибар итә иделәр. Профессор М. Н. Гернет «Патша төрмәсе» исемле хезмәтендә Батыршаның төрмә сакчылары белән сугышып үлүен романнарга лаеклы батырлык, дип атый.

Башкорт галиме Г. Хөсәенов («Татар әдәбияты тарихы», I том) Батырша хатларын әдәби әсәрләр буларак өйрәнә, төпле анализ ясый.

Янәдән романга кайтып, аның берничә сыйфатына игътибарны юнәлтәсе килә. Батырша гаделлек өчен көрәшендә берүзе түгел. Аның авазы шактый кешене яуга күтәрә. Көчекбай, Елан-Эткол, Яубасар кебек кыю, сәләтле алайлар үсеп чыга. Батыр тимерче Әмин белән Асылбикә арасындагы мәхәббәт, гүзәл ханымның үлеме, аны күмү Көнчыгыш әдәбиятының романтик өлгеләре матурлыгында эшләнгән.

Дошманны ангыра һәм ахмак итеп сурәтләү алымыннан да баш тарта Җ. Рәхимов. Оренбург губернаторы Неплюевны язучы рәхимсез, әмма акыллы, алдан күрүчән хаким итеп тасвирлый. «Чукындыру ул — кешенең телен, гореф-гадәтләрен, иманын үзгәртү, аның күңелен яулап алу. Көч куллану белән үзеңне

хатын-кыздан яраттыра алмаган кебек, бу эштә дә тупаслык белән әллә ни кырып булмас»,— дип өйрәтә ул яраннарын.

Татар белән башкортны ызгыштыру, икесен дә кыргыз-кайсаклар белән талаштыру турында хыяллана Неплюев. Ул халыкларны буйсындырып тоту өчен телләрен өйрәнү, вак-төяк реформалар эшләү ягында.

Тугандаш халыклар арасындагы дуслыкка чөй кагу — патша империясенең зур мәкерлекләреннән иде. Җ. Рәхимов Батыршаның халыкка мөрәҗәгатеннән шундый өзек китерә: ***«... урыс түрәләре Уфа өязендәге һәр дүрт юл халкының кыргыз-кайсаклар белән дуслашуыннан, аларның бергәләп баш күтәрүеннән куркалар... Исегездә тотыгыз, йомышлы урыслар безне көннән-көн кыса барып, кыргыз-кайсаклар белән дошманлаштырып, үзара кан түктереп, ике арабызда булган татулыкны һәм килешүне бозарга телиләр».***

«Әй Батырша, Батырша,— дип дәвам итә безнең чор язучысы.— Хатынның губернатор Неплюев кулына барып ирешәсен, шушы юлларны укыганнан соң аның казакъларны башкортларга, ә соңгыларын беренчеләренә каршы котыртып, кан кардәш ике халык арасында сүеш-кырылыш чыгарачагын, шул ук этлекне татарлар белән башкортлар арасын бозуда да кулланасын белгән булсаң, әлеге җөмләне язмас та идең, шәт».

Юк инде, Неплюевлар үз эшләрен яхшы беләләр. Алар татар мулласының үгет-нәсихәтенә һич кенә дә мохтаҗ кавем түгел.

Ниһаять, Җ. Рәхимов Батыршаның уй-хисләрен, ният-омтылышларын безнең чорга, бүгенге сәяси, икътисадый көрәшебезгә бәйли алган.

***«Ие, мортәтләр һәр заманда булган һәм булып кына тора,— дип фикерли Батырша.— Ул сатлык җаннар турында хак сүзне бәндәләргә җиткерми ярамый. Бит дошман үзе бер куркыныч булса, аның ягына ауган аумакай мортәтләр — биш куркыныч... Чөнки алар иманнарын сатып, дошманга кәнди тоту юлына басканнар. Шуңа да алар куркак, куркак булганга — кансыз. Мортәтләрдән якты чырай түгел, коточкыч кабахәтлек кенә көтәргә кала».***

Ике йөз елдан элегрәк әйтелгән әлеге юлларны Татарстанның бәйсезлегенә кизәнеп яткан маңкорт татар депутатларына укытасы иде дә бит, ана телләрендә укый-яза белмиләр. Ахырзаманның бер тамгасыдыр инде бу күренеш.

«Батырша» — әдәбиятта калырга лаеклы әсәр. Шулай да ул тигез язылмаган. Акрын аккан агым суны хәтерләткән беренче кисәге авыр укыла. Язучы булачак каһарманының яшьлек елларын, төрле-төрле мәдрәсәләрдә укуын артык тәфсилле тасвир кыла. Вакыт бишеге акрын тирбәлә. Әсәр бик үк тирәнгә алып кермәгән сөйләшүләрне, һич тә мәҗбүри булмаган табигать сурәтләрен эченә ала, кыскасы, урыны белән «җирдән шуышып» бара. Иҗатчы мавыктыру чаралары турында күбрәк уйласа, бераз юмор бәбчекләрен дә кертеп җибәрсә, роман җиңелрәк укылыр иде.

Әйтергә кирәк, булачак геройның балалык, яшьлек дәверен озын-озак сурәтләү — татар романының «милли үзенчәлеге», аны күп еллар дәвамында эзәрлекли килгән йогышлы чире.

Ә. Фәйзи Тукай турында берничә китаптан торган әсәр язарга алынып та, шагыйрь тормышының башын бәян итүдән ары китә алмады, гомере җитмәде. Хәсән Туфан язмышы да бу җәһәттән Тукай белән уртак булып чыкты. Г. Кашаф-Үзиленең «Киек каз юлы» романы Туфан гомеренең бик кыска бер өлешен генә үзәккә ала.

Кызганыч ки, Газиз Кашафны рәхимсез үлем арабыздан вакытсыз алып китеп, Туфан турындагы олы әсәрне тәмамларга ирек бирмәде. Беренче китап күләме белән саллы гына булса да, Туфан гомеренең дөньяга килеп, малайлык чорларын үтүе һәм үсмер булып житеп, беренче мәхәббәт ләззәтен татуы, әзисе Сәгыйть белән читкә, «Галия» мәдрәсәсенә чыгып китүен тасвирлау белән тәмамлана. Роман укыла. Һәрхәлдә соңгы елларда кульязма хәлендә мин танышкан «производство» романнарыннан күп өстен тора. Г. Кашафның соңгы бүләге бу. Кешелекле моң, үзәккә алынган шәхескә булган җылы мөнәсәбәт, халыкның 1917 елга чаклы тормыш-көнкүрешен күзаллау һәм сурәтләү ышандыра, күңелдә кала.

Язучы Хәсәнне гаилә, көнкүреш ваклыклары эчендә генә күрсәтү юлына төшмичә, бер яктан: сабан туйларын, яшен ату кебек табигатьнең иләсләнгән чакларын, ат каракları тормышын, ягъни халыкның яшәеш рәвешен тасвирлауга мөһим өлеш чыгарса, икенчедән: аны татар тарихы борчый, уйландыра (татар халкының Аксубай якларына күчеп килүе, көчләп чукындыру галәмәтләре, янәдән мөселман диненә кайту, яшәү өчен көрәш, күрше боярлар, жандармнар

белән әвәрә килүләр һ. б.). Аксу җирләренә орынып утырган Биләр, Болгар тарихларын аңларга, үткәнне халыкның бүгенге омтылыш-ниятләре белән бәйләп, берүк чылбыр бөҗралары итеп күзалларга омтылу уңай тәэсир калдыра. Татар халкын изү, рәнҗетү, кешегә санамау киек каз юлы кебек, китап буйлап үтә. Милләтнең көчле шәхесләре гомер-гомергә баш бирмичә яшәгәннәр, шул юлда корбан булганнар. Халыкның холкы, характеры үзгәрү, рухи, әхлакый сыйфатлары ачыла килү Фәхри-Таһир образында җентекләнә. Хәсәнгә җан биргән кешенең дин, тел, тарих турында уйланулары кызыклы. Шомчы Козгын Әзгаре, зимагур-алаклар, булачак шагыйрьнең өлкән абыйсы Сәгыйть, дин әһелләре, бигрәк тә Сиражетдин хәзрәт образы күңелдә уелып кала.

Әлбәттә, иҗатчы үзе безне ишетә алса, «тарихи үткәнгә сәяхәтләрне хәзерге фән казанышларын, ачышларын исәпкә алып тирәнәйтәсе, ачыклыйсы бар, чукындырылып та үз диннәренә, деннәренә әйләнеп кайткан авылларның, «отпавшийларның» язмышын тулырак яктыртасы иде...» дигән киңәшне бирер идек. Әсәргә эчке җегәр, зыялылык өстәмәгән озын урыннар да күз алдында (Хәсән апасының кияүгә чыгуы, туй мәшәкатьләре, җизнәсе белән Үзигә килү, бура бурау, еланнар турында артык тәфсилле сурәтләүләр һ. б.).

Әмма хикмәт башкада. Туфан озын гомер кичергән, төрледән-төрле вакыйга-хәлләргә бай язмышлы шагыйрь. Аның язмышы — татар әдәбияты язмышы, XX гасыр фаҗигасе... Г. Кашаф-Үзиле шагыйрьнең сөргенлек эзләреннән йөреп, биографиясенең четрекле буыннарын өйрәнеп, йомгакның очларын барлап кайткан иде. Туфан әлегә әдәбиятта сәләтле, сизгер шигъри җанлы, яшьтәшләреннән өстен, әмма малай булып калды. Кызганыч...

Бер дәвердә туып, бер мохиттә тәрбия алган кешеләрнең бала һәм үсмер чорлары бер-берсенә ике тамчы су төсле охшаш була. Бишекләрнең рәвешләре төрле булса да, шунда шыншып ятканда, Гитлер белән Сталин бер-берсеннән әллә ни аерылып тормаганнардыр, дип фараз кылырга мөмкин. 1917 елга чаклы татар укымышлылары барысы да мәдрәсәдә белем алган, андагы тәртипләр, нигездә, охшаш булган.

Шуңа күрә дә каһарман олы юлга, хәрәкәткә чыккач, язмышы башкалардан үзгә сукмактан киткәч, ягъни ул мөстәкыйль уйлый, олы эшләр белән шөгыльләнә башлагач кына әдәби әсәргә ишекне ачып керергә тиеш. Башка әдәбиятлар тәҗрибәсе шуны дәлилли.

Тарихи роман остасы Ю. Тыняновның «Смерть Вазир-Мухтара» әсәрендә язучы, дипломат Грибоедов тормышының соңгы, җитлеккән еллары шәрехләнсә, шагыйрь, декабрист Вильгельм Кюхельбекер («Кухля» романы) — пансионатны тәмамлап кайткан егет. А. Толстойның «Петр I» әсәренең каһарманы да, китапның беренче өлешендә үк, сугыш уеннары белән мавыга, хакимиятне үз кулына алган апасы белән көрәшкә әзерләнә. Гоголь турында язганда, Радищев язмышын үзәккә алганда, О. Форш язучыларның иләндә үрмәләп йөрүләренә игътибар итми. Безнең әдәбият бу чирдән һич кенә дә арына алмый.

Хәер, Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романында әдәби кануннарны, укучыны күз уңында тотып эшләү сизелә. Мирсәет Солтангалиев тормышының беренче өлеше күбрәк истәлекләр, лирик чигенешләр аша тасвирлана. Безнең алга ул җитлеккән шәхес, нигездә, тормыш максатын, үз халкының һәм аның аша империядә җәбер-золым күргән башка милләтләр язмышын шәхси язмышы аша кабул итү дәрәҗәсенә күтәрелгән кеше булып килеп баса. Дөрес, аңа әле үз фәлсәфәсен тудыру, ил үсешенең киләчәген төгәл итеп күз алдына бастыру өчен, читтән «ярдәм» кирәк. Сталин, Куйбышев, Фрунзеларның милли сәясәттәге пычраклыгы, үз мәнфәгатьләрен, хакимияткә омтылуларын халыклар язмышыннан өстен куюлар — шуларны күреп яшәү һәм эшләү, Солтангалиевнең дә уяулыгын үстерә, зиһенен зирәкләндерә. Гадәти бер революционердан, хатынының сөяркәсен атып йөргән бер гадәти кешедән, фикер иясе дәрәҗәсенә күтәрелә ул.

Әлегә чаклы Сталинның мөкере, вак халыкларга, бигрәк тә ислам динен тотучыларга эчке үч саклап йөрүе, явызлыгын халыклар башына төшерү өчен уңайлы вакыт көтүе, тиздән шул ук палач башларына җитәчәк яраннарның вак карьеристлар, фарисейлар булуы татар әдәбиятында кыю тасвирланганы юк иде әле. Канга сеңгән курку хисе җиңнән тартып килде. «Әгәр берәрсе каберсннән торып басса, яисә рухы белән шул җәлладларга якын кеше ил дилбегәсен үз кулына алса» кебек хорафатлар иҗатны кысып килде. «Сират күпере»нең сурәтләнгән характерлары җанлы, хәрәкәтчән, теле җыйнак.

Тулаем романны уңай бәяләгән хәлдә, берничә сорау, шик бар. Бездә кеше үлгәч изгеләштерелә. «Сират күпере» романында да, Солтангалиевне, аның концепциясен артык күтәреп кую юкмы? Бит ул соңгы көннәренә чаклы, хәтта

хакимияттән читләштерелгәч тә, шул ук большевик булып кала, коммунистлыгыннан баш тартмый. Аннан килеп, өченче дөнья, бигрәк тә көньяк Африка, Латин Америкасы илләре Солтангалиев хыялларын тормышка ашыру рухы белән яши, аның фәлсәфи, икътисадый, сәяси өйрәтмәләренә таяна, диләр. Хуш, шулай да булсын, ди. Әмма ул илләрнең әлегә берсе дә алдынгы мәмләкәтләр сафына басып, Швеция, Дания, Финляндиядәге демократия рухын тудыра, тормыш муллыгын булдыра алганы юк. Анда шул ук ачлык патша хужа, узара ызгыш-талаш, үтереш дәвам итә. Солтангалиев хыяллары гына бу илләрне торгынлыктан һәм коллыктан алып чыга алмас шикелле. Аларга да шул ук капиталистик мөнәсәбәтләргә кайтып төшәргә туры килмәгәе.

Икенчесе. Татар тарихи романы әлегә чаклы документлар, архив хәзинәләре белән аз эшләде. Хәзер, шундый мөмкинлек ачылгач, китап битләрен реаль хәл-вакыйгаларга таба бордык. Бу мавыгу икенче чиккә алып чыга башлады. А. Гыйләҗев белән А. Литвинның «Алтынчы августка кадәр» романында һәм «Сират күпере»ндә документларны артык мул китерү үзен сиздерә. Бу майны майлау кебек килеп чыга.

Кешенең тарихтагы урыны темасы — соңгы елларда иҗат ителгән бик күп әсәрләрнең үзәгендә ята. Мәгәр һәркайсының үз юнәлеше, үз мәгънәви эчтәлеге бар. Һәр күпер үз баганаларында утыра. Тарихи роман жанры белән мавыгучыларга киләчәктә уйлану өчен бер күзәтү тәкъдим итәсе килә.

Язмыш биргән дәүләтен, ходай тәгалә тәкъдир иткән җирен һәм бәйсезлеген югалткан халык һәртөрле риваятьләргә табынучан, алдавычларга, балык кебек ышанучан була. Һәм һәркемнең үз халкын кыю, булган, сугышчан, дәртле итеп күрәсе килә. Шактый күпертелгән шул ышануга, мифка табынып, «татарлар ул — батыр халык, әнә ул Наполеонны куа барып, башкорт җайдаклары белән бергә, ат өстендә Парижга кергән, рус-япон сугышы кабынгач, әллә ни хикмәтле каһарманлыклар эшләгән, Беренче Бөтендөнья сугышында күп батырлыклар кылган», дип күкрәккә сугып алырга яратабыз һәм 1941—1945 елларда һәлак булган олы язучыларыбызны тантаналы һәм горур төстә санап китәбез: Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Абдулла Алиш... Болары сугышка чаклы ук татар әдәбиятында Сталин репрессияләре нәтиҗәсендә туган, күңелне өшеткеч бушлыкны тутырган беренче дәһшәтле сүз осталары. Һәлак булган офицер-язучылар Нур Баян, Хәйретдин Мөҗәй, Рәхим Саттар, чәчәк шикелле, ачыла алмыйча кырау төшкән күпме мөхтәрәм исемнәрне заяга югалттык әлеге орышта. Ә бит үлем, Равил Фәйзуллин язганча, батырлыгыңны раслауның бердәнбер ысулы түгел. Бу корбаннар татар халкына үз бәйсез дәүләтен төзүгә ярдәм иттеме?

Хуш, мәҗбүри уртак ителгән Ватанны чит ил басып алучыларыннан якларга, аның бәйсезлеге өчен башка халыклар белән иңгә-иңне терәп сугышырга да тиешбез, ди. Ә ни өчен әле уртак ил, уртак җир, уртак коммунистлар фиркасе өчен татар язучылары җаннарын тәслим кылганда, башка милләт язучылары татар кырында үскән ипине тәмләп, ышыкта ятарга тиеш? Ни өчен СССР исемле дәүләтне татар язучысының гына корал тотып яклавыләзем булды соң?

Репрессияләр белән өркетелеп, күңел кыллары соң чиккәчә тартылган татар язучылары арасында, үзе теләп фронтка китү кебек, ялган патриотизм рухы да көчле иде. Әмма үзен хөрмәт иткән, киләчәге турында уйлаган җәмгыять язучысын, галимен, Фәрит Яруллин кебек алтын токымнарын, гомумән, зыялыларын сакларга тиеш иде. Алар — халык байлыгы, алар да халык киләчәге.

Һәр чагыштыру аксый диләр. Бәлки, болай янәшә кую дөрес тә түгелдер. Шулай да М. Җәлил белән Ф. Кәрим шигъри өлгергәнлек дәрәҗәләре ягыннан, В. Боков, Е. Долматовский, Л. Ошанин, А. Софронов, А. Сурков кебек «Чистай шагыйрьләреннән» һич кенә кайтыш түгелдер. Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлары»ы утызынчы елларда иҗат ителгән бик күп әсәрләр белән бәйгедә бил алышырлык, хәттә күбесен сыртка салырлык югарылыкта тора.

Батырлык мәсьәләсенә икенче яктан килеп карыйк. Тарихка кереп калган каһарманлыкларны (Газинур Гафиятуллин, әйтик) татар кешеләре аңлы рәвештә, йөрәге, аң кушуы буенча эшләгәнме? Әллә аны һөҗүмнең алгы сафына гасырлар буенча буйсынырга, әмер үтәргә куркытып өйрәтелгән, үзенчә эш йөртүне, карар кабул итүне оныткан, күндәм холкы, авыр язмышы алып барамы? Мәскәүдән килгән түрәгә баш өсте дип торырга шулчаклы өйрәнгәнбез, мөстәкыйльлек турында игълан иткәч тә, бу халәтебездән чыга алмыйбыз.

Ә менә басмачыларны, дөресрәге, милли азатлык хәрәкәтен авызлыкларга җибәрелгән Татбригадада үз кардәшләренең, диндәшләренең канын коярга, бала-

ларның картларның күз яшен агызырга, үз теләге, үз ихтыяры белән киттеме? Кызыл комиссар Шамил Усманов бу хакта уйландымы икән?

Тарих бит башкарак мисалларны да белә.

Әфган авантюрасы башлангач, политбюро бу илгә әүвәл үзбәк, таҗик, кыргыз, казакълардан торган кораллы көчләрне кертте. Әмма бу алдау барып чыкмады. Бер очракта алар кан кардәшләренә атудан баш тартсалар, икенчесендә «дошман» ягына күчтеләр. Чөнки ләгать — уртак, дин — бер, бүрәнә генә бүлгән...

Татар халкы гомер-гомергә башкалар башлаган шикле эшләрдә катнашырга мәҗбүр ителде. Урта Азия халыклары алдында, гаеп турыдан-туры үзебездә булмаса да, Шамил Усманов оныкларына үкенергә, гафу үтенергә туры килә. Төрки халыкларны бүлгәләү, бер-берсенә каршы кую империянең электән килгән сәясәте.

Азәрбайҗаннан кала бер генә төрки республика да Татарстанны мөстәкыйль ил итеп танымады, аның белән сәяси, икътисадый мөнәсәбәтләрне киңәйтеп җибәрергә артык ашкынып тормый. Тарихи үткәнне, безнең мәгариф, мәгърифәт өлкәсендәге биниһая ярдәмне онытканн өчен үпкәләргә дә хакыбыз бар төсле. Татар егетләре басма хәрефләрне Ташкентка кул арбасы белән тартып барды. Урта Азия халыклары өчен беренче әлифба, китаплар Казанда басылды.

Хәзер дә күпме татар ул якларда хезмәт итә, иң авыр эшләрне башкара. Ничәмә татар хатыны казакъ, үзбәк, кыргыз, төркмәннәргә балалар үстерә, гаилә учагын саклый. Татар хатын-кызларын Урта Азиядә бик тә яраталар, дигән фикер безнең күңелләргә хуш килеп тора. Шулаймы икән чынлыкта?

Берничә ел элек Нүкис шәһәрендә тел, әдәбият, тарих фәннәре буенча бик олы фәнни җыен булды. Хива шәһәренә алып бардылар. Элеккеге мәшһүр ханлыкның хәрабәләрен карап йөргәндә, Казанда авиация институтын тәмамлаган, татарчаны шактый гына тәпәләгән үзбәк егете — гидтан бу якта яшәүче татарларның саны белән кызыксындык. «Хивада татарлар артык күп түгел, әмма кырык процентлап үзбәкнең хатыннары татар, нугай нәселеннән» — дип әйтеп салды озата йөрүчебез.

Без, Татарстан вәкилләре, «шулай шул, татар хатыннары чибәр, эшчән, булган, иренә хыянәт итми», — дип телгә килгән мактау сүзләрен тезеп киттек. Егетебез, күзен тагы да кыса төшебрәк, безнең кикрикне шиңдерде.

— Эш анда түгел, бәкләрем. Беренчедән, татар кызлары өчен калым түлисе юк. Ә калым күләме елдан-ел үсә бара. Икенчедән, аларның бу тәбәктә яклардай туган-тумачалары юк, теләсәң ничек из, кыйна, рәнҗет, кешегә санама. Өченчедән, аны аерып җибәрсәң дә, җәмәгатьчелек гаепләми, ни әйтсәң дә, башка кавем кешесе. Дүртенчедән, соңгы елларда үзбәкләр, мал туплагач, татарны аерып, үзбәк хатын-кызларына өйләнәләр.

Урта Азия илләреннән рус телле халыклар белән беррәттән, татар кешеләренең дә туган якларына кайта башлавы, безне уйландырырга тиеш. Тарихи ялгышлык өчен кайчандыр бер түлисе була.

Ниһаять, егерменче елларда Урта Азиядә барган фаҗигале вакыйгаларга да татар язучысының кулы житте. Т. Әйдинең «Елан угы» романы басылып чыкты.

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң, кеше гомере сукыр бер тиенгә тормый, адәм каны салкын судан арзанрак бәяләнә башлады. Большевиклар урдасы һәм җирдә урнаштыра килгән әлеге сәясәт үз гореф-гадәте, үз җае, үз көнкүреше белән яшәп яткан Бохара ханлыгына да килеп житә. Кырмыска оясына таяк тыгыла. Халык вәкилләре Корылтае (ягъни Рәсәй Чекасы дияргә кирәк) әмирлекне юкка чыгарып, Бохара Халык Совет республикасы төзелүне игълан итә.

Бу темага Т. Әйди кебек үткен күзле, гомере буена милли изү сәясәтенә каршы сугышып яшәгән кешенең алынуын хупламый мөмкин түгел. Язучы ул якларда еш булган, анда яшәүче халыкларның теленнән, йолаларыннан хәбәрдар.

Тарихка мөрәҗәгать иткән каләм иясе ике чынбарлык белән эш йөртә: тарих катламы һәм бүгенге көн. Теләсә кайсы чорны үзәккә алган әсәр нигез сорауга җавап эзли: каһарманнарның эшчәнлеге тирәлек, мохит омтылышларына җавап бирәме, алдынгы карашны алга сөрәме?

«Елан угы» романы менә шул катламнарны күтәрергә, басмачылык дип аталган хәрәкәтнең совет фильмнарында күрсәтелгәнчә, тискәре, реакцион күренеш булмыйча, азатлык, бәйсезлек, читтән бәреп кергән көчләр белән изге көрәш икәнлеген калкытып куярга тиеш иде.

Язучы, безнең фикерләүдәге торгынлыктан арына алмыйча, гадәт буенча басып алучылар ягын алып, Бохара әмирлеген битәрләү юлына баса.

«Әмир үзенең тәхетен ташлап качарга мәҗбүр булды. Әмма ул җылы оясыннан аерылганчы турылыклы түрәләренә, якыннарына корал өләшеп, революция ясаган халыкка каршы көрәшер өчен агулы коткы салырга өлгергән. Нығытмасын штурмлаганда тукмалып бетмәгән гаскәрләрен, тиздән яңадан бер учка җыйнап юксылларның канын кояр өчен, аулаграк кышлакларга таратты. Төрмәләрдәге барлык җинаятьчеләрне, кулларына корал тоттырып, шулай ук ирекка чыгарды һәм тыныч илгә өстәрде. Шымчыларын, куштаннарын, үзе кебек кеше җилкәсендә рәхәт күрүче бәк-морзаларын астыртын рәвештә һәм ачыктан-ачык җәдитләр, «карасөякләр» белән көрәш алып барырга рухландырды».

Мондый юллар аптырышта калдыра. Урта Азиядәге хәлләргә бәя, ВКП(б) тарихының Сталин җитәкчелегендә язылган дәреслектәгечә бирелә. Кан коешка, сугыш, асыш, кисешкә әмир һәм аның яраннары гына гаепле икән ләбаса.

Иленә, өенә чакырылмаган кораллы көч читтән бәреп кереп, ничәмә дистә еллар дәвамында урнашкан әчке тәртипне пыран-заран китерсеннәр дә, син саклану чаралары күрмичә, «агулы коткы» салмыйча, кул кушырып утыр, имеш! Адәм баласының табигатенә ят нәрсә ич бу.

Аннан килеп, әмир идарәсе вакытында төрмәгә утыртылган җинаятьчеләрнең башына тай типкәнме әллә: алар ни өчен үзләрен рәнҗеткән бәндәләрне якласын?! Киресенчә, нәкъ шундыйлар инкыйлабның алгы сафында булдылар. «Ленин гвардиясе»нең күпчелеге төрмәдә чарланып чыкты.

Ниһаять, дөньяда, берәр заманда «кеше җилкәсендә рәхәт» күрмәгән түрә булганмы? Ни өчен әле моның өчен Бохара әмирен һәм аның бәк-морзаларын гына кургаш яңгыры астына алырга?! Коммунист җитәкчеләр хакимияткә кеше җилкәсендә яшәү өчен килмәделәрмени?

Әлбәттә, бу бик гади хакыйкатьләр алдынгы карашлы, чит илләрне күп иңләгән, шуннан алып кайткан язмаларына караганда, большевизм сәясәтен күрә алмаган Т. Әйди өчен сер түгел. Кызганыч ки, иҗатчы үз әсәренең фәлсәфи, мәгънәви нигезен дөрес билгели алмаган. Сәнгатьчә фикерләүдәге сазлыктан, күнегелгән кануннардан, дөресрәге, марксизмның нигез ташы (бәлки, кабер ташыдыр) булган сыйнфыйлык авыруыннан котыла алмаган ул.

Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Тинчурин, Һ. Такташ социалистик реализм канвасы буенча эшләнгән әсәрләрендә инкыйлаб дошманнарын, кеше җилкәсендә утыручы әрәм тамакларны нәкъ менә шулай фаш иткәннәр, укучы шуңа күнеккән, әдәби алымнар сыналган. Ягъни нигә дип баш катырып, Әмерикә ачып утырырга?

Өлкән каләмдәшләрдән, әлбәттә, өйрәнергә кирәк. Әмма үрнәк алу иҗади булсын, гади кабатлауга алып килмәсен иде.

Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы «Фәхрине үтереп ташладылар», дигән атаклы җөмлә белән башланып китә дә, фабула җебе шуңа бәйле рәвештә сүтелә, үстерелә, сәбәплелек бәгланышы каһарманнар язмышында ачыла.

«Елан угы»ның төбендә шул ук алым ята. Алдынгы карашлы, һәрьяктан килгән, уңай герой комиссар Шиһабетдиновны чит, ят, тар бүлмәдә үле килеш табалар, шуннан китә тикшерү, төрле төркемнәр арасындагы көрәш, атыш. Газраил корбаннары, мажаралар мозаикасы...

Биредә әсәрнең төзелешенә, килеш-килбәтенә, каһарманнарның кыланышларына керешеп тормастан, авторның безнең көннәр өчен ифрат кирәкле, файдалы һәм отышлы юнәлешне «әрәм» итүенә генә игътибарны юнәлтәсе килә. Фәлсәфи агымның табылмавы, умыртка баганасы булмау «Елан угы»н укыла торган, әмма урта кул әсәрләр дәрәҗәсендә калдырган.

Романда Урта Азия фаҗигасендә катнашкан татарларны яңачарак сурәтләү, аларның җирле халыкларның омтылышын аңларга, төрки халыкларны бүлгәләүгә алып килгән төеннәрне үзәккә алырга мөмкинлек бар иде. Ул — файдаланылмаган.

Тарихи әсәр күп очракта замана таләбе, сәяси һәм башка ихтыяҗлар нәтиҗәсендә языла. Ә инде үзен дөньяга чакырган чордан соң да әсәрнең яшәве исә сәнгатьчә эшләнешкә, иҗатчының табигый сәләтенә бәйле.

Ни өчен А. Толстой Петр I гә багышланган романын да, Явыз Иванны сурәтләгән драма-дилогиясен дә нәкъ утызынчы елларда укучыга тәкъдим итә? Чөнки чор шундый рухтагы әсәрләрне сорый. Сталин үзе шикелле үк параноик Грозныйны «прогрессив патша», дип атый. Алар арасында якынлык — хатыннарын һәм балаларын үтерүдән (берсе үзе сугып үтерә, икенчесе немецтән аттыра) алып, халыкларны рәхимсез кыруга, хәтта опричнина — НКВД кебек үзләренә генә буйсынган оешмаларына чаклы уртак.

XX гасыр җәллады үзе өчен үрнәк итеп, Явыз Иван белән Петр I не сайлый. Соңгысы татарны юкка чыгару, динен тартып алу буенча, Грозныйны һәръяклап дәвам иттергән. Мәчет-мәдрәсәләрнең иң күп кырылган, җир белән тигезләнгән чоры — Петр I белән Сталин хакимияте дәверләренә туры килә. Безнең гасыр залимы тарихка таяна, үзе кылган явызлыкларны үткән белән акларга, расларга тырыша.

Башка колониаль империяләрдән Рәсәй ике үзенчәлеге белән аерылып торды. Беренчесе, үз илендә яшәгән, көчләп буйсындырылган башка халыкларны урыслаштыру, миллилеген эретү, этнос буларак юкка чыгару булса, икенчесе, башка халыкларны рәнҗетү, кысу исәбенә урысны күтәрү, үстерү, аны иң куәтле, сабыр, эшчән, шәфкатьле, дустанә милләт итеп күрсәтергә омтылу. Инглиз, француз, төрек империяләре буйсынган халыкларның байлыгын сыгудан узмадылар. Күп очракта үзләреннән соң, югары мәдәният калдырдылар.

Урыс әдәбияты тулысы белән шул сәясәткә буйсынды, шуны сәнгать чаралары ярдәмендә расларга тиеш булды. Ул үзен таный, аңлый башлаганнан бирле, шул олылыкны, бөеклекне раслауга хезмәт итте һәм әлеге вазифаларыннан хәзер дә ваз кичми.

Әйтик, Толстой белән Достоевскийны күкләргә чөюнең сере — аларның инсаниятне, урыс мохитен сәнгать чаралары ярдәмендә сурәтләү осталыгына гына кайтып калмый. Камиллек ягыннан Чехов, Тургенев, Гончаров, соңрак дәвер даһие Бунин алардан һич тә калтыш язмый. Киресенчә, соңгылары җинелрәк укыла, хәтердә кала. Дистәләрчә еллар дәвамында (бигрәк тә большевиклар хакимияте килгәч), Толстой белән Достоевскийны мактау, күтәрү, китап, радио, телевидение аша туктаусыз колакка сеңдерә тору үз эшен эшли: гавәм бу әдипләрнең әсәрләрен укып та тормастан, баш ия, соклана, аларга дан тажы кидерә.

Үзенең күпчелек язганнарын урыс халкының кыюлыгын, хәттин ашкан сабырлыгын, бетмәс-төкәнмәс шәфкатьлелеген, халыклар арасындагы туганлыкны олылавын раслауга багышлаган Достоевский, мәсәлән, яһүди, поляк кебек халыкларны кешегә дә санамый. Аны кайбер милләтләрнең һәм мәмләкәтләрнең үз идеяләре артыннан ияртеп алып баруы, дөньяны үзенә буйсындыруы борчый. В. Гроссман «Жизнь и судьба» романында язганча, Достоевскийның рәсеме Гитлер кабинетында эленеп торган.

Тагын бер мисал. Татар-монгол урдасының явызлыгы, вәхшилеге турындагы романнарның зур күпчелеге илдә рәсми сәясәт чарасыннан шовинизм ялкыны дөрләтелгән, «тигезләр арасында беренче», «олкән абый»ның рухын ныгытырга ихтыяҗ булган чорларда язылa. В. Ян, И. Калашников, В. Чивилихин, В. Балашовларны тарихи дөреслек, чынлык, реализм методы артык бимазаламый. Чөнки явызлык хакимиятенең нигезендә һәрвакытта алдау, мәкер ята. Укучыга әлеге иҗатчылар нәкъ булганча язгандай тоелса да, монда ахыр максат бер: урысны күпме генә изсәләр дә, җәберләсәләр дә, ул зиһен көчен, куәтен, олы талантын һәм дәүләтчелеген беркайчан да җуймаган дигән фикерне раслау. Дошман эзләү — халыкны берләштерә торган иң көчле шовинистик махмыр. Үзен яклап аваз сала алмаган Алтын Урда моның өчен иң яхшы темаларның берсе.

* * *

Югарыда сөйләгәннәрдән бер нәтиҗә ясарга мөмкин. Халык үткән аянычлы һәм үкенечле юлны сурәтләү үзмаксат була алмый. Тарихны язучы хыялында туган сурәтләр, мажаралар белән генә бутарга ярамый. Һәр әдәби әсәрнең, бигрәк тә ул тарихилыкка дәгъва итсә, анык максаты, ачык фәлсәфи юнәлеше булырга тиеш. Урыс әдәбиятыннан китерелгән мисаллар дөньякүләм танылган исемнәргә, тарихи әсәрләргә кизәнү, дип аңлашылмасын. Биредә сүз алардан үрнәк алып, милләтне күтәргән, үстергән язучыларны, максатлы әсәрләрне дөрес һәм гадел бәяләү турында бара.

Тарихи әсәрләр дә, гомумән, чорга һәм геройларга багышланып кына калмый. Һәр тарихи роман әхлакый бурыч та үтәргә тиеш. Татар халкы өчен җанын фида кылган Алдар-Күчем, Акай, Батырша, Гаяз Исхакый кебек каһарманнар һәм, гомумән, олы язмышлы шәхесләр эшчәнлеге, батырлыгы — болар безнең тарихи юлыбызның маяклары.

Бүгенге әдәбият турында сүз алып барганда без мәсьәләнең әнә шул катламнарын да читтә калдырмаска тиеш.

Радик Фәизов

# АЛДА ЯКТЫЛЫК КҮРЕНӘ

**Башта ук шунысын кисәтеп куям,
язучы Фоат Садриевның
«Таң җиле» романын укыгач
миндә туган фикерләр кайбер укучыларның
һәм
журнал редакциясендә эшләүчеләрнең дә
күңеленә хуш килмәс.
Белеп торам,
мин монда алар көткән,
алар ишетергә теләгән фикерләрне бәян итмим.
Шулай итеп:
безнең тормыш, безнең әдәбият.
Гәрчә бу ике төшенчә
бер-берсенә аерылгысыз бәйләнгән булсалар да,
без аларның һәркайсына
аерым тукталырга тырышыйк әле.
Иң әүвәле
әдәбиятны алгы планга чыгарып куйыйк.**

Әдәбият — халык күңеленең, халык тормышының көзгесе. Анда халыкның милли үзенчәлекләре, холык-фигыле, гореф-гадәте һәм, гомумән, бөтен яшәү рәвеше тулысынча чагыла. Әгәр син нинди дә булса халыкның әдәбиятын тирәнтен белсәң, ул халыкның үзен дә белдең дигән сүз. Һәм тагын бер бик әһәмиятле нәрсә: әдәбиятларда халыкларның үткән тарихи юлы һәм киләчәккә булган өметләре дә, уй-хыяллары, киләчәккә нинди юл белән атларга исәп тотулары да бик ачык төсмерләнә.

Җөмләдән, безнең татар әдәбияты да нәкъ шулай. Ул үзенең яралган көненнән, Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Мәхмүт Болгариларыннан, аннан килеп Г. Кандалый, К. Насыйри, Ш. Мәрҗаниларыннан алып Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Коләхмәтовларына, революциягә кадәр үк иҗат итә башлаган Г. Ибраһимов, Ш. Камалларына кадәр халык тормышын киң һәм тирәнтен яктыртты. Ул халыкның төп өлешен тәшкил иткән хезмәт ияләренең, эшчеләр һәм крестьяннарның, ярлылар һәм ирексезләрнең авыр язмышын, алар күңелендәге иң татлы омтылышны чагылдырды. Изүче сыйныфларның бары үзләре турында гына кайгыртуын, халык ихтыяҗлары белән берничек тә исәпләшмәвен, аларның хыянәтчел йөзен ачып салды. Сез алыгыз Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Коләхмәтов һәм Ш. Камалның гына революциягә кадәр иҗат иткән һәм хәзерге өлкән буын кешеләре кайчандыр ничек яратып укыган әсәрләрен! Аларда хезмәт ияләренең, гади халыкның җәбер-золым белән тулган гаять авыр тормышы, коллыкта яшәве, иреккә сусавы сурәтләнә һәм илдә революцион үзгәрешләрнең зарурлыгы турындагы фикерләр калку булып ярылып ята. Бу үзгәрешләрнең, ниһаять, өлгереп җитүенә һәм башланып китүенә безнең татар әдәбияты керткән өлеш Рәсәйдәге бүтән әдәбиятлар керткән өлештән бер дә ким булмады. Монысын беркем дә инкарь итә алмас!

Әгәр инде революцияне һәм аннан соң гадел җәмгыять төзүне җитәкләү эше һәртөрле иймансызлар, намуссызлар кулына эләгеп, бүгенге көндә без бәхетле тормышка ирешә алмаганбыз икән, монда әдәбиятларның, минемчә, берниндн гаебе юк.

Әле революциядән соң социалистик җәмгыятьне төзүдә дә әдәбиятлар һәм шул исәптән безнең татар әдәбияты да халыкка берниндн хыянәтсез һәм турылыклы хезмәт итте. Әлбәттә, минем бу фикерем кайберәүләргә бер дә ошамас, ә кемнәргәдер сәер тоелыр. Әмма бу бит шулай. Чөнки халык җир йөзендә изүчеләрдән башка беренче ирекле, гадел җәмгыятьне төзүгә ихлас күңелдән керешде. Эшчеләр, крестьяннар һәм интеллигенция дә бәхетле, якты киләчәккә

чын күнелдән ышандылар. Шуның бәрабәренә үз-үзләрен аямадылар һәм, бер дә купшы сүз түгел: чын хезмәт батырлыклары күрсәтеп эшләделәр. Әдәбият та бу бөтенхалык көрәшеннән читтә калмады, якты киләчәкне якынайту омтылышына үзеннән өлеш кертте. Хезмәт кешесенә, фидакарьлеккә һәм җиңүләргә мәдхия җырлады. Бу тырышлыклар, бу көрәш өчен хәзер эшче-крестьяннарны яисә шул ук әдипләрне битәрләргә мөмкинме?! Ә бит табыла андыйлар. Хәзер кайберәүләрнең ул чорда иҗат ителгән әсәрләре өчен язучыларга яисә шагыйрьләргә төрлечә төрттерү, ярлык тагу очраклары бар. Бер дә килешкән эш түгел бу.

Әдәбиятны тормыштан аерылгысыз, дидек. Алай гына да түгел, ул аннан алда атлый һәм шактый гына алдан. Коммунистлар партиясенең социалистик җәмгыять төзүне тупикка алып килүе, торгынлык елларындагы башбаштаклыклар, гомумән, безнең туры юлдан тайпылуыбыз турындагы фикерләрне дә беренче булып шул ук язучылар һәм журналистлар күтәреп чыкты бит! Халык авыз эченнән генә мыгырданган ризасызлык сүзләрен бөтен ил, бөтен дөнья ишетерлек итеп, кычкырып әйтте. Ул чорны мин әдәбиятта хакимлек итүче режимны фаш итү чоры дип атар идем. Ә бит бөтен бер зур чор булды бу, фаш итү юнәлешендә күп һәм көчле әсәрләр язылды. Исемнәрен санап тору кирәкмәс, ул чорда язылган әсәрләре өчен золым күргән әдипләрне дә бик беләбез.

Нәкъ менә шушы фаш итү чорында безнең татар әдәбияты һәм мәдәнияте: язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, җырчылар һәм артистлар артык кыюсызлык, сүлпәнлек күрсәттеләр, дигән фикер яши. Минемчә, асылда бу фикер дә дөрес түгел. Хакимияттән ризасызлык, аның хәрәкәтләреннән ачыну бездә дә бик киң таралган, тамыр җәйгән иде инде. Ышанып әйтергә була, андый әсәрләр язарга кирәклеге турындагы фикерләр тулып ашкан, хәтта кайберләре язылган да иде. Әмма безнең әдипләр бу хакта, мәсәлән, рус әдипләре кебек иркенләп, авыз тутырып әйтә генә алмадылар. Чөнки, үзегез чамалап карагыз: аларның утырган кетәге шул ук рус әдипләренекенә караганда күпмегә түбән иде? Дөресе, хакимият аларны шул кетәккә утыртып куйган да, учы белән башларына басып тора иде.

Фаш итүгә бездән бер дә өлеш кермәде дип әйтү дә дөрес булмас. Сез Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Р. Батулла, Г. Афзал, С. Батталның ул елларда иҗат иткән әсәрләрен алыгыз. Язучылар һәм журналистларның чын күнелдән ачынып язган күпсанлы публицистик мәкаләләрен хәтерләгез.

Хәзер, менә бүген, кайберәүләр безнең татар әдәбиятын югалып калуда, иҗади һәм тематик банкротлыкка төшүдә гаепләмиләр. Туктагыз әле, ни эшләп безнең татар әдәбияты гына?! Халык ялгышлыклар, социализм эшенә хыянәтләр сазлыгына кереп баткан хакимиятнең җимерелеп төшүен, хөррият килүен көтте. Бу хөррият килде, әмма ул һич көнә дә без көткәнне бирмәде. Кыйблалар буталып бетте, тормыш каядыр түбәнгә тәгәри. Үзгәртеп корулар тора-бара социализм эшенә турыдан-туры хыянәткә әйләнде һәм хәзер коточкыч күләмнәр алды, социаль гаделсезлек көннән-көн тирәнәя, хезмәт ияләре үзләре яулап алган хокуклардан колак кага баралар. Мондый шартларда әүвәлге СССРны тәшкил иткән барлык республикалар әдәбиятлары да югалып калды. Бу хәл, килешик, бер бездә генә түгел.

Минем фикеремчә, хәзерге көндә әдәбият башлыча безнең үткәнне, торгынлык еллары тормышын, шул чор вакыйгаларын сурәтләү, җәмгыятьне һәлакәт чигенә китергән сәбәпләрне эзләү һәм анализлау белән мәшгуль. Партократиянең, хакимиятнең чын йөзен ачып күрсәтү белән. Фоат Садриевның «Таң җиле» романы да нәкъ әнә шундый әсәр. «... Сезнең игътибарга бүгенге көн тормышына багышланган тагын бер яңа роман тәкъдим итәбез» дип, журнал редакциясе бик дөрес эшләмәгән. Роман — безнең үткәнебез турында. Кыска хикәяләрне, сатира-юморны исәпкә алмаганда, бүгенге көнне яктырткан күләмле әсәрләр юк әле.

Әгәр инде безнең тормышка килсәк, әнә ул — «Таң җиле» романы. Әсәр безнең соңгы еллардагы тормышны, фәнчә әйтсәк, бөтен аспектлары белән сурәтләгән.

Әсәрнең төп кешесе, аны күтәреп торган өрлек — авыл хатыны, колхозчы Нуриасма. Ә кем соң ул Нуриасма? Минем бу сорауга биргән җавабым укучыларның да, редакция хезмәткәрләренең дә күбесенә тагын ошамас. Алар исә бер фикерне: «Нуриасма — дөньяга ашмас коммунизм идеяләре корбаны, социалистик режим колы» дигән җавапны көтәләр булыр. Юк инде, агайнеләр! Социалистик режим корбаны түгел, ә аны, дөньяда иң беренче һәм гадел җәм-

гыятьне, төзүче ул Нуриасма. Алай гына да түгел, аны аңлы рәвештә, бөтен тырышлыгын һәм җегәрен куеп төзүче! Хезмәт кешесенең гадел җәмгыять төзүгә омтылышын гәүдәләндерүче. Аның холкының соңгы чиккәчә пакь, гадел булуы да бер дә тикмәгә генә түгел. Ул — социализм колы түгел, а Сталинның казарма социализмы һәм үзләрендә шул Сталин юлыннан тайпылырлык, хәлне дөрес юлга кертерлек зиһен тапмаган коммунистлар партиясе, партократлар хакимияте корбаны.

Ул заманда Нуриасма кебек социализм эшенә чын күңелдән бирелгән, эшчән, намуслы кешеләр — авыл халкының зур күпчелеге иде. Әле мин, утызынчы еллар малае, үзебезнең авылдагы шундый кешеләрне, кара таңнан кулына сәнәген тотып түбән очтан югары очка кадәр йөгереп менгән Шәрифҗан абыйны, колхоз өчен җан атып йөргән Гыймади, Закир, Закирҗан, Кәрим абыйларны, урак батырлары Маһитап, Нәсимә апаларны һәм тагын шундый бик күп фидакарьләрне хәтерлим. Күмәк хуҗалык, күмәк эш алар өчен изге иде. Иманым камил, әгәр хыянәт булмаса, Нуриасма һәм аның кебек бирелгәннәр социаль гадел җәмгыятьне төзеп тә чыгалар иде.

Уйлап карагыз, җәмәгать: романдагы Нуриасмага, димәк ки, социализм эшенә дошманлык тоткан Бәрияләр, Хәдичәләр белән нинди генә җәмгыять төзеп булачак? Алар тагын шул хезмәт кешесенең җилкәсенә менеп утырачаклар. Дөресе, менеп утырдылар да инде.

Ул заманда ризасызлык белдерүләр бар идеме? Әйе, бар иде. Мин үземнең дус малаемның әнисе Гатүфә апаның: «Мин ул Ленин белән Сталинның башларын тотып кимерер идем»,— дип берничә тапкыр әйткәнен хәтерлим. Сүз уңаенда, Гатүфә апа булган, тәвәккәл, гаҗәеп эшчән хатын иде. Әмма ул да совет властена каршы түгел иде! Аның бар каргышы халык белән хисаплашмаган, аны изгән, мәсхәрә иткән большевикларга каршы иде. Ул да гомере буена колхозда батырып эшләде. Сез хәзер авылга кайтып сиксәнне үткән әбиләр белән сөйләшеп карагыз. Андый озын гомерле карчыклар авылда җитәрлек хәзер. Алар сезгә революциягә кадәр авыл кешесенең тормышы никадәр авыр, караңгы булганын сөйләп күрсәтерләр. Хәтта бүгенге шушы авыр заманда да алар тормыштан зарланмыйлар.

Нуриасма апа өчен мин, укучы буларак, Фоат Садриевка рәхмәтле. Әсәр барышында мин Нуриасма үз юлыннан тайпылыр, үзенең якты омтылышларына хыянәт итәр дип бик курыккан идем. Җитмәсә, аны бу хыянәткә өндәп, басым даими булып торды. Әмма Нуриасма бирелмәде! Фидакарь, намуслы булып, кырыс гаделлеккә омтылып ничек яшәсә, бу дөньядан шул иманында килеш китеп тә барды. Соңгы сулышынача социализм эшенә бер мыскал хыянәт итмәде. Бүтәннәргә дә зур йогынты ясап калдырды әле. Төрле ялганчылар, исерекләр ваемсызлыгы аркасында һәлак булган Рәмзинең хатыны Мәдинә өметсезлеккә бирелгәч, аңа әйткән сүзләре менә нинди: ***«Ялгышасың, кызым. Өрфия калынлыгы гына түбән төштеңме, беттем, дип уйла. Ә өрфия калынлыгы күтәрелү өчен кайчакта бер кеше гомере дә җитми... Яманлык җиңеп килә...»***

Әйе, бу белемсез диярлек, гомерен фермада терлекләр карап үткәргән авыл хатыны, үзенең табигать биргән акылы, зирәклеге белән безнең рухи халәтнең соңгы елларда никадәр түбән тәгәри баруын бик яхшы чамалый: ***«Ничә генә көн үтте, Рәмзи рухы өстендә ялган белән хыянәт калыкты. Моңа сәбәпче — газиз хатыны белән якын туганы иде... Җитәкче халыкка каршы, хатыны иргә каршы, бала ата-анага каршы, туган туганга каршы... Хөснуллин... Бәрия... Хәдичә... Мәдинә... Мизхәт... Тикшерүче... Врачлар... Урман кисүчеләр... Бөтенесе ялган эчендә бикырдый...»***

Менә ул безнең соңгы еллардагы тормыш! Сталинның шәхес культы, партократия идеологларының безгә биргән тәрбияләренең соңгы нәтиҗәләре. Нуриасма апа аңа төгәл бәя бирә.

Әсәр барышында Нуриасма рухының яңадан яңа югарылыклары, күркәм сыйфатлары ачыла бара. Аның өчен хезмәт, басулар, башаклар — барысы да газиз. «Башакларны күргәч, әнисенең йөзе яктырып китте, иреннәре елмаеп куйдылар. Ул аларны әйләндереп-әйләндереп карады, учы белән сыйпады:

— И җаныкайларым, басуыгыздан аерылыр көннәрегез җитте шул. Яшел чакларыгыз узган, саргаер чакларыгыз җиткән...

Аннары әнисе бик озак тавышсыз-тынсыз гына башакларга карап торды. Фәрит аңа сүз катарга да, чыгып китәргә дә кыймыйча басып торды».

Сүз уңаенда, шәһәрдә яшәгән улы Фәриткә бәйле рәвештә Нуриасма рухының тагын бер тетрәндергеч биеклеге ачыла. Фәрит Нуриасманың үз баласы түгел, ә бәлагә тарыган иптәш кызының баласы икән. Ул аны үзенә алып, үз

балаларына тиң итеп үстергән, бу серне беркемгә дә чишми һәм үзе белән алып китә. Хәтта бу дөньяда бернинди принципы, дөресен әйткәндә, намусы булмаган Хәдичә дә, Нуриасма рухының йогынтысына бирелеп, уйга кала һәм ахырда аның янына гафу үтенергә керә.

Нуриасма — олы шәхес. Мин соңгы елларда безнең татар әдәбиятында аңа тиң булырдай хатын-кыз образын хәтерләмим. Һәм, аллага шөкер, безнең тормышта андый асыл затлар булды, бар һәм киләчәктә дә булачак.

Әмма, зур кызганычка күрә, бу дөньяда барлык кеше дә Нуриасма кебек түгел, һич кенә дә алай түгел шул. Торгынлык елларында башланган күгәрек безнең җәмгыятькә тирәнтен, бик тирәнтен үтеп керде шул. Ул күгәрек безнең арага Гарифҗан кебек кеше алдауны тормыш кануны итеп куйган бәндәләрне, Бәрия кебек хыяллары җимерелү ачуын үз якыннарыннан алучыларны, Мизхәт ише агымга гына ияреп баручыларны, Закирҗан ише кеше намусын аяк астына салып таптауны чүпкә дә санамаган хайвани затларны, янә бер колхоз рәисе Хөснуллин кебек уголовный җинаятьчеләрне алып килде. Бу ике колхоз рәисенә килгәндә, алар инде коммунистлар партиясенең авылга, халык белән идарә итәргә китереп куйган наместниклары иде. Әнә шундый кешеләргә таянып, партия үзенең буйсындыручан сәясәтен тормышка ашырды.

Мин монда бөтен колхоз рәисләре өстенә гаеп ташларга җыенмыйм. Алар арасында үз постына тулысынча лаеклы, менә дигән җитәкчеләр булды һәм әле дә бар. Әмма Закирҗан белән Хөснуллин ишеләре дә җитәрлек булды.

Җыеп кына әйткәндә, Фоат Садриевның «Таң җиле» романы — безнең соңгы еллардагы тормыш үзе ул. Анда әлеге тормышның бөтен югарылыклары һәм түбәнлекләре, барлык мажаралары бар. Безнең заманга хас үзгәрешләре дә ярылып ята:

***«Нуриасма алар белән сөйләшкәндә шушыларны уйлап ятты. Нуриасмалар буыны киткәч, авылда мондый кешеләр калмый инде. Авырыйсыңмы, авырмыйсыңмы, ике-өч көн саен, атна саен, бер-береңнең хәлен белешергә керү, тормыш хәлләрен сөйләшеп утыру Нуриасмалар, Мәһинурлар, Разиялар, Гыйзденисалар, Мосаллиялләр өчен һава кебек зарур иде. Хәзер халык һәр көн каядыр кабалана, чаба, иң якын туганы, терәлеп торган күршесе белән сөйләшеп утырырга вакыт таба алмый, табигатькә чыгып, су буена төшеп узган гомере, башкарган эшләре, кылган гамәлләре, иртәгесе көне, тормышның мәгънәсе хакында ашыкмыйча, җентекләп уйланырга вакытын кызгана. Коры, җансыз, вак, кабаланучан, әйбергә мөкиббән киткән кешеләр ишәйгәннән-ишәя бара. Барысының да авызында бер сүз: «Ник бусы юк та, ник тегесе юк?— Гел бүген белән генә яшиләр».***

Бу юлларны укыйсың да, ачыну белән тел шартлатып куясың: Шулай шул, нәкъ менә шулай шул! Матди яктан байлыкка омтылабыз, җитмәсә, бөтен сәясәте аның хәзер шуңа корылган. Ә менә рухи яктан гел ярлылана, бернигә тормаган кешеләргә әйләнә барабыз. Түбән таба юл алдык шул!

Әмма тормыш өметсез түгел әле ул. Һәм бу асыл мәгънә «Таң җиле» романында да чагылыш таба. Авылның әле аның Гыйздениса кебек һәрвакыт, һәркемгә ярдәм итәргә әзер торган, үзен-үзе аямаган, бик әйбәт күңелле изгеләре бар. Мәдинә кебек эшчәннәре, Рәмзи кебек булганнары, Хәдичә кебек тәүбәгә килгәннәре бар. Тормышлар бер эзенә төшәр, рәтләнер. Явызлык чигенер, изгелек һәм иман кайтыр әле, алла боерса.

«Таң җиле» романын автор киләчәккә өмет рухында, тирәнтен гуманлык рухында тәгәлли. Киләчәкнең якты буласына ишарәли.

Шулай гына була күрсен иде. Амин!

Миргазиян Юныс

# «МИТАКСА-АТЛАС»

Адәм баласының гомерендә алтын укага тәрелгән бер чоры була. Пикассоның андый чоры хәтта берничә: зәңгәр һәм алсуга манылган чорларыннан тыш кубизм, кыргый халыклар сәнгате белән мавыгу вакытлары.

Шундый чорда кояш аеруча көчлерәк яктырта. Кошлар моңлырак сайрый. Кешеләр сиңа гел елмаеп кына карыйлар сыман тоела. Тирә-юньдә тоташ көлечлек. Шул алтынга манылган алсу-зәңгәр чорның 24 сәгатенә сыйган шатлыкны тигезләп таратсаң, ул алтмышлар тирәсендәге гомернең ким дигәндә ун елына җитә алыр иде...

«Одесса» ресторанын без ул чакта «Лондонский» дип атап йөртә идек. Иван Бунин, Александр Куприннар монда яшәгән заманда ул чыннан да «Лондонский» дип аталган булган.

Виктор Петрович Смирновның беренче тапкыр капитанлык дәрәҗәсендә диңгездән кайткан көне иде. Без рестораннан чыктык та, портка төшү өчен, Потемкин баскычына таба юл тоттык.

— Әйдә, миңа сугылып чыгабыз,— диде Смирнов баскычтан аска төшә башлагач.— «Митакса-Атлас» алып кайткан идем. Шуны «сытыйк» әле.

— Лаеклы закускаң бармы соң?

— Табабыз аны,— диде Виктор Петрович тыйнак кына. Чит илләрдә йөреп кайткан чакларда капитанның суыткычында — балык уылдыгы, краб, сервилат, хәтта устрица һәм артишок шикелле деликатеслар булуын мин яхшы белә идем. Шулай да сорадым:

— Конкретно нәрсәң бар соң?

— Хәтта коньякның классик закускасы бастырма да бар. Без бит кайтышлый Истанбулга кереп чыктык.

— Юк, Витюля,— дидем мин.— «Матакса-Атлас»ны мин бары тик персик кабып кына эчә алам.

— Ну и сноб та икәнсең инде. Кайчан өйрәнеп өлгердең? «Чолым» пароходында эшләгәндә геросфера юарга бирелгән сасы спиртны тюлька белән закускалап эчкәнне тиз онытkансың икән.

«Чолман» — Поти белән Мариуполь арасында күмер һәм марганец мәгъдәне ташучы штрафниклар пароходы иде. Смирновны аттестация вакытында характеристикасына помполит Кирюшин «партия һәм хөкүмәт сәясәте турында сарказм белән сөйли» дип язган да шуннан соң, аның визасын ябып, «Чолман»га җибәргәннәр иде. Ул чакта Виктор белән без бер сыныкны икегә бүлеп ашадык, авырлыкларны бергә күтәреп, шатлыкларны урталай бүлешеп яшәдек. «Җылымса» еллар килгәч, Викторны кабат чит илләргә йөри торган корабка күчерделәр һәм ул бер-ике ел эчендә капитан күперчегенә күтәрелеп, «Муром» исемле зур лайнерны йөртә башлады.

Персик татарча шәфтәлу дип аталамы әле? Шулай, ахры, ләкин ул сүз инде үлгән һәм без аны, бик күп башка татарча исемен югалткан әйберләр белән берргәттән, «персик» дип йөртәбез.

Гадәттә, коньякны имән мичкәләрдә өлгертәләр. Тау битенең кояш караган ягында үскән ялгыз имән кәүсәсеннән ясалган мичкәдә. Грек коньягы «Митакса»ны исә кипаристан ясаган мичкәләрдә өзерлиләр. Шуңа күрә «Митакса»ның тәм нәзберeклегe, аннан бөркелгән назлы хуш ис үзе бер могҗизага тиң.

Ул чорда Одессаның кибетләрендә теләсә нинди җимеш була иде. Без персикның яңа гына өзеп алынганын эзләп Привозга киттек. Һәм телгәнне таптык та. Сәяхәттән кайткан мариман кесәсенә янчык салып, кулына сумка тотып йөрергә ояла. Җимеш хуҗасының төрергә кәгазе юк иде. Кесәләремне актара башладым һәм ресторанга керер алдыннан гына сатып алган «Моряк» газетасының соңгы санын чыгардым.

— Күрсәт әле, соңгы битенә нәрсә язганнар?

Виктор, газетаны кулымнан алып, укырга керeште,

— Константин Паустовскийның 70 еллык юбилеена конкурс игълан иткәннәр. Кыска хикәя язарга. Беренче бүләк 500 сум.— диде дустым белдерүне укып чыккач.

— Кара ничек юмартланганнар. Өч айлык эш хакы бит бу. Язарга кирәк, Витек. Язабызмы?

— Әгәр син язган хикәя өченче урынга эләгә алса, бүләккә мин бер шешә «Мартелл» өстим,— диде «Муром»-ның капитаны.— Син бит беләсең минем Паустовскийны яратканымны. Паустовскийның егерменче елларда «Моряк» газетасының баш редакторы булып эшләгәнен син ишеткәнсеңме икән?

— Белмичә,— дидем мин.— Бөек прозаикның нинди әчемлек яратуын гына белмим. Мин үзем «Фундадор»-ны «Мартелл»-дан югарырак куям.

Без ул чакта Виктор Смирновның каютасында таң атканчы диярлек сөйләшеп утырдык.

* *
*

Аерылышу хакында сүз чыкса, гадәттә, урысча «разошлись как в море корабли», диләр. Хак сүзләр: иртән «Муром» теплоходы Бомбей портына юл тотты. Без әле Одессада тагын ике тәүлек тордык һәм ямансу бер таңда Мисырның Александрия портына юнәлдек. Дустым белән куешкан бәхәс, алып килгән бодайны Александриядә бушатып, балласт белән Могадишо портына арахис төяргә барганда гына исемә төште һәм Кызыл диңгездә — күк йөзе тоташ йолдызлардан торган бер төндә урыс телендә «Железный слон» дигән хикәяне язып та ташладым. Язган нәрсәне кат-кат үзгәртеп, редакцияләп камилләштерү турында белми идем әле. Язып бетерү белән хикәямне конвертка салып ябыштырып та куйдым. Икенче конне без диңгездә Одессага кайтып баручы «Фараб» исемле кораб белән очраштык. «Фараб»-ның рейска алган оны беткән иде. Радиотелефон белән сөйләшкәндә алар инде дүртенче тәүлек иписез, бары тик макарон һәм консерва белән тукланып торулары турында сөйләп зарландылар. Без аларга он бирергә булдык һәм «Фараб»-тан шлюпка төшерделәр. Шлюпка безнең янга килеп туктагач, онга өстәп мин диңгезчеләргә «Моряк» газетасына адресланган хатымны да тапшырдым.

Диңгездә йөзгәндә көннәр үзара укмаша да, вахталарга бүлгәләнеп, очсызкырыйсыз тасма рәвешендә ага-агыла башлый. Диңгездә үткән гомерне көнләп тә, хәтта айлап та үлчәп-чутлап булмый. Туган илдән чыгып китү һәм кире әйләнеп кайту... Гомер шул берәмлек белән үлчәнә. Өч ай, алты ай, тугыз ай. Кайчакта ул берәмлекнең күләме елга сузыла. Һәм синең газиз гомерең, сиңа бары тик бер, бер генә тапкыр Аллаһе Тәгалә тарафыннан бүләк итеп бирелгән яшәешнең, шундый зур-зур кисәкләргә ярчыкланып кыскарып тора.

1962 елның җәе иде. Пушкин урамының тротуарыннан пароходчылыкка таба атлап барам. «Моряк» газетасының редакциясе урнашкан йорт. Одессада яшәгәндә бу йортта Пушкин торган. Шул йортның тәрәзәсеннән диңгезчеләр газетасының җаваплы сәркатибе Евгений Косоногийның башы күренде:

— Иптәш Юнысов, сез нигә бүләгегезне алырга килмисез?

— Нинди бүләк ул?

— Конкурста беренче урынны алган өчен, билгеле.

Кемнең кайсы урынны алганын газетага да басып чыгарган булганнар икән. Миңа беренчелекне биргәннәр. Икенче урында «Аркадий Гайдар»-ның механигы Аркадий Хасин, өченчелекне пароходчылыкта инженер булып эшләүче Базоев (исемен оныттым) алган. А. Хасин хәзер Одессада яшәүче зур язучы. Базоев тоньяк Кавказда яшәүче бер халыкның (кайсы халыкныкы икәнлеген ачык кына әйтә алмыйм) данлыклы шагыйре. СССР исән чакта Одесса, чыннан да, Э. Хемингуэйның «Праздник, который всегда с тобой» исемле китабында күрсәтелгән Парижны хәтерләтә иде.

Конкурска катнашуда Виктор Смирновның да өлеше булуы турында әйтеп узган идек бит. Аның язмышы турында да әйтеп китү кирәктер. Мин аны озак еллар очрата алмадым. Вьетнам сугышы чорында америкалылар Тонкин култыгын миналар белән биклəп куйгач, ул корабы белән шунда ябылып калып елдан артык ятты. Соңрак Брежнев сәясәтенә тел тигергәне өчен аны партиядән чыгардылар. Совет чорында, дөресрәге, партия хакимияте вакытында, партия әгъзасы булмаган кешегә кораб белән идарә иттермиләр иде. Минем дустым Витя да озак еллар эшсез калып, бик авыр шартларда яшәде.

* *
*

Мин икеме, өчме ел урыс телендә хикәяләр яздым. «Тимер фил» исемле беренче китабыма кергән хикәяләр тулысынча диярлек урысчадан үзем тәрҗемә иткән әсәрләр иде.

Шулай гамьсез урысча хикәяләр язып азапланганда, ни сәбәптәндер, мин кинәт кенә тукталып калдым. Бу тойгы тәнлә йокымсырап ятканда уянды. Эчне ачыттырып, бәгырьләргә тиеп үземнең туган телемдә нәрсәдер язасы килү бугазымнан тотып алды да бик озак җибәрмичә торды. Бу чакта инде мин егерме ел гел урыс арасында, гел урысча сөйләшеп, урысча уйлап, көндәлектә тулысынча диярлек «өлкән абыйлар»ның гореф-гадәтләрен тотып һәм алардан бер ягым белән дә аерылмаска тырышып яшәп килдем. Татар мәктәбендә тоташ йөреп бары тик биш кенә ел укып калдым. Алтынчыда һәм җиденчедә, өйтергә оят, кыш урталарында, колхоз эше беткәч кенә йөрештергәләдем.

Безнең Исергәп мәктәбе, минем бу турыда язганым да бар, искиткеч бер уку йорты иде. Аның атмосферасы белем алуга, гыйлем эстәүгә гаҗәп тәэсирле иде. Исергәп мәктәбе бүгенге көндә дә көчле мәктәп: фидакяр педагоглар дисеңме, тәрбияви тәэсир дисеңме, әхлак һәм тугрылык кануннарын үзләштерү дисеңме, анда боларның барысы да мәктәп атмосферасының үзенә сеңгән. Мин укыганда да шулай иде. Ләкин, кызганычка каршы, мин мәктәптән бер бик зур кимчелек белән чыктым: туган телне сөяргә, аны ихтирам итәргә һәм күз карасы шикелле сакларга өйрәнә алмадым. Бу эштә кем гаепле булган: мин үземме, әллә безгә ана теле укыткан педагогмы? Минем үземнең исә педагогны гаеплисем килә. Ул бар көчен диярлек дәрес вакытында тәртип саклауга, кагыйдәләр ятлауга тотып бетерүче каты бәгырьле бер укытучы иде.

«Безнең өй өянке астында иде...» исемле хикәяне язарга утырганда, мин өткәм-өнкәм телен тулысынча булмаса да, җитмеш-сиксән процентка онытып бетергән булганмындыр. Шуңа карамастан, хикәяне бер утыруда диярлек язып ташладым. Каядыр җибәреп бастыру турында уйламаган идем мин. Эчемә чиктән тыш күп кирәксез күзәтүләр, уй-фикерләр, тойгылар җыелган иде булса кирәк. Алар миңа тыныч кына яшәргә комачаулыйлар иде. Хикәя язуның сәбәбе — шулардан котылып, бушанып калу һәм җанга тынычлык табу максаты гына иде. «Безнең өй өянке астында иде...»не «Совет әдәбияты» журналына энем Вахит җибәргән һәм аның бер сүзен дә үзгәртмичә диярлек шундук басып та чыгарганнар иде. Журналның баш мөхәррире Газиз Мөхәммәтшин: ***«Язган әйберләрегезне һәр очракта безнең журналга җибәреп торыгыз»,*** — дип миңа хат салган. Утыз елга сузылган иҗат эше дәверендә минем мондый хатны икенче тапкыр алганым булмады.

Әгәр иҗат юлында очраган газапларны алдан белгән булсам, мин кулыма каләм алыр идемме икән? Белмим. Иҗат эше адәм баласының тәкъдиренә охшашлы. Ул Җиденче кат күкләрдә хәл ителә. Мәсәлән, минем белән бер чорда яза башлаган әдипләрнең күбесе егерме-утыз-кырык китап чыгарырга өлгерделәр. Ә мин — биш китап авторы. Юк, көчем комга сеңгән су шикелле исрафка китә, дип кимсенмим мин. Әдәбият күләмдә түгел, сыйфатта. Мине сыйфат мәсьәләсе борчый. Кайчакта төн урталарында уянып шул хакта уйлыйм, баш ватам, газапланам.

Миңа нәрсәдер җитми. Канәгатьлек хисе юк. Әллә көч җитмәү бу, әллә талантсызлык? Җир йөзендә ир-егетне тулысынча канәгатьләндерә, аны җанытәне белән беркетеп җибәрмичә тота торган ике көч бар: хакимият һәм Иҗат. Баш идертү, буйсындыру һәм шушы юл белән мин-минлеккә күтәрелеп идарә итү ир җенесләрнең канында һәм күзәнәкләрендә, ахрысы. Бу халәт безгә хайванлык чорында ук кереп калган. Көтүнең юлбашчысы булу өчен язларын болан үгезләренең сугышканнарын күзәткәнегез бармы сезнең? Шул ук хәл Рәсәйнең парламентында спикер, аннан да көчлерәк хәлдә президент сайлаганда сурәтләнә түгелме? Хакимияткә омтылуның аяусыз кыргый көчен бары тик иҗат, яшәвеңне һәм гомереңнең һәр мизгелен иҗатка багышлап яшәү генә җиңә ала. Адәм баласын җир йөзендәге өшәкелекләрнең күбесеннән коткара алучы көч — Иҗат. Пакь, хәрәмсез, мал табуга бәйләнешсез — изге Иҗат. Һәм шул Иҗат дигән нәрсә дә миңа тулысынча канәгатьлек китерә алмый. Кемгә дә булса кирәкме икән минем иҗатым? Чын әсәрме икән, әллә бары тик имитация, фальшивка, халтурамы икән мин язган нәрсәләр? Мене шулар борчый мине, тынгы бирми, газапландыра.

Югалтуларымның иң зурысы — иҗат эше минем холкымны бозды. Элек мин йомшак күңелле, көләч, мөлаем кеше идем шикелле. Дошманлык хисе миңа

таныш түгел иде. Юлымда очраган кеше әхлаклымы, түгелме, иманлымы, имансызмы — бу мәсьәлә мине болай ук каты борчымый иде. Борчылулар моның белән генә чикләнми әле. Нәрсә ул әдәбият дигән сорауга да җавап таба алмыйча газапланып йөрим мин. Белмим, нигә кирәктер инде шушы нәрсәне ачыклау? Ә минем ачыклыйсым килә.

Чыннан да, нәрсә соң ул әдәбият? Адәм баласының ялгышулар тарихымы? Әллә шул ялгышудан котылу юлын эзләп адашып йөрүеме? Әллә ул ялган белән хакыйкать, әшәкелек белән яхшылык арасындагы көрәнмәс, һәрдаим үзгәреп, эзен яшереп торучы чикне эзләү газаплары гынамы? Кайчакта әдәбият (шигърият һәм проза!) бары тик сүз тылсымы гына булып тоелып китә. Им-том! Бәддога! Гипноз! Җиденче кат күкләргә ялварып бәхет эстәү. Әдип бу сорауларга, һичшиксез, җавап табарга тиеш. Башкача ул ничек иҗат итә алсын? Ничек яши алсын ул шушы сорауларга җавап тапмыйча?

Сүз тылсымы. Аһәң! Моң! Җирсү! Сагынулар! Җан сыкрау! Алар нинди шартларда, нәрсәдән туа? Йөрәк өрнү! Бәгырь сыктау! Тынгы таба алмыйча вөҗдан өрнү! Шушы хасталарга диагнозны әдип куймаса, кем куя алыр? Адәм баласы нигә бәхетсез? Нәрсә соң ул бәхет? Җанга азык, ял кирәк булу гынамы? Җавап юк. БУ турыда күптөрле кагыйдәләр бар. Кагыйдә — шул ук җавап таба алмыйча газаплванудан туган өнсезлек. Әдәбият фәнендә, фәнни эзләнүгә без чарасызлыктан ташланабыз. Адәм баласын терепте дә, үтерә дә ала торган чын әдәби сүз менә нинди була:

«... Ай күрдем аман белән, авызым тулды иман белән, куеным тулды Коръән белән, бу айларда вафат булсам, үткәр, Аллам, иман белән».

Соңгы елларда китап кибетләрен, урамнарга, базарларга куелган өстәлләрне өем-өем китаплар басты. Детектив, порнография, кешене ничек итеп ботарлау, эчәгеләрен агызып, тиресен тунап үтерү турында язылган «матур» әдәбият. Укучы шуларга ябырылды. Безнең буынга кадәр килеп җиткән бер бөек аңлатма бар иде — Китап Сүзе. Коръән айәтләре дә, Габделҗаббар Кандалый шигырьләреннән алынган тәгъбирләр дә, Дәрдемәнднең «Кораб»ындагы юллар да Китап Сүзенә керә иде. Бездән соң килгән буыннарга мәгълүмме икән бу Бөек мәгънә?

Ялымны калдырып, төнге йокымны үземнән үзем урлап утыз елдан артык китап язып чиләнгән елларыма борылып карыйм. Җиңел генә башланып киткән старттан соң бәлки миңа гел «өлкән абыйлар» телендә язарга кирәк булгандыр? Тургенев әйткәнчә, «бөек һәм гайрәтле» телдә. Аллавыт Иван Сергеевич чорында ул тел, чыннан да, бөек һәм гайрәтле булгандыр? Бүгенге көндә шул телдә Штаниннар, Грачевлар, Хафизовлар һәм Жириновскийлар сөйләшә. Саранча явы шикелле минем туган җиремә ябырылган шәҗәрәсез һәм токымсыз өтрәкләләм дә нәкъ шул телдә үзенә өстенлек даулый. Шуңа өстәп, Шәһри Болгарны, Казан каласын саклаганда шәһит киткән бабаларыбызның васыятьләрен эстафета итеп киләчәккә алып китәргә тиешле газиз балаларыбыз да тулысынча диярлек шул Явыз Иван һәм Аксак Каратун теленә күчеп баралар түгелме?

«Язмыштан узмыш юк» дигәннәр борынгылар. Бу дөньяның күп, бик күп газаплары язмышны белмәүдән һәм тәкъдирнең күрәзәчел авазларына колак салырга теләмәүдән барлыкка килә. Мин үзем дә бу хакыйкатьне, кызганычка каршы, бик соң, гомер узып киткәч кенә аңладым. Әткәм-әнкәм телендә язуны максат итеп куйгач, миңа шул телдә сөйләшүчеләр арасына кайтып яши башларга кирәк иде. Кырык тугыз ел гел урысча сөйләшеп, гел урыс һәм урыска әйләнеп беткән «тарихи уртаклык» тудырган милләтләр арасында яшәү дәверендә минем бишек җыры, Ык суының талгын агымы белән кергән туган телем бюрократлар шивәсе, манкортлар лексикасы астында калып сытылды, гариплэнде.

«Тозлы җил» исемле китабымны мин урысчага тәрҗемә итеп карадым һәм аңладым: «туган телдә әйтелгән сүзнең эчтәлегенә тәңгәл килгән сүзне «өлкән абыйлар» теленнән табуы ифрат кыен. Күбесе бөтенләй юк диярлек. «Мөселман» сүзе — туган телдә изгелекнең бер билгесе. Ә урысчасы? «Басурман» — аларча иң әшәке, бетерергә, юкка чыгарылырга тиешле кеше. Хәтта бер гөнаһсыз «сабантуй» — безнең милли бәйрәмебез дә — урысча әйтелгәндә, эчеп-исереп сугышып йөрү, бер-береңне дөмбәсләүне аңлата.

Көнбатыш Европа, Америка һәм башка чит илләрдә берничә тел белү культуралы һәм белемле булуның даими бер шарты булып санала. Яшь чагымда мин дә телләр өйрәнергә, берничә телдә сөйләшә алу бәхетенә ирешергә омтылдым. Хәзер аңлыйм, язучының теле бары тик бер, катгый рәвештә бер генә булырга тиеш. Китап яза торган тел ул бөтенләй икенче тел. Адәм

баласының иманы ике булмый бит. Аның намусы да, язмышы да һәм Алласы да бары тик бер генә була. Әдипнең теле дә шул категориягә керә. Аллаһе Тәгаләдән бәхет сорый, бала тәрбияли һәм беренче мәхәббәтне сөйгәненә аңлата торган тел — Ана теле, бары тик Ана теле генә булырга тиеш. Картайган көнемдә генә аңлау дәрәҗәсенә ирештем мин шушы хакыйкатьне. Ә бит бу турда Җиденче Кат Күкләр күптән аваз биреп торган булган. Без бит ашыгабыз. Безнең тыңлап торырга вакытыбыз юк. Без кыбырсыйбыз. Кабаланабыз. Куркабыз. Ирексез яшәү, колониаль шартлар, коллык калдырган җәрәхәтле эзләр бу...

Адәм баласы телсез яши алмый. Тел аңа сөйләшү өчен генә түгел, рухлану өчен дә, өметләнү һәм куаныч табу өчен дә, кыскача әйткәндә, тулысынча үзеңне кеше затыннан икәнлегеңне тоеп яшәү өчен дә кирәк. Без, татарлар, тел аркасында фаҗигале хәлгә юлыкканбыз. Туган тел әкренләп онытыла. Алай гына да түгел, өткем-әнкем теле күзгә күренеп шиңә, парга әверелеп һавага очкан су шикелле, күренмичә юкка чыгып килә. Тел белән бергә безнең мең еллар туплаган тарих авазлары, әхлак кагыйдәләре, җанга рәхәт тынычлык биреп торган рухи гимн — туган телнең шифалы һәм моңлы тавышы югала. Туган тел югалган урыннар бушлыкка әверелми. Ул урыннарга манкорт теле, манкортлык агылып керә. Әгәр татар теленә урыс Лев Толстой, Владимир Соловьев һәм Александр Пушкин әсәрләрендәге теле керсә, мин курыкмас, сөрән сугып азапланмас та идем. Югала барган туган тел сүзләре урынына бүгенге рәхимсез сәясәт, куркытуга һәм оятсызлыкка көйләнгән хакимият тудырган шыксыз салкын манкорт шивәсе тула лабаса. Шушы процесстан саклану безгә искиткеч авыр һәм катлаулы.

Урыс телендә язылган классик әсәрләрне укыган кеше белә, бу бөек һәм гайрәтле телгә берничек тә битараф калып булмый. Телисеңме-юкмы, ул сине җәлеп итә һәм син аны ирексездән ярата башлыйсың. Урыс теленең тирәнлегенә ирешкәннән соң сиңа тагын бер хакыйкать ачыла: татарларга карата күп гасырларга сузылган рәсми дошманлык, урыс дәүләтенең даими сәясәтенә әверелгән татарларны юкка чыгару максаты аларның теленә сеңгән һәм шушы яшерен дошманлык тәэсирен син һәрдаим тоеп торасың.

Әдәбият тарихында Владимир Набоков һәм Иосиф Бродский шикелле ике телдә иҗат итеп, икесендә дә зур уңышлыкларга ирешкән әдипләр бар. Набоковны мин ике телдә дә укыганым бар. Бродскийның инглиз телендә язылган шигырьләре белән таныш түгел. Мин аның ике телле булуына бераз шикләнеп карыйм, чөнки «алар» үзләренең тавыкларын күркә, хәтта тәва кошы итеп күрсәтә беләләр. Инглиз теле белән урыс теле арасында дошманлык та, бүлсә мал да юк. Бәлки бу ике телнең башлары бер казанга сыя да торгандыр. Ә минем менә гомер буе урыс теле белән мавыгуым, бөек әсәрләр укып шатланырга мөмкинлек бирүе белән бергә, иҗатымда зур югалтуларга дучар итте. Мәкаләмдә мин шуны аңлатырга тырыштым. Аңлата алдыммы икән, белмим.

*1993 ел, февраль.*
*Мәскәү.*

♣♣♣♣♣

## ПУБЛИЦИСТИКА

# ТАТАР МӘКТӘБЕНЕҢ КЫЙБЛАСЫ

Татар мәктәбенең киләчәге, аны яңарту, үзгәртү турында күп сөйләнелә. Газета-журнал битләрендә зур-зур бәхәс-сөйләшүләр булып үтте. Бер ук вакытта республикабызда күпләп татар гимназияләре, мәктәпләре ачу хәрәкәте бара. Аларның саны инде йөзләр белән генә исәпләнмидер. Бигрәк тә районнарда, авылларда урыс мәктәбе итеп үзгәртелгәннәре хаклы рәвештә кире үз кыйбласына кайта. Күңелне сөендерә торган күренеш бу. Милли кадрларга һәр өлкәдә, һәр адымда кытлык кичергән бүгенге чорда бигрәк тә. Чөнки һәр милләт үз мәктәбен ачканда үзенең телен-тарихын, гореф-гадәтләрен, традицияләрен белгән, үз милләтенә хезмәт итәрлек акыллы, зыялы кешеләр әзерләп чыгаруны күз алдында тота. Башкарып чыга алырмы татар мәктәп-гимназияләре бу эшне, юкмы — милләтнең киләчәге шуңа бәйләнгән.

***Сүземне дәвам иткәнче, бер кызыклы мисал китерен үтәсе килә. Миңа быел Казан дәүләт университетына яшьләрне кабул итү нәтиҗәләре белән танышырга туры килде. Кабул ителүчеләрнең 45,97 проценты татар милләтеннән, ләкин шуларның 3 проценты гына татар мәктәбен тәмамлаган һәм язма эшне туган телендә эшләргә теләк белдергән. Саннарга мөрәҗәгать итик. Абитуриентлардан 3418 гариза кергән, шулар арасында татар мәктәбен тәмамлаучылар — 114 (3,3 процент.) Университетка кабул итү планы — 1148 кеше, ә татар мәктәбен тәмамлап 33 бала (3 процент) укырга кергән. Аларны 13 факультетка бүлеп карагач (әлбәттә, бу мәгълүматларга татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетына килүчеләр керми), бик кызганыч нәтиҗәләр күзәтелә. Мәсәлән, география факультетына татар мәктәбеннән 1 абитуриент килгән, ләкин үтә алмаган. Мехматка унөч кешедән өчесе кергән, химфакка дүрт кешедән берсе дә конкурстан үтмәгән, хисаплау математикасы һәм кибернетика факультетына бишнең берсе дә керә алмаган, тарих факультетына уникедән икесе кергән һ. б.***

Әлбәттә, бу урында миңа каршы төшүчеләр булырга мөмкин. Татар мәктәпләре әле яңарак кына ачыла башлады, аларны тәмамлап югары уку йортына керүчеләр ун-унбиш елдан соң күп булачак, янәсе. Шулай, ул ун-унбиш ел үткәнче хасил булачак бушлыкны исәпкә алмадык та ди. Ләкин бүген ачыла торган татар мәктәп-гимназияләре, аларда укыту рәвеше, әзерлек дәрәҗәсе мондый оптимистик фаразларга юл калдырмый.

Мәктәпнең абруен иң элек аңа укырга килүчеләр билгели. Җәмәгатьчелек фикере — лакмус кәгазе кебек: яхшы белем бирә, дигән даны чыктымы, ата-аналар баласын нәкъ шул мәктәпкә бирергә тырыша башлый. Моның өчен махсус үгет-нәсихәт тә кирәк түгел. Мәктәпне тәмамлап чыккан балаларның ВУЗга керү-кермәү проценты теләсә нинди яхшы рекламадан да тирәнрәк тәэсир ясый.

Җитәкче урыннарда эшләүчеләрнең, фән, әдәбият-сәнгать өлкәсендә хезмәт итүчеләрнең балалары-оныклары бүген дә дәрәҗәле махсус, инглиз, немец, француз телләренең берсен тирәнтен өйрәнә торган мәктәпләрдә укыйлар. Гимназияләрдә аңдыйлар бармак белән генә санарлык. Бирелә күбесенчә ата-аналары шәһәргә яңа килеп урнашкан балалар белем ала. Ә мондый гаиләләр, аларның балалары үз-

ләрenә генә хас үзенчәлекләргә ия катлам тәшкил итә. Гаиләдә аралашу теле булып күп очракта татар теле тора. Ләкин бу балалар, мәктәп тәмамлагач, нигездә ВУЗларга китмиләр. Балалары үсеп җитүгә аларның ата-аналары әле тормышларын көйләп, матди якны ныгытып өлгермәгән була. Алар акча күп төшә торган урыннарга урнашырга тырышалар. Бу балалар өчен рухи як, милләт язмышы түгел, ә кешечә яшәү шартларына ия булу беренче планга чыга. Биредә тагын бер нәтиҗә ясала: баласының яхшы белем алуын теләгән ата-ана балаларын гимназиягә китерергә бик ашыгып тормый икән, димәк, бу уку йортлары аларны кайсы ягы беләндер канәгатьләндерми дигән сүз.

Бу турыда тәфсилләп сөйләп, мин һич кенә дә татар гимназияләре ачуга каршы төшмим, киресенчә, укытуның бу формасы киләчәктә үсәргә, ныгырга, камилләшергә тиеш дип саныйм. Урыс мәктәпләре җирлегендә татар мәктәпләре түгел, ә гимназияләр ачу үзенең дөреслеген раслады инде. Әгәр бу уку йортлары татар мәктәбе буларак кына эшли башласа, аларга балалар җыю бик авырлык белән барган булыр иде.

Аннары, татар мәктәп-гимназияләренең урыс мәктәпләреннән тагын бер өстен ягы бар: алар баланы үзенчәлекле милли мохитка алып керү мөмкинлеге тудыра. Шул мохитта бала уку-өйрәнү аша гына түгел, хәтта бер-берсе белән аралашу аркылы да туган халкы, аның тарихы-тамыры, гореф-гадәтләре турында хәбәрдар була. Милләттәшләре арасында булу урыс мәктәпләрендә еш кына үзен икенче сортлы итеп сизгән укучыны «тигезләр арасында тигез» шартларга куя. Биредә бала үзенә дуслар, аралашу даирәсе таба, бермилләтле коллективта үзен зур халыкның бер вәкиле итеп тоя башлый.

Көн саен татар сөйләмен ишетү, туган телендә сөйләшү ул телгә күнектерә, яраттыра, акрынлап татар әдәбиятына якынайта, татарча фикерләүгә китерә. Болар исә үз чиратында яшь алмашны татар рухы белән сугара, халкының шатлык-кайгыларына битараф булмаган шәхес формалаштыруга өлеш кертә.

Гимназияләрдә татар мәдәнияте белән якыннан таныштыру өчен дә зур мөмкинлекләр бар. Бу уку йортлары татар галимнәре, язучылары, рәссамнары, композиторлары, җырчылары белән тыгыз бәйләнештә торалар, һәрвакыт аларның ярдәмен, рухи таянычын тоеп яшиләр. Мондый бәйләнеш баланың эчке дөньясы формалашкан вакытта аеруча әһәмиятле: бай күңелле, кызыклы шәхесләр белән аралашу укучының тормышка карашын киңәйтә, фикерләвен үстерә, һәрнәрсәгә үз бәясен булдырырга, үз җанын аңларга өйрәтә. Милли музыка, театр сәнгате, музей-күргәзмәләргә йөрү халкыңа мәхәббәт, аның казанышлары белән горурлану хисләре уятуга ярдәм итә. Музыка, сәнгать төрләре буенча түгәрәкләрдә дә турыдан-туры татар мәдәниятенә йөз тотып эшләргә була. Дөрес, бу мөмкинлекләрнең күбесе укытучының теләгенә бәйле булып кала.

Шунысы да билгеле, гимназия дип үзгәртү генә мәктәп базасында оештырылган әлеге уку йортларын мәктәптән яхшы мәгънәсендә аера алмады. Моның объектив сәбәпләре һәркемгә мәгълүм: программа-дәреслекләр юк, аерым фәннәрдән дәрес саны арттыруны укытучыларның күбесе рациональ файдаланмый. Укытучыны гаепләп тә булмый, ул галим дә, методист та түгел. Аның төп бурычы — әзер материал ярдәмендә балаларга белем һәм күнекмәләр бирү. Шуннан башкасына укытучының мөмкинлекләре, көче, бигрәк тә вакыты җитмәскә мөмкин. Бу ике эшне бик сирәк укытучылар гына бергә кушып алып бара алалар. Шулай икән, гимназия укытучысына бүген үк махсус әзерләнгән ярдәмлекләр, дәреслекләр, программалар кирәк. Ә инде аларны тиз өлгертерлек кешеләребезнең аз булуы — монысы тагын шул ук милли кадрлар мәсьәләсе.

Шулай ук гимназиягә укытучылар җыю, фәннәрне татарча укыту мәсьәләсе дә бүген көн тәртибендә тора. Гимназия үзенең беренчел мәгънәсендә шушы дәрәҗәдәге уку йорты таләпләренә җавап бирә торган кадрлар белән тәэмин ителгән булса гына, максатка ярашлы эшли ала.

**Гимназия шулай ук иҗади эшләүче укытучыларга да ирек бирмәде. Программадан читкә китеп булмый, чөнки һәрвакыт тикшереп торалар. Гимназиянең үзенең нинди дә укыту юлларын эзләү мөмкинлеге юк. Беренчедән, унберенче сыйныфка кадәр 300—800 бала җыелган уку йортында тәҗрибәләр үткәрү бик авыр.**

**Ләкин бу саналган сәбәпләр, җитешсезлекләр — һәр күчеш чорына хас кимчелекләр, арыйырга мөмкин булган кимчелекләр. Иң төп җитешсезлек, бөтен авырлыкларның чишмә башы — татар мәктәбенең кыйбласы, үзенә генә хас юнәлеше юклык. Шул юнәлеш булмадымы — аның үз йөзе, үз асыл мәгънәсе дә юк дигән сүз. Ул урыс мәктәбенең күчермәсе генә булып кала. Әлбәттә, мондый мәктәптә бала татарча сөйләшә, фәннәрне татарча укый. Ләкин уку-укыту, тәрбия эшенең эчтәлеге ике тамчы су кебек, урыс мәктәпләренекенә охшаш булып чыга. Чөнки аерым фәннәр буенча программалар-дәреслекләр урыс мәктәпләренекеннән тәрҗемә итеп яки аларга якынайтып төзелгән.**

Мондый уртаклык егерменче-утызынчы еллардан ук башлана. Кешеләрне режим теләгән рәвешттә бердәм калыпка салып тәрбияләү өчен, революциядән соң бердәм мәктәпләр системасы төзелә, укыту дәүләт күрсәткән юнәлештә алып барыла башлый.

Дөрес, мәктәп һәрвакыт тормыш, дәүләт һәм сәясәт белән күпмедер күләмдә бәйләнештә була, ләкин 1917 елга кадәр ул үзенең мөстәкыйльлеген дә саклый. Революциядән соңгы үзгәрешләр мәктәпне дәүләт идеологиясенә сукырларча буйсынырга мәҗбүр итә. Бердәм мәктәп төзү милли сәясәт һәм халыкларны бер телле совет кешесе ясау идеясенең бер чагылышы була. Моның өчен өстән фәрман белән бертөрле уку планнары, программалары эшләтелә. Милли педагогик әдәбият «җиз иләк» аша уздырыла, аның бик аз өлешен генә кулланырга рөхсәт ителә. Бу хәрәкәтнең тарихына тукталу «бердәм мәктәп»нең юнәлешен ачуга ярдәм итәр.

Совет власте урнашуның беренче көннәреннән ук мәгариф өлкәсендә мәктәпне социалистик үзгәртеп кору, изүче сыйныфларны юк итү коралына әверелдерү бурычы куела. Тәрбия эше хезмәт тәрбиясенә кайтып кала. Бер үк вакытта укуукыту эшендә, үткәннең рухи мирасыннан баш тартып, яңа пролетар аңны үстерерлек җирлек әзерләү башлана.

1923 елдан башлап комплекслы программалар кертелә. Аларның төп үзенчәлеге — укытуны партия сәясәте, илне революцион үзгәртеп кору белән бәйләү була. Бөтен предметлар партия мәнфәгатьләреннән чыгып укытыла, аларга коммунистик идея юнәлеше бирелә. Мәктәп өчен иң мөһим өйрәнү объекты итеп җәмгыять һәм табигать билгеләнә. Педагогика нигезенә җитештерүче көчләр, җәмгыять һәм сыйнфый көрәш теориясен өйрәнү, хезмәт тәрбиясе, В. И. Ленинның тормышы һәм революцион эшчәнлеге мисалында тәрбияләү кебек бурычлар ята. Яңа коммунистик буын тәрбияләү хәрәкәте әнә шулай башлана. Балаларны кеше турында түгел — ә үз сыйныфы, иҗтимагый күренешләр турында уйларга өйрәтү, шәхеснең роле кечерәю, коллектив хисе, атеистик караш тәрбияләү... 1927 елның язында Казанда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының беренче Бөтенсоюз конференциясе уздырыла. Төп докладта: «Совет мәктәбенең төп бурычы — коммунистик тәрбия бирү һәм коммунизм төзүчеләр әзерләү», — диелә. Алга таба мәктәп шушы бурычны үтәү өчен барысын да эшли. Үткәннең рухи мирасыннан баш тарту мәктәпкә дә тирән үтеп керә. Утызынчы елларның вульгар социологлары мәктәпне дәүләт идеологиясен сеңдерүнең бер чарасы итеп карыйлар. Гасырлар тәҗрибәсенә «буржуаз» дигән ярлык тагыла. Шушы чорда башланган урыслаштыру сәясәтенең яңа дулкыны соңрак милли мәктәпне тәмам күмеп китә.

Утызынчы-кырыгынчы елларның кешелексез каты җәбер-золымы да мәктәпне читләтеп үтми. Сталин культы шәхесне дәүләт машинасының шөребенә әйләндерә, ә бу «эш» мәктәптән, балалар бакчасыннан ук башлана. Революциягә кадәрге татар тормышы гел кара буяулардан, кешенең кешене эксплуатацияләвеннән, халыкның изүчеләргә нәфрәтеннән, «надан-аңгыра» муллалар, «әхлаксыз» байлар көчләвеннән торган итеп күрсәтелә. Тәрбия эше, нигездә, совет чынбарлыгына дан җырлау, бәхетле балачак өчен коммунистлар партиясенә рәхмәт хисләре белән сугарыла. Мәктәп алган әлеге юнәлеш сиксәненче еллар ахырынача түгелми-чәчелмичә килеп җитә. Иң аяныч шул: дәүләт идеологиясенә, хөкүмәт сәясәтенә сукырларча буйсыну мәктәптә гуманитар предметлар дөньясына гына түгел, хәтта төгәл фәннәргә дә үтеп керә.

Шулай итеп, революциядән соң төзелгән «бердәм мәктәп» тулысы белән дәүләт таләпләренә җавап бирүче, рәсми идеологиягә дан җырлаучыга әверелә. Ул дәүләт-

кә кирәк күләмдә генә белем бирә башлый, хәтта тәрбия эшен дә гаилә җилкәсеннән алып, үзенекенә күчерә һәм коллективта, билгеле бер стандарт буенча, дәүләт машинасын ныгытучылар әзерли. Мәктәпнең төп юнәлеше, кыйбласы — берсүзсез буйсынучы төссез масса тәрбияләүгә кайтып кала.

Җәмгыятьтә 1985 елда башланган үзгәртеп кору процессы, тормыш үзе куйган таләпләр мәктәпкә дә кагылмыйча калмый. Без бүген белем бирү системасының бу таләпләрдән нык артта калуын аңлыйбыз. Ләкин мәгариф — реформаларга иң авыр кушыла торган өлкә. Хәтта 1991 елгы август фетнәсе алып килгән үзгәрешләр дә мәктәпне дәүләт тарафыннан көчләп тагылган кыйбласыннан яздырмады. Дөрес, бу хәлләргә, тормышыбызда барган үзгәрешләргә аерым уку йортлары күз йомып кала алмады. Кайберләре, «дөньянык белеп булмый» дип, көтеп тору позициясенә басты. Кайсылары элекке юнәлешне, «кызыл» линейкаларны, совет халкы һәм туган партиягә дан җырлауны дәвам итә. Балаларда икейөзлелек тәрбияләүнең моннан да шәбрәк тагын нинди ысулы бар икән. Ә күп кенә мәктәпләрдә бу урын, элекке кыйбла урыны, буш. Монысы инде тагын да куркынычрак. Ул урынны тутырырга теләүчеләр мәктәп стенасын атлап чыгута ук көтеп тора.

Әйе, бу фикерләр, мәктәпне үзгәртүдә юнәлеш эзләү яңалык түгел, диючеләр булыр. Чыннан да, яңалык түгел. Инде берничә ел мәгариф эшен өйрәнәбез. Төрек, американ, инглиз, гарәп мәктәпләре белән танышабыз, журналларда чит ил педагоглары белән әңгәмәләр басыла. Яңа төр мәктәпләр саны арта. Төрек лицейлары, инглиз колледжлары... Укыту предметларын һәм сәгать санын үзгәртү, яңа алымнар кертү... Ләкин мәктәп һаман канәгатьләндерми. Бигрәк тә милли мәктәп төзү идеясе һавада асылынып тора бирә. Чөнки бер халыкка белем бирү эшен шул халыкның тормыш шартлары, табигый сәләтләре, тарихы һәм традицияләре белән бәйләп оештырырга кирәк. Милли мәктәп чит тарих һәм чит тәҗрибә нигезендә тумый, чөнки ул тәҗрибә билгеле бер урында, билгеле бер вакытта, мохитта эшләнгән, шул дөнья таләпләренә һәм рухына туры китереп корылган. Шул халыкның эчке дөньясына хас сыйфатларны туплаган, шул милләтнең рухи халәтеннән үсеп чыккан. Димәк, милли мәктәп, эшли торган, файда китерә торган җанлы милли мәктәп төзү өчен үз халкының психологиясен, тарихын, хәзерге тормыш хәлен һәм җәмгыятьне өйрәнү зарур.

«Бердәм мәктәп» биргән нәтиҗәләр дә гыйбрәтле. Мәктәпнең педагогик бурычларын сәясәт белән үрү, яшәп килүче идеологиягә яраклашу аяныч хәлләргә китерде. Димәк, уку-укыту һәм тәрбия эшен, әхлакны һәм мәктәп программаларын дәүләткә хезмәтче итеп кую мәктәп өчен үлемгә тиң. Мәгариф өлкәсендәге бүгенге кризис та шуның бер дәлиле.

Шулай итеп, бер мәктәпкә яңа тормыш сулышы өрергә, яңа идеаллар кертергә кирәк, дигән фикергә килеп җиттек. Ул сулыш, ул идеалларны билгеләү өчен милли мәктәп тарихына мөрәҗәгать итеп карыйк.

Революциягә кадәр татарларның бик яхшы эшләп килә торган, үзенчәлекле белем бирү системасы була. Безнең мәктәпләребез тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Мәктәп-мәдрәсәләр, кагыйдә буларак, мәчетләр каршында эшли. Алар хисабына түгел, бәлки мәхәллә җыйган акчага, төрле бүләк рәвешендә килгән байлыкка (бүгенгечә әйтсәк, спонсорлар ярдәмендә) яши. Димәк, мондый мәктәп матди яктан дәүләткә бәйсез була. Күп уку йортларында математика, физика, химия, география, тарих, фәлсәфә, мантыйк, психология кебек предметлар укытыла. Татарлар арасында грамоталылык югары була. «Һәр ата баласын тизрәк укытырга бирергә тырыша» (А. Сперанский. Казан татарлары. Казан, 1914. 28 б.). Уку йортларыннан муллалар гына түгел, галимнәр, язучылар, журналистлар, укытучылар да чыга.

Мәктәп тарихыбыз ерак гасырларга барып тоташа, дигән идек. Белем бирү ислам дине белән тыгыз бәйләнештә бөреләнә, нигезләнә башлый. Ислам дине кабул итә торган әхлак таләпләрен, кануннарын өйрәтү, хак мөселман тәрбияләү оеткысы мәктәпнең милли йөзен билгеләүче беренче бурыч булып тора. Җәмгыятьнең әхлакый принципларына берсүзсез буйсыну уку йортына шулай ук ислам дине аша үтеп керә. Милли мәктәп, үсешенең беренче адымнарыннан ук, төп бурычы итеп Кеше тәрбияләүне аерып чыгара. Дини схоластика белән янәшә кеше рухын, кеше җанын, эчке дөньясын камилләштерергә омтылу яши. Остаз, мөгаллим кешенең максаты билгеле бер күләмдә белем һәм мәгълүмат бирү генә түгел, бәлки үзенең

дөньяга карашы, яшәешне кабул итүе аша шәкертләрен тәрбияләү дә була. Бу турыда методик тәкъдимнәр, фәнни-педагогик хезмәтләр сакланып калмаган. Ләкин XIII—XVIII йөзләрдә язылган китапларда (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Мәхмүд бине Галинең «Нәһҗел-фәрадис»е, Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия»се, «Нәсихәтес-салихин», «Кисекбаш китабы» һ. б.) тәрбия, әхлак, фәлсәфә, белем бирүгә караган фикерләр бар.

XVIII йөз ахыры — XIX йөз мәктәпкә үзгәрешләр алып килә. Мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту тәртибенә яңалыклар кертергә омтылыш сизелә. XIX гасыр уртасында бик күп проектлар языла. Гыйлем аша дөньяны үзгәртү өчен уку йортларында фәнни мәгълүматларга нигезләнгән уку китапларын булдыру кирәк. Татар милли мәктәбе өчен, гарәп, төрек, урыс дәреслекләрен өйрәнеп, милли үзенчәлекләрне исәпкә алып, махсус төзелгән уку китапларын кертү ихтыяҗы туа.

Шундый дәреслекләрнең берсе — К. Насыйриның 1860 елда басылып чыккан «Буш вакыт» китабы. Аның төп максаты — балаларга дөнья, табигать турында беренчел мәгълүмат бирү, фәнни төшенчәләрне балаларча гади, җиңел тел белән аңлатып күрсәтү. Үз вакытында зур уңыш казанган бу китап бер төркем энциклопедик, ягъни тормыш-яшәеш турында мәгълүмат туплаган дәреслекләр төзелүгә башлангыч була. Мәсәлән, 1872 елда В. Радлов «Буш вакыт»ка охшашлы «Белек» исемле уку китабы төзеп бастыра. Анда астрономия, биология, география, зоология, ботаника, минерология кебек фәннәрдән белем нигезләре туплана. Безнең өчен шунысы әһәмиятле: танып-белү характерындагы материал белән янәшә, әлеге китапларда әхлак төшенчәләре турында сүз алып барыла, бу турыда кызыклы хикәятләр бирелә.

XIX гасыр ахырында ислам дине идеологиясенең үз эчендә дини-реформаторлык агымы барлыкка килә. Аның тарафдарларын җәдитчеләр дип йөртә башлыйлар. Бу вакытны чын мәгънәсендә эзләнү чоры дип атарга мөмкин. Әкренләп мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту рәвеше үзгәрә. Ләкин алар башлангыч юнәлештә баруны дәвам итәләр. Уку-укыту һәм тәрбия эшендә төп игътибар Кеше, Шәхес тәрбияләүгә бирелә. Гуманитар предметлар — әдәбият, тел, фәлсәфә, әхлак, әхлак теориясе һ. б. буенча дәреслекләр билгеле бер шәхес идеалын күз алдына бастыра, шул идеал сыйфатларын һәр балада булдыру өчен хезмәт итә. Дәреслек-хрестоматияләр белән танышу әлеге идеалга хас сыйфатларны тулырак күзалларга ярдәм итә. Укымышлы, игелекле, киң күңелле, ярдәмчел, тырыш, юмарт, олыны олылый, кечене кече итә, ата-ана хакын хаклый, дөресен сөйли, намуслы, җаваплы... Бу сыйфатлар дәрестән — дәрескә, дәреслектән — дәреслеккә, предметтан-предметка күчеп өйрәнелә, мисаллар өстендә ныгытыла. Моңа дин дәресләренең дә күп өлеше кешедә шундый сыйфатлар тәрбияләүгә юнәлтелгән булуын өстик. Гомумән, гуманитар фәннәрнең күбесе дини китаплардан, Коръәннән үсеп чыга да инде.

Бу юнәлеш төгәл фәннәр укытуда да әйдәп барудан туктамый. Математика, химия, геометрия, физика, астрономия һ. б. өлкәләрдә татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен татар галим-мөгаллимнәре тарафыннан махсус дәреслекләр эшләнә. Алар милли мохитны, үзаңны, ихтыяҗны, традицияләр һәм үзенчәлекләрне исәпкә алып төзелә. Алай гына да түгел, һәр предмет буенча уннарча дәреслек басылып чыга — сайлап ал да укыт! Бүген без хыялда гына йөртә торган альтернатив дәреслек-программалар, үз галимнәребез төзегән дәреслекләрнең мәктәпкә барып ирешүе кебек проблемалар инде гасыр башында ук куелган һәм хәл ителгән булган лабаса.

Җыеп кына әйткәндә, 1917 елга кергәндә татар мәктәбенең гасырлар сынавын үтеп камилләшкән, үскән, ныгыган юнәлеше, кыйбласы була. Ул — мәрхәмәтле, ярдәмчел, белемле, намуслы, игелекле, милләтен яратучы һ. б. шундый сыйфатларга ия Кеше, Шәхес тәрбияләү.

Дөрес, егерменче елларда төзелә башлап, бүгенге көнгәчә яшәп килүче «бердәм» мәктәп тә үз бурычларының берсе итеп кеше тәрбияләүне куя. Ләкин җәмгыять, сыйныф ихтыяҗларын үзенекеннән өстен куя торган, коммунизм идеясенә бирелгән, шул юлда берни алдында да тукталып калмый торганын... Әхлаклы, гуманлы шәхес дигәндә нәрсә күз алдында тотылуын ачыграк күрсәтү максаты белән, бу урында тагын бер мисал китереп үтәсе килә: «Гуманлылык — кешенең шәхес буларак кыйммәтен таный торган тарихи үзгәрештәге система... Марксизм... гуманизмның яңа концепциясен — пролетар яки социалистик гуманизмны формалаштырды. Марксизмның сыйнфый көрәш теориясе, әгәр дә шуннан башка социаль

мәсьәләләрне хәл итеп булмый икән, күпчелек өчен азчылыкның буйсынмавын революцион көч куллану юлы белән бастыруны аклый»,— дип яза Зур Совет Энциклопедиясе (Өченче басма, М., 1972. 7 том, 444—445 бб.) Биредә инде барысы да аңлашыла: кан коюны яклый торган системаның гуманлы була алмавын, ә гуманлылыкның көч куллануга корыла алмавын исбат итеп торуның кирәге юк.

Шулай итеп, татар мәктәбенең үз кыйбласына, үз мәсләгенә әйләнеп кайтуы хәерле. Әлбәттә, ул нәкъ менә XX гасыр башында өзелеп калганча ук булмас, чөнки тормыш бер урында тормый, үсә-үзгәрә, мәктәптә укытыла торган предметларның да фәнни нигезе үсештә. Ләкин әхлак тәрбиясе, XX гасыр башында күзалланган сыйфатларга ия шәхес тәрбияләү идеясе искермәгән. Шул идеягә нигезләнеп татар милли мәктәбен торгызу, тәҗрибә-традицияләрне файдалану мөмкин эш.

Мәктәп ул — бала тормышындагы билгеле бер вакыт аралыгы. Соңрак бүгенге укучыбыз җәмгыятьнең бер әгъзасына әвереләчәк, гомуми яшәештә үз урынын алачак, үз кылган гамәлләре өчен үзе җавап бирәчәк, дөнья нигезендә яткан Яхшылыкка үз өлешен кертәчәк. Яшәештә яхшылык юкка чыкмасын өчен җәмгыять мәктәптән бу юнәлештә күпне таләп итәргә хаклы. Хәзерге җәмгыятьнең әхлакый үсеш дәрәҗәсе никадәр генә түбән булмасын, мәктәп һәрвакыт аның дәрәҗәсен күтәрү үзенә бәйле булуын, һәм күп очракта бары тик уку йортына гына бәйле булуын һәрчак истә тотарга тиеш. Бүген, базар мөнәсәбәтләренә күчеп барганда, җәмгыятебездә тискәре күренешләр чәчәк аткан бер чорда, әхлак тәрбиясен күтәреп чыгу сәер тоелырга да мөмкин. Ләкин аны күтәрмәү шул җәмгыятьнең тагын да түбән тәгәрәвенә китерер иде.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Бүгенге уку-укытуның торышы, алдагы яшәү ихтыяҗлары өчен булмыйча, күп очракта мәктәпнең үзенә генә кирәк булуын күрсәтеп тора. Мәктәп программалары бик катлаулы, авыр, аның аерым өлешләре еш кына билгеләнгән күләмдә мәгълүматлар биреп бетерүне күздә тота. Материалның катлаулылыгы үзләштерү өчен бирелгән вакыт белән тәңгәл килми. Укытучы белем бирүне башлыча тикшерү килгәндә һәм имтиханнарда укучы мөмкин кадәр күбрәк белүен күрсәтерлек итеп оештырырга мәҗбүр. Димәк, мәктәпнең бурыч-максатлары баланы яшәргә әзерләү белән ярашмый. Шуңа күрә уку йортлары алдына укучыны тормышка әзерләү бурычы кую мөһим. Ә бу бурычны үтәү идеалдан, тәрбияви юнәлештән башка мөмкин түгел. Гомуми белем бирү мәктәбе гыйлемле, акыллы кеше идеалына йөз тотса, мәктәпнең билгеле бер максаты булачак, бөтен укытучылар да шуңа ирешү өстендә эшләячәкләр. Ләкин безнең «бердәм мәктәп»тә белем бирү идеясе дәүләт таләп иткән ихтыяҗларны үтәү белән бәйләнештә генә аңлашыла, дигән идек инде. Шуңа күрә әхлаклы, белемле кеше әзерләү идеалы тормышка аша алмый. Укучыны фәннәрнең нигезләре белән таныштыру әлегә максатка ирешүнең бер юлы гына икәнлеге игътибардан читтә кала. Ә бит мәктәпнең кыйбласын билгеләү милли үзенчәлекләрне, традицияләрне исәпкә алып башкарылырга тиеш.

Бу мәсьәләләр татар мәктәбен генә түгел, башка милләтләрнең уку йортларын да борчый. Башка халыкларда да милли мәктәпнең мәсләген табу, аны үстерү юлларын эзләү бара. Бигрәк тә урыслар бу юнәлештә күп көч куя. Аларда төрле-төрле тәрбияви максатларны күздә тоткан йөзләрчә шәхси мәктәп ачылды. Араларында табигатьне яратырга өйрәтү, сәнгатьне тирәнтен аңларга күнектерү, кешенең рухи дөньясын баету, тормыш күренешләренә фәлсәфи якын килергә ярдәм итүне максат итеп куйганнары да бар. Мондый юнәлеш алган уку йортлары башка милләт балаларының ата-аналары күңеленә дә хуш килә. Әгәр без, үз тарихыбыз-тамырыбызны өйрәнеп, милли мәктәбебезне торгызу эшенә керешмәсәк, бераздан инде соң булуы бар. Бүгенге ата-аналар татар мәктәп-гимназияләренең оешу процессын бик кызыксынып күзәтә. Ләкин заман таләпләренә җавап бирә, милли үзенчәлекләрне исәпкә ала торган татар мәктәбе бүген оешмаса, иртәгә инде анда укытырлык укытучылар да, укырлык укучылар да калмаска мөмкин. Шуңа күрә төрле формадагы милли уку йортлары — шәхси мәктәпләр дә, гимназияләр, колледжлар да ачылсын. Тик аларның үз йөзе, үз кыйбласы ачык булып күренеп торсын, үсәр юлы киң һәм якты булсын иде. Шул чакта гына милләтебезне җитәкләп алга барырдай кадрлар да булыр, татар да яшәр!

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
КДУ укытучысы.

**Гүзәл**

**Вәлиева-Сөләйманова**

# ИДЕЛ—УРАЛ БУЕНДА МӨСЕЛМАН МӘДӘНИЯТЕ

«Мөселман мәдәнияте» төшенчәсе ислам динен тоткан халыкларның сәнгатенә хас булган стиль барлыкка китерүче универсаль сыйфатларны ача. Мөселман дөньясы сәнгатенең уртаклыгы вакыт ягыннан да, мәйдан ягыннан да күренә. Билгеле бер сыйфатлары уртак булган мөселман мәдәнияте тарихи яктан оешкан географик төбәкләрнең һәм милли сәнгать мәктәпләренең үзенчәлекләрен дә үз эченә ала.

Мөселман дөньясында үзенчәлекле географик төбәк дип казан татарларының милли мәдәнияте формалашкан Урта Идел-Урал буйларын атарга мөмкин. Ислам дине 922 елда рәсми рәвештә кабул ителгән бу төбәккә карата «мөселман сәнгате» дигән атама, безнеңчә халык авыз иҗаты, милли гореф-гадәтләр белән бәйләнүдән бигрәк югары катлауларның зәвыкләрен һәм рухи ихтыяҗларын чагылдырган шәһәрчә профессиональ, сәнгати-һөнәри традицияләргә карый. Әмма мөселман мәдәниятенең йогынтысы бу якларны Рәсәй яулап алганнан соң авылларда үсә башлаган төрле һөнәрләрдә дә чагылыш таба. Ул һөнәрләргә элеккеге шәһәр мәдәнияте һәм һөнәрчелеге традицияләре нык йогынты ясый.

Идел-Урал буенда мөселман мәдәнияте сыйфатлары эзлекле рәвештә Идел-Кама Болгарстаны (X—XIII гасырлар), Алтын Урда (XIII-XIV гасырлар), Казан ханлыгы (XV-XVI гасырлар) кебек дәүләтләрнең үсеш чорларында һәм Рәсәйгә бәйлелек дәверендә чагылыш таба. Татар-болгар мәдәниятенең үсеше Якын һәм Урта Көнчыгыш, Кырым һәм Кавказ арты, барлык гарәп-мөселман дөньясы мәдәниятләре белән тыгыз аралашып бара. Бер үк вакытта татарларның төрле төбәк төркемнәре үзара йогынтысы, сәнгатьтә бердәм милли стиль формалашу дәвам итә. Нәтиҗәдә, Идел буе татарларының үзенчәлекле мәдәнияте формалаша. Билгеле бер тарихи заманда ул мөселман мәдәниятенең гомуми үсеш кануннары белән сыйфатлана.

Идел болгарларының гамәли сәнгать әйберләрендә гарәп язмалары күренә башлау төбәктә мөселман йогынтысы көчәюенең беренче дәлиле. Бу язулар мәҗүси болгар кабиләләре арасында ислам дине таралу белән бер үк вакытта барлыкка килә. Ислам динен кертүнең баштагы чорларында гарәп язуы төрки рун язуы белән янәшә кулланыла. Иң борынгы эшләнмәләр XIII гасырга карый. Борынгы Болгар шәһәрләре каберлекләрендә (Олы Тархан, Тәнки, I Измәр һ. б. VIII-X гасырлар) болгар осталары язган гарәп язулары, шулай ук рун язуларына охшаш тамгалар белән бизәлгән эшләнмәләр табылды. Алар гарәп язуының болгарларда әле ислам дине рәсми кабул ителгәнгә хәтле үк кулланыла башлавын раслый.

721—732 елларда Төньяк Кавказдан Идел буена килгән кайбер болгар кабиләләренең (сувар, берсула) инде мөселманнар булганлыгы мәгълүм. Идел болгарлары арасында ислам диненең әле рәсми рәвештә кабул ителгәнгә кадәр үк таралуы хакында 913 елда Гаркави һәм X гасырның бүтән гарәп авторлары, әйтик, Әхмәт ибн-Фадлан да хәбәр итә.

Идел елгасы Идел Болгарстанын Каспий диңгезеннән көньяктарак яшәүче халыклар белән бәйләп торучы иң төп юлларның берсе була. Шушы бөек елга, кәрван юллары күп гасырлар буена болгарларның, гарәпләрнең, иранлыларның,

шулай ук Якын һәм Урта Көнчыгышның бүтән халыкларының бер-берсе белән тыгыз аралашуын тәэмин итеп тора. Идел буенда Болгар һәм Хазар дәүләтләре арасында, бигрәк тә, ислам динен тараткан чорда (VIII-X гасырлар), элемтәләр тагын да ныгый төшә. Язма мәгълүматларга караганда, Хазар каганлыгының утыз мәчетле башкаласы Итилдә мөселман сәүдәгәрләре, һөнәрчеләре һәм яллаган солдатлары яши. X гасырда, Хазар дәүләте Хәрәзем мәнфәгатьләре йогынтысында яшәгән заманда, исламны аның хакимнәре, элеккеге яһүдиләр дә кабул итә. Идел Болгарстаны шулай ук Хәрәзем һәм анда кабул ителгән мөселман йолалары йогынтысында була. Идел Болгарстанына илчелек җибәргән Багдад хәлифе мөселман гореф-гадәтләрен җәюне максат итеп куя.

Мөселман мәдәниятенең сыйфатлары, мөгаен, Алтын Урда чорындагы болгар-татар архитектурасы үсешендә иң нык чагылыш тапкандыр. Идел Болгарстаны гаять зур империянең бер өлеше, ә Болгар шәһәре бер үк вакытта Алтын Урда башкаласы булып та китә. 1722 елда Петр I килгән вакытта монда җитмешкә якын таш корылма сакланып калган була. Алар арасыннан Җәми мәчетнең «Кара ташпулат» диванханәсе, Кече манара, Хан төрбәсе, Олы һәм Кече төрбә хәрабәләре әле дә исән. Алар һәммәсе дә Борынгы кала урынында XVIII йөздә нигез салынган урыс православие монастыре хаҗәтләре өчен файдаланылган. Хәзерге вакытта кала мәйданында архитектура-сәнгать тыюлыгы булдырылган, таштан салынган истәлекләрне яңарту һәм саклап калу чаралары үткәрелә.

Әл-Бәлхи, ибн-Рустә, ибн-Хаукәл һәм бүтәннәрнең язмаларыннан ул заманнарда ук Болгарның сарайларга, мәчетләргә, мәдрәсәләргә, кәрвансарайларга, мунчаларга һәм башка корылмаларга ия гаять зур кала булуы мәгълүм. Алтын Урдага кергән илләр белән тыгыз мәдәни элемтәләр XIII-XIV йөзләрдәге Болгарстанның сәнгате һәм архитектурасында яңа сыйфатлар барлыкка килүгә ярдәм иткән. Болгарстан, Алтын Урданың бер өлеше буларак, сәлҗүкләрнең Кече Азиясе, мәмлүкләрнең Мисыры, Сүрия һәм Кырым белән тыгыз сәяси, мәдәни һ. б. элемтәләр тота. Яңа элемтәләр Болгар каласы һәм Алтын Урданың бүтән калалары архитектурасында ачык чагылыш таба һәм, киресенчә, төрки (болгар-кыпчак) сыйфатлары мәмлүк Мисыры сәнгатендә очрый. Археологик казулар вакытында табылган Мисыр тукымалары, чигелгән әйберләр, бизәнгечләр, тәңкәләр һәм бүтән нәрсәләр, болгар биналарының конструктив-декоратив системасындагы Мисыр архитектурасы элементлары кебек үк, үзара мөнәсәбәтләрнең дәлиле булып тора. XIII-XIV гасырлардагы корылмалар мөселман архитектурасына хас күләм-пространство нисбәтләренчә салына. Алар сәлҗүкләр чорындагы Кырым, Кече Азия һәм Кавказ арты архитектура мәктәпләре истәлекләрендә дә очрый. Бу гыйбадәт һәм хәтер корылмаларының төзелешен сәнгати үзенчәлекләрен тикшерүгә байтак галимнәрнең хезмәтләре багышланган. Аларны җентекләп анализлап тормыйча, шунысын гына әйтеп үтик: сакланып калган биналар, күбесенчә, квадрат рәвешендә төзелгән. Мөселман архитектурасына хас булган тромплар аша алар куб рәвешендәге нигездән сигез һәм уналты кырлыга күчеп, ярым шар рәвешендәге гөмбәз яки пирамида рәвешендәге чатыр белән тәмамлана. Алар арасында Җәми мәчете озынча өчпочмак рәвешендә булып, биш рәт аркылы баганалар белән бизәлгән, әрлекләр белән ныгытылган. Мөселман мәдәнияте сыйфатлары «Көнчыгыш классицизм» принципларында чагылыш таба. Биредә композициянең үзәкләштерелгән алымнары һәм архитектура биналарына геометрик формалар бирү, шулай ук болгар биналарын гөмбәзләр, чатыр, ярым гөмбәз һәм пирамидалар рәвешендә төзү, баганаларга аркалар кую, «мәмлүкләрдәгечә» , өчпочмаклы кыеклар һ. б. кулланыла. Сакланып калган материаллар, шул исәптән археологик материаллар да, архитектура декорацияләренең төрле төрләре булуы хакында сөйли. Болар: фреска бизәкләре, эчке диварларны, төрбәләрне майолика, мозаика белән бизәү, ташны кисеп бизәү, гипстан кою. Бизәкнең геометрик сызыклар, үсемлекләр рәвешендәге формалары, «куфи», «нәсх» стилендәге гарәп язулары белән бергә, биналардагы ишек-тәрәзә уемнарын, кәрниз һ. б. кебек аеруча мөһим өлешләргә игътибарны юнәлтү өчен кулланылган. Болгар архитектурасының ташка чокып ясалган бизәкләре композициясенең төгәллеге һәм ачыклыгы белән аерылып торган. XIII-XIV гасырлардагы Якын һәм Урта Көнчыгыш архитектурасыннан аермалы буларак болгар корылмаларында мойолика белән тышлау, порталларны челтәрләү кебек декоратив чаралар, күрәсең, зур урын алып тормаган. Таш һәм кирпечтән салынган корылмаларның таштан уеп, гипстан коеп эшләнгән бизәкләре тәэсирле булуына күбрәк әһәмият бирелгән. Ташка чокып бизәк ясау сәнгате, бигрәк тә, болгар-татар каберташларында (XVI-XVIII йөзләр) ачык

күренә, алар купшы орнаментлар һәм гарәп язулары белән бизәлгән. Гарәп язулары кабертешларның алгы, арткы, ә кайвакыт, хәтта ян якларын да каплаган. Ташка чокып бизәк ясаганда иң яраткан мотивлар гөлчәчәк, хөрмә агачы, чәчәк һәм яфрак сурәте, бәхет төеннәре һ. б. булган. Аларның күбесе Якын һәм Урта Көнчыгыш сәнгатендә киң таралган, әмма алардан аермалы рәвештә, болгар бизәк композицияләре иркенрәк шәкелле, күп төрлерәк, формасы буенча капма-каршы һәм азрак стильләшкән. Алар кануннардан һәм искелек тенденцияләреннән күбрәк азат. Якын Көнчыгыш, Урта Азия орнаментларындагыча Болгар бизәкләре композиция ягыннан гадирәк, аларда абстракт геометрик сурәтләр юк дәрәҗәсендә. Мондый бизәк системасы декоратив-гамәли сәнгатьнең бүтән төрләренә хас.

Кече Азия, Азәрбайҗан, Кырым һәм Идел Болгарстанының сәлҗүкләр һәм Мисыр мәмләкләре чорындагы мөселман таш корылмаларына хас «сәлҗүк бароккосы» сыйфатлары Казан ханлыгы архитектурасында һәм сәнгатендә үсеп китә. Әмма болгар сәнгатенең стиль сыйфатлары төрлелеге — кисеп эшләнгән архитектура декорациясе, канунар белән кысрыкланмаган орнамент ясау системасы XVIII—XIX йөзнең агач мәчетләре һәм чокып язылган кабертешлар бизәлешендә дәвам итә.

Баштарак Болгар әл-җәдид исемен йөрткән Казан каласы, Алтын Урда һәм Идел Болгарстаны традицияләренә таянып, XV—XVI йөзләрдә иң нык чәчәк ату чорын кичергән Идел буе мөселман мәдәниятенең үзәгенә әйләнә. Язма чыганаклардан Казан ханлыгында мәдәни, рухи һәм дини тормышның чәчәк атуы, аның атаклы муллалары, мәдрәсәләре булуы мәгълүм. Муллаларның күбесе Иранда, Бохарада һәм Сәмәркандтә белем алганнар. Суфилар шигъриятенең һәм төрле һөнәрләрнең, мәһабәт архитектураның, декоратив сәнгатьнең чәчәк атуы да билгеле. Бу чорда ханлык белән Госманлы Төркиясе арасында иң тыгыз элемтәләр урнаша. Кайбер төрек архитекторлары һәм һөнәрчеләре Казанда, хан сарае каршында эшли. Татар риваятьләрендә, урыс елъязмаларында чагылып, Казан Кремле корылмалары, шул исәптән, Кол Шәриф исеменә бәйле Җәми (аның күп катлы сигез манарасы булган), Нур Гали, Хан мәчетләре, зур мәдрәсәләр, китапханәләр, төрбәләр, хан сарае турындагы мәгълүматлар безнең көннәргәчә килеп җиткән. Алар ак таштан һәм кирпечтән салынганнар. Мәчетләр ханлыкның авылларында да булган.

XVIII йөздә Казан губерниясендә булган француз рәссамы һәм сәяхәтчесе А. Бар ханлык чорындагы бер авыл мәчетенең хәрабәләрен ясап калдырган. Рәсем буенча аркалары булган өч рәт баганалы корылманың озынча өчпочмак төсендәге планын ачыкларга мөмкин. Үзәк гыйбадәт кылу залы кирпеч гөмбәз белән капланган. Бина ике катлы һәм манаралы. Манара аның көньяк-көнбатыш почмагына тоташкан. Манараның сигез кырлы өске өлеше «мәмлек кисеме» аша дүрт кырлыга күчеп, түгәрәк белән тәмамлана. Бинаның диварлары таш белән кирпечне аралаштырып салынган, болай итеп төзү Алгы һәм Кече Азия архитектурасында киң таралган була.

Казан ханлыгының архитектурасы турында Касыйм шәһәрендә (хәзер — Рязань өлкәсе) сакланып калган истәлекләр буенча да хөкем йөртергә мөмкин. Болар — цилиндр рәвешендәге таш манара, ул ярым шар-конус формасындагы гөмбәз белән (болгар корылмалары тибында) тәмамлана; икенчесе — шулай ук таштан салынган Шаһ Гали төрбәсе. Аның фасадын Коръән сүрәсе һәм төрбәнең салыну датасын күрсәткән (1555 ел) таш плитә бизәгән.

Казан Кремлендәге археологик табышлар бу чорда үсеш алган декоратив сәнгать төрләре турында сөйли. Алар арасында гарәп орнаметлары белән бизәлгән алебастр плитәләр, майоликалы чынаяк кирпечләр, чокып бизәлгән таш үрнәкләре. Казан ханлыгының орнамет сәнгате турында без сакланып калган кабертешлар буенча да хөкем йөртә алабыз.

XV—XVI гасыр башы архитектурасында һәм сәнгатендә яңа сыйфатлар күренү татар мәдәниятенең мөселман халыклары йогынтысы астында үсүе белән бәйле була. Биредә Госманлы Төркия мәдәнияте аерым роль уйный. Ул татар җәмгыятенә яңа сәнгати фикерләр үтеп керү белән бәйле яңа күтәрелешне барлыкка китерә. Болгар архитектурасының кырыс геометрик формаларын Казан дәвере мәһабәт һәм хәрәкәтчән композицияләр, конструктивлыкны декоративлык, сәлҗүк бароккосы алмаштыра. Алар шулай ук Кече һәм Алгы Азияда, Азәрбайҗанда, Кырымда һәм өлешчә Урта Азиядә ачык чагыла.

Татар архитектурасындагы яңа казанышлар ханлыкның пыгуына бәйле иде. Әмма милли архитектура 1552 елда Казанны урыс дәүләте яулап алганнан соң тулысынча юк ителә һәм, бары тик XVIII йөздә Екатерина II нең таш мәчетләр

һәм югары катлау өчен таш йортлар салырга рөхсәт биргән Указыннан соң гына, Казан, Уфа, Нижгар, Сембер, Әстерхан һәм Рәсәйнең башка губернияләрендә яңа матур корылмалар барлыкка килә. Болгар һәм Казан татар архитектурасы казанышлары халыкның агач корылмалары йөзендә үсүен дәвам итә, анда ике кыеклы түбәнең уртасыннан күтәрелгән манаралы мәчетләр салына.

Татар дәүләтенең сәяси яктан җиңелүе Идел буенда мөселман мәдәнияте зәгыйфьләнүгә китерә. Әмма үзләренең дәүләтчелеген югалтса да, Идел буе татарлары этник мөстәкыйльлекләрен югалтмый. Алар мөселман Көнчыгышы белән мәдәни, сәүдә һәм бүтән төрле элемтәләрне өзми. Сирәк очрый торган китаплар, кульязмалар Ираннан, Төркестаннан килә, тукымалар, бизәнү әйберләре, савыт-саба Урта Азиядән, Төркиядән һәм Азәрбайҗаннан кертелә. Дини белем бирү югары дәрәҗәдә була: һәр татар авылында мәчет, ә мәчет каршында мәктәп яисә мәдрәсә яшәп килә. Нигездә гарәп телендә укыйлар.

Болгар һәм татар декоратив-гамәли сәнгатен өйрәнүдән мөселман мәдәнияте үсешенең гомуми закончалыклары ачыклана. Урта гасырлар мөселман дөньясында туган сәнгать стиле универсаль була бара, ул матурлык критерийлары, сурәтләү кануннарының уртаклыгында чагыла. Сурәтләүнең «мөселман» кануны (хәлифәт кануны дип йөртелә) сәнгати һөнәрдән туры бәйлелектә була һәм сурәтләү нормаларын, гамәли сәнгать төсендә, каллиграфия һәм орнамент нормалары белән якынайтуны максат итеп куя. Мәсәлән, сәнгать үзенчәлегенең үсеше, мөселманнардагы кебек үк, монголларга кадәрге болгарлардагы, өлешчә, Алтын Урдадагы тасвирлыктан орнаментальлеккә, шартлы декоративлыкка таба бара. Чынбарлыкны реалистик сурәтләү белән бәйле мәҗүсилек мәдәнияте мотивлары, зооморф тематика (болгар металлы, бизәнү әйберләре, керамика) нигездә XIII—XIV гасырларда кысрыклап чыгарыла һәм болгар орнаментикасы өчен характерлы «хайван стиле» (зооморф мотивлы сюжетлар) үсә, гарәп әлифбасы язуы үз урынын органик рәвештә үрелгән чәчәк һәм геометрик композицияләргә бирә. X—XIII гасырларда болгар орнаментына геометрик сызыклар, аерым алганда, симметрия, үзәкләштерелгән композицияләр, бизәкне түгәрәк эченә урнаштыру, декорациядә геометрияләштерелгән куфины файдалану хас була. Гамәли сәнгать әсәрләрендә гарәп бизәкләренең таралуы — шуның нәтиҗәсе. Болгар сәнгатен геометрияләштерү, барлык мөселман Көнчыгышындагы кебек үк, каберташ, төрбә бизәкләре таралуга китерә. Алтын Урда сәнгатендә ул гамәли сәнгать архитектурасы әсәрләрен бизәүдә актив кулланыла. Язулар орнаментның состав өлеше булып китә, чәчәк бизәкләре белән тулыландырыла («чәчәк атучы куфи») һәм алга таба эчтәлеге буенча гомуми бизәккә әверелә. Каллиграфик язу биналарны һәм каберташларны бизәгәндә кулланыла, куфидан һәм нәсхтән күчкән формалар металл әйберләрдә — беләзекләрдә, көзгеләрдә, Коръән савытларында чагылыш таба. XVI гасырдан алып «чәчәк стиле» татар сәнгатендә тирә-як дөньяны сәнгатьчә чагылдыручы бердәнбер диярлек форма булып китә.

Декоративлык сыйфатының үсеше мөселман сәнгатендә гомуми таләпнең эволюциясен дә күрсәтә. Ислам рәссамының дөньяга карашы, аның иҗади рухы формалашу шуның белән бәйләнгән. Көндәлек тормышны ничек бар, шулай сурәтләүдән тайпылып, эчтәлеге белән шартлы бизәкле композицияләргә, асылын образлы күрсәтүгә күчү сәнгатьлелекнең зарури критерие булып санала. Бизәкле-декоратив сурәтләүнең үсүе болгар-татар сәнгатендә абстракт эчтәлекле мотивлар таралуга ярдәм итә. Үсемлек бизәге схемалаштырыла, аның өлешләре абстрактлаштырыла. Әмма абстрактлаштыру табигатьтә булган үсемлек төрләреннән килә. Еш кына бер тупланышта чыгышлары буенча төрле мотивлар берләшә. Идел буе болгарлары һәм Казан татарлары сәнгатенә хас үзенчәлекле сыйфатлар нигездә җирле флораны чагылдырган үсемлек мотивларын кимрәк стильләштерүдә, бизәк композицияләре уйлап чыгаруда һәм кабул ителгән үрнәк белән тыгыз бәйләнмәгән образларның төрлелегендә чагыла.

Мөселман сәнгатендә билгеле бер сәнгати гомумиләштерү формасы төсендә абстраклаштыру бизәк сурәтләренең күптөрле булуын күздә тота, бу татар мәдәниятендә дә чагыла. XIX йөзнең бизәнү әйберләрендә чәчәк бәйләме (гравировка) формасындагы сурәт рәссам фантазиясе тудырган үсемлек мотивларыннан тора, рәссамны үсемлек дөньясының реаль образын тасвирлау түгел, ә аның гомуми фәлсәфи эчтәлеге кызыксындыра. Урта Азия мөселман халыклары сәнгатендә абстрактлаштыру XIII—XIV йөзләр өчен хас, ә шул ук вакытта Казан татарлары сәнгатендә ул соңрак чагыла, чөнки аңарда дини тәгълимат белән бәйләнмәгән халык авыз иҗаты нигезләре көчле була.

Казан татарларының мөселман мәдәнияте сыйфатлары XVIII йөз урталарыннан шактый үзгәреш кичерә, бу вакытта Көнчыгыш, бигрәк тә Урта Азия

халыклары белән тыгызрак мәдәни һәм сәүдә элемтәләрен көйләү мөмкинлеге туа. Урыс мәдәнияте йогынтысы даирәсендә булганлыктан, көчләп чукындыруга дучар ителеп, татар халкы үз көчләрен ислам динен саклауга туплый. Роле көчәя барган ислам дине этник, милли үзаң факторы булып китә. Рухи мәдәнияттә дини башлангычның көчәюе, көнчыгыштан килгән товарлар һәм көнкүреш әйберләре киң таралу белән бергә, татар сәнгатендә яңа традицияләр урнашуга этәргеч бирә. Гарәп язмаларының, Коръәннән цитаталарның бизәнү әйберләрендәге, чигелгән әйберләрдәге тоткан урыны киңәя. Гарәп язулары шамаилләрне, китап япмаларын бизәүдә, бизәнгечләрдә (беләзекләр һ. б.) мөстәкыйль рәвештә кулланыла. Аларның эчтәлеге еш кына дини-магик мәгънәдә «явыз» көчләрне куучы һәм күз тиюдән саклаучы бөти төсендә файдаланыла.

Әмма XIX йөзнең икенче яртысыннан алып сәнгать әсәрләрендәге гарәп язулары элек чагылган стиль билгеләрен югалта, каллиграфик язуның кимүе белән бергә кульязуның охшашлана баруы күзәтелә (әйтик, каберташларда). Реаль мотивларның күренүе (чәчәкләрне, күбәләкләрне һ. б. охшатып сурәтләү) гамәли сәнгать әйберләрендә язмаларның мәгънә һәм бизәү ягыннан әһәмияте кимүгә һәм XIX йөз ахырында тәмам юкка чыгуга китерә.

XVIII йөздән Урта Иделдә мөселман мәдәнияте нигезләре ары таба үсә һәм гәрчә соңрак — XIX йөз ахырында — XX йөз башында татар сәнгате урыс һәм Европа мәдәнияте белән актив сугарылса да, урта гасырларда формалашкан мөселман мәдәнияте традицияләре юкка чыкмый. Бу чорның халык декоратив сәнгатендә азәрбайҗан һәм госманлы төрекләре сәнгате белән уртаклык сизелә.

Шулай итеп, татар мәдәниятен шактый ерак заманнардан — Идел болгарларының ислам динен кабул итү көннәреннән алып күздән кичергәндә, менә мондый төп нәтиҗәгә киләсең: аның үсеше мөселман мәдәнияте белән үрелеп бара. Урта Идел буе мөселман сәнгате һәм архитектурасының үзенчәлекле үзәге булган. Ул үзенең тарихи җирлегендә — борынгы төрки, иран һәм эллин сыйфатлары (болгар-алан мәдәнияте традицияләрендә) чагылыш тапкан болгар сәнгате нигезендә үскән, формалашкан. Бер яктан, мөселман сәнгате стиле, кануннары һәм, икенче яктан, этник традиция, бер-берсе белән керешеп, татар мәдәниятенең милли үзенчәлеген билгели. Нәтиҗәдә, безнең алга Көнчыгыш мөселман халыкларының йогынтысы чагылган үзенә бертөрле матурлык системасы килеп баса. Татар мәдәниятенең мөселманлык тәэсирендә үсүе аның йөзен күп гасырларга билгеләгән тарихи чынбарлык булды. Шуңа күрә Идел-Урал буе халыкларының мәдәниятен, сәнгатен һәм архитектурасын өйрәнгәндә аларның этник традицияләрен генә түгел, гасырлар буена формалашкан мөселман мәдәнияте традицияләрен дә искә алырга кирәк.

Милли үзаң күтәрелә барган безнең көннәрдә татарның сәнгати традицияләрен яңарту, мөселман Көнчыгышы белән өзелгән бәйләнешләрне торгызу омтылышы күзәтелә. Яңа заман мәчетләрен проектлаганда Татарстан архитекторлары сәнгать әсәрләренә символиканы, декоративлыкны кертә, мөселман сәнгатенә хас булган сыйфатлар белән бизәкле һәм ритмик композицияләр төзи, аның абстрактлылык асылын үстерә. Алар Көнчыгыш миниатюралары традицияләренә мөрәҗәгать итә, шамаилләрдә каллиграфия сәнгатен аякка бастыра, татар язмаларын стильләштерә, кириллица белән язылган язмаларны гарәп графикасына яраклаштыра. Мөселман мәдәниятенең хәзерге заман сыйфатлары татарның төрле этник төркемнәрен берләштерүче башлангыч булып китә. Алар хәзерге заман профессиональ татар сәнгате милли үзенчәлегенең дә бер нигезе булып хезмәт итә.

**Гомәр Саттар**

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ИСЕМ-АТАМАЛАР

Тел белеменең барлык төр ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган ономастика дигән бер өлкәсе бар. Ул күп тармаклы. Шулардан берсе — шагыйранә (поэтик) ономастика. Ул, матур әдәбият әсәрләрендә барлык төр ялгызлык исемнәрен атау вазифасыннан тыш, характерлау, стилистик һәм идеологик функцияләрне өйрәнү белән дә шөгыльләнә. Шагыйранә ономастиканы, икенче төрле, матур әдәбият әсәрләренә һәм әдәби каһарманнарга исем бирү сәнгате дип тә саныйлар.

Атаклы сүз остасы Г. Ибраһимов татар прозасының шагыйранә ономастикасын тудыру, үстерү-камилләштерүдә дә матур үрнәкләр барлыкка китерде, күп кенә каләмдәшләренә бу өлкәдә дә остаз була алды. Аның әдәби әсәрләренең исемнәре җисеменә туры килә, эчтәлекне дөрес һәм тулы итеп ача. Ул үзенең кайбер хикәяләрен бер сүз белән, мәсәлән, «Диңгездә», «Көтүчеләр», «Адәмнәр» һ. б. дип атый. Тамырдан гыйбарәт әлеге атама килеш яки күплек кушымчасы алган була. Урынвакыт килеш кушымчасы алган «Диңгездә» хикәясенең исеме вакыйганың кайда баруын анык-төгәл атап белдерә. Күплек кушымчасы алган «Көтүчеләр», «Адәмнәр» хикәяләрендә тасвирланучы төп каһарманнарның берәү генә булмавы аңлашыла.

Ул хикәяләрнең беренчесендә Әптерәш картны беркем дә, беркайда да әтисе һәм әнисе биргән тулы исеме белән Габдерәшит дип атамый. Бу исемне бик ярлы һәм авыр хезмәт кешесе (көтүче) булуына ишарә итеп, социаль функция дә башкара торган варианты белән «Әптерәш» дип кенә атыйлар. Әптерәш — татарларга гарәп теленнән кергән Габдеррәшит *(«үгет-нәсихәт бирүче, туры юлга өндәүче колы»)* исеменең диалекталь варианты. Бу исемнең татар теле шивәләрендә тагын: Гаптерәшит, Габдрәш, Абдерәш, Әбдерәш, Әптерәшкә, Әбдрәк, Әбдрәү, Әбрә, Абдрүк, Рәш, Гаптекәй, Аптекәй һ. б. вариантлары да бар.

Әптерәш картның бернинди мал-мөлкәте дә, хәтта үз йорт-җире дә юк, улы Вахит белән бергә, кеше суюда гаепләнеп Себергә куылган Нурый карактан калган кечкенә бер өйдә, дөресрәге, алачыкта яши. Улы Вахиттән башка аның беркеме дә юк. Хатыны күптән үлгән. Вахит — аның бер байлыгы, бердәнбер өмете. Әдип аны шуңа, исемен җисеменә туры китереп, Вахит дип атый. Гарәпчә Вахит исеме «бердәнбер» дигән мәгънә белдерә.

Г. Ибраһимовның күпчелек әдәби әсәрләре ике сүздән торган сүзтезмә, башлыча, «исемле исем сүзтезмә» яки «сыйфатлы исем сүзтезмә» белән аталганнар: «Яз башы», «Карак мулла», «Карт ялчы», «Табигать балалары», «Гыйшык корбаннары», «Кызыл чәчәкләр», «Яңа кешеләр», «Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар» һ. б. «Йөз ел элек» хикәясенең исеме исә өч сүздән торган сүзтезмә тәшкил итә.

Татар теленең лексик-синтаксик структурасы төрле төр сүзтезмәләргә ифрат бай. Сүзтезмәләр исә әйбер, күренеш яки процессны, аерым сүзгә караганда, төгәлрәк, ачыграк итеп атыйлар. Шул әйбергә, күренешкә яки процесска *(гомумән, төшенчәгә)* хас булган сыйфатларны, билгеләрне, үзенчәлекләрне тулырак, калкурак рәвештә күз алдына китереп бастыралар.

Нәфис сүз остасы һәм туган телне нечкә тоемлаучы әдип һәм галим-филолог татар телендәге сүзтезмәләрнең үзенчәлекләреннән әдәби әсәрләренә исем-атама

---

Гомәр САТТАРОВ (1932) — *филология фәннәре докторы, профессор, «Ни өчен шулай аталган», «Татарстанның антропотопонимнары», «Исемең матур, кемнәр куйган?» җыентыклары — барысы егермеләп фәнни китап, төрле телләрдә басылган йөзләгән мәкалә авторы. Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Казанда яши.*

биргәндә бик оста файдалана. Күпчелек әсәрләрен укучыга төшенчә, предмет билгесен, сыйфатын билгеләүче, ачыклаучы, характерлаучы сүз — «аергыч *(эпитет)* + аерылмыш» төзелмәсеннән гыйбарәт сүзтезмәләр белән атый: «Карак мулла», «Кызыл чәчәкләр»...

Күрәбез, «аергыч + аерылмыш» төзелмәсен тәшкил итүче әлеге әсәр атамаларында аергыч сүз сәнгатьчә тел бизәү, стилистик тасвирлау чарасы эпитет булып килә. Уңышлы кулланылган эпитетлар ярдәмендә язучы сурәтләнә торган предмет яки күренешләрнең укучылар игътибарын үзенә җәлеп итәрлек асыл үзенчәлекләрен һәм билгеләрен аерып алып, калку итеп күрсәтүгә ирешә.

Г. Ибраһимовның халыкчан һәм актив кулланыла торган тел-сурәтләү чараларыннан берсе булган эпитетлардан ифрат мул һәм яратып файдалануын әйтеп китәсебез килә. Ул әдәби әсәрләре исемнәрен «Кызыл чәчәкләр», «Яңа кешеләр», «Карт ялчы» һ. б. рәвешле эпитетлы сүзтезмәләр белән атаудан тыш, шуларны әсәр теле тукымасында да бик еш, оста куллана. Фикеребезне раслау өчен, «Көтүчеләр» хикәясеннән бер мисал китерик: «Башында ертык бүрек, өстендә сәләмә кием, билендә җеп, аягында тузган чабата, аркасында капчык, кулында озын чыбыркы уддыгы хәлдә, озын таякка таянган да, байып барган кояшка карап, авыр тирән уйга баткан». Шушы бер җөмләдә генә дә, Г. Ибраһимов карт көтүченең тышкы кыяфәтен калку итеп укучы күз алдына китереп бастыру өчен, җиде эпитетлы сүзтезмәдән гаять урынлы файдаланган.

Г. Ибраһимов иҗатына табигатьне, аның җанлы күрке булган хайваннар дөньясын, бигрәк тә ат малын *(колын, тай, байтал, бия, айгыр, алаша, чаптар, юртак, юрга, аргамак һ. б.)* сөеп-яратып тасвирлау хас. Әдип монда да эпитетларны эшкә җигә, аларның сурәт тудырудагы тасвирый мөмкинлекләреннән оста файдалана. Мәсәлән, «Казакъ кызы» романында Карлыгач-Сылуның әтисе Сарсымбай җылкылары арасында күптәннән күзе төшеп йөргән һәм әтисеннән үзенә бүләк итүне сораган асау *(өйрәтелмәгән)* ала айгырның тышкы кыяфәтен сурәтләгәндә, Г. Ибраһимов эпитетларга еш мөрәҗәгать итә, аларны, сүзтезмә эчендә туры яки кире сүз тәртибендә китереп, эзлекле һәм уңышлы куллана: «Буе озынча, зурлыгы уртача, чем-кара ял, койрык көлтәдәй тулкынланып, үзеннән-үзе бөтәрләнеп уйнап тора; ботларындагы бераз тышка бәреп торган калын, каты итләр белән киң күкрәк, маңгайдан авызгача боргаланып төшкән яра кашка айгырның нечкә, сылу гәүдәсенә аерым бер оригиналь төс бирәләр. Аскарак салынган иреннәре белән зур авыз эчендә тезелгән ак, озын тешләр, ут уйнап торган ялкынлы зур күзләр, бигрәк тә, ут чыгаргандай каты, үткен, тиз баса торган йомры, кечкенә ялтыр тояклар аның бу киң далада бик күп җылкыларга алын бирмәс йөгереклеген күрсәтәләр. Симезлектән ялтырап торган чем-кара җон өстеннән аркасында, ялдан алып койрыккача, бераз гына тулкынланып сузылган ак буй эз, шундый ук ак авыз белән ак аяклар бу юрганы мең юаш мал арасыннан бер күрүдә әллә кайдан танырлык итеп аерып торалар».

Г. Ибраһимовның «Габдрахман Салихов» хикәясе кеше исеме һәм фамилиядән гыйбарәт тезмә белән аталган. Габдрахман исемен *(дөресрәге Габдрахман исемле шәхесне)* Салихов фамилиясе ачыклап, конкретлаштырып килә. Фамилия бер гаилә яки нәсел кешеләрен вакыт ягыннан диахроник һәм синхроник яссылыкта бергә берләштерү, җыйнап атау, гомумиләштерү белән беррәттән, теге яки бу гаилә яки нәселне һәм аларның вәкилләрен башка гаилә яки нәселдән һәм аларның вәкилләреннән аеру, шәхесне аныклау вазифасын башкара.

Татар әдәбиятында әдәби әсәрне конкрет исем-фамилия белән тәүге башлап Г. Ибраһимов атады.

Г. Ибраһимов кайбер хикәя һәм повестьларының исемен гади йә булмаса җыйнак структуралы кушма җөмләләр белән дә атый. Мәсәлән, «Сөю — сәгадәт» хикәясенең исеме ияse дә, хәбәре дә исем сүз белән белдерелгән гади җыйнак хикәя җөмлә белән аталган. «Уты сүнгән җәһәннәм» хикәясенең исеме исә иярчен кушма җөмләдән гыйбарәт. Уты сүнгән — иярчен аергыч җөмлә, җәһәннәм — атау, баш җөмлә. Күрәбез, җыйнак структуралы бу иярченле кушма җөмләдә, атау җөмләдән торган баш җөмләне иярчен аергыч җөмлә ачыклап килә һәм җәһәннәмне үзенчәлекле итеп, «Уты сүнгән җәһәннәм» дип атый. Хәлбуки, җәһәннәм булгач, уты сүнмәгән булырга тиеш.

«Татар хатыны ниләр күрми» повестеның исеме үзенчәлекле раслау җөмлә белән аталган. Биредә инкяр формасы *(күрми)* аша раслау *(күрү)* белдерелә, ягъни тормыш чынбарлыгы инкяр формасы аша үзенчәлекле рәвештә расланып бәян ителә. Г. Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән тәүге хикәясенең исеме исә турыдан-туры атау җөмлә белән аталган.

Күрәбез ки, Г. Ибраһимовның җөмләдән гыйбарәт әдәби әсәр атамаларына да җыйнаклык, мәгънәви тыгызлык, җөмлә белән коеп ясалган исем-маяк аша, әсәрнең сурәтләнәчәк эчтәлеген укучыга калку һәм төгәл итеп күрсәтү, исемен җисемгә туры китерү хас.

Г. Ибраһимовта әдәби әсәр атамасы башлам барлыкка китерүдә һәм әсәрнең текстын ясау-оештыруда мөһим роль уйный, әсәр тукымасын бербөтен итеп бәйләүче, туплаучы әһәмиятле чара функциясен башкара.

«Казакъ кызы» романы — прозабызның гүзәл үрнәкләреннән берсе. Бу романда Г. Ибраһимов иҗтимагый теманы көнкүреш мәсьәләләре, казакъ халкының гореф-гадәт картиналары, этнографик үзенчәлекләре белән тыгыз бәйләп сурәтләү остасы булып күз алдына баса. Язучының үткен каләме казакъ халкы тормышының эченә үтеп керә, аның тирән тамырларын күтәрә, җәмгыятьнең социаль яраларын, каһарманнарның үзенчәлекле рухи дөньяларын сәнгатьчә ачып бирә. Моңа әдип романдагы каһарман исемнәрен, географик атамаларны, шәхескә иркәләп эндәшү сүзләрен, ыруг-кабилә исемнәрен *(этнонимнарны)*, хайван кушаматларын *(зоонимнарны)*, милли тел үзенчәлекләренә туры китереп атый белүе, ягъни әсәрнең шагыйранә ономастикасын урынлы файдалануы белән дә ирешә.

Автор «Казакъ кызы» романының баш каһарманын, казакъларга хас булганча, матур һәм житез кош исеме белән иң башта Карлыгач дип атый. Ләкин моның белән генә чикләнми. Даланың зифа булып буй җиткән бу гүзәл кызын тора-бара Карлыгач-Сылу дип исемли: «Карлыгач сахраның матуры булып пешеп өлгерде. Тавышы өчен аны былбыл диләр. Җырлаганда казакъның акыннары аның зифа буен төз камышка охшаталар — билең нечкә, күзләрең тирән, керфекләрең уктай, үзең айдай, дип мактыйлар иде. Ил эчендә дә коры исеме белән генә әйтмичә, Карлыгач-Сылу дип атыйлар иде». Карлыгач — шәрекъ халыкларында матурлык һәм житезлек символы булып санала.

Г. Ибраһимов казакъ халкының антропонимик үзенчәлекләрен, атап әйткәндә, кыз һәм ир балаларга исем кушу йола-гадәтләрен бик яхшы белеп эш итә. Казакълар хатын-кызга табигатьтәге матур, күркәм әйберләрнең, күренешләрнең *(кош, гөл, чәчәк, күк җисемнәре, кыйммәтле металл, асыл таш һ. б.)* атамаларын исем итеп бирүчән. Шуңа таянып, Г. Ибраһимов та «Казакъ кызы» әсәрендәге каһарманнарына Карлыгач, Айбала *(«ай кебек чибәр кыз бала»)*, Гөлчәчәк, Алтынчәчәк, Чулпан, Миңсылу һ. б. кебек исемнәр бирә. Күпчелек казакъ исемнәрен төрки чыгышлы *(үзтума)* булуларын күздә тотып, гарәби чыгышлы хатын-кыз һәм ир-ат исемнәрен аз куллана, каһарманнарыннан өч-дүрт шәхескә генә гарәби чыгышлы исемнәр белән атый. «Казакъ кызы» романында болар — Рәкыя бикә, Гөлсем, Якуп, Кәрим карт, Юныс карт.

Казакъ халкы әлек-әлектән далада, табигать кочагында яши, көн итә. Шуңа ул җанлы һәм җансыз табигатькә аеруча якын тора, аның белән нык аралашып гомер итә. Менә шуңа күрә исем һәм атамалар бирүдә аның әйләнә-тирәсе әһәмиятле роль уйный. Г. Ибраһимов моны яхшы белә. «Казакъ кызы» романындагы күпчелек каһарманнарның исемнәре казакъ халкы өчен яшәү-көнкүрешнең төп чыганагы булып саналган йорт хайваннары һәм кыргый кош-кортлар дөньясына нисбәтле рәвештә, аларның атамалары кушма сүздән гыйбарәт кеше исеменең нигезе итеп кушылган: Куйбагар, Каҫкырбай *(бүре + бай)*, Тургайбай *(чыпчык + бай)*, Этбай кебек персонаж исемнәре әнә шундыйлардан. Мондый хайван һәм кош-корт атамаларына нигезләнеп ясалган төрки исемнәрнең асылында исә бик борынгы тотем һәм тотемистик ышанулар ята.

Дала тормышының үзенчәлекле ягы — малларга мул азыклы көтүлек җирләрне эзләп бер урыннан икенче урынга күчеңү вакытында туган ир балага Күчәрбай исеме кушылган. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романындагы бер персонажы — көтүче Күчәрбай карт шушы исемне йөртә. Сарман ыругының ил агасы Сарсамбай *(«чәршәмбе»)* исемле. Яңгыр яуган көнне туганга, бер каһарман Яңгырбай атлы, икенчесе исә йолдызлы, аяз төндә туганга, Йолдызбай булган.

Арысланбай дигәне, чыннан да, арыслан кебек көчле, гайрәтле, курку белмәс егет. Г. Ибраһимов аңа исемне җисеменә туры китереп сайлаган.

Гаиләдә ир балалар тугач та озак тормастан үлеп барсалар, баланың үлеме туктасын, бу ир бала инде яшәсен, торсын дигән теләктән чыгып, төрки халыкларда, шул исәптән казакъларда, ир балаларга туктасын, яшәсен, торсын һ. б. боерык-теләк фигыльләре кергән исем кушу гадәт-йоласы булган. Әнә шулай Туктасын, Яшәсен, Торсын, Торсынбай һ. б. исемнәр барлыкка килгән. «Казакъ кызы» романында да бер персонаж Торсынбай исемен йөртә.

Күреп үткәнебезчә, «Казакъ кызы» каһарманнарының күбесе *бай* компонентлы кушма исемгә ия. Моның хикмәте нәрсәдә соң?

Бай антропоилексемасы — полисемантик сүз. Әлектә төрки халыкларда бай сүзе «хуҗа; мал-мөлкәтле, олы дәрәҗәле ир кеше; әфәнде» мәгънәләрен белдергән. Феодаль җәмгыятьтә өстен катлауларның сан-дәрәҗә титулы булып йөргән. Бай антропокомпонентлы исемнәр бу ир бала бай, мал-мөлкәтле, дәрәҗәле булсын; гаилә зыру башлыгы булсын, дигән ырым-теләктән чыгып кушылган. «Бай»ны актив куллану кыпчакларга хас, ул аларның башка төрки халыклардан *(угызлардан, уйгырлардан, карлуклардан һ. б.)* аерып тора торган исем-тамга функциясен үтәгән, дигән караш та бар. Чыннан да, казакъ, кыргыз, башкорт, татар, үзбәкләрнең кыпчак ыругларында, нугай, каракалпак һ. б. кыпчак төркеменә керә торган төрки халыкларда бай компонентлы кушма төзелешле ир-ат исемнәре ифрат күп.

«Казакъ кызы» әсәре каһарманнары арасында кайбер исемнәр, конкрет шәхесне белдерү вазифасыннан тыш, социаль-идеологик йөкне дә йөртә. Найман ыругысы ил агасы Байтүрә морза һәм сарман ыругысы ил агасы Сарсымбайның ялчысы Җолкынбай исемнәре әнә шундыйлардан.

Байтүрә морза исеме ике катлам титулы *(бай һәм түрә)* кушылып ясалган. Бу исем аны атау, шәхес буларак белдерү белән бер үк вакытта, аның түрә, башлык, өстен сыйныф вәкиле булуын да күрсәтә.

Җолкынбай *(«Җолкынып яшәүче бай, ир кеше»)* исеме аның ярлылыгын, түбән катлау кешесе *(ялчы)* булуына да ишарә итә. Бу исемнең җолкын компоненты — җолкыш, ярлы тамырыннан килүче сүз. Тулаем алганда, Җолкынбай исеме «ярлы бай» төшенчәсен белдерә.

Казакъларда ир баланың тыныч табигатьле, сабыр холыклы булып үсүен теләве җирлегендә Тынычбай исеме барлыкка килгән. Әсәрдәге бер персонаж шул исемгә ия. Тынычбай исеменнән Тынычбаев фамилиясе ясалган. Арысланбайны сөргеннән йолып алган казакъ адвокаты шушы фамилияне йөртә. XX йөз башларында казакъларда урыс теле үрнәгендәге фамилия башлыча укымышлылар арасында гына очрый әле. Найманнар ыругысы башлыкларыннан берсе булган Янгырбайның мулласы — татар шәкерте Габдулла Әлказаный. Шәрекъчәрәк Әлказаный фамилиясе Габдулланың туган шәһәре Казанга нисбәтле рәвештә ясалган. Әхмәт исемле казакъ баеның мулласы — Зәки Гайфи.

Казакъларда бу вакытта антропонимик категория буларак фамилия әле актив кулланылышка ия булмаган. Моны «Казакъ кызы» романында Байтүрә морза җиназасындагы фидиячеләрнең мулланы баеның исеме белән генә атап чакыру эпизоды да бик ачык күрсәтә:

— «Исәхмәт молдасы, кил бире!» «Бүребай молдасы, кил бире!»

«Казакъ кызы» романында составында *җан* сүзе булган исемне йөртүче каһарманнар өчәү генә. Кызылкорт ыругының мәшһүр аксакалы Биремҗан әкә, аның яшьли үлгән улы Җанбирде һәм шигъри сүз остасы Былсымҗан акын. Язучы әлеге исемнәрне яратып тасвирлаган уңай геройларына биргән. Әдипнең үз исеменең Галим + җан булуын истән чыгармыйк.

«Казакъ кызы» романында Г. Ибраһимов шәхескә иркәләп-яратып әйтү-эндәшү сүзләреннән һәм туганлык терминнарыннан, казакъ теленең милли хасиятен гаҗәеп оста һәм урынлы файдалана. Әсәрдә: иркәм, иркә таем, карагым *(«сөеклем»)*, чырагым *(«яктым»)*, сәүләм *(«нурлы йөзем»)*, бавырым, колынчагым, ике күзем, сәүләмҗан, ялгызым, җегетем, чичәм *(«анам»)*, атам, карым, киленчәк, агам, әкә, тукал, данибикә *(«зирәк акыллы бикә»)*, ил агасы, ут агасы, аксакал, кимпер, молдакәм һ. б. кебек иркәләп-яратып эндәшү-мөрәҗәгать итү сүзләре һәм туганлык терминнары белән очрашабыз.

Г. Ибраһимов бу романда казакъ даласының табигате үзенчәлекләреннән чыгып җәйләү, кышлакларга һәм башка географик җисемнәргә тапкыр атамалар бирә. Мул үләнле, бай җәйләүләргә Якты-Күл, Алтын-Күл, Яшел-Сырт кебек исемнәр бирсә, суы кибеп, корып калган җәйләүләрне Кипкән-Үзән, Корган-Күл, Кызыл-Уйсу, Таштүбә, Яман-Чүл һ. б. исемнәр белән атый.


Әдәби осталыкка өйрәтүдә Г. Ибраһимов иҗатының шифалы йогынтысы, уңай тәэсире Г. Бәширов, Ә. Еники, Ф. Хөсни, И. Гази, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, М. Хәбибуллин һ. б. прозаикларыбызның әдәби иҗатында сизелә.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов иҗатында әсәр атамалары, барлык төр ялгызлык исемнәрне, тулаем алганда, шагыйранә ономастикасы төп максатка ирешүгә — тормышны реалистик рәвештә сәнгатьчә югарылыкта сурәтләргә, дөрес һәм тулы итеп чагылдырырга зур булышлык итә.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә урын алган барлык төр ялгызлык исемнәренең аңлатмалы сүзлеген төзү, минемчә зур әһәмияткә ия. Бездә әле бер генә классик язучының да шагыйранә ономастиконы төзелгәне юк. Хәлбуки, татар лексикографиясендә бу «чирәм җирне» күтәрә башларга вакыт җитте инде.

## *КОТЛЫЙБЫЗ!*

# Флүс Латыйфига 50 яшь



Флүс Латыйфи (Латыйпов Флүс Фатыйх улы) 1943 елның 3 июнендә Татарстанның Мөслим районы үзәгендә дөньяга килә.

Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Алабуга дәүләт педагогия институтына укырга керә, икенче курстан армия хезмәтенә алына.

Аннары Казан дәүләт университетын тәмамлый.

Флүс Латыйфи әдәби иҗат белән бала чагыннан ук шөгыльләнә. Аннары инде хикәяләре һәм очерклары республика гәзит-журналларында даими басылып килә. Хикәяләр һәм лирик повестьтан торган «Кырагай» исемле беренче җыентыгы 1988 елда дөнья күрә. Шул ук елны «Вөҗданыңнан сора» дигән китабы да басылып чыга. Очерклар һәм публицистик мәкаләләрне туплаган бу җыентык өчен язучы 1989 елда Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге бүләгенә лаек була. 1992 елда Ф. Латыйфиның повесть һәм хикәяләре тупланган «Ак-карага тимәскә» исемле күләмле җыентыгы да укучыларга барып ирешә. Ләкин прозаик буларак киң танылуны аңа «Хыянәт» романы китерде. Казан ханлыгының мөстәкыйль дәүләт буларак яшәгән соңгы 17 елындагы вакыйгаларны тасвирлаган бу әсәр 1991 елны «Казан утлары» журналында дөнья күрде.

Быел бу роман аерым китап булып басылып чыгачак.

Хәзерге вакытта Ф. Латыйфи «Татарстан хәбәрләре» гәзитендә әдәбият-сәнгать бүлеген житәкли. Ул — 1990 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Казан утлары» журналы юбилярны туган көне белән котлыйлар һәм иҗат уңышлары телиләр.**

*Латин әлифбасы нигезендә*
*татарча уку күнекмәләре*

**Татарстан Республикасы Президенты**
**М. Ш. Шәймиев Указы (29 март, 1993 ел) нигезендә,**
**хәзерге милли**
**татар әдәбиятын үстерүгә**
**зур өлеш керткән өчен,**
**язучы Фатих ХӨСНЕТДИН улы ХӨСНЕТДИНОВКА**
**(Фатих Хөснигә)**
**«Татарстан Республикасының халык язучысы»**
**дигән мактаулы исем бирелде.**
**Мөхтәрәм әдипне**
**олуг исемгә лаек булуы белән**
**чын күңелдән котлыйбыз**
**һәм**
**укучыларыбызга**
**«Совет әдәбияты» журналында**
**(1939 ел, 2 сан)**
**басылып чыккан «Хәзинә» исемле**
**хикәясен тәкъдим итәбез.**

**FATЬJX XƟSNI**

# XƏZINƏ

**Xikəjə**

Spektakl' ʙaşlanьrƣa jartь səƣət qaldь digəndə genə, ʙaş roldə ujnajacaq Saʙirnьꞑ isenə «qьlt» itep ʙer nərsə kilep tɵşte. Komandir ʙulьp kieny ɵcen şljom qajan alьrƣa?

— «Ax!» dip qujdь Saʙir. Anьꞑ avzьnnan kinət ɵzelep сьqqan ʙu «ax» səxnədəgelərneꞑ ʙitlərenə gyjəki utlь çil ʙulьp kilep ʙərelde, alar ʙarsь da ʙer julь Saʙirƣa əjlənep qaradьlar. Truppada rezissjorlьq dəƣvasь qьla torƣan Zahrettinef, kyz acьp jomƣancь, Saʙirnьꞑ qarşьna kilep ʙastь:

— Nigə axьldisьꞑ? Taƣьn nərsə çitməde?

Zahrettinef Saʙirnьꞑ kyzlərenə turь itep qarap tordь. Bəlki ənə şul turь qaraş ʙeraz jardəm itkənder, Saʙirƣa nicekter çiꞑelrək ʙulьp kitte. Ul qaʙalanmьjca ƣьna səjlənde:

— Barsь da ʙar, tik menə ʙer nərsəne onьtqanʙьz ic ʙez, jegetlər.

— Nərsəne?

— Komandir ʙulьp kieny ɵcen şljom qajan alaʙьz?

Bik az ƣьna vaqьtqa ʙarsь da tьndьlar, ujcanlandьlar. Jəzlərgə çiddilek ʙərep сьqtь, kyzlər kɵzge tɵn şikelle kinət salqьnajdьlar.

Tьnlьqnь zaldaqь xalьq bozdь. Xalьq spektaklneŋ tizrək başlanuьn sorap, рьг tuzьp qul cabarqa totьndь. Qullarь bulqan keşelərneŋ ajaqlarьda вar — qullar tik tormaqac, ajaqlar qьna nişləp tik torsьnnar. Qul cabuların ajaq belən tьpьrdavlar kilep quşьldь. Ber syz belən əjtkəndə, zal qort ile təsle gəzləde. Xalьqnьŋ şljomda eşe juq, xalьq tyzemsezlek belən kətə həm kətkən nərsəsen taləp itə ide. Monь işetkəc rezissjor Zaherttinefneŋ jomşaq qьllarь caq qьna şartlap əzelmədelər. Ul, вəjdən ьcqьnqan jəş arьslan təsle, kinət quzqalьp, aşьqьp-aşьqьp jərergə totьndь həm səxnə artь ədəвe turьnda вətenləj onьtьp, Sabirnь qatь syzlər belən şeltələrgə kereşte:

— Çeвer jərisen, kakoj cort artist sin. Yzeŋ turьnda yzeŋ qajqьrtmaqac, sine şajtanьm qajqьrtьrmeni. Bolamьq bulma, ujla, taqьn un minut vaqьt birəm.

— Min xəzer genə ujlap qajan şljom taвьjm, di. Sineŋ вaşьnda aqьlьŋ вarmь, juqmь?

— Bezneŋ вaşьвьzda aqьlьвьz вar, şljomьвьz qьna juq, — dip aculanu qatьş tərtep çəvap qajtardь Zaherttinef həm acudan anьŋ iŋ вaşlarь ysə вaşlaqan şikelle вuldь. Iŋ вaşlarь şul caqlь ystelər, xətta ul səxnəgə sьjьp tora almьj вaşladь həm tiz-tiz atlap сьqьp kitte.

Səxnədə qalqannar yzara kiŋəşləşə вaşladьlar. Qajsь anь, qajsь monь təqdim itte. Kyp kenə əjвət təqdim taвьldь, ləkin nacar qьna вulsa da вer şljom da taвьlmadь.

Zaherttinof вərelep-suqьlьp taqь kilep kerde. Bu julь ul şaqtьj uq acьlqan ide.

— Tuqtaqьz əle, iptəşlər, qarap qarьjq əle, вerərse şljom kiep kilməgənme ikən? — dide ul, pərdəneŋ вer citen kytərep, səxnə aldьna сьqьp вastь. Anь kyrgəc, xalьq taqьn da nьqraq tuzqi təşep, qul cabarqa totьndь. «Tizrək qьlanьqьz, irtəgə вəjrəm tygel ic», «əllə juq isə qojmaqьqьzпьŋ əcye çitməgənme?» digən cəneckele syzlər anьŋ вaşьna вozlь jaŋqьr вulьp javdьlar.

— Tьnьc вulьqьz, iptəşlər, xəzer spektaklne вaşlьjвьz, — dide ul, az qьna tьnьp torqan вulьp, zaldaqь xalьq əstennən kyz jərtep сьqtь. Ləkin zaldaqь keşelər вarsь da вaş kiemnəren salьp utьrqanlьqtan, ul ezləgən nərsə monnan da taвьlmadь.

Zaherttinef kiredən pərdə artьna cumdь. Bu — aqtьq ьşanьcьŋ synye ide. Axrьnda ul artistlar aldьna kilep, keşelərgə rux вirə torqan ujьncaq həm çьlь tavьş belən вelderde:

— Jarar, şljomsьz da ujnarвьz. Tege jьllarnь partizannar əcen şljom kiy şart tygel, çiŋy genə şart ide. V kontse kontsof, вezneŋ əcen də ciŋy genə şart.

Anьŋ вu caqьştьruь qьtьrşь сьqtь. Səxnədəgelər aŋa ni dip tə çəvap вirmədelər həm вu «qьtьrşь caqьştьru» keşelərneŋ jəzlərenə вərep сьqqan вorcьlu ezləren də jua almadь.

Sabir taqьn вer mərtəвə «ax» dip əjtergə avzьn acqan ide, ləkin ul вu julь əjtep əlgermi qaldь, səxnə artьna altmьş, altmьş вiş jəşlər camasьndaqь вer qarcьq kilep kerde. Maŋqajьna çьrcьqlar сьqqan həm javlьq citennən cal cəce kyrenep tora torqan вu qarçьqnь, sul jaŋaqьndaqь zur qьna miŋenə qarap, Miŋleвikə dip əjtergə də вik məmkin ide, ləkin сьnlaв-

raq tikşerə torƣaç, ul miꞑsez вikə вuльр сьqть. Həm ul qarcьq апь-торь kətep tormьjca, işektən kerye веlən yk syzgə kereşte:

— Тьꞑlар, тьꞑlар toram da, taƣьn вer тьꞑlар qujam. Aldanraq ajaq kienergə kirək ide, вalaqajlarьm. Хаlьqпь аlaj kətterergə jaramьj, хаlьq віt ul sezgə teatr ujьпь tygel. Yzem şulaj alama вulsam da, əjtməgənem вulsьn, qolaqlarьm sav minem, nərsə turьnda рьşьldaƣalьƣьzпь işetep utьrdьm. Komandir вyrege tава alьjca təqətegez qorьj вulsa kirək, nigə soꞑ miꞑa — Хəвівçamal əвiegezgə kilmədegez? Minem Şərəfettin ulьm komandir ide віt, вiсаraqajьmпьꞑ xatlarьп da, yzennən qalƣan qajвer kiemnəren də kyz almam təsle itep saqlap toram. Əgər menə kyzegez-вaşьƣьz aqajьр, juƣaltьр qaldьrьrlьq вulmasaƣьz, əjdəgez, ulьmпь kyrgən təsle вulьrmьп, kienep ujnaƣьz, вyregen də, kirək вulsa, вytən kiemnəren də вirep toram.

Səxnədəgelər kinət асьlьр kittelər. Хəвівçamal qarcьqпьꞑ sul jaq jaꞑaƣьndaƣь zur miꞑe alarƣa təmle qавartmaƣa oşap kyrenə вaşladь. Хəttа, çiꞑel səjəkle Zaherttinef qarcьqпь qocaqlap uq aldь:

— Сьnlap əjtəseꞑme, Хəвівçamal əвi? Birep torasьꞑть?

— Sineꞑ anaꞑ вelən вergə ƣəmer itkən keşe вulam min, ujnap səjləşergə vaqtьm da juq, annarь taƣьn seznen вelən ujnap torьrƣa вeraz soꞑƣaraq ta qaldьm вuƣaj inde.

Ul işekkə вorьldь həm taƣьn вer qat jəşlərgə əjlənep qaradь:

— Əj, sezne, uꞑmaƣannar, aş peşergənsez, ə toz salьrƣa опьtqansьz. Ваş qaşьр torunьꞑ vaqtь tygel, jə, qajsьƣьz minem вelən вara?

— Min вaram, Хəвівçamal əвi, — dip, Saвir апьꞑ artьnnan ierde.

Biş minut ta vaqьt ytmədе, Saвir, qьzьl joldьzьna tuzan da qunmaƣan jaꞑa şljom вelən jaꞑa gimnastjorka həm taƣьn nilərder kytərep alьр qajttь. Аvьzƣa yze «cəcrəp kergən» вu вəxet əcen ozaqlap вer quanьrƣa kirək ide, ləkin vaqьt qьsqa вulƣanlьqtan, quanuпь ikence planƣa qaldьrьр tordьlar. Saвir, qarşьsьna kəzge qujьр, tiz-tiz genə kienə вaşladь. Ləkin ul, ni caqlь aşьqsa da, Хəвівçamal qarcьqпьꞑ вu şljom вelən gimnastjorkaпь nicek рəxtə itep saqlavьп iptəşlərenə səjləmicə вuldьra almadь:

— Əj, əj ecendə sandьq, sandьq ecendə çəjmə, ecendə aq javlьq, javlьq ecendə aq kəƣəz, kəƣəz ecendə menə вu şljom, Хəвівçamal qarcьq əcen вu əjвerlərneꞑ nicaqlь qəderle вuluьп şunnan yzegez ujlap сьƣarьƣьz inde.

— Кyrəseꞑ, ul апь ulь təse itep saqlьj torƣandьr, апьꞑ ulь Şərəfi tege jьllarпь, grazdannar suƣьşь vaqtьnda ylep qalƣan ic, — dip çəvapladь aradan вersе.

Taƣьn вeraz ьƣь-zьƣь kilep alƣannan soꞑ, хаlьqпьꞑ qul савuь astьnda, pərdəne асьр çiвərdelər. Sufljor, ojasьnnan вaşьn сьƣarьrƣa qurьqqan jomran təsle, вudkasьnnan сьƣar-сьqmas рьşьldarƣa totьndь. Spektakl' вaşlandь.

* * *

Хəвівçamal qarcьq aldaƣь rəttən urьn alьр, spektakl' вetkənce hic tə quzƣalmьjca, şul urьnda utьrьр qaldь. Qajsьdьr вer ozьn tellese aꞑa:

— Хəвівçamal tyti, siꞑa namazlьq əstendə genə utьrьrƣa kirək ide inde, ə sin jəşlər urьпьn alьр, monda utьrasьꞑ, — digən ide, вu syz Хəвівçamal qarcьqqa вer də oşamadь.

— Min yz urnьmda utьram. Əgər sin, aqьllьm, klubqa simьj başlaqan ikənsen, ənə uram bik irken, uramqa cьqьp utьr, — dip aculanьp çəvap qajtardь ul. Spektakl' hic tə ketelməgən rəveştə jaxşь ytte. Ujnavcьlar, bigrək tə, komandir rolendə ujnavcь Sabir səxnədə yzen qajət irken tottь. Xəbibçamal qarcьqnьn ana, barь tik ana qьna tekələp qarap utьrub Sabirnь çьlьttь, başqa vaqьtta hic tə kicerergə turь kilməgən təmle ber xis belən tutьrdь. Bu rajonda janaraq eşce bulqanlьqtan, Sabir Xəbibçamal qarcьqnь həm anьn ulь Şərəfine rətləp belməsə də, yz anasьn jaxşь belgənlektən, ul, Xəbibçamalnьn nərsə ujlavьn ber cama belən sizenə həm bu sizeny ana ellə nicaqlь ecke kec birə ide. Xəbibçamalnьn kerfek tə qaqmьjca qarap toruь ujьnnьn vaq detallərenə də nьq qьna tə'sir itte. Məsələn, cişmə bujьnda qьzьl armieslərnen jal itep jatularьn surətləgən ikence pərdədə, Sabir yze də sizməstən, qulьn kytərep çibərde. Monda qulnь kytərmicə də qotьlьp bula ide. Qomumən, qul kytəry nicekter artьq həm jəmsez kilep cьqtь. Sabir monь yze də sizde, ləkin sonqa qalьbraq sizde. Ənə şul minutta Sabirnьn kyzləre alqь rəttə utьrucь Xəbibçamalqa kilep teşte. Xəbibçamal «minem ulьm alaj tygel ide» digən sьman itep başьn cajqap utьra ide.

Spektakl' betep, pərdə teşkənnən son, xalьq bik ozaq qul captь həm, xətta qajber «nьqraq isergənnərə» tege də bu, «Sabir vo ujnьj!» dip seјləngələp tə aldьlar. Spektaklnen jaxşь ytye ujnavcьlarda da jaxşь ez qaldьrdь, alar ujnьj-kelə jerep, dekoratsiələrne, estəl estenə çəjelgən aşjavlьqlarnь həm «joldьzlarnь» çьştьra başladьlar. Zaherttinef yzenen rezissjorlьq qanatlarьn çiьp beterməgən ide əle, Sabirqa qarap, bojrьq tavьşь belən əjtte:

— Qara anь, Sabir, Xəbibçamal qarcьqqa şljom belən gimnastjorkasьn irtəgə irtyk iltep bir. Rəxmət əjt, qart keşenen şuna kynele bula anьn.

Ləkin alar rəxmət əjtergə də, qart keşenen kynlen tabarqa da elgermədelər, qart keşe Xəbibçamal yze kilep kerde. Ul qajət dərəçədə acьq jezle, xətta, şatlьqtan anьn manqaj çiьrcьqlarь da, sul janaqьndaqь mine də juqalqan tesle ide. Ul işektən kereşli yk sejlənə-sejlənə kerde:

— Juq, sez mina tygel, min sezgə rəxmət əjtergə tieşle, balaqajlarьm. Sez bygen, minem kyz aldьma minem Şərəfettin balaqajьmnьn nəq yzen kiterep bastьrdьqьz. Seznen tesle ul da şulaj başьn artqa taşlap, onьtьlьp kelə torqan ide. Rəxmət, çannarьm, əgər Şərəfettinem isən bulqan bulsa, ul yze də rəxmət əjter ide. Ujьn-kelkene bik jarata torqan ide mərxym.

Xəbibçamal qarcьq tьnьp, citkə qarap tordь. Anьn in başlarь tirbəldelər, ul kyzləren keşegə kyrsətmicə, əkren genə çьlьj ide. Jəşlər taqьn ujcanlanьp qaldьlar. Ləkin bu bəxetle həm gyzəl ujcanlьq ide.

Berazdan son qarcьq quzqaldь da, qujnьnnan aq javlьq cьqarьp, şljom belən gimnastjorkanь şul aq javlьqqa pextələp tərə başladь. Ə yze haman sejlənde:

— Ulьmnьn tese itep saqlьjm min alarnь. Menə bu joldьzlь byrekne kyrgən sajьn ulьmnь kyrgən tesle bulam. Minem ulьm da seznen şikelle şat ide, ujnarqa, başьn artqa taşlap kelərgə jarata torqan ide...

---

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ ВЕНГРИЯДӘ

1993 елның 10—13 май көннәрендә Татарстан Җөмһүрияте Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге рәсми делегация Венгрия Республикасында эш визиты белән булды.

Татарстан делегациясен Будапештның Ферихедь аэропортында Венгрия Республикасының халыкара икътисади элемтәләр министры Б. Кадар һәм башкалар каршы алды. Кичен доктор Б. Кадар җөмһүриятебез Илбашы хөрмәтенә мәҗлес оештырды.

11 майда Халыкара икътисади элемтәләр министрлыгында Татарстан һәм Венгрия арасындагы сәүдә-икътисади хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды. Аңа Венгриянең халыкара икътисади элемтәләр министры Б. Кадар һәм Татарстанның тышкы икътисади элемтәләр министры Ш. Арсланов имзаларын салды.

Татарстан Президенты М. Шәймиев Венгрия Президенты А. Генц белән очрашты. Ул шулай ук Премьер-министр И. Анталл белән әңгәмәләр алып барды. Яклар халыкара хокук кысаларында эш йөртергә килештеләр. М. Шәймиев Венгрия Президентын һәм Премьер-министрын Татарстанга визит белән килергә чакырды. Шул ук көнне Татарстан делегациясе вәкилләре әгъзалары Будапешт мэриясендә булдылар. Татарстанның Будапештта үтәчәк «ЭКСПО-96» Бөтендөнья күргәзмәсендә катнашуы хакында килешенде. Татарстан вәкилләре Венгрия һәм Татарстан халыкларының дуслык җәмгыятен оештыру җыелышларында да катнаштылар. Анда М. Шәймиев чыгыш ясады.

Делегация әгъзалары — Татарстан Фәннәр Академиясе Президенты М. Хәсәнов һәм Премьер-министр урынбасары И. Хәйруллин җитәкчелегендәге галимнәр 12 майда Венгрия Фәннәр Академиясе Президенты Д. Кошари әфәнде һәм Фәннәр Академиясе президиумы әгъзалары белән очраштылар. Президентлар фәнни хезмәттәшлек турында беркетмәгә кул куйдылар.

Венгриянең киң җәмәгатьчелеге, массакүләм мәгълүмат чаралары М. Шәймиев һәм аның җитәкчелегендәге делегация визитына зур әһәмият бирде. Газеталарда Татарстан турында күп кенә мәкаләләр басылды, телевидение һәм радио аша Президентның, шулай ук делегация әгъзаларының әңгәмәләре яңгырады.

Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең, башка иҗат коллективларының чыгышлары, җөмһүриятебез рәссамнарының күргәзмәләре венгр дусларның күңелләренә хуш килде.

12 майда М. Шәймиев Венгрия һәм Татарстан журналистлары өчен, визит йомгакларына багышлап, матбугат конференциясе үткәрде.

### М. ШӘЙМИЕВ — ГРЕЦИЯДӘ

13—15 май көннәрендә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге делегация эш визиты белән Греция Республикасында булды.

Җөмһүриятебез Илбашы визит көннәрендә Греция республикасы Премьер-министры К. Мицотакис, энергетика, промышленность һәм сәүдә министры В. Контогианнопулос, сәүдә-промышленность палатасы президенты А. Кириазис, Спарта шәһәре янындагы җиләк-җимеш продукциясен эшкәртә торган уртак «Олимпикорп-Татарстан» предприятиесе генераль директоры Т. Орфанос, «Метон» төзелеш компаниясе предприятиеләре Советы рәисе Н. Ченис әфәнделәр һәм әлеге илнең киң танылган бизнесменнары белән очрашып сөйләште.

Грециянең рәсми кешеләре белән сөйләшү нәтиҗәсендә, яклар сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләр буенча уртак эшмәкәрлеккә кадрлар әзерләүне киңәйтү буенча тиешле документларга нигез салдылар. Греция ягы Европаның икътисад берләшмәләре комиссияләре белән элемтәләр урнаштыруда Татарстанга ярдәм итәргә теләге барлыгын әйтте.

### ҺӘРВАКЫТ ЙӨРӘКТӘ

Татар әдәбиятының бөек улы Габдулла Тукайның туган көне уңаеннан, һәр елны апрель аенда җөмһүриятебездә, күрше республикаларда, өлкәләрдә шигърият сөючеләр белән очрашулар, әдәби музыкаль кичәләр киң күләмдә үткәрелә. Быел да бу олуг бәйрәм зур оешканлык белән үтте.

Г. ТУКАЙГА ЧӘЧӘКЛӘР. Халкыбызның яраткан шагыйренә тирән ихтирам күрсәтеп, 26 апрельдә Татарстан Җөмһүрияте Президенты Минтимер Шәймиев, Югары Совет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр Мөхәммәт Сабиров Г. Тукайның Кабан күле буе бакчасындагы һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре салдылар. Аннары алар башкалабызның Г. Тукай музеенда булып, шагыйрьнең тормышы һәм иҗатына багышланган күргәзмә белән таныштылар.

ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ. Шул ук көнне М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры янындагы мәйданда — Г. Тукай һәйкәле янында — шигырь бәйрәме үткәрелде. Ул быел 28 нче мәртәбә уздырыла инде.

Бәйрәмне Татарстан язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары, шагыйрь Зиннур

Мансуров ачты һәм алып барды. Ул җыелган күпсанлы халыкны Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенең быелгы лауреатлары турында Татарстан Республикасы Президенты Указы белән таныштырды. Бәйрәмдә беренче булып яңа лауреатлардан язучы Ринат Мөхәммәдиев һәм рәссам-сынчы Әхсән Фәтхетдинов сөйләделәр.

Алар чыгышыннан соң шигъри трибунага бер-бер артлы шагыйрьләр Мөдәррис Әгъләмов, Ренат Харис, Лена Шагыйрьҗан, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Рөстәм Мингалим, Флера Гыйззәтуллина, Ркаил Зәйдулла, Рафаил Газизов, Фәйрүзә Исмәгыйлова һ. б. чыкты. Ялкынлы, дәртле, фәлсәфи фикерле шигырьләргә ялганып, мәйданда төрледән-төрле җырлар яңгырады. Халкыбызның күңел сандугачлары булган җырчылардан Хәмдүнә Тимергалиева, Искәндәр Биктаһиров һәм башкалар тамашачыларга бәхетле мизгелләр бүләк иттеләр.

Шигырь бәйрәме зур күтәренкелек белән үтте. Ул бәйрәмгә килгән барлык кешеләрнең «Туган тел»не җырлавы белән тәмамланды.

**ШАГЫЙРЬ ТУГАН ТӨБӘКТӘ.** Елдагыча, быел да, бер төркем татар язучылары бөек Тукаебызның гомер бишеге булган Арча төбәгенә юл тоттылар. 1993 елгы Тукай бүләге лауреатларыннан язучы Ринат Мөхәммәдиев белән рәссам-сынчы Әхсән Фәтхетдинов, өлкән язучыларыбыздан Аяз Гыйләҗев белән Мөхәммәт Мәһдиев, шагыйрьләрдән Зөлфәт, Лена Шагыйрьҗан, Мансур Шиһапов, Төркиядән килгән кунак кыз Нармин Гүлтекнен, җырчы Искәндәр Биктаһиров белән баянчы Марат Дәүләтшинның чыгышларын Арча педагогия колледжында да, Тукай-Кырлайда да бик яраттылар. Кунаклар Тукай-Кырлайда яңа китапханә ачу тантанасында да катнаштылар.

* * *

Быел Г. Тукайның туган көне Олы Әтнәдә дә, район яңадан оешканнан соң беренче тапкыр буларак, зурлап билгеләп үтелде. Бу бәйрәмдә Әтнә төбәгеннән чыккан шагыйрьләр, язучылар, журналистлар Самат Шакир, Хәкимҗан Халиков, Илдар Низамов, Радик Фәизов, Газинур Вәлиев һ. б. катнашты һәм чыгыш ясадылар.

Район мәдәният бүлеге һәм «Әтнә таңы» газетасы редакциясе узган елның декабрь аенда Г. Тукайга багышлап газета битләрендә әдәби конкурс игълан иткән иде. Бәйрәм көнне әлеге конкурска йомгак ясалды, җиңүчеләрнең исемнәре аталды.

Олы Әтнәдәге тантанадан соң бер төркем кунаклар Тукайның туган авылы Кушлавычка бардылар. Биредә алар шагыйрь исемендәге китапханә һәм музей белән таныштылар, шагыйрь туган йорт нигезенә баш иделәр.

* * *

Г. Тукайның газиз әнисе — Бибимәмдүдә абыстай Зиннәтулла кызы күмелгән Сасна Пучинкәсе авылы зиратына (Балтач районы) быел да Татарстан Язучылар берлегеннән бер төркем әдипләр, шагыйрьләр килде. Әдипләр һәм Балтач районының хакимият башлыгы урынбасары, шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин изге Ана каберенә чәчәк бәйләмнәре салдылар.

## КҮРШЕЛӘРЕБЕЗДӘ

**Ульяновск.** 26 апрельдә, сөекле шагыйребез Г. Тукайның туган көне уңаеннан, Ульяновск өлкәсендәге «Туган тел» җәмгыяте, «Чишмә» телевизион тапшыруы һәм «Өмет» газетасы шигырь бәйрәме уздырдылар.

Анда шәһәр мәктәпләренең аерым татар классларында укучы балалар Тукайның шигырьләрен укыдылар, шагыйрь сүзләренә язылган җырларны башкардылар. Аеруча сәләтле укучыларга бәйрәмне оештыручылар тарафыннан әзерләнгән истәлекле бүләкләр тапшырылды.

**Уфа.** 3—4 май көннәрендә Башкортстан Республикасы башкаласында, М. Гафури исемендәге дәүләт театры бинасында Тукайны искә алу кичәсе булып үтте. «Рамазан» исемендәге төрки үзәк (җитәкчесе Марат Шәрипов) инициативасы белән уздырылган бу әдәби-музыкаль кичәдә, Башкортстанның күренекле сәнгать осталары белән беррәттән, Татарстан иҗат вәкилләре дә катнашты. Тамашачылар артистлар Х. Бегичев, З. Сәхәбиева, И. Әхмәтҗановларның чыгышларын бик җылы кабул итте. Кичәнең тантаналы өлешендә «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, Татарстан халык депутаты, шагыйрь Равил Фәйзуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

**Екатеринбург.** 12 майда Свердловск өлкәсе үзәгендә әле яңарак кына оешкан милләтара китапханә бинасында М. Гафури исемендәге мәдәният җәмгыяте Г. Тукайны искә алу кичәсе үткәрде. Татар халкының бөек улы турында китапханә хезмәткәре Инна Маркова һәм М. Гафури җәмгыяте рәисе Сөфхәт Надыйр чыгыш ясадылар. Тукайның шигырьләрен Россиянең атказанган артисты Дауд Бикбов осталык белән башкарды.

Очрашуга украин һәм казах җәмгыятьләре вәкилләре дә чакырылган иде. Тукай турында алар да үзләренең җылы сүзләрен әйттеләр.

Очрашу мәктәп балаларының Тукайга багышланган концерты белән, чәй өстәле янында тәмамланды.

## РЕФЕРЕНДУМ ЙОМГАКЛАРЫ

Инде матбугатта хәбәр ителгәнчә, 25 апрель көнне Бөтенроссия референдумы үткәрелде. Аның төп максаты — Россия Президенты Б. Ельцинга һәм ул үткәрә торган сәясәткә халык ышанычын ачыклау, шулай ук Президентны һәм Россия Югары Советы депутатларын срогыннан алда сайлаулар кирәкме, юкмы икәнен аныклау иде.

Үзәк сайлау комиссиясе рәисе И. Галиевның рәсми белдерүенә караганда, референдумда Татарстандагы яшәүче сайлаучылардан 593.155 кеше катнашкан. Бу — исемлеккә кертелгән гражданнарның 22,8 проценты дигән сүз.

Халык Россия сәясәтенә карата үз сүзен бик ачык әйтте. Референдумга татарларның гына түгел, русларның да, башка милләт вәкилләренең дә күпчелеге бармады.

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТӨРЕК КОНГРЕССЫНДА

Урта диңгез буенда урнашкан Анталия шәһәрендә Төркия Республикасының Премьер-министры Сөләйман Демирель җитәкчелегендә Бөтендөнья төрек конгрессы булып узган иде. Кунаклар арасында Татарстан делегациясе дә бар иде. Аны Татарстан фәннәр Академиясе Президенты М. Хәсәнов җитәкләде һәм форумның пленар утырышында җөмһүриятебездә барган үзгәрешләр турында чыгыш ясады.

М. Хәсәнов Төркия Президенты Т. Озал һәм Премьер-министр С. Демирель белән очрашты.

## ХАЛЫКАРА СӘНГАТЬ БӘЙГЕЛӘРЕ

Сәнгать өлкәсендә Казаныбыз Халыкара үзәккә әверелеп бара. Быелның 4—18 апрель көннәрендә, Татарстан Президенты М. Шәймиев указы нигезендә, җөмһүриятебез башкаласында опера җырчыларының данлы якташыбыз Ф. Шаляпин исемендәге III Халыкара конкурсы булып узды. 17—21 май көннәрендә үткәрелгән «Татар җыры-93» Халыкара конкурсы да милләтебезнең асыл талантларын барларга һәм тиешенчә бәһаләргә ярдәм итте.

«Дөньяның биюче шаһы» буларак, барлык кыйтгаларда танылган мәшһүр милләттәшебез Рудольф Нуриевның якты истәлегенә багышлап классик балет буенча 13—23 май көннәрендә Казанда уздырылган халыкара фестиваль дә гаҗәеп якты бер бәйрәм буларак истә калды. Анда җөмһүриятебезнең, БДБ илләренең һәм дөньяның танылган бию осталары катнашты.

## БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧЛАР

Татарстан матбугаты яңарыш кичерә. Республикабызда чуваш телендә «Суар» дигән газета чыгару өчен рөхсәт бирелде. Чаллыда «Керәшен сүзе» газетасы дөнья күрде. Яңа оешкан Татарстан милли-мәдәни җәмгыятьләр ассоциациясе «Бергә» дигән газетага нигез салды. Җөмһүриятебез эшкуарлары урыс һәм инглиз телләрендә нәшер ителә торган «Бизнес в Татарстане» дигән яңа журналның беренче саны белән таныштылар. Һәм менә татар укучысының кулына тагын бер яңа газета — «Заман» килеп керде.

«Төрек мәдәнияте казанышларының берсе булган «Заман» гәзитенең Татарстанда чыгуын һәм таралуын дуслык элемтәләренең бер чагылышы итеп кабул итәргә кирәктер. «Заман» гәзите Төркия яңалыкларын Татарстан халкына җиткерергә мөмкинлек бирсә, Татарстан яңалыклары белән төрек халкын таныштырып барырга да ярдәм итәр». Төркия Җөмһүриятенең шушы араларда гына вафат булган Президенты Т. Озал үзенең тәбригендә әнә шундый сүзләр язып калдырган.

Ике атнага бер тапкыр зур форматта чыга торган 8 битлек бу газета Татарстан белән Төркия арасында мәдәни күпер салырга ярдәм итәчәк. Уртадагы дүрт сәхифә — төрек телендә. Ул Төркиядәге укучыларны җөмһүриятебез тормышы белән таныштыра.

«Заман» — беренче карлыгач. Аның канатлары нык, очышы җитез булсын, ул Татарстан матбугаты күгендә биек очсын иде!» — дип тәбрикли ошбу газетаны Татарстан Җөмһүрияте Илбашы М. Шәймиев. Амин, шулай булсын!

## МАТБУГАТ КӨНЕ УҢАЕННАН

Җөмһүриятебездә 7 май көне, Матбугат көне буларак, быел аеруча зурлап билгеләп үтелде. Иртәнге якта Президентыбыз М. Шәймиев район шәһәр һәм республика газеталары редакторлары, нәшриятлар, полиграфия предприятиеләре, китап палатасы, китап сәүдәсе берләшмәсе, «Связьинформ» җитәкчеләре белән очрашты.

Шул ук көнне төштән соң Казан шәһәренең Бауман урамында Матбугат көненә багышланган зур тантана булды. Анда республикабызда чыгучы төрле газета-журнал редакцияләре, Татарстан китап нәшрияты, «Мәгариф» нәшрияты хезмәткәрләре халык белән очраштылар. Нәфис сүз, җыр-бию осталарының чыгышлары нур өстенә нур булды.

Президент белән очрашуда һәм Бауман урамындагы бәйрәмдә Премьер-министр урынбасары И. Хәйруллин, Мәдәният министры М. Таишев, Информация һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов катнаштылар.

## ШАГЫЙРЬНЕ ИСКӘ АЛУ

26 апрельдә танылган шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең вафатына 40 көн тулды. Шагыйрьнең кырыгын Татарстан хөкүмәте, Татарстан мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге М. Хөсәеннең тууына 70 ел тулуга багышланган кичә итеп үткәрергә карар кылган иде.

Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрына җыелган дуслары өчен бу кичә якты хатирәләр, моңсу истәлекләр, шагыйрь иҗат иткән җырларны тыңлау кичәсе булды.

М. Хөсәен чын мәгънәсендә җырчы шагыйрь иде. Җырчыларыбыз Зилә Сөнгатуллина, Миңгол Галиев, Эмиль Җәлалетдинов, Гали Ильясов, Хәмдүнә Тимергалиева, Разия Үзбәкова шагыйрьнең җырлы-моңлы сәламен яңгыраттылар.

# ҖӘЙГЕ ИШЕГАЛДЫ

Уфа каласында яшәүче татар рәссамы Зәйнулла Шәйхелислам кояш нурлары белән өртелгән, җылылык бөркеп торган рәсеменә әнә шундый гади генә исем биргән: «Җәйге ишегалды». Сез ул рәсемне журнал тышлыгының беренче битендә күрәсез. Бу гадилек бер исемдә генә дә түгел, безнеңчә, ә җисемдә дә. Чынлап та, Зәйнулла Шәйхелислам бик үзенчәлекле талантка ия рәссам-пейзажчы. Урман-кырларны, тау-болыннарны, елга-күлләрне, гөлчәчәкле бакчаларны, кала-салаларның гади генә урам-тыкрыкларын сурәтләүче, илһамнарын табигать белән кешелек дөньясының берләгән-бердәмләгән расларга омтылучы рәссамнар алар — пейзажчы рәссамнар.

Рәсем сәнгатенең кеше күңеленә иң якын шул игелекле жанрын үз иҗатының төп юнәлеше итеп сайлаган Зәйнулла Шәйхелисламның әсәрләре һәрвакыт ихлас күңелдән, җан җылысы салып, гаять бер илһамланулы җиңеллек белән эшләнгән булыр. Ул әсәрләр, гадәттә, натурадан, — ягъни табигать манзараларының берәр кыйпылчыгын, диикме, почмагын, диикме, — үз күзләре белән күреп-тоеп, иҗатчының йөрәге аша үткәреп язылган булыр. Зәйнулла Шәйхелислам — туган төбәгенә, туган туфрагына чиксез гашыйк рәссам.

Табигать күренешләренең тиз үзгәреп-алмашынып торучан кабатланмас мизгелләре рәссамның әсәрләреннән безнең күңелләргә дә күчә, алар бездә самими шигъри хис-тойгылар уята. Безне: «Кара әле, бу кабатланмас манзаралар безгә бик таныш, бик якын ләбаса! Көндәлек тормыш мәшәкатьләренә чумып, без аларны күреп кенә бетерә алмыйбыз икән бит...», — диган сагышлы-сокланулы уй телеп узадыр шикелле.

Әйдәгез, «Җәйге ишегалды»на кайтыйк әле. Рәсемдә — иске Уфаның бер почмагы, гап-гади татар ишегалды. Мондый ишегаллары безнең Казаныбызда да шактый очрый әле. Байтагыбыз шундый чәчәкле-гөлле ишегалларында уйнап-тәгәрәп үскәнбездер дә, мөгаен. Якты кояш нурлары искереп-тузып килә торган йортларны гына коендырып калмаган, ачык тәрәзәләр аша өй эченә дә үтеп кергән. Кояш нурларына буйсынып, дигәндәй, тәрәзәләргә чәчәкле алмагач ботаклары да үрелеп карый. Алдагы шау яшел яфраклы куаклар, төрле-төрле гөлчәчәкләр дә шул шифалы нурлар астында иркәләнеп утыралар. Әмма күңел нәрсәдер көтә, нәрсәнедер сизенә: бу кояшлы-нурлы дөнья менә-менә үзгәрер, көн сүрәнәер, күләгәләр озыная-сузая төшәрләр. Әнә бит, шәйләнер-шәйләнмәс кенә сурәтләнгән татар әбисе, оныгын җитәкләп алган да, каядыр ашыга. Шул ике җан — әби белән оныгы безнең күңелләрне айкый да ташлый. Яшел чирәмле ишегалларын сагыну моңы, көчле җирсүгә әверелеп, саркый да сыктый... Кайда ул самими-саф татар ишегаллары хәзер? Шунда бит инде табигатьнең җаннарны савыктыргыч шифасы, җылы-якты олуглыгы кешеләр мөнәсәбәтләренә күчә иде. Кешеләр бер-берләренә ихтирамлы-ягымлы, олыны — олы, кечене кече итеп хөрмәтли иде. Шунда халыкның гореф-гадәтләре тамырлана, иманнарыбыз яңара иде түгелме соң?

Игътибар итегез: декоратив орнаменталь төс-буяуларда ниндидер әкияти серлелек тә бар сыман. Ә зәңгәрсу күк йөзе чалт аяз. Шул аяз зәңгәрлектән ишетелер-ишетелмәс кенә сагышлы татар җыры иңәдер төсле:

> Ишегалдым — гөлбакча,
> Гөлбакчада гөлләрем;
> Юк гөлбакча илләремне
> Сагынмаган көннәрем...

Рәссам Зәйнулла Шәйхелислам (1938) Башкортстанның Караидел районы Татар Үреше авылында туып үскән. Уфада сәнгать училищесында белем алган. Аннары башы-аягы белән иҗат эшенә чумган, бихисап күргәзмәләрдә үз әсәрләре белән катнашкан.

Соңгы елларда рәссам шартлы-декоратив сурәтләр аша ислам диненең асылына кагылышлы әсәрләр иҗат итә. Аның «Иске мәчет», «Фәрештәнең тууы», «Мөхәммәт пәйгамбәрнең төше» кебек әсәрләре шундыйлардан.

Халкыбызның иманын яңартырга ярдәм итәрдәй янадан-яңа асыл сәнгать әсәрләре илһамландырса иде бу талантлы рәссамны!

**Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Кая китә бу татар? Ни өчен Татарстан жирендә аның яртысы да яшәми? Яшәгәннәренең дә күбесендә милли хис, милли горурлык югалып бара. Гомумән, ни сәбәпле шушы хәтле таркалган бу татар?

Татарстан китап нәшрияты 1992 елда бастырып чыгарган «Кая китә бу татар?» исемле жыентыкта күпсанлы авторларның — галимнәрнең, язучыларның, журналистларның әнә шул темага кагылышлы кызыклы язмалары урнаштырылган. Аерым алганда биредә Әмирхан Еники, Әбрар Кәримуллин, Рафаил Хәкимов һ. б. ларның мавыктыргыч мәкаләләре бар.

Төрки халыклар тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән, дөнья күләмендә күренекле галим-тарихчы, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Әхмәтзәки Вәлидинең (1890—1970) исеме безнең укучыларга берникадәр таныш инде. Аның «Кыскача төрек-татар тарихы» исемле хезмәте Октябрь революциясенә кадәр берничә мәртәбә басылган була. Ләкин әлеге борылыштан соң галимнең исеме дә, әсәрләре һәм хезмәтләре дә тыелды. Бүгенге укучыга хәзерге әлифба язуында бу китап беренче мәртәбә тәкъдим ителә.





Якындагы кибетләрдән таба алмасагыз, бу китапларны түбәндәге адрес белән соратып алдырырга мөмкин:

**420084, Казан шәһәре, Куйбышев урамы, 3. 13 нче китап кибете, «Китап-почта» бүлеге.**

Бәясе 20 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог